ISSN 0206-4189
Индекс 73210

# КАЗАН УТЛАРЫ

3.2011



# Татарстан Республикасы Президенты
# УКАЗЫ

## Татарстан Республикасында 2011 елны Габдулла Тукай елы дип игълан итү турында

Бөек татар шагыйре Габдулла Тукай истәлеген һәм иҗади мирасын мәңгеләштерү максатларында, аның илебез һәм дөнья мәдәниятенә керткән зур өлешен исәпкә алып, шулай ук 2011 елда аның тууына 125 ел тулу уңаеннан карар бирәм:

1. Татарстан Республикасында 2011 елны Габдулла Тукай елы дип игълан итәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына элек үзе кабул иткән хокукый актларны әлеге Указга туры китерергә, шулай ук аны гамәлгә ашыру өчен кирәкле башка карарлар кабул итәргә.

3. Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына, җәмәгать берләшмәләренә һәм оешмаларга Татарстан Республикасында Габдулла Тукай елын уздыруда актив катнашырга тәкъдим итәргә.

4. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына, «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе» ачык акционерлык җәмгыятенә, республика һәм урындагы массакүләм мәгълүмат чараларына Татарстан Республикасында Габдулла Тукай елын уздыруны киң яктыртуны тәэмин итәргә.

5. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н.МИҢНЕХАНОВ**

*Казан, Кремль, 2011 ел,*
*11 февраль, № ПУ-56*

# Казан утлары
# Qazan utları

2011

# 3
**(1061)**

*ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:*
***«ТАТМЕДИА»***
***ачык акционерлык җәмгыяте***

*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Габдрахман улы Фәйзуллин**
**Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Зилә Вәлиева**
**Разил Вәлиев**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Дамир Исхаков**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Рөстәм Галиуллин, Марат Закир, Камил Кәримов, Алмаз Хәмзин.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Флера Сабирова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Гөлнара Галиева** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

✉: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир—562-10-62.*
*Баш мөхәррир урынбасары—292-93-16.*
*Җаваплы сәркәтип, компьютер үзәге—562-11-28.*
*Шигърият, публицистика, фән һәм сәнгать бүлеге—292-39-63.*
*Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.*
*Гамәли хезмәткәрләр—562-11-28.*
*Исәп-хисап бүлеге—222-09-80. kazanutlari@yandex.ru*
✆: **Факс**—*(843) 562-11-28.*
💻: **E-mail:** *kazanutlari@telebit.ru.*

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ–НӘФИС ҺӘМ ИЖТИМАГЫЙ–СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## Бу санда

### ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Рәдиф ГАТАШ. Ихлас сүзем. *Шигырьләр* ..... 5
Әхәт МУШИНСКИЙ. Һаваларда—ак күгәрчен... *Роман.* ..... 11
Клара БУЛАТОВА. Фани дөнья—миңа үзе җәннәт. *Шигырьләр.* ..... 44
Нурислам ХӘСӘНОВ. Золым. *Роман.* ..... 48
Әхмәт РӘШИТ. Яшәү диңгезендә... *Шигырьләр* ..... 101
Мөхәммәт МИРЗА. Адәм баласы. *Яңа бишьюллыклар* ..... 105

### САТИРИК ӘСӘРЛӘР КОНКУРСЫ

Ләбиб ЛЕРОН. Шадра юморкалар яки нормальный робагыйлар ..... 108
Мөнирә САФИНА. Теге дөньяга хат. ..... 110

### ХӘТЕР

Фәнис ЯРУЛЛИН. Хәтер төпләрендә утлы күмер. *Көндәлекләр.* ..... 116
Рөстәм АКЪЕГЕТ. Су йоткан авыл өстендә ялгыз көймә. ..... 164

### Г. ТУКАЙНЫҢ 125 ЕЛЛЫГЫН КАРШЫЛАП

Бөеклек баскычлары ..... 130
Лирон ХӘМИДУЛЛИН. «Китап» ширкәте һәм Тукай. ..... 135

### ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Фәридә ХӘСӘНОВА. «Мәхәббәт шагыйрен таный белегез!» *(Рәдиф Гаташка 70 яшь).* ..... 143
Миргазиян ЮНЫС. Тормыш сәхнәсендә. ..... 150
Әлфинур НӘҖИПОВА-ЗИННӘТУЛЛИНА. Гомер балкышлары *(Фоат Галимуллинга 70 яшь).* ..... 153

### ФӘН

Раиф МӘРДАНОВ. Исмәгыйль Гаспринскийның тууына 160 ел. ..... 157
Фирдәвес ГАРИПОВА. Авылларыбыз тарихы. ..... 158
«Татар энциклопедиясе» битләреннән. ..... 161

### СӘНГАТЬ

Розалина ШАҺИЕВА. Бөдрә таллар симфониясе. ..... 171

### АК ЖИЛКӘН

Хикәя яза аласызмы? ..... 177
Зәки ЗӘЙНУЛЛИН. Бәләкәй Зәки. ..... 181

«Казан утлары» архивыннан ..... 114, 174
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ..... 189

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: роман А. МУШИНСКОГО «Шейх и звездочет» (прод.); роман Н. ХАСАНОВА «Насилие» (начало); эссе-воспоминания Р. АКЪЕГЕТ; стихи Р. ГАТАША; К. БУЛАТОВОЙ; А. РАШИТА; М. МИРЗЫ.
«Память»: дневниковые записи Ф. ЯРУЛЛИНА.
«К 125-летию Г. Тукая»: хронология жизни поэта;
Л. ХАМИДУЛЛИН. «Издательско-торговая компания «Китап» и Тукай».
«Сенной базар». Конкурс сатирических произведений.
«Литературная критика»: Ф. ХАСАНОВА. «Любите поэта любви...» (к 70-летию Р. Гаташа); М. ЮНУС. «На сцене жизни»; А. НАЗИПОВА-ЗИННАТУЛЛИНА. «Свет души» (к 70-летию Ф. Галимуллина).
«Наука»: Р. МАРДАНОВ. «160 лет со дня рождения И. Гаспринского»;
Ф. ГАРИПОВА. «История наших деревень» (прод.).
Страницы из «Татарской энциклопедии».
«Искусство»: Р. ШАГИЕВА. «Симфония плакучих ив».
«Белый парус»: З. ЗАЙНУЛЛИН. «Маленький Заки».
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Деревня Березебаш». Картина Зуфара Гимаева; писатель Равиль Сабиров.

## IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*

«Prose and poetry»: novel by A. MUSHINSKY «Sheikh and astrologer» (continuation); novel by N. KHASANOV «Violence» (begining); essay-memoirs by R. AKEGET; poems by R. GATASH, K. BULATOVA, A. RASHID, M. MIRZA.
«Memory»: diaries by F. YARULLIN.
«To 125th anniversary of G. Tukay»: Chronology of poet's life;
L. KHAMIDULLIN. «Publishing trading company «Kitap», and Tukay».
«Hay market». Competition of satirical works.
«Literary criticism»: F. KHASANOV. «Love poet of love ...» (to 70th anniversary of R. Gatash); M. YUNUS. «On stage of life»;
A. NAZIPOVA-ZINNATULLINA. «Light of soul» (to 70th anniversary of F. Galimullin).
«Science»: R. MARDANOV. «160 years since I. Gasprinsky's birth»;
F. GARIPOVA. «History of our villages» (continuation).
Pages from Tatar Encyclopedia.
«Art»: R. SHAGIEVA. «Symphony of weeping willows».
«White Sail»: Z. ZAYNULLIN. «Little Zaki».
Diary of social-cultural life.
On our covers: «Village Berezebash». Picture by Zufar Gimaev; writer Ravil Sabirov.

★ Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★ Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★ Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 01.03.2011, график буенча 01.03.2011.
Офсет ысулы белән басылды. Кәгазь форматы 70X108 1/16.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ Р–259. Тираж 4211.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча Федераль хезмәтнең Татарстан буенча идарәсендә, 2010 елның 1 апрелендә теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ №ТУ 16-00337
Индекс 73210 (физик затлар өчен), 16262 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

«ПИК «Идел-Пресс» ААҖ «ТАТМЕДИА» филиалы типографиясендә басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2011 ел.



Рәдиф
Гаташ

# ИХЛАС СҮЗЕМ

## «Әдрән диңгез» һәм «Динар тавы» җырларын тыңлаганда

**Моңнар таша—аша күңел Динар тауга;
Кайтам гүя Әдрәннәргә, Балканнарга—**

**Атта җилеп җиткән ерак бабам сыман,
Яугир чагын тоя мәллә борынгы кан?**

**Гаярь көчем кайткан кебек, Әдрән диңгез!
(«Диңгез» сүзе һаман җырда—юкка, димсез?!)**

**...Бәлки, бүген Динар тауда, җанын ачып
Биеклеккә, җыр сузадыр яшь бер гашыйк?**

**Ишетеп аны, шат көлсә—гүя динар-
Алтын чәчеп, ул сөйгән яр, балкыр нурлар.**

**Явар аннан «акча-акча», «тәңкә» карлар.
Чын байлык шул: ватан—исән, сакта—таулар.**

**«Чын бәхет тик үз илеңә мәхәббәттә!»—
Җанны айкар моңда шуны Сәйдәш әйтә.**

**Мин дә дәшәм илһам килгән шушы мәлдә
Моңсыз заман җырын откан яшь гүзәлгә:**

**—Борынгы моң иң алдаусыз, кушыл аңа!
...Тарих булып таулар тетри бүген җанда...**

## Каләмнән өстен сер

**Сез миңа иң якты язмыш—
Каләмем ачасы Сер:**

Сезгә тиң чәчәк булырмы
Һаман бөредә шигырь?!

Сез—җиһанның могҗизасы,
Кыз атлы... йолдыз? Җисем?
Саф сулы чишмәдер, бәлки?—
Сездән бит илһам көчем!

Хәтта миңегез дә маяк—
Гел сәях йөрәгемә:
Сез—аның һәр тетрәвендә,
Теләкләр күкрәвендә.

Яшәлгән саен яшь тойгым:
Сездәндер шундый тәкъдир.
Гомер буе язса каләм,
Ул—Сезнең бүләк-шигырь:
Камилме? Юктыр,
Сез—безгә
Мәңгегә ачылмас Сер,—
Каләмнән өстен Шигырь!

## Нәзыйрә-тәрҗемә

Әһле хатын-кыз! Тумыштан бар серең:
Яшерен имля-хатлы иткән тәкъдирең.

Ул әүвәл «языктан тыйган Сүз ирде»:
Хактан Хәүвабызга—фәрман, мөһерле...

Адәм-атабыз бит сергә юл сузган—
Укыйм дип хатны, мөһрен дә ул бозган.

Без-инсаннар тарихы—әмрен Хакның
Тотмый, һаман уку юлы шул Хатның.

...Хәүва нәселе—гүзәл зат! Шул имляны
Танытып, син алга илттең дөньяны!

Әле дә һәр яшь кызда шул хат: серле ул...
...Көне җитми уку юк!—мөһерле ул...

## Яңа робагыйлар

* * *

Дүртъюллыклар, сездә минем өметем,
Робагый шәклендә—Ярга үгетем:
Борынгы сүз—үтемле, дим... Кем белә,
Бәлки Аңа бер ретро-җыр кебек мин?!

* * *

Быелгы кызу җәйнең коры көзе!
Әлсерәп хис, ачылырмы моң күзе?
Өмет гөлләрем, кышын сез нишләрсез?
Дымсыз туфракта калдырам мин сезне!

* * *

Егерме беренче йөзгә җиттек, җыр!
Инде ун елын бит имин кичтек, җыр!
Синдә һаман узган гасыр тузаны,
Күп «гөнаһлар» белән мәллә күчтек, җыр?!

* * *

Нинди өннәр килә узган юллардан?—
Ил сыналган мең дәһшәтле еллардан?
Ике гасыр улы—җан бер айнырмы
Үткән йөздәге гамь, афәт, шомнардан?!

* * *

Кайдадыр, океан артында зилзилә—
Ураган-җил... Әллә безгә дә килә?
Әллә галим Вил[1], аһәңсаз Мәсгудә[2]
Тарих актара төркиләр көлендә?!

* * *

Бохарай, бул рух илчебез Лондонда!—
«Әхмәдиләр»дән бигрәк, күзең син сал—монда:
Яңгырат бар дөньяга татар шигырен,
Кол Галидән—«фәлән»гәчә... Яз, тынма!

* * *

Мондашларым, рухташларым! Ник дөнья
Таный безне тик диңгез аръягында?
Ир—бәхетен, шагыйрь—шанын тапмасмы
Идел-йортта, сүнмәс дәрт ватанында?!

* * *

Ничә мең еллык тарихың, әйт, халкым?!
«Күк асты»—Кытайда хәтта бар хаккың:
Болганган кан, кушылган моң—тоя җан,
Үзәк өзгән уртак җырлар бар—якын...

* * *

Шуннан килде—гүя Һун йә Тураннан,
Төрле тел, фәннәр нурына уралган
Миркасыйм[3] да! Чал тарихын татарның
Кайтарыйм, дип, кичте урау чорлардан.

* * *

«Белем эстәп Кытайга (кирәксә!) бар»—
Сүзең татарга да карый, пигамбәр!
... Бардык, укыдык... Ә бүген, гаҗәпме?—
Шәкертләр Кытайдан безгә килсәләр!

* * *

Моң баласы Нурия, Сез кайларда?—
(Измайловалар юктыр тик Айларда?)

[1] Вил Мирзаянов. Автор.
[2] Мәсгудә Шәмсетдинова. Автор.
[3] Күренекле галим Миркасыйм Госманов. Автор.

Авазыгыз, моңыгыз иңли Җирне,
Колак куйсам—бар илләр, кыйтгаларда.

* * *

Җанга кага диңгез... Төркия кебек:
Чулпан Зариф, сәламең килә кебек—
Газәлләр багы Садабад гөлләре
Һәр сүзеңдә нур чәчә, көлә кебек!

* * *

Мәҗлесе хуш дусларың бармы анда?
Сан бармы анда бездәй гашыйк җаннарга?
Үз холкына, йолдызына Гаташтай
Гел тугрылар бармы—читен чакларда?!

* * *

Шәһре Мугъла исеме гел ядымда:
Син бит шунда—төрки телләр сагында,
Дарелфөнүндә! Талиблар ни әйтә
Диңгезләр аша мәхәббәт хакында?!

* * *

Безне аера һаман ни?—җәбер итә?
Илдән читкә тарта ни?—әмер итә?!
«Рәмиевләр алтыны»? Юк, мөгаен,
Моңга үчле, җырга дошман Әмрикә!..

* * *

Сөйлисе сүзләрем, сизәм, җыелган
(Ташыйм дип бит күпме еллар җыенам!)...
Җитмешем алда, васыятьләр күп—телдә,
Нидер яшерен әле, нидер—тыелган...

* * *

Ниләр кичермәде җан бу елларда,
Юлыктык күп кайгы-югалтуларга:
Улым үлде—бердәнбер ...Соңгы абыем...—
Әл дә каргыш яудырмыйм дөньяларга!

* * *

Гомер кичә—һәркемгә ахырзаман:
Юл—кыскарган, бетә—көч, уй—күп һаман.
Изге әнкәм кадере—хәтеренә бәйле
Үкенечләр калка еш—узганнардан...

* * *

Яшьләремне эчкә йоттым, түкмәдем.
Сыгылсам да, сынмадым да чүкмәдем.
Агарды чәч... Ә өмет йолдызым яшь:
Милләт кызы, сизәм яшем сөрткәнең.

* * *

Тетрәнде җан дөньям ташкын-сил белән:
Йөрде уй-кораб галәми җил белән.

Ил үзе упкын аузында—Иблисләр
Күрсәткән «туры», «иң дөрес» юл белән!

* * *

Үзгәрешләр күпме җанны үзгәртте:
Иман сүндереп, көферлек көйрәтте.
Җан Татарым, тик син аман калсайдең!
...Ишет, Тәңрем, бәлки, соңгы теләктер...

* * *

Шул бушлыкта син ни хәлдә, Мәхәббәт?
Үлемнәргә баш имим дип, бүген дә әйт!
Яшәү хаккың—халкың язмышындадыр,
Соңгы сынаудыр бит инде бу, шаять?!

* * *

Башкача язмыш юктыр да хисләргә:
Җирдә Ходай тузаны без, нишләргә?!—
Күк чакыра безне, ә Җир җибәрми—
Элгәрләрдән, бәлки, бурыч-эш барга?!

* * *

Робагыйлар! Сез—күңелем көзгесе,
Булыгыз, дим, көзге бакчам билгесе:
Хис гөленнән, кайнар сүздән бостан ул,
Ярыма дим бер ирешер гөл исе!

* * *

–Исмен язма, булсын сер,—ди нинди Көч?—
Инде каләмең дә—малай түгел ич...
Бу—ишарә: яшь Кояшка, яшеренми,
Якынаер вакытың беткән, җитеп Кич.

* * *

Аңа бар син, хәлем сөйлә, робагый!
Диген:—Берәүдән сәлам мин, бел, җаный!
...Нәсер белән сүзем туйдырган ярны,
Дәригъ! Ул бала шигырь дә аңламый...

* * *

Моңсыз чор гөлен шигъри дым сугармый!—
Әрли алмас ләкин гашыйк җан Ярны.
Оныклары укып аңлар—ачар дим
Газаплы—димәк, чын җырлы дөньямны!

* * *

Зөядә—җыр: «Ончы Фәхри», «Зиләйлүк»;
Бакыйлыктан тавышы илгә килә күк;
Урманченың яд итеп зур юл башын,
Эзләреннән моң-тулпарлар җилә күк!

* * *

Зөя, ярларың иңләсә буй кызлар,
Суыңда чәчләрен юса ул кызлар,—

Матурлык, Сәнгать дәресе шул—рәсемен
Кабрендә дә йөрәкләр, сагынып, сызар!

* * *

Ә бит килмим—кайтам монда хисемдә:
Бөек рәссам ватаны, син—исемдә.
Милли төбәк, милли ярлар әтрафы
Мәдхия укыр, дим, мәңге—исменә!

* * *

«Күл янында утырып җырлар язам» дип,
Такташны кабатлыйк монда, әй Рәдиф!
Урман, су кызына хис колы—шагыйрь,
Мәңгелек сер, әкият улы—һәр әдип...

* * *

Күңел тарафларыма мин төбәлдем:
«Сорауларга җавап бармы төгәл?»—дим.
Соңгы китап булмасын бу—иртә әле...
Йә бер дога! Бабны шулай төгәллим...

***

Борынгылар сүзе: «Битик битидем»,—
Ягъни яздым, әсәр, «белек» бетердем!

Язган элгәрләр ташкамы, тузгамы—
Шунда сыйган ил-халыкның узганы.

Ә «Сөю битиге»н, тәүге Сүз итеп,
Язгандыр Хак?! Укыйбыз бит ис китеп!

...Инде яңа гасыр—уздык ун сәнә;
Укыйм һаман—кайтам аңа мин янә.

Юкса, гомер киче: мөмкин күз бетү;
Тик соңгы битләрен күрми юк китү!

Беләм, языгым күп—тәүбә китерим:
Шул битикне укып гел, аз «битидем»...

Язганнарым ил көткәнчә булмады,
Гыйшкым гөлләре «богаулап» кулларны...

...«Җитмеш» көен уйна, әй сазым, бүген!
Ихлас бу гомер китабым—«белег»ем,

Соң көнгәчә үзгәрмәс!
Гаташ: Сүзем...

Әхәт
Мушинский

# ҺАВАЛАРДА—АК КҮГӘРЧЕН...

РОМАН

## ИКЕНЧЕ КИСӘК

### ҖИДЕНЧЕ БҮЛЕК

### Беренче мәхәббәт

Очраклы гына туры килү булдымы, тормышы таңында Николай Новиков мәктәп анкетасында: «Мин ялгыз булачакмын. Мин тормышымны беркем белән дә һәм беркайчан да Гименей богавы белән бәйләмим»,—дип язган иде. Таня Родимцевага үзенең үсмерләрчә дәртле шигъри әсәрләрен багышлаганда ул үзенең бу катгый карашы турында хәтерләдеме икән соң?

Аның ул беренче мәхәббәте астрономик рәвештә биек һәм, еш кына була торганча, иң беренче очракта аны шулкадәр рухландыручы кешесеннән сер булып сакланды.

Беренче мәхәббәт...

Аның икенчесе булмады.

Николай Сергеевич белән күршеләр булып торганда мин аның ялгызлыгы сәбәпләре турында бер дә уйланмадым. Хәтта аның ялгыз булуы ничектер башка да килмәде. Безнең һәр көнге аралашуларыбыз вакытларында андый хәл миңа гадәти, күктәге ай, ишегалдындагы имән шикелле объектив чынбарлык булып тоелды, һич тә гаҗәп булып күренмәде...

Хәер, безнең имәнне яшен егып ташлады бит.

Әйе, аның мәхәббәте, тормышының асылы, гүзәллеге, хакыйкатьне ачу рәвеше астрономия иде. Ләкин Таня Родимцева да бар иде бит әле дөньяда. Черек күлдәге шугалак та, тынлы оркестр да, ай да һәм ялтырап торган кар дисәң кар, сыкы дисәң сыкы булмаган нәрсә дә, күктән коелган йолдызлар да бар иде. Моны ана кыз үзе әйтте:

—Күр, Николай, күктән йолдызлар коела!—диде.

Үткер зәңгәр күзләр дә бар иде, булды, аның шуа белмәвеннән хәтерен калдырмаслык итеп көлү дә, һәм үбү дисәң үбү булмаган, бары тик үзенең кинәт кипшенеп калган иреннәре белән кызның салкыннан суык яңакларына һәм салкында да ничектер кайнар, коры кебек тоелган ирен читенә оялып кына, җинелчә генә кагылып алулар да булды ич.

Шулай булгач, нидән килә соң ул ялгызлык: барып чыкмаган шул

*Дәвамы. Башы узган елның 12нче санында*

мәхәббәт аркасындамы яисә жаны-тәне белән йолдызлар турындагы фәнгә бирелгәнлектәнме? Чынлап та ябык, нечкә кулы белән борынгы грек философиясе фәнен укытучысы Сотонинның сорауларына җавап язган үсмер үзенең язмышын шулай рәхимсез һәм кискен итеп сыза алганмы?

Семён Пичугин белән Таня Родимцева университетка нәкъ имтиханнар алдыннан ике яклы үпкә ялкынсынуы белән авырып китеп айдан артык Шамов хастаханәсендә аунарга мәҗбүр булган, ә аннары ярты ел диярлек өендә яткан Николайдан бер ел алдан керделәр. Әй, аның яшьлектәге ул авырулары!..

Дуслар хәл белергә килеп тордылар. Алар, тыела алмыйча, математик фразалар белән сибәләр генә иде... Николай, сахрадагы юлчы шикелле, тизрәк аякка басу һәм иптәшләрен куып җитү турында хыялланып, һәр тамчы мәгълүматны комсызлык белән йота барды. Үз сабакташларыннан күпмегә артта калды ул ярты ел эчендә? Ничек булса да, аларны аңламаслык дәрәҗәдә үк түгел бит инде ул. Дуслыкларының беренче адымнарыннан ук үзенең табигате белән астыртын Семён һәм бөтен колачы ачык булган Таня Родимцева белемлелек ягыннан Николайның беренчелеген таныйлар иде. Тарих һәм әдәбият буенча аның укымышлылыгы күпләрне аяктан егарлык! Сонрак математика, физика, ботаника буенча да мәктәптә аңа тиннәр булмавы ачыкланды.

Шулай булуга карамастан, әйләнә-тирәдә һәм мәктәптә аннан мыскыллы көләләр иде. Янәсе, үзе колгасар, ягъни чандыр, озын буйлы, килбәтсез, ә күзләрендә нindидер шайтан көләгәсе томанлана. Аннан читләшәләр дә иде. Күршеләре һәм сабакташлары Семён Пичугин һәм Татьяна Родимцева, берсе-берсеннән бәйсез рәвештә, әйе, аерым-аерым, караңгы чырайлы, кешеләр белән аралашудан кача торган, беркайчан да балалар уены уйнамаган бу яшьтәшләренә гел тартыла бардылар һәм ул, әкрен генә, хәтта кайчак үзенең кадерле ялгызлыгын кызганган сыман, теләмичә генә аларның дуслыкка омтылышларына җавап бирә барды. Якынаюларына очраклы рәвештә генә тәрәзәдән килеп төшкән гөл утыртылган чүлмәк этәргеч булды. Тик бу турыда алдарак әйтелер.

Үзенә алдан ук ялгызлык юрап куйган Николай Новиков тормышындагы шушы беренче дусларын язмыш бары тик баланы гына бүләкли торган чиста һәм тугрылыклы яратуы белән яратты. Ул бала иде шул. Аннары да бөтен гомере буена зур бала булып калды ул. Сабый чагында—житди, табигый төплелеге, ә олы яшьләрдә исә тиктормаслыгы һәм яхшылыкка, изгелеккә, гаделлеккә һәм Галәм океанындагы акыл буенча туганнарыбызга балаларча ышануы белән гаҗәпкә калдырды.

Бер шигырендә Николай дусларын танып белү өчен «гомер мизгеле генә житми» торган галактика белән чагыштыра. Паровоз машинисты малае Семён Пичугин Николайны үзенә житеп бетмәгән сыйфатлары белән сокландырды. Кечкенә буена һәм аз гына бөкре булуына карамастан, Семён нык, житез, агач башларына орангутанг шикелле менә иде. Шулай ук Казансуда үз стихиясендә булган дельфин сыман йөзә, су астында озакка юкка чыгып тора ала һәм борчылырга мәҗбүр итә, бура уенын да карап туймаслык итеп уйный. Ә менә йөгерүен начар йөгерә иде, чөнки аяклары кыска, ә аларны кулың белән алыштырып булмый ич. Ләкин үзе сажинлы адымнар белән атлап, тиз, омтылышлы йөри. Гәрчә аның өчен бу бик табигый булмаса да, шулай йөрергә тырыша иде. Николай үзенең «колга»ларында аның артыннан көчкә өлгерә. Алай да Семён Пичугин аны үзенә физик булдыклылыгы белән түгел, ә рухы, сугышчан темпераменты, стандарт булмаган, кайчак кәкре-бөкре, кытыршы һәм көлке тоелган, ләкин үз башында туган, читтән алынмаган хикмәтле фикерләр басымы

белән дә тартты. Ана эрудиция житеп бетми иде, кайчак аның белеме бик гади нәрсәләрдә дә ике аягына аксый иде. Ләкин ул фикерле ала иде. Зәгыйфь аяклар ныгыган куллар белән көчле булган шикелле, ул үзенең белеменен тотрыксыз нигезен дә төрле өлкәдәге—тарих, әдәбият һәм хәтта математика белән физикадагы оста, тапкыр фикерләре, үткен күзәтүләре, чагыштырулары, нәтиҗәләре белән җинел генә алыштыра ала иде. Мәктәптә бирелгән кайбер бик гади, ә Николай гомум билгеле кагыйдәләр буенча чикләвек ваткан шикелле чишкән мәсьәләләрне Семён Пичугин, белеме житенкерәмәү аркасындамы, ә бәлки үз-үзен артык яраткангамы, яисә: «Алар алдында талант иясеме, әллә гадәттән тыш көчәнә-тырыша торгач, очраклы рәвештә генә дөрес җавап ала торган булдыксыз баламы?»—дип уйлаган укытучыларны икеләндереп, үзенчә чишә иде. Николайның дустына карата шикләнүенең күләгәсе дә юк иде. Талант—табигать бүләге, ә белемнәр җыелмасы—ирешеп була торган нәрсә, дип уйлый иде ул.

Малайларның дуслыгын уртак кызыксынулар да көчәйтте. Икесе дә, бүтән нәрсәләрдән башка, Пушкин һәм Блок иҗатлары белән мавыга, икесе дә открыткалар коллекцияли (дөрес, бабасы үлеменнән соң Николай бу эштән читләште), маркалар җыя, гербарийләр төзи. Шулар өстенә Семённың зур гына коңгызлар коллекциясе бар. Николай дустында булганда аларны һәрвакыт бик бирелеп карый иде. Алай да бер-берсенә бик охшаш булмаган бу ике малай дуслыгын барыннан да бигрәк шигырьләр язу ныгыта иде бугай. Силлабик төзелешле шигырьләрне алар һәр көн, һәркайда, һәрнәрсәгә язды. Хәтта Семен бер тапкыр үзенең ниндидер бөек рифмасын ашъяулыкка да язып куйды, шуның өчен әтисеннән эләкте дә үзенә. Аларның шигырьләре һәрнәрсә —яшәү һәм үлем, җир һәм йолдызлар, Ньютон биномы һәм тычкан тотмыйча, чыпчыклар ауларга яраткан ата мәче Васька, җирдән гайре цивилизацияләр һәм, әлбәттә, мәхәббәт турында иде. Кичләрен нинди дә булса берәр тыныч почмакта, Таня Родимцева алдында шагыйрьләр үзләренең яңа, кайберсендә сүзнең мәхәббәт турында икәнлеге йә бик сизелеп торган, йә исем ачыктан-ачык әйтелгән кайберләреннән башка, шигырьләрен кычкырып укыйлар иде.

Семён Пичугинның да Таня Родимцевага гашыйк булуында берниндн гаҗәпләнерлек нәрсә юк иде. Ул вакытта аның белән янәшәдә булып та аңа гашыйк булмый калу мөмкин түгел иде. Николай шикелле үк, Семён да Таняга булган үз хисләрен яшереп килде.

Алар бер-берсендә моны сизәләр идеме икән соң? Әлбәттә. Ә Таня үзе? Ул кыз алар өчен үзенең дус кына түгел, ә тәңре икәнен белә идеме? Заманында күренекле табиб-психолог Георгий Михайлович Родимцевның холкы белән үзенә тамчы су кебек охшаш, теләктәшле, сизгер кызы сабый чакларында, әле кечкенә кызчык чагында ук, якыннары, бигрәк тә дуслары күңелендә ниләр булганын сизмичә калмый иде. Аннары, университеттан соң, аларның берсе кызга күңелен ачып салды. Ләкин бу соңыннан булды әле. Хәер, бу аңлату, күңелен ачып салу дигәне дә, дөресен генә әйткәндә, кызга инде күптән билгеле булган нәрсәне кабатлаудан гына гыйбарәт иде. Әйе, ул мәктәптә укыганда ук башкалар күңелен олы хатын-кыз шикелле үк укый, күрә, аңлый белә иде. Теләсә кайсы кеше,—хәер, кеше генәме?!—хәтта теләсә кайсы хайван да үзен кем ятратканын бик яхшы сизә. Моны Таня да белә иде, ләкин моны беркайчан беркемгә дә сиздермәде, аның өчен аларның икесе дә—бер-берсенә һич тә охшамаган Семён да, Николай да бик кадерле иде.

Төрле полюслы ике холыклы дуслар арасында Таня Родимцева, бер яктан, берсенең тыелгысыз кабынуларын сүндерә, икенче яктан, икенчесендәге салкын үз-үзенә бикләнүне җылытып эретә алу сәләтенә ия

булган алтын урталыкны саклап килүче җан иде. Ни әйтсәң дә, чынында өчлектәге тотрыклы климатны ул саклап килде бит. Гәрчә малайларның уртак мавыгуларына һәм бер-беренә һәрвакыт юл куюларына карамастан, алар укыган мәктәп Семён кебек зәһәр, мыскыл итәргә яратучан башка кешене белми иде һәм, мөгаен, юморны Николай кебек аңламаучылыкны күрсәткән бүтән кешене дә сирәк күргәндер. Ә бәлки Николайның кайчак дусты Семённың мәкерлелек, ачы теллелек чигенә җиткән юморын кабул итә алмавы да алар арасындагы дуслыкның Таня Родимцеваның аналарча акыллы йогынтысыннан бер дә ким булмаган әһәмиятле өлеше дип кабул ителергә тиештер? Николай аның алдында торган чакта Семённың гаҗәеп, вагондагы поездны туктатырлык тормоз шикелле булып кала алуын да истән чыгарырга ярамый. Семён үзенең ачы юморы белән дусты алдында да чәнчеп-чәнчеп ала иде, әлбәттә, ләкин алай ук зәһәр итеп түгел. Ул Николайны ярата иде бит. Тегесе аны яраткан шикелле. Ә алар икесе дә Таняны яратты, һәм бу хәл аларны гаҗәеп рәвештә, ә бәлки ниндидер закончалык буенчамы шунда, үзара якынайта иде. Алар хәтта Танякың икесенең берсенә дә өстенлек бирмәвенә яшертен генә сөенәләр дә иде, чөнки башкача аларның кире кагылганына ничек читен булыр иде!..

Ул аларның икесен дә бертигез яратты. Ә бит аларның берсенә генә өстенлек бирер сәбәпләр дә, әй, кирәгеннән артык иде. Шунысын гына алыйк, Семён буе белән Танядан тәбәнәк, ә Николай бер башка диярлек биегрәк. «Озынрак»,—дип ачыклаган иде Семён. Мәхәббәт—эгоизмның иң югары күрсәткече, дигән тотрыклы фикер яшәп килә. Семён белән Николай ул елларда көнчелекнең ни икәнен белмәделәр, чөнки алар үзләренең йөрәкләре турында гына түгел, ә бер-берсенең күңелләре хакында да янып-көеп кайгырттылар. Бәлки шуңадыр, аларның өчлеге күпсанлы башка беркөнлек мәктәп өерләре шикелле читкә чәчелмәде.

Кеше, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр—күк шикелле. Биекме ул, түбәнме, сорымы яисә зәңгәрме?—кистереп кенә әйтеп булмый... Бүген ул бер төрле, ә иртәгә, йә бер минуттан соң аның нинди буласын бөтенләй күз алдына да китерә алырлык түгел. Гасырдан гасырлар буена чиста күк турында: «Ул зәңгәр»,— дип әйтә килделәр. Ә менә бер галим кеше табылды да: «Күк зәңгәр түгел, күк төстә дә түгел, ә сапфир, ягъни зәңгәр якут төсле ул»,—диде. Һәм, сапфир спектрының аяз күк төсенә гаять дәрәҗәдә якын торуын фәнни яктан раслап, хаклы булып чыкты. Чагыштырмалылык теориясе физикага, математикага гына түгел, барыннан да бигрәк кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләренә дә кагыла. Кеше бертөрле, монотонлы яктылыкка да, тавышка да бирешми, һәм инде, әлбәттә, әдәбияттагы түгел, ә башваткыч, хикмәтле, тормышның язылмаган законнары белән бәйле булган кешеләр төркеме бигрәк тә.

Николай Сергеевич Новиковның, шулай ук өч дусның тормышы, әгәр аксыл чәчле малайның мәктәп анкетасына язган җавабын санамаганда, алдан фаразланмаган траектория буенча үтте.

Бер елдан соң (бу мең дә тугыз йөз егерме өченче ел иде) авыруыннан терелеп, Николай Новиков атаклы Казан университетына керү имтиханнарын бик яхшы тапшырды һәм, Семён белән Таня шикелле, тик шундый гына аерма белән—укуы түләүле иде—физика-математика факультеты студенты булды. Монда аның эшләре бик яхшы барды, инде беренче курста ук сәләтле студентны ике «кит»-профессор—астроном-математиклар Тарутин һәм Покровскийлар истә калдырды. Аларның беренчесе—үзенең Казан адресына чит илдән Ленин «Искра»сы килеп торган Николай Николаевич Тарутин иде. 1905 елда студент митингларында катнашуы өчен патша властьлары тарафыннан укытучылык эшеннән читләштерелеп урамга

куып чыгарылганнан соң, озак уйлап тормыйча, Берлин университетына китеп барган, аннары, атаклы немец галимнәренең калырга кыставына карамастан, үзенең туган, акташлы университетына кайткан Тарутин. Ул унтугызынчы елда университетта эшче факультетын оештыручы да, оештыру комиссиясенең председателе дә була.

Менә шулай итеп, Тарутин һәм Покровский беренче курс студенты Новиковка, искәрмә рәвешендә, программа буенча өлкән курс студентлары өчен каралган үзләренең махсус курсларын тыңларга, семинар дәресләренә керергә һәм хәтта практик фәнни тикшеренүләрдә катнашырга да рөхсәт иттеләр. Шулай ук Новиковны үзенең дуслары Семён Пичугин һәм Татьяна Родимцева белән бергә икенче курс лекцияләрендә дә күреп була иде.

Ике семестр очып та китте. Дуслар Николай өчен шат иде. «Шундый баш әйләндергеч аллюр турында кем уйлаган!—диде Семён.—Сиңа, Николай, бездән алдан, туп-туры өченче курска сикерергә дә була, ә аннары инде—безгә, гади ятлаучыларга карап тормыйча,тагын да алгарак китәргә». Таня аңа: «Кем уйлаганмы?.. Мин...мин шулай уйлаган идем,—диде.—Хәер, уйламадым, ә Николайның барысын да гаҗәпләндерәчәгенә һәм тагын шундый ... нинди икәне бер Аллага гына билгеле булган фәнни биеклекләргә җитәчәгенә шикләнмәдем дә».

Май аенда, имтиханнарга бер ай кала, профессор Тарутин чакыруы буенча, беренче курс студенты Николай Новиков, шәһәрдән егерме чакрымда поездан төшеп, беренче мәртәбә кара урман белән капланган обсерватория тавына менде һәм аннары үзе шунда гомеренең соңгы көненә чаклы эшләячәк Василий Павлович Энгельгардт исемен йөртүче астрономия сараена аяк басты. Обсерваториядә беренче төн... Гасыр башында ук Иван Михайлович Симоновның үзе тарафыннан куелган тугыз дюймлы телескоп-рефракторга юнәлгән беренче түземсез караш... Һәм әллә керфекләрнең, әллә кинәт могҗиза сыман якынаеп килүче йолдызлар калтыравы-дерелдәве... Шуннан соң мондый дулкынланулы халәтне Николай Новиков һәрвакыт кичерәчәк иде. Телескоп янына һәр килүе, хәтта йөзенче, меңенче тапкыр килүе дә, аның өчен һәрчак беренчесе сыман булып тоелыр. Бу инструментның егәрлегенә, яңалыгына һәм беренчесенә, аны калтыранырга мәҗбүр иткәненә охшамавына карамастан, аның өчен һәрчак беренчесе шикелле булып тоелыр. Шунда һәрвакыт аның хәтерендә бабасының карлыккан тавышы ишетелгәндәй булыр һәм ул менә—аның артында гына, һәр сәгатьтә монда һәм, Козловкада сарай түбәсендә үзе ясаган обсерваториядәге беренче төндәге шикелле, оныгының тере күзләре белән телескопка текәлергә һәм шундагы беренче төнен, шул ук йолдызларны һәм, бәлки, Алланы да күрергә дип көтеп кенә тора, аны кочаклый...

Июнь, май шикелле үк, коры, үтә күренмәле торды. Июньдә яшь астрономның алмашучан тотылу классындагы икеле йолдызлар белән кызыксынуы тәмам ачыкланып бетте.

Икеле йолдыз... Болар—үзара тарту көчләре белән бәйләнгән һәм шундый якын урнашкан йолдызлар, хәтта аларны аерым-аерым иң көчле телескоп аша да күреп булмый. Алар үзләре өчен гомуми булган авырлык үзәге тирәли әйләнгәндә чиратлашып бер-берсе артына яшеренәләр һәм шуңа күрә аларның ялтыравы тирбәлгән шикелле тоела да. Мондый парлы йолдызлар узган чорларда да һәм хәзер дә бер генә дистә йолдызчыларның башын әйләндермәде инде. Тарутинның аталарча канаты астында һәм турыдан-туры талантлы астрофизик, киләчәктәге әгъза-корреспондент Яковлев башлангычында яшь табигать фәннәре белгече Новиков икеле йолдызлар әсир иткән отрядка килеп кушылды.

Җәйге сессия ничектер сизелмичә дә узып китте. Зачетлар, имтиханнар... Болар аның өчен барысы да таныш, бик кызыклы да түгел, формаль генә. Новиковның аларга һич тә исе китми, ул эш, чын эш белән шөгыльләнә. Обсерваториядән шәһәргә кайта да, колоннада аша ак ташлы белем йортының берәр аудиториясенә очынып килеп керә дә, өстәлдән имтихан билетын эләктереп ала һәм, әзерләнеп тә тормыйча, акбур белән кара тактаны шакый да башлый. Аннары шундук, берничә минуттан, инде кире вокзалга таба йөгерә, юк, оча.

Аның шундый бер очышы күңелсез булып бетте.

## Исемсез стена

Новиковны зачет кенәгәсендәге билгеләр түгел, ел сөендерә, авырудан соң үткән ел, ышанып бетмәслек дәрәҗәдә уңышлы, ул үзе көндәлегендә язганча, «ерып үтелгән» ел. Әйтерсең ул университетка керүе белән җир тартуы тышауларыннан ычкынды һәм ирекле очышта галәмнең чиксез киңлекләренә күтәрелде. Аннары фәнни әдәбиятның беренче чыганакларына юл ачучы һәм тиз генә үзен кызыксындырган фәнни темалар белән шөгыльләнү мөмкинлеге бирүче төп чит ил телләрен өйрәнү дә ул елның бик әһәмиятле нәтиҗәсе булды.

Менә нинди иде ул уку елы. Мөгаен, аның тормышында бик бәхетле елларның берсе булгандыр ул. Аны әллә ни борчымаган сессия уңышлы тапшырылды, алда—җәй, обсерваториядә шөгыльләнүләр, җәй ахырында Таня, Семён һәм үзенең җилкәнле көймәсе булган геофак укытучысы Ибраһимов белән Казансу—Идел—Зөя—Казансу боҗрасы буенча сәяхәт. Ә аннары университетның икенче курсында илаһи йолдызлар һәм аларның җир әһелләре Тарутин, Покровский, Яковлев белән аралашулар... Тормыш матур! Һәм ул, шул матур дөньяның бер ком бөртеге, аңа бирелгән тормышның миллиард дәрәҗәсендәге кыска мизгелендә нәрсәдер эшләп өлгерергә тиеш. Нәрсә икәне—монысы көн кебек ачык.

Икенче университет елының башлануы бернинди катастрофа да алып килергә тиеш түгел кебек иде. Уку да, фәнни эшчәнлек тә борылышларда бер-берсен уза-уза йөгерешеп киттеләр. Ноябрь аенда Семённы комсомолга алу да, ә аның үзен эшче сыйныф вәкиле булмаганга күрә алмаулары да, юк, бер дә сагайтмады аны. Кәефсезләндерүен кәефсезләндерде, әлбәттә. Ләкин офык, элеккеге кебек, ачык булып кала бирде. Ул бит аны да комсомолга керергә кыстаган Семёнга, үзенең машинист малае булмавы, ә бары тик Идел-Кама районы буенча Төньяк-Көнбатыш Дәүләт сәүдәсе вәкиле малае гына икәнен әйткән иде. Ул беркайчан да: «Учак булып күккә күтәрелегез, зәңгәр төннәр, без пионерлар—эшчеләр баласы»,—дип җырлап йөрмәде. Моңа хокукы юк иде. Ләкин социаль хәле иң мөһименә—уку һәм фәннәр белән шөгыльләнүенә йогынты ясый алмады. Шулай уйлады студент Николай Новиков. Озак уйлады, инде студент булудан туктаган чагында да, үзенчәлекле язмышының боргаланышларына, аның акыл белән дә, йөрәк белән дә аңлап, төшенеп җитеп булмаган, безнең Алмалыда әйткәнчә, үтерсәң дә сизеп булмаган барышына карамыйча, бөтен гомере буе уйлады.

Акча чутын Новиковлар гаиләсендә әтисе алып барды. Сүз уңаенда әйтеп үтик, бик тә намуслы һәм эшне җиренә җиткереп эшли торган кеше иде ул. Ләкин бер командировкасы вакытында аны бик каты салкын тию тәмам аягыннан екты, аннан аны, ике атна район хастаханәсендә ятканнан соң, өзлеккән хәлдә туган шәһәренеке—Шамовныкына алып кайттылар. Анда тагын бер ай ятты ул. Шушы сәбәп аркасында кызы һәм малаеның

укулары өчен университетка булган бурычларын түләүдә бераз тоткарлык килеп чыкты.

Ләкин бу кискен санкция ни өчендер тик Николайга гына кагылды. Шунда аны университеттан куып чыгардылар.

Аннары, эшнең асылына төшенеп, кире торгыздылар.

Әмма торгызылганнан соң бер атна да укымады, факультет комиссиясе, «матди яктан яхшы тәэмин ителүенә (сәүдәгәр) карамастан, аз өлгерешле студент буларак» аны физматфак студентлары сафыннан чыгару турында карар кабул итте.

Николай белдерүләр тактасына эленгән Студентларның академик өлгерешен тикшерү комиссиясе бюллетенен укып чыкканнан соң, аның күз алдында хәрефләр төрле якка таралышып китте...

«Беренче номерлы нигез: политкоммунизм буенча зачеты бирелмәгән...»

Алар стенд янында өчәү басып торалар иде.

—Ничек бирелмәгән?!—дип борылды Николай Таня белән Семёнга.—Мин бу зачетны бирдем бит! Обсерваториядән махсус кайттым. Дөрес, ахырдан икенче булып, ләкин бирдем. Бернинди өстәмә сорауларсыз. Әгәр поезд Кызыл Тауда тоткарланмаган булса, бәлки, беренчеләр арасында булып, шул беренчеләр белән биргән булыр идем...

—Кызыл Тауда түгел, ә Юдинода,—дип төзәтте аны Семён.—Оныт ул революциягә кадәрге исемне! Юдино станциясе бар...

—Соң, мин бит гадәт буенча гына... Нинди аерма булсын монда?

—Менә-менә, синең сәяси әзерлегең аксый.

Николай нервыланып тыңлаусыз чәчләрен артка таба җибәреп куйды.

—Ләкин нинди сәүдәгәр булыйм ди мин? Мин бит бер дә эшләмәдем, димәк, беркайчан бернинди акча да эшләп алмадым. Мәктәптән соң ук, авыруымны санамаганда, шушында кердем һәм шушы көнгә тикле, бернинди өстәмә акча эшләргә алынмыйча, шушында укыйм ич.

Татьяна белән Семён да аптырап калган дусларыннан ким борчылмыйлар иде. Алар аның бөтен гаиләсен яхшы беләләр. Чыннан да Николай нинди сәүдәгәр булсын ди инде? Көлке бу. Әйтик, студент яисә мәктәп укучысы сәүдәгәр була аламыни? Житмәсә, аның йөрәге авыртулы әнисе урын-жирдән дә тормый һәм гаилә әгъзалары бөтенесе дә бары тик хезмәттәге әтиләренең эш хакы исәбенә генә яшиләр. Ә егерменче еллар башында хезмәте дә булмады әле аның, чөнки өлкән Новиковны егерме беренченең башында Арча кантромкомыннан штат кыскарту буенча эштән чыгардылар һәм ул егерме өченче елның жәендә Севзапгосторгка эшкә кергәнче эшсез булып йөрде. Ничек ачка үлмәделәр диген әле? Менә бу сорау дисәң дә сорау! Хәтта аларга бабасы Федор Софроновичтан калган кайбер әйберләрен дә сатарга туры килде ләбаса. Менә шул коткарып калды алар гаиләсен. Димәк, бабасы аларга үзенең үлеменнән соң да бик нык булышты диган сүз.

—Ләкин алай да синең бабаң барыбер сәүдәгәр булган бит!—дип хәтерләтте Семён.

—Булган...—дип хәтта ниндидер горурлык белән килеште аның белән Николай.—Һәм советлар хезмәтендә дә булды, унжиденче елдан... унсигезенче елның августына, аны хезмәтеннән ак чехлар гомере белән бергә азат иткәнчегә тикле. Әти дә булды, ул да сәүдәгәр булып эшләде...

—Сәүдәгәр булып эшләгән...—дип көлемсерәп куйды Семён.

—Нәкъ шулай: эшләгән. Ул революциягә кадәр чит илгә йомырка чыгару фирмасында икенче гильдия сәүдәгәр рангына туры килә торган һәм юридик нигездә шунсыз чит ил сәүдә вәкилләре белән бернинди аралашуга да рөхсәт

ителмәгән вәкил хезмәтендә торган. Ләкин аның бу вазифасы чынында коры административ хезмәт кенә булып, билгеләнгән нык хезмәт хакы белән түләнгән һәм хезмәтне шәхси максатларда эксплуатацияләүгә дә, үз хезмәтең белән табылмаган керемнәр алуга да юл куймаган.

—Тынычлан, Николай.

—Тукта, Семён, бүлдерми тор. Мин аңламыйм, көн кебек ачык бит югыйсә! Кешегә бәя бирү нигезен шәҗәрә дә, эти һәм бабайларның үзләренә хас сыйфатлары билгеләми ләбаса, бигрәк тә, әгәр ул математик, механик, астроном булса. Ә бары тик аерым кешенең үзе, аның башы, аның шәхси сыйфатлары гына билгели аны. Бабай—сәүдәгәр... Нәкъ дөрес—сәүдәгәр. Тик миңа беренче булып күкне һәм аның буенча йөзүче Арго Корабын менә шул сәүдәгәр күрсәтте бит!..

—Тынычлан әле син, Николай, тынычлан. Моны миңа түгел, ә бу кәгазь кисәген әвәләгән кешегә аңлатырга кирәк,—дип белдерүләр тактасына бармагы белән сукты Семён.—Апелляция язарга... Ә болай кирәк бит шулай язарга: аз өлгер-реш-шле, имеш!.. Һәм синең профессорларың—Тарутин да, Покровский да, җиннәрен сызгансыннар да, шулай ук үзләренең саллы кәгазьләре астына кулларын куйсыннар.

Бер елдан соң Главпрофобр машинист малае Семён Пичугинны студентлардан Университет Идарәсенә сайлый. Ләкин ул студент Новиковка карата гаделлекне торгызу өчен нәрсә эшли ала иде соң?

Кайчак кешеләр тыштан үзгәрмичә, эчтән бик тиз, хәтта ашкынулы рәвештә алышынып куялар.

Кайчак кешеләр эчтән үзгәрмичә, елдан-ел бары тик тышкы яктан гына алышыналар.

Машинкада зәңгәр сызыклы кәгазьгә «а» хәрефе төшерелеп басылган теге бюллетендә Новиков өчен иң зур көтелмәгән, ул чакта әле гади студент кына булган Семённы да, Таняны да барыннан да бигрәк аптыраштa калдырганы, артыннан политминимум буенча зачет бирмәү турындагы аңлатма килгән «аз өлгерешле» дигән сүз булды.

Өйдә, әле генә сызыклы бюллетеннән укыган, ә аннары комиссиянең кечкенә күзләрен генә түгел, җанын да, хәтта үзен башыннан табанына кадәр бөтен барлыгы белән яшереп торган шикелле тоелган ялтырап торган түгәрәк күзлекле төксе секретаре авызыннан да ишетергә туры килгән бу күнелсез хәбәр турында эти-әнисенә ничек итеп җиткерергә икәнен күз алдына китерә алмыйча, аның белән бу нәрсәнең ничек килеп чыгуын әле үзе дә аңламыйча, Николай Новиков искәрмәстән зачет кенәгәсен ачты һәм анда... политминимум буенча бирелгән зачетны тапмады. Димәк, белдерүләр тактасындагы сызыклы кәгазь һәм күзлекле секретарьлар хаклы, ә ул—юк, чөнки... чөнки ашыгычлык белән (моны ул яхшы хәтерли) үз белеменең уңай билгесен яздырырга оныткан, өлгермәгән, бу тантаналы эшкә игътибар итмичә чыгып чапкан. Димәк, моны укытучы да үзенең исемлегендә билгеләп куймаган. Ул да оныткан мы икәнни? Әллә ул бу студентның үзенең абруйлы шәхесенә һәм үзе укыткан фәнни предметына ихтирамсызлыгына рәнҗегән булганмы? Тукта, аның фамилиясе ничек соң әле? Ул Николай Сергеевичның хәтерендә дә, шул еллардагы документларында да, ялтыраган күзлекле төксе секретарьның исеме, ул еллардагы үтә күрүчән комиссия һәм идарәләрнең башка хөрмәтле бик күп кенә әгъзаларының исем-фамилияләре кебек үк, сакланмаган.

Ә менә Тарутин Николай Николаевич, Покровский Стахий Григорьевич, Яковлев Владимир Леонардович, Ибраһимов Мәхмүт Ибраһим улының исемнәре аның хәтерендә генә түгел, ә студент-математикны университетта яңадан торгызуны сорап язган хатларында да калган. Ул хатлар миндә

саклана һәм мин алар арасыннан чын галимнең акылы белән йөрәге, аның фәнни бөеклеге белән гражданлык асылының аерылмаслыгын күрсәтүче документ сыйфатында тик берсен генә китерәм.

*Казан Университеты физика-математика факультеты студентларының академик өлгерешен тикшерү комиссиясенә.*

*Шушында астроном профессор С.Г.Покровскийның һәм астроном-күзәтүче В.Л.Яковлев, шулай ук геофак укытучысы М.И.Ибраһимовның Астроном-Математика Җәмгыятенә икенче курс математигы Н.С.Новиковны студентлар сафыннан чыгару уңаеннан язылган гаризаларын теркәгән хәлдә, мин үз чиратымда Комиссиягә аны Университет студентлары хокукында кабат торгызуны үтенеп сорыйм. Дәүләт барлык талантлыларны ачыкларга бурычлы һәм мин талантлы студент Новиковка аеруча игътибар итәм: ул әле беренче курс студенты булган чакта ук минем махсус курсларыма, мәсәлән, махсус характердагы бик авыр фән булган чамалылык теориясе курсларына йөрде. Ул Чамалылык Теориясе буенча уздырылган практикада бик актив рәвештә һәм беренче курс студенты өчен гаҗәеп зирәклелек белән катнашты, ә бу елның май аенда астроном Яковлев җитәкчелегендә икеле йолдызларны аеруга багышланган бик кызыклы фәнни теманы тикшеренүгә кереште. Мондый студентлар—сирәк, һәм мин, әгәр Дәүләт бу үсмер йөзендә зур фәнни көчне югалта калса, бөтен җаным белән кызгану хисе кичерер идем. Бәлки, аны чыгаруда чыгышы турында фикер йөртү роль уйнагандыр, ләкин Дәүләт—яңа типтагы социалистик, халык Дәүләте— күзлегеннән караганда, андый позициянең өстенлеге талантларга карата чын исраф итүчәнлек булыр иде.*

*Шуның өстенә Новиков, аның апасы—безнең Университет студенткасы Новикова кебек үк, югары дәрәҗәдә тыйнак, алар икесе дә фәнгә бирелгәннәр, намуслылар һәм, гомумән, сөйкемле яшь кешеләр. Минем фикеремчә, аларның берсен, ә атап әйткәндә—Николай Новиковны укудан чыгару бернинди логик аңлауга да бирелми торган рәхимсез һәм акылсыз гаделсезлек булыр иде.*

*Астроном-Математик Җәмгыять рәисе,*
*Профессор Н.Н.Тарутин.*
*Казан. 1924. XII. 23.*

Физмат студентлары исеменнән үтенеч хатын студентка Родимцева язды. Хатка унлап студент, шулар арасыннан биш минуттан Университет Идарәсе әгъзасы булачак Семён Пичугин да кул куйды. Апелляцияне зыян күрүче дә язды. Һәм аны башта Университет Комиссиясенә, аннары Идарәгә һәм ахырдан студентлар составын тикшерү буенча Өлкә Комиссиясенә бирде.

Университет комиссияләре һәм идарәләреннән бернинди нәтиҗә дә көтеп ала алмаган Тарутин, Покровский, Ибраһимов, Яковлев, Родимцева шулай ук Главпрофобрга, аның студентлар составын тикшерү буенча Өлкә комиссиясенә дә яздылар.

Сораучыга да, яклаучыларга да бирелгән җавап катгый иде: җирле Комиссия карарын расларга һәм апелляцияне кире кагарга. Майлы мөһер астындагы имза танып булмаслык иде. Танып та булмаслык, шулай ук бөтен бу нәрсә аңлашылырлык та түгел. Туры, ачык күңелле яклаучыларга болар барысы да коточкыч аңлашылмаучылык, акылга сыймаслык мәгънәсезлек булып тоелды. Ничек шулай килеп чыкты соң әле бу? Талантлы бер студентның язмышы һәм дәрәҗәле кешеләрнең, галимнәрнең, студентларның эчкерсез тырышлыгы нигә исемсез, сизелми торган һәм ышанычсыз тоташ стенага килеп бәрелде соң? Монысы гына аз тоелды бугай, җитмәсә, бу студентны яклаучыларны да исләрендә калдырдылар

әле. Родимцеваны факультет Президиумы келәменә чакырдылар һәм, партиянең студентлыкның пролетар үзәген нығытуга юнәлтелгән курсына саботажлык дип бәяләп, сыйнфый йөзен югалткан элементны яклап чыккан өчен, берочтан иләп кенә аның үзенең дә нинди каннан булуын искәртеп, ике сәгать буе кыздырдылар. Профессор Тарутинны, беренче курс студентын өлкән курсларның махсус дәресләренә рәсми булмаган рәвештә катнаштыруы өчен, язма рәвештә дә һәм телдән дә аңлатма бирергә мәҗбүр иттеләр һәм сәүдәгәрләргә астыртын булышлык күрсәтүе өчен оялтып маташтылар. Оялтуын Идарә оялтты. Аны—РСФСРда барлыгы биш кенә булган рабфакны оештыру комитеты председателен, Казан шәһәрендә эшче һәм крестьяннарның ирекле һәм тәртипкә салынган укуларының баш оештыручысын бит!

Тарутинның имтиханында «киселгән» студентларны: «Сезнең уңышсызлыгыгыз җитди дөньякүләм нәтиҗәләргә китермәячәк. Мәсәлән, Франция Англиягә сугыш игълан итмәячәк»,—дип юата торган гадәте бар иде. (Ул вакытта газеталар Антанта державасы станындагы каршылыклар турында күп яздылар.)

Аның яраткан укучысы белән политминимум буенча зачет мәсьәләсендәге очрак бөтен бер сәяси акциягә әйләнде. Дөресен әйткәндә, ул җирле газеталар, «университет Совет властена дошман элементлардан һәм үле җаннар булган 387 студенттан, ягъни бөтен составның унтугыз процентыннан азат булды» дип язган зур кампания башланган чорга туры килде. Һәм партиянең студентлыкның пролетар үзәген нығытуга юнәлтелгән курсына саботажлык итүе, сыйнфый йөзен югалткан элементны яклап чыгуы өчен әдәпле рәвештә профессорны үзенең киләчәк практикасында үткен телле һәм, аңа озак вакыт күренгәнчә, ялгышмый торган, гөнаһсыз фразадан баш тартырга мәҗбүр итте.

Ләкин үзенең укучысыннан түгел, ул аннан һич тә баш тартмады.

Бу хәлдән соң бер ай үткәч, Николай Новиков Энгельгардт исемендәге Астрономия обсерваториясенең /ЭАО/ астрофизик секторының исәпләп чыгаручысы сыйфатында вазифаи эшкә кабул ителде, анда ул беренче курста башлаган фәнни темасын дәвам итте.

Бу—профессорның куркынычлы адымы иде. Хәтта моны аның җәмәгатьчелек фикеренә каршы килүе, дип бәяләргә дә мөмкин иде.

Хәер, нәрсә соң ул җәмәгатьчелек фикере? Покровский, Яковлев, Ибраһимов, Родимцева һәм университетның башка намуслы хезмәткәрләре һәм студентлары фикереме, әллә югары идеяле, югары дәрәҗәле, югары урыннарда утыручы һәм югары активлык күрсәтүче комиссияләр, идарәләр, главпрофобрларныкымы?..

Бу турыда профессор Тарутинның үз фикере бар иде.

## Нинди декадент?

Шул ук вакытта Тарутин Новиковны университетта торгызу уен да калдырмады. Эш эш белән, әлбәттә, шөкер, хәзергә Новиковның эше—физматны тәмамлаган теләсә кем көнләшерлек. Ләкин заманалар үзгәрә тора бит һәм еллар узу белән дипломсыз килеш аңа да авырга туры килүе мөмкин. Аннан соң, мәктәп белемен санамаганда, фәнни дәрәҗәсез генә түгел, ә югары белеме турында мөһер белән расланмаган дипломы да булмаган галим кешенең нинди киләчәге булырга мөмкин? Мөгаен, аны эченнән рәнҗетелгән профессор горурлыгы да кымырҗата иде бугай. Аңлашыла бит: Новиковка ясалган удар—ул, Астрономия-Математик Җәмгыяте председателе буларак, аның үзенә карата да көчле удар, ә бәлки

иң беренче очракта аның иң сәләтле һәм якын булган укучысы аша аңа юнәлтелгән удардыр да әле. Бик житез һәм ансат эшләнгән! Ул монын кем мәкерлеге икәнен дә сизенә иде. Әмма моны ачыктан-ачык раслаучы дәлилләр юк шул. Кайчандыр ул университетның югары дәрәжәле кайбер кешеләренең үз канатлары астына алган ике-өч булдыксыз һәм елгыр адәмнәрнең юлларына аркылы төшкән иде, менә хәзер ерып чык, сәләтле укучыңны бүре чокырыннан тартып ал!

Үзенең башыннан чыкмый, күңеленнән китми, һаман җанын кимереп торган сызлануы белән Тарутин губком секретаренә барып керә алды һәм тегесе профессор дәлилләре белән килеште дә, чөнки, чыннан да, университетның физмат факультетында укучы Новиковның академик аз уңышлылыгы (документларда ул йә «аз өлгерешлелек», йә әнә шулай «аз уңышлылык» дип языла иде) бик тә аз ышандыра иде шул. Ләкин студентны, вуз Идарәсен узып, үз хокукында ул да, губком да, губисполком да торгыза алмый икән. Иптәш секретарь, Тарутин көткәнчә, «сәүдәгәр» һәм «матди яктан яхшы тәэмин ителү»гә әллә ни игътибар итмәде. Шунда профессорның ахыргы дөреслекнең барып чыгачагына булган ышанычы кинәт яңадан ныгыды.

Губком секретаре Тарутин Николай Николаевичны әле революциягә кадәр үк партия әгъзасы (үзенең партия стажы алай ук түгел иде әле), кызыл профессор буларак белә иде. Шуңа күрә аны, гадәттәгечә, стена сәгатенә карый-карый түгел, ә ашыкмыйча, хөрмәт белән тыңлады.

—Безгә университетның тулы курсы өчен зачетлар бирүгә бер ел житә.—Профессор «безгә» диде, чөнки үзенең кайгыртуына ышана һәм аның өчен бик каты борчыла, Новиков имтиханнары аның үзе— чәчләре чаларган фән эшлеклесе өчен дә имтихан иде.— Асылда без университетны тәмамлауның мөмкин булган төрле формаларына да риза. Әйтик, экстерн рәвештә имтихан тоту яисә тиешле дип табылган вакытта тулы имтихан тапшыру шарты белән теләсә кайсы курска кире торгызылу...

—Житәр сәңа, Николай Николаевич, житәр,—дип тынычландырды аны иптәш секретарь,—борчылмагыз, үз улыгыз шикелле кайгыртасыз. Ә андыйларны, аның шикелләләрне, бүген өч йөзләп чыгардылар бит.

—Андыйларны, ләкин бик андыйларны түгел...

—Аңлашыла, аңлашыла, сезгә күренәрәк төшә. Мин университетка шалтыратырмын. Бүген үк. Ә сез... Ә ул гариза язсын.

—Кем исеменә?

—Университет идарәсенә. Миңа түгел бит инде!

—Инде анда өч гариза ята.

—Менә дүртенчесе дә ятсын. Кайчан чыгардылар әле аны? Аһ, әйе... Әйе, әйе, дөрес, инде еллар үткән, таләпне яңартырга, үз позициянең ныклыгын расларга кирәк.—Губком секретаре уйга калды һәм, үз эченә бикләнүдән айнымыйча, әйтеп куйды:—Еллар, еллар, нишләтәсез сез безне? Эзсез генә нинди кара тишеккә төшеп югаласыз? Сез, хөрмәтле профессор, инде бөтенләй чал чәчле. Минем куе чәчләр дә җемелди башлады әнә. Ә чәчләре иртә агарганнарга йолдызлар ни юрый икән?

Профессор үзенең астролог булмавы турында мыгырданып алды да, бик әдәпле генә саубуллашып, чыгып китте.

Ул губкомда яхшы кабул ителүе турындагы хәбәр белән обсерваториягә, үзенең шәкерте янына ашыкты. ЭАО ның барлык хезмәткәрләре дә шунда ук, урманда, төрле уңайлыктагы йортларда обсерватория тирәсендә яшиләр иде. Анда аларның, сүз уңае белән әйткәндә, үз зиратлары да бар. Новиковка, вакытлыча дип, инде узган гасырда ук бүрәнәдән салынган барактан бүлмә бирелгән иде.

Дүртенче хат-үтенеч шул ук көнне язылды.

Ай-һай, көн саен глобаль сәяси һәм хуҗалык проблемаларын чишүче губком секретаре наркомпрос реформасы нигезендә куылган, үзенә охшаш башкалар шикелле үк фабрика, завод, авыл коммуналары һәм Кызыл гвардияләр җибәргән яшьләр өчен урын бушаткан ниндидер студент турында университетка шалтыраттымы икән?..

Университетта торгызуларын сорап язган дүртенче гаризасыннан соң Новиков, аларның һәрберендә килеп туган хәлне җентекләп һәм аны укудан читләштерү сәбәпләренең нигезсез икәнен математик төгәллек һәм төпле итеп раслап, бишенчесен дә, алтынчысын да язды. Җаваплары йә бөтенләй дәшми калу, йә директив җәмәгать оешмалары әгъзалары һәм председательләренең гаҗәпсенүле рәвештә инбашларын җыерулар гына булды. Очына чыга алмаслык хәл! Хәтта астрономга да табигатьтән өстен көчләр барлыгына ышанырлык вакыт иде бу.

Таня да, Семён да һәм апасы Ольга да университетны тәмамладылар. Инде Таня Ленинградка эшкә китеп барды, Ольга—Әстерханга. Семён туган шәһәрендә уңыш казанды һәм тынычсыз рәвештә тагын каядыр җыена иде... Профессор Тарутин үлде. Инде Новиков обсерваториядә тәҗрибәле астроном иде...

Ә университетта торгызу яисә университетның тулы курсы буенча имтиханнар тапшыру турындагы табигый һәм законлы сорау гына һич тә урыныннан кузгалмады. Юк, ул моңа ябышып ятмады һәм, моңа карап, үзен кимчелекле итеп тә сизмәде. Ул эш белән мәшгуль иде. Ләкин дуслары (Танядан хатлар атна саен килеп торды), аңа күп акыл саткан, ә үзе вакытында коллектив хат-үтенечкә дә кул куймаган апасы, шулай ук әдәпле акыллыбаш-коллегалары гына тынгылык бирмәде...

Николай Николаевич Тарутинның соңгы сүзләре күңеленә кереп калды. Новиков аның янына үлеменә берничә сәгать кенә кала килгән иде. Ак чәчле һәм чәчләре шикелле үк ак йөзле профессор шунда әкрен генә: «Юлга чыгуы җиңел, улым минем, аны үтүе авыр...»—дигән иде. Менә шундый хикмәтле фикер әйтте аңа укытучысы. Кайчак үлем түшәгендә ятучыларның кайберләре, тәэсирләнеп, тормышта үзенең нәрсәдер эшләргә өлгермәвенә үкенмичә генә: «Мин дистанциядән төшәм, ә синең барысы да алда әле...»—дигәнрәк сүз әйтәләр.

Йолдызлар үз вакытларында яналар, үз вакытларында сүнәләр.

Утыз беренче елның язында Новиков кабат, беренчесе кебек үк, басынкы, җентекле соңгы хатын язды һәм, матур бер көндә шәһәргә чыгарга җай табып, аны альма-матерга алып китте. Инде аның юлы сайланган, тик аны җиңеп чыгар өчен университет, аның тиешле документлары һәм гади-гадәти административ-бюрократик булышлык кирәк иде. Чөнки, ни әйтсәң дә, обсерватория, гәрчә кайбер автономиягә ия булса да, университет учреждениесе иде бит.

Нәрсә язган иде соң ул бу хатында? Кызганыч, ул сакланмаган. Аның белән кемгә мөрәҗәгать иткән ул? Хәтерендә калдырмаган. Әлбәттә, һичшиксез, шул ук исемсез стенагадыр инде. Ләкин аның бу походында монысы түгел, башкасы игътибарга лаек иде. Вакыт үзгәрде, төрле сораучылар һәм шикаятьчеләр белән диалог формалары да үзгәрде.

Новиков белән әңгәмә, элеккеге шикелле, «аз уңышлы уку» турындагы бәхетсез мәсьәләдән дә, «сәүдәгәр»дән дә түгел, ә ( менә сиңа—исәнмесез!) килеп керүченең тышкы кыяфәтеннән башланды. Килеп керүгә, бусага төбендә үк үҗәт хаклык эзләүчегә үзенә көзгедән карап алырга киңәш иттеләр. Нинди күлмәк бу, нинди чалбар, ниткән штиблетлар?! Ә бу попныкы сыман озын, таралмаган чәчләр тагын! Кырынмаган. Төкләр белән

фән сараена?! Нindидер декадент яисә авыр махмырданмы әллә син?

Новиков үзенең кыяфәтенә әһәмият бирмәде һәм шуның өчен үзенчәлекле бу сәламләүне колагы янында гына үткәреп җибәрде. Ул үзенең тышкы кыяфәтенең, гади, ышанычлы, унайлы киемнәренең халыкның кайбер өлешенә һич тә ошамавына күнеккән иде инде. Нишлисең, зәвык—шәхси сыйфат, әйберләргә карата һәркемнең үз карашы, үз симпатиясе һәм антипатиясе бар. Тик шунысы мөһим, болар барысы да дәүләт ышанып тапшырган эшкә намуслы, объектив мөнәсәбәткә бернинди дә йогынты ясамаска тиеш. Бигрәк тә тапшырылган ул эш объективлыктан һәм вөҗданлылыктан башка кешеләр язмышына бәйле булса. Новиков аның хәленең асылына төшенүләрен сорады. «Яхшы, төшенербез»,—диделәр аңа.

Гади, казна эшендәгеләр фразасы инде бу. Ә әгәр уйлап карасаң? Болай «яхшы»—яхшы, ягымлы, җылы сүз кебек бит. «Төшенербез» дигәне дә күңелдә өмет тудыра торган сүз. Димәк, кемдер күпме еллар буе өсте-өстенә өелә килгән катламны, аңлашылмаучылык дуемын сүтәчәк, ә аннары башта ук урын алган ялгышлыкларны, ялганнарны да, шулай итеп, асылда әллә ни тирәндә ятмаган хакыйкатьне дә казып чыгарачак.

Тормышны кайчак йә матрос тельняшкасы, йә зебра белән чагыштыралар: юллы-юллы, ягъни барысы да кара, ак сызыклар белән чиратлаша тора. Николай Новиков үз әйләнә-тирәсендә бары тик яктыны һәм яхшыны гына күрә, тышкы кыяфәтенә, үз хәленә кагылышлы авыз еруларга һәм ачыктан-ачык мәсхәрәләүләргә беркайчан да игътибар итми торган кеше итеп яратылган иде. Ул хакыйкатькә бик ышана, инана. Ничек яшәргә ди инде ул ышанусыз?! Ышануың юк икән, дөньяда яшәргә дә кирәкми, дип саный иде ул.

Новиков университетның ак ташлы портигы астыннан чыгуга аның йөзенә шундук кояш нурлары һәм яз исе килеп бәрелде. Шундый коры, төче яз исе иде ул: инде кар күптәннән юк—эреп беткән, шул ук вакытта әле агачларда да бер генә яфрак та күренми, табигатьтә бары якты зарыгу, көтү генә... Һәм аяз, якты көннең күге дә зәңгәр дә, зәңгәрсу да түгел, ә сапфир төсендә иде.

## Пьедесталдан—таш юлга

Дөньяда май аеннан да кыска башка бернинди ай да юк. Җимеш бакчалары әле-әле генә алмагачлар чәчәге сөте белән кайный гына башлаганнар шикелле иде, ә менә инде алар бөтенләй коелып та беткән, үз урынына чәчәкләр өеме дә, алмалар да түгел, ә ниндидер шыксыз яшел җимшәннәр калдырып качып та киткән.

Әмма вакыты җиткәч аларга сок, хуш ис белән тулышырга, Алмалының һәм тирә-якның барлык тәмле тамакларын ымсындырырлык алсу, авыр гүзәлләргә әверелергә язган.

Ләкин ул гүзәл алмаларга хәтле ерак әле.

Әлегә шәһәр буенча бары тик июнь генә атлап китте.

—Николай, балконга чык әле, улым, кара әле, синең йолдызларың ни әйтә, иртәгә нинди иртә көтелә?—дип чакырды Сергей Андреевич Новиков үзенең егерме алты яшьлек улын, гәрчә көн буе үзе белән портфелендә йөртсә дә, эшкә хәтле дә һәм эштә дә караштырырга өлгермәгән газеталары белән йокы алдыннан кыштырдап. Бу юлы аның алдында караштырмаган газета саннарыннан торган өем ята иде. Ул хезмәте буенча җибәрелеп, өч атна буе Кама Тамагы авылларында югалып торганда, малае аларны аның өчен тәртип белән җыеп барган иде.

Сергей Андреевич Новиков тырыш, тыйнак һәм, күнел хисләре бәреп чыккан чакларда тыелучан булса да, бик тормышны яратучан кеше иде. Жил ишегалдындагы имәнне талкыган шикелле, аның гаиләсен дә төрле бәлаләр азаплады. Сергейга бары алты гына яшь булганда әнисенең янгында трагик үлеме, унсигезенче елда хатынын дәвалап булмый торган йөрәк авыруына китергән каенатасының коточкыч үлеме, малаеның университеттан куылуы, егерменче еллар ахырында үзенең эшен югалтуы, хезмәт биржасы, Идел пристаньнәрендә вак-төяк төяү-бушату эшләре... Өстәвенә, һәрчак дару артыннан куып ярым ач яшәүләре, чөнки гаиләләрендә һәрвакыт кем булса да авырый иде. Ләкин тормыш үҗәт күренеш. Бернигә дә карамастан, ул дәвам итте. Ул тормыш, ничек кенә гаҗәп тоелмасын, кайчак үзенең тын таңнары, өстәлдәге ипи телеме, хатынының ышанычлы елмаюы белән дә шатландырып-шатландырып алгалый иде... Кайчак тормыш балаларның чагыштырмача уңышлары белән дә җылытты: туганнан бирле зәгыйфь булган, җаны менә чыгам-менә чыгам дип торган, аның исән калырына күпләр ышанмаган Колялары да тернәкләнде әнә. Дөрес, авыр яши, ләкин авырый-авырый булса да, яши бирде; Ходайга шөкер, инде тиздән Ольгага да утыз яшь тула, университет тәмамлады. Дөрес, әлегә һаман кияүдә түгел, тик монысы инде аның шәхси эше.

—Йә, нәрсә, улым?—дип газетасыннан аерылды Сергей Андреевич, Николай балконнан кергәч.

—Иртәгә, әти, аяз һава, менә дигән кояшлы көн булачак.

—Искермәгән риваять...

—Юк, чынлап та. Бүген күк йөзе ачык китап шикелле.

—Алайса, бик яхшы, алайса, бик әйбәт.—Сергей Андреевич шушы сүзләре белән җирле газетаның чираттагы санын кулына алды һәм аның дүртенче, соңгы битендәге белдерүләр бүлегендә: «Аппаратны чистарту башланды...»—дип укыды. Аннары Сергей Андреевичның үзе эшләгән эш урыны аппаратының тулы исеме бирелгән иде. Бу нәрсә бу? Сергей Андреевич ашыга-ашыга сирәк файдалана торган күзлеген борынына элде дә, газетадагы шул урынны эзләп тапты. Юк, аның күз алдына гына килгән шикелле түгел иде бу хәбәр. Хәер, кая күз алдына гына килгән шикелле генә булу, хәзер андый белдерүләр һәр җирдә, бөтен газеталарда, хәтта коймаларда да чекерәеп эленеп торалар. Калын баш хәрефләр белән: «Идел-Кама районы буенча Төньяк-Көнчыгыш Госторг аппаратын чистарту башланды» дигән язу чекерәеп карап тора иде. Аннары ваграк итеп, боргес белән: «Соңгыларның эшендәге житешсезлекләр һәм аерым хезмәткәрләр турындагы материалларны Госторгка, чистарту буенча комиссиягә җибәрү сорала»,—дип язылган. Сергей Андреевич газетаның чыгу датасына күз төшерде, ул әле яңа, бүгенге сан иде.

—Жиллләтә торган мәгълүмат бу!—диде Сергей Андреевич.

—Ни бар?—дип сорады Николай.

—Юк, алай берни дә... Күптән өйдә булмадым, ә монда күп кенә кызыклы нәрсәләр җыелган. Тормыш минсез дә бер урында гына тормаган. Тормаган, әй-йе-е...

Командировкадан соң ул әле эш урынында булмаган иде. Нәрсәләр эшләнеп ята анда, кемнәрне чистартырга телиләр икән?

—Димәк, көн болытсыз була, дисең?

—Болытсыз, әти.

Николай ялгышмады. Яңа көннең иртәсе Алмалы өйләренең тәрәзәләренә, шәһәрнең көнчыгыш читендәге кырыеның күләгәле урамнарына якты һәм тыныч күз белән карады. Ул бүлмәләр буенча чиста, әле көндезге тузан сөреме кунмаган авыш, укка охшаш нурлары белән үтеп китте, тәрәзә

төпләрендәге гөлләрнең бөрешкән чәчәкләрен ачты, төнгә тынып калган чебеннәрнең күнелләрен күтәрде, аларга җан кертте һәм, стеналарда дерелдәп торган нур шәүләләре калдырып, шәһәрне хезмәт һәм шау-шулы тормышка уятырга дип, юлын арыга таба дәвам итте.

Өйдә барысыннан да элек, иртәнге алтынчыда, Немец Швейцариясе итәкләрендәге кыр канәфере шикелле, Николай күзен ачты. Аның исәбе буенча, ул йокларга иртә, төнге уникенчедә үк ятты, шуңа күрә иртүк уянды да. Аның астрономия тарихы турындагы мәкаләсен язып бетерәсе һәм университетка илтәсе бар. Анда обсерватория директоры белән очрашу һәм аңа университет нәшриятында бастырып чыгару өчен үзенең кулъязмасын тапшыру турында килешкәннәр иде. Обсерваториядә Николай Новиковны чиста күңеллелеге, тыйнаклыгы, бернинди шөһрәт сөймәүчәнлеге өчен яраталар, талантлы галим буларак һәм Сизиф дәрәҗәсендәге үҗәт хезмәт сөючәнлеге өчен хөрмәт итәләр иде. Анда эшли башлаган беренче елларыннан ук аңа үз эшен үзенә планлаштыру, аның күләмен (әйтергә кирәк, күләм дигәндә, ул аларны үзенә фантастик дәрәҗәдә бик күп планлаштырды) билгеләү хокукы да бирелде. Башында ноктасына хәтле уйланылган тарихи мәкалә кәгазьгә бик җиңел төште һәм иртән аның гомумиләштерүче ике-өч абзацын гына язып бетерәсе бар иде.

Николайның университетның «төп йорты» белән бәйләнеше әллә ни яхшыдан түгел, шуңа күрә директор белән очрашу да бу абруйлы уку йортының нәкъ шул «иске башкала»сында булырга тиеш иде. Ә яшь галимгә анда берочтан тагын аны студент итеп торгызу турындагы гаризасының язмышы турында да белешәсе бар. Нишләптер бик озак ята ул анда каралмыйча. Хәер, бу турыда уйлыйсы да килмәде, бик кызыклы һәм галимнәр даирәсендә бик аз гына билгеле булган фактик материалларга нигезләнгән мәкаләсен тизрәк язып бетерәсе килгән иде. Ләкин иртәдән, җәй башында гына була торган бик яхшы, зөбәрҗәт сыман матур иртәдән үк тик торганда башы авырта башлады. Ә өйләрендә мондый очракларда кирәк була торган дарулар табылмады. Әле кичә генә каләм очында эленеп торган кара тамчылары бүген мәкалә юллары булып кәгазьгә төшәргә теләмәделәр.

Мәкаләне зур авырлык белән генә тәмамлап, Николай университетка, һәрвакыттагы шикелле, еш кына сиңа кирәкле нәрсәләрне табып булмаган аптекаларга кагыла-кагыла китте.

Николай Державин даруханәсенә (аны Державин бакчасы каршында урнашканга шулай дип йөртәләр иде) тикле барып җитте, ләкин бормалы тоткалы биек ишектән эчкә кермәде. Аның игътибарын Державин һәйкәле янындагы тавышлар гөрелтесе, нindидер дулкынлану, шау-шу, ыгы-зыгы җәлеп итте. Бер төркем малайлар биек булмаган чуен рәшәткәләр аша сикереп чыкты да тавышлар килгән якка таба атлап, куаклар арасына кереп югалды. Ә анда, куаклар артында чыннан да гадәттән тыш нидер бара иде бугай. Николай башы авыртуы турында онытты, аптека баскычыннан аска таба атлады...

Керү җаенда, бакчаның тыл ягында, аның юлын бакча эченә агылучы, башында чая барабанчылар торган пионерлар колоннасы бүлде. Аларны үткәрү өчен бераз көтеп торырга туры килде. Тагын унлап кайнар, түземсез башларны үткәреп җибәрмичә булмады. Кешеләр һәйкәл янында булачак, үзләре яхшы белгән, тик әлегә ул, Николай төшенмәгән нindидер вакыйга турында күңелле генә сөйләшәләр.

Халык, Николай әле аптека янында ук сизенгәнчә, Державин һәйкәле тирәсенә җыелды. Һәйкәлнең нигезендә, шагыйрьнең бронза лирасына тотынып, кыска пинжәген җилбәгәй итеп җибәргән оратор кызып-кызып

шундагы халыкка үзенең фикерләрен җиткерә иде. Киеренкелектән аның йөзе кызарган, муен тамырлары бүртеп чыккан, әйтерсең сүзләр төере муенын кабартып, турыдан-туры аның буенча үтә.

Нәрсә турында сөйли соң ул? Сүзләренең мәгънәсе Николайга бары тик бераздан гына килеп җитте. Ә сүзенең ни турында баруын аңлап алгач, үз колакларына үзе ышанмый торды, аның өчен ниндидер бозлы салкынлык биләп алды.

Оратор, скульптурага җайлырак, инде лирага түгел, ә шагыйрьнең кулына тотынып:

— Безнең шәһәребез үзәгендәге аксөяк һәм морзага куелган бу һәйкәлгә күпме түзеп торырга була!—дип кычкырды.—Бу урын патша ялагае өчен түгел, ә халык юлбашчысы Емельян Пугачев истәлегенә тиешле. Утыра җәелеп!

Төркем хуплап гөрелдәп куйды, хәрәкәткә килде.

—Нәстә аңа монда торырга. Ул бит Пугачев артыннан куып йөргән, бик ялагайланып, баш күтәргән кешеләр дингезен җәзалаган.

—Мәд-хи-я-че!

—Нәрсә бугаз киерергә, тартып төшерергә үзен!

—Хәзер трактор килә!

—Ә бәлки трамвайга элэктерербез?

—Тагын ниндәй техник көч көтеп торырга? Без үзебез—көч. Тере көч!—дип кулын селтәп алды оратор.—Мөгаен, аударырбыз да, көчәнә торгач. Ән-нә күпме без! Ә-ә?

—Ауда-ра-бы-ыз!

Алдан ук әзерләп куйган шикелле, шундук пароход арканы пәйда булды. Тагын берәү, тагын бер бәйләм...

Барабаннар гөрселдәде, быргылар яңгырады. Монда барган хәлгә тик бер йөз генә гамьсез, битараф булып кала бирде. Хәрәкәтсез, мәһабәт, бөек. Ул әйләнә-тирәгә җыелган кешеләрнең башлары өстеннән каядыр чиксез гасырлар ераклыгына караган, ә аның бронза маңгаенда кояш уйный иде.

Николай күзләрен йомды, яман төштән арынырга теләгәндәй, башын селкеп куйды, ләкин коткарулы, бар нәрсәне дә үзенең законлы урынына куя торган чынбарлык килмәде, юк, пәйда булмады.

Ә янәшәдә генә (менә бит ул, законлылык сакчысы!) берни дә булмаган шикелле ап-ак гимнастеркалы милиционер басып тора.

—Иптәш постовой!—дип Николай милиционерның җиңеннән элэктереп алды.—Сез ни карыйсыз?

Теге ризасыз гына читкә тайпылды:

—Син китсәң иде моннан, студент.

Ни өчендер милиционер аны студент дип атады.

—Ничек—китсәң? Һәйкәлне җимерәләр бит хәзер, ул—халык байлыгы ич!

—Халык төшерә, ха-лы-ык. Аңладыңмы?

Ике аркан һәйкәлне күкрәге аша аркылы-торкылы ныклап чолгап алды, ә өченчесе муенында тартылды. Кыска пинжәкле оратор соңгы киңәшләрен бирде дә һәйкәл нигезеннән җиргә төште.

—Башладык!—диде ул.

—Бер-ике,—дип элэктереп алды төркем аның сүзен.

—И-их, күсәккәй, томырабыз!—дип кычкырды кемдер.

Өч арканны өч кешеләр төркеме сырып алды да, аны сынның бронза гәүдәсе шыгырдап куйганчы, кылдай сузылганчы, корыч тыгызлыгына җиткәнче тарта башладылар.

—Акылга килегез, сез нәрсә эшлисез? Кешеләр!—Ни булганын аңламыйча, күз алдында җәелгән акыл белән аңлап булмаган шундый мәгънәсезлекне күреп ярсыган Николай шагыйрьнең муенын арканлаган уртадагы халык күченә ташланды.—Туктагыз! Бу бит б-бөек р-рус шагыйре, бу бит безнең барлык шагыйрьләребезнең атасы, безнең якташ! Йа Ходаем, сез аны җимермисез, ә тарихны, тарихны ватасыз бит!—дип ул портфельчыгы белән селтәнеп җибәрде һәм аяк-терәүләре белән бурлакларча нык итеп җиргә терәлгән төркем стенасына ташланды.—Иптәшләр...

Каршысына очраган нокаут ясардай сугу аны һәйкәл нигезе төбенә ташлады.

Аңа, җаен туры китереп, оратор тондырды.

—Яклаучылар табылган, Екатерина ялагае турында кайгыртучылар, ананны синең!—дип сөйләнә-сөйләнә ул йодрыгы белән озын һәм акрын кыймылдаучан Николайга астан өскә таба китереп бирде.—Менә кайчан шуышып чыгалар әтрәк-әләмнәр! Кискен борылышларда, искене сындырган чакларда...

Җиңелеп җиргә егылган коры гәүдәдә көчләр кайдан җыелгандыр, ләкин шунда Николай аягына торып басты һәм тагын пароход баулары белән чолганып беткән тере стенага таба китте.

Өердән берничә кеше бер-берсен бүлеп: «Милиция нәрсә карый!?»—дип кычкырды. Николай мөрәҗәгать иткәндә үз тирәсендә бернинди яман эш тә күрмәгән ак гимнастеркалы шул ук милиционер, аңа халык массасы кычкырганнан соң, мизгел эчендә күзен ачып, хәлне төшенеп, тәртип бозучы Николайны эләктереп алды да бакчадан алып чыгып китте. Шундук тагын бер ак гимнастеркалы пәйда булды. Күз аллары караңгыланып киткән Николай ни булганын, аны кая, нинди максат белән алып баруларын һич тә төшенә алмый иде. Кояш нур чәчә, күктә болытның әсәре дә юк. Ә артындагы шау-шу, бәрмә дулкын сыман, һаман көчәя барды. Бик күп тавышлы бердәм акыруның иң югары ноктасында ыңгырашуга охшаш шыгырдаумы, шыкырдаумы тавышы ишетелде, аның артыннан куркыныч гөрселдәү авазы барлыкка килде. Гадәттә менә шушылай металл ташка барып керә, менә шушылай нинди дер бик зур һәм авыр әйбер авып төшә.

Николай башка берни дә хәтерләми.

Ул элек әле беркайчан да булмаган җирдә—төрмәдә генә аңыша төште.

Юк, аңа башта күренгәнчә, төрмәдә түгел икән түгелен, ләкин барыбер сак астында иде ул.

Исенә килгәч, аннан: «Аңыштыңмы?» дип сорадылар. Уңай җавап ишеткәч, нинди дер кәгазьләргә кул куярга, нинди дер сәер сорауларга җавап бирергә куштылар. Янәсе, ул Аллага ышанамы һәм, әгәр ышанса, кайсысына? Илдәге машина төзелешенең үсешенә ничек карый? Демонстратив чыгыш ясау турындагы карарга килергә аңа кем булышты? Моңарчы аңа психиатрлар һәм шуның ише хастаханәләр хезмәтеннән файдаланырга туры килмәдеме? Аннары һич тә таныпукып булмаган нинди дер язмалар астына кулларын куйды. Аңы минут саен томанлана барды һәм яңадан югалу мөмкинлеге белән янады.

Кичен миңгерәү тоткарланучыны, иртүк университетка да, обсерваториягә дә түгел, ә туп-туры һәм мәҗбүри рәвештә психик хастаханәгә барырга киңәш итеп, чыгарып җибәрделәр.

Улын күреп, авыру әнисе аһ итте һәм әкрен генә елап җибәрде. Кабинетыннан әтисе йөгереп чыкты:

—Ни булды синең белән? Кем кыйнады сине?

—Нигә андый нәтиҗә ясадың әле син, әти?—дип хәлне бераз йомшартырга

тырышты Николай.

—Үзенә көзгедән карап бак!

—Йә, нәрсә анда көзгедә?

Николай трюмо янына килде. Пыяладан аңа чәчләре тырпайган, пычранып беткән, ирене кырыенда кипкән, оешкан канлы, йончылган, бөтенләй чит кеше карап тора иде. Николай әти-әнисе күзеннән тизрәк югалырга ашыкты. Ничек уйлап житкермәгән соң ул бу турыда! Башта юынырга, үзен тәртипкә китерергә, аннары гына кайтып керергә кирәк иде ләбаса.

Әти-әнисе аннан хәлне аңлатып бирүен көтә иде. Николай нәрсә, ничек булуы турында барысын да сөйләп бирергә мәжбүр булды. Ул алардан беркайчан һәм бернәрсәне дә яшерми иде.

Шунда әнисенең хәле начарланып китте. Әтисе аңа инъекция (әтиләре гаилә башлыгы гына түгел, бәлки аның баш табибы да иде) ясады һәм шуннан соң әниләре тиз генә йоклап киткәч, ирләр, аны әкрен генә калдырып, нигәдер бөтен гаилә балкон дип йөрткән террасага чыктылар.

Инде көн сүнде, күк йөзе читеннән-читенә хәтле колач житмәслек һәм үзендә чынбарлыкка һич тә охшамаган кебек күренгән анлашылмас йолдызлар һәм ай күренеп торган кара пәрдә белән каплангандай булып калды. Жиңелчә генә жил исте, ләкин һавада әле барыбер көндезге эсселек ертыклары тирбәлә һәм бик көчле юкә чәчәге исе килеп тора иде.

—Димәк, син университетка барып житмәдең...—диде әтисе.

—Житмәдем,—диде Николай.

—Ә ашыгыч мәкаләң белән ничек була инде хәзер?

—Югалттым мин аны. Портфель белән бергә.

—Аллага шөкер, әле дә ярый башыңны югалтмагансың.

—Гаеплисеңмени?

—Юк, ләкин мин уйланылмаган һәм стихияле гамәлләрне беркайчан да хупламадым.

Алар, әле күзләрен йолдызларга күтәреп, әле бакчаларның тигез булмаган караңгылыгына караштыргалап, әкрен генә сөйләшәләр иде. Аларга карап, искитәрлек берни дә булмаган, дип уйларга мөмкин иде. Янәсе, йокы алдыннан әтисе малае белән әңгәмә кора һәм әле яшь булганга күрә башы бик үк аек булмаган малаена жиңел күңел белән тормыш чынбарлыгын төшендерә.

—Мин һәрвакыт акылны хистән өстен күрдем, улым. Килеш син минем белән, хис акылга ия булмаган тереклек белән дә идарә итә бит, хайваннар белән дә... Икенче яктан, кайчак йөрәк шундый матур, акыл белән аларга гасыр буе да житеп һәм формулалар белән һич тә исәпләп чыгарып булмаган нәрсәләр әйтеп куя, кайвакыт шундый, кешелек тарихында калырлык адымнарга этәрә. Ләкин алар өчен бик кыйммәт түләргә туры килә, хәтта тормыш белән дә булырга мөмкин. Менә син бүген, нәрсә, Державин бакчасындагы вакыйгалар барышын үзгәртергә теләдеңме? Үзләренең хаклыкларына ышанган йөзләрчә яшьләрне шул ышанычларыннан кире кайтарырга уйлаган идеңме? Ләкин алар бит бүген йөзләрчә һәм меңнәрчә генә дә түгел.

Николай атасының тавышында моңарчы билгеле булмаган әрнү хисләре тойды. Әйе, әрнү, һич тә үгет түгел.

Әтисе, туктаусыз өйрәтергә һәм шелтәләргә яраткан апасы Ольгадан аермалы буларак, гаилә әгъзаларының барчасына да демократик карашта булды. Юк, ул апасын хөрмәт итә, өлкән буларак аны тыңлый иде. Ә әтисен... Әтисен ярата иде. Һәм аның ул кичтәге, дөресрәге, ул төндәге бөтен барлыгына каршы килә торган калын, әрнүле тавышы Николайны

сагайта төште. Аның үзенең малае белән килеп чыккан шундый хәлдән соң гаҗәеп тынычлыгы,ниндидер заговорчылар тынычлыгы, үз җаваплыгына алуы, һәм бу әңгәмәнең зигзагка охшаган әле генә әйтелгәннәрне, урманда адашкан юлчы сукмак эзләгән сыман, сызып ташлый-ташлый баруы да сагайтты. Әтисенә нәрсәдер булган иде.

—Шулаен шулай ул, улым: акыл—җанны коткару хакына Аллаһы Тәгаләгә дан җырлау өчен. Ләкин кайчак бернинди котылу әмәле дә булмый. Менә монда инде, болай гына яшәгәнче, эш өчен газап чигәргә кирәк. Акыл акыл белән, ә, гәрчә дөрес фикерле, намуслы булса да, кемнендер мускулын сынар өчен төннек сыйфатындагы мин-минлексез статист булырга, дөресен генә әйткәндә, белмим, кем генә теләр икән! Фу, бу аңгыра, битараф ай астында ниндидер күңел төшенкелеге, апатия чолгап алды бугай мине. Гафу ит, синең астроном икәнеңне истән чыгарганмын. Әлбәттә, монда айның гаебе юк, ләкин аның астында күп кенә аңгыралыклар булып тора. Ә балачакта мин астрономнарны йолдызлы кара калфактан һәм табанына хәтле житкән киң озын халаттан, кулында ерактан күзәтә торган торба һәм култык астына калын-калын китаплар кыстырган, әллә кайчангы үткәннәрне дә, әллә кайчангы киләчәкне дә белүче, алдан күрүче, щи ашап тук булган түгел, ә бары тик йолдызлар тузаны белән генә тук булган кешеләр дип күз алдыма китерә идем. Менә ничек! Һәм менә кинәт минем улым—Йолдызчы. Ә? Бу Забродин эше, сине ул—хөрмәтле Фёдор Софронович йолдызларны танып белергә өйрәтте. Ничек атала иде әле астрономия искечә?

—Йолдыз сүзлеге.

—Менә ул картка,—урыны җәннәттә булсын,—актыгында бер генә күз белән сезнең обсерваториядәге иң көчле телескоптан шул йолдызларга карап алырга мөмкинлек бирәсе иде!—Өлкән Новиков малаен кочаклап алды.—Ярар, барысы да яхшы булыр. Университет турындагы борчылуыңнан да тукта. Юк икән, юк. Ахырында, әгәр эш шунда гына тора икән, үз-үзен кеше үзе белемле итә.—Сергей Андреевич малаеның ничек кенә булса да университет дипломы алуга омтылышын уртаклашмый иде. Яраткан эшең белән аннан башка да шөгыльләнергә була бит, янәсе. Диплом—белем түгел. Ә малаеның белеме бар. Аз да түгел аның белеме. Сергей Андреевичның күңеленә ниндидер тынычлык һәм ышанычлык инде. Шөкер, бу дөньяда аның дөрес, яхшы дәвамы кала. Ул үзен көндезге, аны чистарту буенча комиссиягә чакырылуы аркасында чолгап алган күңелсез уйларыннан тәмам арынып житте. Комиссия досьесында аны «Новиковның Госторг вәкиле вазифасындагы контрреволюция эшчәнлеге» турында бик җентекләп язылган һәм пөхтә итеп «эш»кә тегеп куелган ике аноним хат көткән булган. Билгеле инде, алда тагын да яңа фаш итүләр, яңа тикшеренүләр булачак... Гомумән, күңел күтәрелерлек нәрсә түгел иде бу. Әмма ул бу турыда малаена бер сүз дә әйтмәде.

## Туйга чакыру

Халыкта, ит изгелек, көт явызлык, диләр.

Тормышта еш кына нәкъ шулай килеп чыга да ул. Өметләр буталып йөри, соңаралар, кире кайтмаслык булып юкка чыгалар, ә яшереп куелган, көтелмәгән явызлык исә, бер дә сонга калмыйча, шундук килеп тә житә.

Бер көннән соң элеккеге студент Николай Новиков университетка апелляция комиссиясенә чакырылды һәм анда аның бөек Ленин исемен йөрткән вузның җәмәгать оешмаларына яла ягуы, Державин бакчасында бөтен халык алдында патшалыкның сынлы апологетын алып аткан вакытта ясаган советка каршы чыгышы өчен кирәген бирделәр. Сәүдәгәр сәүдәгәр

инде ул, диделәр ана, бер кулы белән шикаять һәм апелляцияләр сырлый, социализм төзү белән мәшгуль кешеләрнең башларын катыра, ә икенчесе белән пролетариатның муенына ябырыла.

—Сез бит, Новиков, сыйнфый йөзен югалткан элемент, искелек калдыгы!—дип чыгыш ясады комиссия утырышында аның күн киемле, чибәр, буйлы, кара кашлы, аксыл чәчле яшь кенә бер әгъзасы. Өстәл өстендә, аның каршында ук Новиковның кыршылып беткән портфеле ята иде.—Йөзегезгә битлек киеп алгансыз да гап-гади булып күренергә тырышкансыз, ләкин чын йөзегез барыбер ачылды. Кирәк бит әнә шундый булып күренергә тырышырга, хәтта бу эшкә милициягә катнашырга туры килгән! Хәтта документлар, мәкалә, китапханә укучысы билеты белән портфелегезне дә тотып бәргәнсез. Менә нинди икән сезнең университетка карата чын мөгамәләгез. Ул чагында ни телисез, бездән нинди мөнәсәбәттәшлек таләп итәсез соң сез? Сезнең белән сөйләшүне монда түгел, башка җирдә алып барырга кирәк иде, тегендә...—Кара кашлы, аксыл чәчле егет, ниндидер учреждениене, мөгаен, барыннан да элек инде Новиков булып чыккан җирне күз алдында тотып, тәрәзәгә таба төртеп күрсәтте. Оратор күрсәткән тәрәзә артында, июнь кызулыгында яшел яфраклар ялкау гына селкенә, сугыш чукмарлары сыман чыпчыклар чыркылдаша иде. Күн киемдәге ораторга эссе, ул кызарып чыкты, ләкин түзә, хәтта төймәләрен дә ычкындырмаган.— Без һаман либераллык күрсәтәбез, һаман сакланабыз, түзәбез. Мин, иптәшләр, Новиковның бик хөрмәтле астрономия обсерваториясе штатында торуының максатка ярашлымы, юкмы икәнлеге турындагы мәсьәләне күтәрергә тәкъдим итәм. Югары белемсез ничек эшли икән соң ул анда?!

...Яфраклар селкенде, чыпчыклар тагын да катырак котырынды. Күнелле халык бу чыпчыклар, аларга берни дә комачауламый—кызулык та, суык та...

Өйдә аны Ленинградтан килгән хат көтә иде. Анда Татьяна Родимцева белән Семён Пичугинның өйләнешүләре турында хәбәр ителгән һәм алар Николайны үз туйларына чакырганнар иде.

Университет курсын тәмамлаганнан соң Семён Пичугинны, гадәттән тыш көчле математик һәм җәмәгатьче буларак, үзләрендә, кафедрада калдырырга теләгәннәр иде дә, ләкин ул бу тәкъдимне кире какты. Һәм инде беренче курстан ук эшлекле бәйләнештә торган җирле фәнни-тикшеренү институтына юллама алды. Ә аннары, җай килеп чыкты да, андагы эше әллә ни кызыгырлык ук булмаса да, Ленинградка китеп барды, чөнки анда университеттан соң Таня Родимцева яши һәм эшли иде.

Николай шикелле үк, аның белән Семён да язышa иде. Ләкин, хатлары фәкать дустанә характерда гына булган дусыннан аермалы буларак, Семён Пичугин аңа булган мәхәббәтен белдерми түзә алмады һәм үзенең ялкын белән тулып ашкан күнелен машинкада басылган егерме дүрт битлек хатында тулысы белән ачып салды. Бу хат артыннан, дөресрәге, бандерольдән соң, аның Таняга карата булган мөнәсәбәтен тулысы белән яктырткан, үзе яхшы дип санаган берничә шигырен дә җибәрде, ә аннары, җаен туры китереп, шул Төньяк Пальмирга үзе дә китеп барды.

Семённың ачышы Таня өчен бөтенләй көтелмәгән нәрсә түгел иде, әлбәттә. Аны үзенең хатларына төгәл җавап бирүче, Таня өчен тигез, махсус каллиграфик хәрефләр белән язуы артында (ул моны сизә иде) күп нәрсәсе күренмичә, беленмичә кала биргән дип санаган икенче даими корреспонденты—Николай Новиковның тыйнаклыгы, басынкылыгы кайгыга салды. Николайның университет белән күп елларга сузылган үзара мөнәсәбәтләрендә эшләр чынында хәзер ничегрәк тора икән ? Аның авыру

әнисе терелгәнме? Сергей Андреевичнын эш мәсьәләсендә хәле ничек? Шатлыклы хәбәрләре белән Николай, әйе, анысы шулай, саранланмыйча уртаклашып килә. Алар асылда фәнгә, әдәбиятка гына кагылышлы була... Еш кына шигырьләрен дә җибәргәләде, ләкин барысы да һаман җирдән читтәге цивилизацияләр, бар нәрсәне җинүчән акыл турында, алмашучан тотылган йолдызлар турында... Таня өчен ул, Николай, үзе тотылган, алмашучан күк яктырткычларынын берсе булып тоелды. Семён белән бергә. Аның күз алдында бу дуслар йә чиратлашып кабыналар, йә бер-берсе белән үзара тотылалар, йә бер-берсенең яхшы якларын юмарт рәвештә ачып, якты итеп ялтырап куялар. Күпме вакыт инде ул үзенең икегә аерылган халәттә булуын сизеп яши, үз-үзенә аның өчен бу дусларның кайсысы кем икәнен төгәл һәм кистереп әйтә алмый азаплана. Икесе дә кадерлеләр, икесе дә аның башын да, йөрәген дә—кызның кайнар йөрәген, математикның салкын, уйлап эш итүчән башын яулап алдылар. Бары шактый соңрак, шундый соңрак, инде аннан да соң булуы мөмкин булмагач кына, аңа арифметик ачык җавап ачылды.

Баш белән уйларга кирәк, диләр. Һәрвакытта да алай түгел икән шул. Кайчак йөрәккә ышану зарурлыгы да туа икән бит...

Ялгыз чакта ялгышмыйча гына яшәве авыр.

Ә ул ялгыз иде. Бик ялгыз. Ленинград та тәрәзә артында гына булсын, ләкин, ни генә әйтсәң дә, туган шәһәр түгел бит ул, Нева елгасы да булсын, ләкин ул Идел түгел, Нева урамы да булсын, ләкин ул Алмалы түгел, эштәге коллектив та, фатир күршеләре дә Семён белән Николай түгел, әти-әнисе түгел. Бары тик алардан бик еракта гына аларның үзенә рухлары белән ничек якын икәнлекләрен, ваемсыз балачактан ук ир туганнары шикелле булуларын бөтен барлыгы белән аңлады Таня Родимцева.

Һәм менә шуларның берсе килә дә аңа кулын суза. Аның өчен махсус килә. Ул аның үзенә булган мәхәббәте хакында белә, тик үзенең аның кияүгә чыгарга тәкъдименә ник риза булуын гына белми, чөнки йөрәге тын гына һәм түземлек белән икенчесен, үзенең тормышына шулай ук бала чактан ук, ләкин бераз соңрак, авыр кыймылдаучан, хәтта көлке булып кергәнен көтүен дәвам итә. Әмма ул, ягъни икенчесе, аның күңеленә Идел буендагы ерак шәһәрдә аларның тугрылыклы дуслыклары барыбер элеккечә матур һәм намуслы булып калган килеш кереп калды.

Ә болай кереп калды ул...

Җәйге иртәдә кызый Таня яран гөлгә су сибә иде. Шулчак тәрәзә төбенә ата мәчеләре Черныш сикереп менде.

—Перс, перс!—дип куды аны Таня ягымлы гына.

Әмма мәче идәнгә сикермәде, ә чак кына читкә тайпылды да, гөлле чүлмәк икенче кат тәрәзәсеннән урамга төшеп китте. Таня курыкты, күзләрен йомды һәм тере дә, үле дә булмаган халәттә урындыкка килеп утырды. Өйләрендә аннан башка беркем дә юк иде. Тиздән алгы бүлмәдә кыңгырау чылтырады. Таня хәлсез калган аяклары белән килеп ишекне ачса, аның алдында кулына яран гөле һәм чүлмәк ватыклары тоткан озын буйлы ябык кына бер малай басып тора иде. Ул аны, Алмалының кешеләрдән читләшә торган, олыларча җитди, беркем белән дә дуслашмый һәм танышмый торган, әле монда күптән түгел генә күренә башлаган бу малаен шундук танып алды.

—Сезнең өскә төштеме әллә?—дип сорады Таня, каушап.

—Юк, чак кына алгарак,—диде малай.

—Керегез!

Һәм ул керде. Аны Николай дип йөртәләр иде, Николай Новиков...

Аның Ленинградтагы фатирына Семён килеп кергәч, Танянын хәтере

ирексездән һәм тыңлаусыз рәвештә башка, икенче бер көнне, икенче кешене, кулларына яран гөл һәм ватык балчык чүлмәк ватыклары тоткан әнә шул малайны исенә төшерде.

Семённың кулларында ялтыравыклы, кыштырдавыклы нәрсә белән төрелгән гладиолус чәчәкләре иде.

Таня, исенә килеп, аның муенына ташланды.

Кунакның башыннан эшләпәсе шуып төшеп китте. Ул бер—букетлы кулы белән хуҗабикәне кочаклады, икенчесе белән эшләпәсен җилкәсеннән урынына шудырды.

Чәй эчтеләр. Таня аннан туган шәһәре, дуслар-танышлар турында сорашты. Семён аңа бик җентекләп җавап бирде.

—Ә Николай ничек яшәп ята анда?

—Ул сиңа яза бит.

—Йолдызлар турында. Тик үз тормышы турында түгел.

—Йолдызлар—аның тормышы инде ул.

—Алай да... Университет белән ничек булып бетте аның? Берәр алга китеш бармы соң?

—Юк.

—Без дә яхшылар инде, Семён, синең белән...

—Ә монда безнең ни катнашыбыз бар?!—диде Семён, аңа гаҗәпләнеп карап.

—Өстән килеп төшәчәк нindидер дәреслеккә өметләнеп яшәдек. Тотарга да: «Йә алай, йә болай!»—дип өздереп әйтергә иде. Йә ул студент, йә без студент түгел, дип! Тик әйтә алмадык бит.

Семен кашларын җыерды.

Таня исенә килде. Карьерасына да карамыйча, монда аның өчен килгән кеше белән бу турыда сөйләшергә кирәкми иде бугай әле.

—Семён, ә Семён?

—Нәрсә?

—Ә син мондый фантастик гладиолусларны кайдан таба алдың?—дип сүзне икенчегә борган иде ул чакта Таня.

Тиздән алар загска гариза бирделәр.

Таня соңгы көнгә хәтле икеләнеп йөрде. Семён нервыланып үз сүзендә торды. Янәсе, мондый балаларча әйлән-бәйлән уенын күпмегә кадәр дәвам итәргә мөмкин? Янәсе, аның бер кулы аңа, икенчесе—Николайга тартыла... Җитәр, җитәр! Сайларга кирәк. Бу гади эш түгел, әлбәттә. Ләкин иртәме, соңмы, моны барыбер эшләргә кирәк. «Мин яратам сине, Таня. Балачактан яратам. Һәм үлгәнче яратачакмын»,—дип үйлый иде ул.

Тәбәнәк буйлы, үзсүзле, яна гына көмешләнә башлаган матур маңгай чәчле һәм бик чибәр булмаган, ләкин котылгысыз рәвештә бөкрелеккә алып килүчән гадәти аркасы бераз гына кабарып-чыгып торган, күзләре яшь һәм сөю тулы Семён Пичугин тигез булмаган сугышка ыргылды. Әйе, тигез булмаган сугышка. Юк, Танянең прозаик рәвештә аннан ярты башка биегрәк булганы өчен түгел, ә шуңа тигез булмаган: ул, Семён, максатка омтылышлы, үз дигәнендә нык торучан, ә ул, Таня, икегә аерылып калган, чит шәһәрдә ялгызлык белән хәлсезләнгән булуы өчен.

Таня кияүгә чыгарга җыенуы турында әти-әнисенә дә хәбәр итте. Алар ризалыкларын бирделәр.

Таня, никахларын рәсмиләштерү вакытында шаһит булырга дип һәм туйларына (бу сүзне гадәттә анлаганча, тау шикелле өеп әзерләнгән мул сый мәҗлесенә түгел, ә дусларча тыйнак кичәгә) килүен сорап, Николайга хат язды.

Бу хат Николайга ул университетны тәмамлау турындагы уеннан

бөтенләйгә саубуллашкан көндә килеп төште. Җавабын иртәнгә калдырды. Ә төнлә әтисен кулга алдылар.

Урамда, машина янында аларның ничәсе калгандыр, анысын бер Алла гына белә, ә фатирларына икесе күтәрелде.

...Төн уртасы җитеп килә иде. Новиковлар гаиләсе Николайның апелляция комиссиясе утырышы турындагы күңелсез хәбәреннән һәм бу хакта тар гаилә әгъзаларының файдасыз фикер алышуларыннан соң йокларга ятырга җыена иде.

Бөркәүле йөк машинасының төнге тынлыкны бозып өйләре янында тавыш белән килеп туктавы гаилә башлыгында тирән тынычсызлык хисе тудырды. Үзенең зур бүлмәсендәге урын-җирендә ятучы Александра Федоровна да борчылып куйды, агарынган бармаклары белән өстенә япкан җәймәсен капшаштырды, тыңлап, тын калды.

Машинаның ишекләре янгырап куйды. Акрыная төшкән тавышлар, кече капканың тимер келәсе чыкылдавы ишетелде, ишегалдына сукмак итеп җәелгән такталар шыгырдашты. Беренче катның ишегенә кактылар, тагын тавышлар: бу-бу-бу, бу-бу-бу... Һәм күрше хатынның:

—Новиковлар өстә яшиләр,—дигән ачык тавышы ишетелде.

Кыңгырау.

Сергей Андреевич ишек ачарга китте. Александра Федоровна еларга кереште, урын-җиреннән күтәрелде дә, нишләргә дә белмичә, бүлмә ишеге төбендә әрле-бирле йөренде. Ә табиблар ана, анда йөрәк мускулы инфаркты булганга күрә, урыныннан торуны катгый рәвештә тыйганнар иде.

Төнге кунакларның берсе штатский киемдә иде. Икенчесе, кыска муенлысы, нык гәүдәле, яшен билгеләве авыр булганы—кысан гомум хәрби гимнастеркадан һәм бик зур итекләрдән, үзен тотышына караганда, бу төнге операэкспедициянең командиры да ул иде.

Сергей Андреевич өйалдыннан кухняга беренче булып керде. Йөзе белән ул тыныч күренә, гәүдәсе дә ничектер бөтенләй тураеп-язылып калды.

Александра Федоровна күзләрен иренә таба күтәрде дә барысын да аңлап алды.

—Җыяргамы?—дип сорады ул.

—Ник тордың син?!—диде Сергей Андреевич шелтәле тавыш белән, ләкин, хатынының күзләрен күреп, туктап калды.—Ә... иптәш Дубов?

—Алай нәрсәсен җыярга инде аның?—дип, хәрби кин күңеллелек белән үзенең аксыл керфекләрен челт-челт иттереп алды.—Ярар, җыеныгыз. Әйе... мине фамилиям белән атау мәҗбүри түгел. Вәкил булам мин. Иптәш вәкил.

Бу берничә әһәмиятсез фразалардан Николай бу төнге визит сәбәпләренең инде аста керү юлында ук сөйләшенгәнен, вәкил кунакларның әтисенә килүе, дөресрәге, вәкилләрнең әтисен алып китүләре нинди дә ялгышлык түгел һәм әтисе белән әнисе өчен бөтенләй үк көтелмәгән хәл булмаганлыгын аңлап алды. Телсез калган Николай әнисенең ничек ярты кирпеч ипине кулына алып, аннары аны читкә куюын, чиста күлмәкне дә башта кулына алып, аннары тагын читкә алып куюын күзәтеп торды. Аннары кырыну приборы, сабын... Юк, ул фикерләрен бер ноктага туплый алмый иде.

—С-син аны кая җыендырасын?—дип сорады Николай әнисеннән.

Иптәш вәкил кулъяулыгы белән тирләгән муенын сөртеп алды.

—Шунда, сез чиратта торган җиргә, яшь кеше. Шулай бит, Николай Сергеевич Новиков? Ялгышмыймны?

—Шулай,—дип җөпләп куйды Николай.

—Ничек?!—дип кычкырып куйды Александра Федоровна.—Малайны да алып китәсезмени?!

—Хәзергә юк,—дип Дубов, штат киемендәгене ишек төбендә калдырып, Сергей Андреевичның кабинетына таба атлады. Һәм, борылып, өстәп куйды:—Хәзергә... Ләкин чыгышлар ясый-ясый шунда әләгергә дә бик мөмкин. Моны минем сезгә кешеләрчә, хезмәтем буенча әйтүем түгел, диярргә була.

Өй хуҗасы, инде бөтенләй хуҗа түгел, учы белән кызының яңагына кагылып алды, малаеның кулын кысты да:

—Николай, синнән сорыйм, акыллы була күр!—диде.

—Әти...

—Ярар, ярар... Александра, мин әзерме?

Ә Александра Федоровна аннан нәрсә соралганын оныткан да иде инде. Ул күз алдында картаеп калган шикелле тоелды, берни күрмәс карашы белән әле иренә, әле малаена карады...

—Аһ, хәзер, хәзер, Ходаем!

—Ашыкмасагыз да ярый,—диде Дубов кабинеттан. Ачык ишектән аның язу өстәле янындагы кәнәфидә ничек утыруы һәм кульяулык белән муенын сөртә-сөртә нәрсәдер актаруы күренеп тора иде. Өстәлдән ала да актара, киштәдән ала да актара. Ниһаять, ул торып басты.

—Вакыт, вакыт...

Ольга улап елап җибәрде:

—Әтием!

Сергей Андреевич кызын кочып алды, малаен кочты, хатынын кочты.

—Бәлки, ниндидер аңлашылмаучылыктыр,—дип Николай нинди булса да өмет уятырга тырышты.

—Мөмкин, барысы да булырга мөмкин,—диде Сергей Андреевич.

Дубовның зур итекләреннән идәндә коры тузан эзләре калды.

Озатырга чыкмадылар. Сергей Андреевич гаиләсенә өйдә калырга кушты. Сүзен тыңлап калдылар, тәрәзәгә карап бактылар, тик анда берни дә күрмәделәр.

Александра Федоровна төн буе бүлмәдән-бүлмәгә йөренде, урындыкларны, тумбочкаларны күчерде, киштәдәге китапларның урыннарын алыштырды, кухняда савыт-саба шалтыратты... Бернинди авыр уфылдау, бернинди яшь чыгару да сизелмәде. Бу исә Николай белән Ольганы барыннан да күбрәк борчуга салды.

Икенче көнне кичкә табан Николай Таняга телеграмма җибәрде: «НИКАХЫГЫЗ БЕЛӘН ЧЫН КҮНЕЛЕМНӘН КОТЛЫЙМ КИЛӘ АЛМЫЙМ».

## СИГЕЗЕНЧЕ БҮЛЕК

### Профессор белән танышу

Көзнең бер якшәмбе көнендә Шәех Пичугиннарга кулына «Альпинист»ны тоткан һәм куенына почта күгәрченен тыккан килеш килеп керде. Александрдан башка бөтен гаилә әгъзалары да өйдә иде.

Аңа ишек ачкан Роза апа белән бераз сөйләшеп алганнан соң Шәех Юлия янына кермәкче иде, тик аны ниндидер үз эшләре белән коридорга килеп чыккан, эш халаты кесәсеннән сабы өскә караган чүкеч күренеп торган Кыям абый туктатты.

— Ә-ә, Шәех! Тәмам югалдың син, кермисең дә!—Ул кунакчыл рәвештә үз бүлмәсенең ишеген ачып җибәрде.—Ә мин синең калаеңны чокыйм.

Шәех бүлмәгә үтте һәм яз көне танышкан чакта рәссамга үзе биргән һәм монда алып килергә дә үзе булышкан бер табак кызыл калайны күреп алды. Анда, кулына чыбык тоттырып, кабарынкы итеп ясалган малай

сурәтләнгән иде. Ә аның баш өстендә—күгәрченнәр. Әлегә берсе канатсыз килеш иде.

—Аңладыңмы хәзер теге калайның нигә кирәк булганын?

—Аңладым, Кыям абый,—диде Шәех.

Кыям абый үзенең әсәренә карап алганнан соң, әле төгәлләнмәгән үз эшләрен читтән сынап, үлчәп караган рәссамнар шикелле үк, күзен бераз кыса төште.

—Чүкеп ясалган...—диде Шәех.—Тик сезнең күгәрчен хуҗасының чыбыгы кыскарак шикелле. Аннары кая куясыз инде аны, ясап бетергәч?

—И-и! Бу картина, бу тимер картина—малай белән күгәрчен генә түгел. Минем бу картинам тынычлыкка тантаналы җыр булачак. Мәдхия! Беләсеңме, Җиңү көненә, киләсе язга тикле Бөтенсоюз күләмендә художество конкурсы игълан ителгән. Һәм аның мәгънәле үзенчәлеге шунда: анда үзешчәннәр дә катнаша ала.

—Барып чыгармы икән соң?—дип сорады Шәех.

—Ничек барып чыкмасын! Ничек кенә барып чыгар әле! Минем күңелдә шундый композиция төсмерләнә, шундый... Ләкин вакытыннан алда әйтмим әле. Тора-бара үзең күрерсең. Күрсәтербез әле без ул төрле профессионал һөнәриләргә! Әйе, Шәех, ә бездә бәла.—Кыям абыйның көр тавышы кинәт әкренәеп калды, йөзе сүрелә төште, инде ул сөйләмәде, ә борынын тартып, трагик рәвештә мыгырданды гына:—Безнең Александр өйдән чыгып китте бит. Өйләнергә уйлаган. Әтисе каршы: янәсе, сиңа ничә яшь? Син үз акылыңдамы? Уйларга да кыйма!.. Һәм шуннан соң ул чыгып китте.

—Кая?!—дип сорады Шәех, гаҗәпләнеп.

—Аңа. Үзенең сөяркәсе янына. Ул хатын-кыз аннан ун яшькә олырак. Аның инде Саша буендагы кызы бар.

—Ул утыз яшь тулгач кына һәм әле хәзер балалар бакчасына йөрүче скрипкачы кызга өйләнергә җыенган иде бит.

— Булса соң, ул ни әйтмәс! Гашыйк булган, имеш... Менә сиңа ушамараха!—бөтен планнар.

—Ә ул хатын кем соң?

—Һөнәре буенча револьверщица, милләте буенча—руслашкан татар кызы. Рая исемле. Чынында Рәисәдер, мөгаен, яисә—Раилә, Рәфисә... Сихерләде. «Яратам мин аны»,—ди һәм—вәссәлам! Әтисе белән көлен күккә очырганчы ачуланыштылар. Александр фатирны бүлүне таләп итә. «Минем үз бүлмәм бар,—ди,— нишләп мин аны сезнең фатирдан аерып ала алмыйм?» Ә әтисе аңа: «Менә кайчан үзең фатир алырсың, ул чагында үзеңә кирәк кадәр алыштыр да һәм алмаштыр да»,—ди. «Ул чагында мин чыгып китәм»,—диде Саша. Ә әтисе: «Дүрт ягың кыйбла!» Җыенды да чыгып китте әнә. Җыенды, дим. Хәер, ул үзе белән берни дә алмады. Китаплар-дәреслекләр, футболкалар, аһ, әйе, әлбәттә, үзенең открыткалар коллекциясен алып китте. Белмим, болар барысы да ни белән бетәр инде? Әнисе кайгыра, Юлия суга төшкән кеше шикелле йөри, ә әтисе тыныч. Аңа хәтта яхшырак та булып калды бугай әле. Өйдә тавыш азрак. Саша музыка тыңларга ярата иде бит.

Ишек шыгырдап куйды.

—Юлия!—дип пышылдады Кыям абый.—Мин сиңа Саша турында берни дә әйтмәдем дип сана...

—Кемдер минем транзисторны алып килгән, диләр бугай?—Юлия болай бөтенләй ак диярлек, тик чәче кебек үк бодай төсмерендәге кофтадан һәм муенына бәйләнгән, күзләре сыман зәңгәр төстәге яулыктан иде.—Төзәттеңмени, мастер-ломастер?

Моңа җавап итеп, Шәех төймәсенә басты да, «Альпинист» җырлап җибәрде:

—Кешеләр үлә металл өчен... Мета-а-алл өч-чен...

—Искиткеч! Ә куенында нәрсә ул?—Кыз әнисе дә, бабасы да сизмәгәнне сизеп алды.

Шәех саклык белән генә ак карга охшаш, бернинди табы да булмаган күгәрченне куеныннан чыгарды.

—Ышанычлының сөеклесе. Хәтерлисезме, сөйләгән идем? Бөгелмәдән кире очып кайткан Ышанычлы. Менә кичә югалды ул. Карап җиткермәдем бугай. Әллә берәр чит төркемгә кушылды инде?.. Ә бәлки, карчыга суккандыр. Белмим. Йөрим менә хәзер, төрле җирдән аның дустын очыртып карыйм, бәлки, юлдан язган гаилә атасын алып кайтыр.

—Әйдә балконнан очыртып карыйк!—дип кулларын җәеп җибәрде Юлия.

—Мин нәкъ шулай дип... Мөмкинме, Кыям абый?

—А-абсолютно!

—Дөрес, мин башта түбәдән очыртып карарга теләгән идем дә, ләкин дүртенче каттан да яхшы булыр. Хәзер анда ике өер очып йөри, карап карарбыз, нишләр икән?

—Ә аны да үзләренә ияртмәсләрме соң?—дип кызыксынды Кыям абый.

—Тиеш түгелләр, мин аның астындагы ике ояны алып куйдым. Шуңа күрә кире кайтыр ул...

Көзге соры һавада ике өер ак күгәрченнәр очып йөри иде. Берсе Шәехнең күгәрчен кетәгеннән ерак түгел генә әйләнә, икенчесе—ипи заводы тирәсендә. Юлия түземсезлек белән әле Шәехкә, әле күгәрченгә карап-карап ала. Шәех, чит өерне күзәтә-күзәтә, нишләптер бик әкрен кыймылдый кебек иде, һәм Юлия аннан:

—Мин җибәреп карасам ярыймы?—дип сорады.

—Мә тот.

Аның ымы буенча Юлия почта күгәрченен кулыннан ычкындырды да, кош, канатлары белән тавыш чыгарып җилпи-җилпи, туп-туры өйләренә таба очып китте. Ул биеккә күтәрелде, бик якын ук килеп, чит өер тирәсеннән әйләнде, ләкин аңа кушылмады. Шәех җинел сулап куйды һәм бу сулышта: «Ышанычлыны кайтара алмадың, ахырында үзең эләгә күрмә!»—дигән авазны ишетергә була шикелле иде. Һәм кинәт ул: «О-о!»—дип кычкырып җибәрде һәм бармагы белән Юлия белән Кыям абый карап торган яктан бөтенләй читкә таба төртеп күрсәтте. Шунда ерак өердән бер ак нокта аерылды да, әкренләп түбәнәя-түбәнәя барып, Шәехнең күгәрчен кетәгенә таба очып китте. Ул кош турында әле төгәл берни дә әйтеп булмый иде, әмма Шәех бик ышанган хәлдә:

—Ул! Ышанычлы бу!—диде.—Чаптым мин.

—Мин дә синең белән,—диде Юлия.

—Мин дә, Шәех, туктагыз,— дип тиз-тиз әйтеп куйды Кыям абый.— Нинди эшләр, нинди эшләр! Әй, Шәех, Шәех, әй, Ышанычлы! Тылсымчылар! Ә монысы, агы... Сихерче! Әй, әй...

Ләкин Шәехкә Пичугиннар фатирын ул теләгәнчә алай тиз генә ташлап чыгып китү насыйп булмады.

Коридорда житез өчәүнең юлын Семён Васильевич Пичугинның йон спорт костюмында булган бөкреле фигурасы кисте.

—Үз юлыгыздагы бөтен нәрсәне җимереп кая җилдерәсез болай, күгәрченкәйләр?—диде ул.—Безнең гаиләдә аның турында бик күп сөйләнелгән һәм әлегә мин танышу бәхетенә ирешмәгән, билгеле булганча,

минем күптәнге дустым Николай Сергеевич Новиковның күршесе булган Шәех шушымыни инде?

Туктарга, бугазга тикле күтәрелеп типкән йөрәкне тыеп, аның сорауларына әдәпле генә итеп җавап бирергә туры килде.

Кыям абый бераз вакыт баскан урынында таптанып торды да, үзенең бүлмәсенә кереп югалды. Бераздан аннан тимерне тимергә суккан тавышлар ишетелә башлады. Бөрмәле юбкасының итәге белән җилфердәп, Юлия дә каядыр юкка чыкты. Профессор, ягымлы гына елмаеп, аңа кабинетына үтәргә тәкъдим итте. Шәехкә буйсынудан башка чара калмады. Әгәр Ышанычлы кайткан икән—ярар, кайткан, әгәр юк икән, аңа серле булып тоелган шәхес—Семён Васильевич белән биш минутлык сөйләшү Ышанычлы белән аның сөяркәсенә берниндидә зыян китермәс.

Профессорның уртасында бик зур язу өстәле торган, чиста, гипстан ясалган берниндидә бизәк тә төшерелмәгән түшәмгә хәтле җиткән киштәләрендә тигез, матур рәтләр белән китаплар тезелгән иркен кабинетында Шәех үзен уңайсыз тойды. Почмактан кунакны бәбәксез күзенең агы белән ниндидер төксе мәрмәр философ күзәтеп тора иде. Тәрәзә өстенләге лак белән капланган ботактан сары ерткыч күзләре белән әллә бөркет, әллә бөкләнгән томшыклы кошлар семьялыгыннан ниндидер бүтән кош карап тора. Бу ерткыч кош биек, идәннән түшәмгә кадәр булган көзгедә дә чагыла һәм шуңа күрә ялгыз түгел шикелле тоела. «Ул да, күгәрчен шикелле үк, кош бит!»—дип уйлап алды Шәех. Стенадагы китаплардан буш булган бердәнбер уемда Пушкин линогравюрасы эленеп тора. Пушкин кулларын күкрәгендә кушырган һәм шулай ук Шәехкә карап баккан иде.

—Рәхим итегез,—дип профессор ишарә белән готик артлы урындыкка күрсәтте.—Оялмагыз, әһә?

Шәех үзен кыен хәлдә калган сыман хис итте. Ул кыска буйлы, бөкрерәк, ләкин көрәшче шикелле нык бәдәнле, үрдәкнекенә охшашлы зур борынлы, карауга ук эләктереп ала торган зәңгәр күзле, башын ак панама кебек каплап алган, бары тик чигәләрен һәм колак артларын гына кара килеш калдырган ак чәчле, һәм авызы тулы, шул панама шикелле үк сөткә охшашлы тешле, елмаюлы бу кешедән ояла иде. Профессорның аның күзенә йә урамда, йә кибеттә күп мәртәбәләр чалынганы булды, ләкин Шәехнең аның белән күзгә-күз карашып менә шушылай икәүдән-икәү генә калганы һәм сөйләшкәне юк иде әле. Икенче төрле әйткәндә, алар рәсми рәвештә таныш түгелләр иде. Хәер, булгалады, Шәех Пичугиннарга килеп йә Юлиядә, йә Кыям абыйда утырган кайбер чакларда Семён Васильевич та өйдә туры килгәли, үзенең кабинетында була торган иде. Ләкин аның бер генә сәгать тә буш чагы булмады һәм ул үз кабинеты ишегеннән беркайчан да чыгып күренмәде. Нәрсәләр бар иде анда, бу биек ак ишек артында? Николай Сергеевич Новиковныкы кебек үк, колачлап булмастай үз галәме микән? Алар, Николай Сергеевич һәм Семён Васильевич, бер-берсен яхшы беләләр иде бугай. Бу Николай Сергеевич сөйләгән хикәятләрдән дә сизелеп-сизелеп киткәли, әмма ул һәрчак нәрсәнедер әйтеп бетерми кебек, еш кына «у-ту-ту» дип үзен-үзе ярты сүздә бүлеп куя, уйга кала һәм сүзне башкага борып җибәрә иде.

Менә, ниһаять, аның алдында ул серле ишек ачылды.

Профессорның китаплары Николай Сергеевичныкыннан һич тә ким түгел, бәлки, күбрәктер дә әле.

Шәех кабинетны күзәтә һәм чагыштыра торды. Күренеп тора, профессорда тәртип бик яхшы куелган: һәр китап бер-берсенә ятыштырып тезелгән, киштәләрдә тузанның әсәре дә юк, өстәлдә язу приборлары һәм пыялалар ялтырап тора, кабинет почмагындагы философ бюсты астындагы

махсус аскуймада төрле зурлыктагы ике пар гантельләр ята. Әлбәттә, Николай Сергеевич өендә дә тәртип моннан ким түгел, тик анда бар нәрсә дә үзенчәрәк оештырылган. Гади генә әйткәндә, бәлки, күзләрне бик иркәли торган сыман булмагандыр гына. Шәех үзенең чагыштыруына башка, чит күзлектән карап бәя бирергә тырышты. Семён Васильевич белән Николай Сергеевичларның бүлмә-кабинетларында уртаклык күп һәм барыннан да бигрәк аларда—китаплар, китаплар, китаплар. Ләкин болар барыбер ике төрле ике планета шикелле иде. Монда, профессор планетасында, аңа ничектер салкынчарак шикелле тоелды.

Яшь кунакның беренче, кеше интеллектының бу оазисына әлегүче кешеләрдә һичшиксез туа торган кызыксынуы басылганын бераз көткәннән соң, Семён Васильевич тәүге очрашу өчен гадәти булган берничә сорау биреп алды: яшь кешегә ничә яшь? Алмалыда күптән яшиме? һәм шуның ише башка сораулар.

Шәех аларга җавап биреп торды һәм профессорда үз җавапларының алай зур кызыксыну уятмавын сизеп алды.

Ләкин менә профессор, сүз уңаенда гына дигәндәй, Николай Сергеевич турында сораштырды Һәм шунда аның зәңгәр күзләре ниндидер очкын белән кабынып китте. Әмма ул элеккеге дусты турындагы яңалыкларга түгел, ниндидер башка нәрсәгә мохтаҗ иде шикелле тоелды. Нәрсәгә? Ул бит үз сорауларының барысына да диярлек үзе үк җавапларын да бирә барды.

—Шулай берүзе яшиме һаман? Язмыш... Һәм үзенчә бәхетле дә ул. Башка төрле яшәү рәвешенә мәҗбүр итеп, ул теләмәгән якка борып карагыз аны—файдасыз. Кем әйтмешли, кайда утырдың, шунда төшәрсең дә. Карап торырга гына тыңлаучан: «уту-ту» да «уту-ту...»—Профессор күн кәнәфигә килеп утырды һәм бераз биегәеп киткәндәй булды, кызыл тимгелле авыр йодрыкларын язу өстәленең пыяласы өстенә куйды.—Ялгызлыгын ничек җиңә ул? Яшь, сау-сәламәт елларда бер эш, ә хәзер? Башкаларга бәйле икәнлегенең бөтен ачы барлыгын сизү өчен кешегә томау төшү дә җитә. Ә картлыкка таба барганда ярдәмчесезлек Алланың һәр бирмеш көнендә геометрик прогрессия буенча арта бара. Син, күгәрченем, аңа еш керәсеңме? Беләм—еш керәсең. Йә, ничек ул, саулыгы ничек? Ул бит, мин хәтерлим әле, яшь чагында бик еш авырый торган иде. Бер тапкыр ел буе урын-җирдә аунады. Зәгыйфь, зәгыйфь иде безнең Николай, әйе... Армиягә дә алмадылар аны. Колга шикелле ябык булды, менә-менә җил сындырыр сыман иде. Ә аннары кинәт ныгып китте, хәтта иңбашлары түгәрәкләнде. Илленче еллар уртасында иде бу, юк, икенче яртысында, фәнни эшләре тауга таба менә башлагач бугай. Мәскәүнең җитди бер астрономик басмасында берьюлы өч мәкаләсен бирделәр. Академик басмада!.. Булыштылар аңа ул чакта, әйе... Ул чакта аңа кинәт барысы да, гәрчә аның фәнни дәрәҗәсе, исеме, вазифасы булмаса да, ирек куя бирә башладылар... Менә шул вакытта безнең Николай, халыкта әйтелгәнчә, симереп китте. Мин бит, күгәрченем, халык арасыннан чыккан кеше. Минем әти паровоз машинисты булып эшләгән. Синең кайчан да булса паровозда утырып йөргәнең бармы? Юк? Э-э, нинди рәхәтлек анда! Бигрәк тә кышын. Мич авызын ачып җибәрәсең дә күмер ташлыйсың, шунда ут әкияти кош сыман үрсәләнә башлый. Кызу! Ә тышка, салкынга башны чыгарсаң, сине каршы җил өтеп ала, теләмәсәң дә борылып состав койрыгына карыйсың, ә анда бары тик тәгәрмәчләр астыннан кар тузаннары гына оча. Кычкырткычка тотынасың да—ту-ту-ту! Машинист ул музыкант та булырга тиеш, ишетү сәләте дә яхшы булырга тиеш аның. Минем әти баянда уйный иде. Башкача машинист—бетте диген, корт ашаган урынны ишетми-тоймыйча калдынмы, поезд җәһәннәмгә очты дигән сүз. Үзе тулы бер фән ул! Машинист булып туалар. Интеллигентлар шикелле,

өченче буында туалар. Ничек таң калып тынлап тора идем мин балачакта сүз музыкасын: вестингауз, контрпар, компаунд...—Семён Васильевич тынып калды, аннары чәнчә бармагының тырнагы белән кашын кашып алды. Аның пөхтә итеп очланган озын тырнаклары калдырылган, бер генә секунд та тик тормаган чәнчә бармаклары йә кәнәфи култыгына суккалыйлар, йә бизәп ясалган язу өстәленең уемнарына, ярыкларына керәләр, йә, менә хәзерге шикелле, аның калын кашын аралыйлар иде.

—Күгәрченем, аның янына Татьяна Георгиевна кермәдеме?

—Хәтерләмим андыйны,—дип җавап бирде Шәех.

—Родимцева... Татьяна Георгиевна...

—Хәтерләмим—димәк, мин барында кермәгән.

—Вакыт-вакыткайлар...— дип көрсенеп куйды Семён Васильевич.— Тәгәри, һич тә туктамый ул. Әле күптән түгел генә ул мина—Николай гына, ә мин аның өчен Сёма гына идем. Һәм безнең тагын Танябыз бар иде. Танечка Родимцева... Ә хәзер—юк. Николай да юк, Танечка да юк, бары тик Николай Сергеевич белән Татьяна Георгиевна гына бар, тик болар бөтенләй башкалар инде, башкалар... Күптән түгел генә «Пассаж» янында Татьяна Георгиевнаны очраттым. Танып та булмый иде инде аны—тәмам карчыкка әверелгән.

—Сез, кереп чыкмадымы, дип аның турында сорадыгызмыни?

—Әйе, шуның турында... Әгәр дә ул мине танымаган икән, ә мин... мин... мин үзем аның күз алдында ничек булып күрендем икән соң?—Авыр хәтер йөкләре басымы астында профессор беразга тагын сүзсез калды.—Ул аның янында күренеп йөрмәгән булып чыга алайса...— диде ул аннары, йөзендә бернинди үзгәреш тә күрсәтмичә.

—Сез дә кереп чыкмыйсыз бит ана, Семён Васильевич,—диде Шәех,— гәрчә бер үк урамда яшәсәгез дә. Мин аңлыйм, тормышта төрлесе булырга мөмкин... Ләкин Николай Сергеевич сезне һәрвакыт зур хөрмәт белән искә ала. Ул сезне югары бәяли.

—Ә Татьяна Георгиевна турында бер дә искә алганы булмадымы?

—Бер дә.

—Шулай, Николай Сергеевич мине югары бәяли, дисенме?

—Әйе... Ләкин сезнең турыда сөйләгәндә ул нәрсәнедер әйтеп бетерми сыман. Миңа шулай тоела...

— Билгеләп үтәргә рөхсәт ит: син, Шәех, үзеңнең яшеңдәгедән күпкә олырак һәм үтә күрүчән кеше икән.—Семён Васильевич Шәехкә беренче тапкыр, күгәрченем, дип түгел, исеме белән дәште.—Шулай килеп чыга, сине безнең гаиләдә юкка гына хөрмәт итмиләр икән шул. Һәм син әле,— менә сиңа кирәк булса!— Николай Сергеевичның якын, яхшы дусты да икәнсең. Ә бит ул кешеләр белән аралашу мәсьәләсендә авыр кеше, аның белән үзара бәйләнешкә керү—марсианин белән контактка керү белән бер. Хәтта сенсация!

—Киресенчә, ул гади һәм ачык...

—Син менә нәрсә, хөрмәтле Шәех, бүлдерүем өчен гафу ит, син аңлый торган кеше, ә мин эшкә якынрак килергә телим... Менә нәрсә: син аңа минем сәламемне тапшырсаң иде, тик алай туп-турыдан, маңгайга бәреп түгел, ә әдәпле итеп кенә әйт. Аңа минем дә аны бик тә һәм үзенә бертөрле аерым хөрмәт итүемне җиткер. Шунда сорап та куй: әгәр дә тиздән аның янына кереп чыксам, ул каршы килмәсме икән?

—Ниткән каршы килү ди!—дип Шәех урыныннан сикереп үк торды.

—Ашыкма, күгәрченем,—дип, профессор аны кул ишарәсе белән кире урынына утыртты.—Мин Николай Сергеевичны синнән ким белмим, аның холкын беләм, ул сугыш чукмары булган исерекбашны да ишек артына

куып чыгарырга ояла, өстәвенә әле бурычка түгел, болай гына, кайтарып бирүен таләп итмичә генә акча да бирер. Ләкин эш анда түгел.—Үз фикерен төгәлрәк житкерү өчен сүзләр сайлый-сайлый, профессор уйланып калды, хәтта чәнчә бармагын йөртүдән дә туктады. Аннары ике кул чугынын барлык сөякләре белән кәнәфинең култыксаларына суккалап алды.—Эш шунда, аның бу ризалыгы көчәнеп, үзен ирексезләп, сүз белән генә дә түгел, ә жаны-күңеле белән дә бирелергә тиеш. Бөтен күңеле белән дияргә кирәк. Сүз белән ул бер дә шикләнмичә кире какмас анысы, ә менә... Әмма, син мине аңлагансыңдыр, дип беләм. Син сизгер кеше, жебенә хәтле аңлатып тору артык бугай... Безнең бу игелекле очрашу минем берүзем өчен генә әһәмиятле түгел.

Алар бер-берсе янында тагын бераз утырдылар әле. Семён Васильевич—үзенең әйләнә торган күн кәнәфиендә, Шәех—язу өстәленең башындагы готик бизәлешле биек артлы каты урындыкта. Профессор, барыбер тыелып кала алмыйча, үзенең үтенечен тагын яңадан бер кат кабатларга жыенган иде дә, ләкин коридорда ниндидер ыгы-зыгы, шау-шу тавышлары ишетелде, кемдер килде бугай. Һәм шул килүче белән берьюлы берничә кеше башта әкрен генә, аннары каты итеп сөйләшә башлады.

—Бу —Саша...—диде профессор әкрен генә, хәтта авызын ачмыйча диярлек. Аннары ул кәнәфиеннән сикереп торды да кабинетыннан тышка ташланды.

Үзенә генә чит кабинетта калырга уңайсыз иде, ул инде монда болай да бик озак утырды. Аны анда, күгәрчен кетәгендә, күптән сөйгәне белән Ышанычлы көтә-көтә көтек булганнардыр, мөгаен. Шәех профессор артыннан ук коридорга чыкты.

## Гаиләдәге орыш-талаш

Пичугиннар гаиләсе Александр бүлмәсенең ачык ишеге янында жыелган һәм барысы да берьюлы сөйли иде. Ишеккә барыннан да бигрәк Роза апа якынрак тора, ул, бала шикелле, йодрыгы белән яшьләрдән кызарган күзен сөртә һәм сулкылдап елый иде:

—Үстердем, үстердем, тырыштым, үземне кызганмадым, ә син? Син бит мине беркайчан да кайгы китермәм дип ышандырдың... бары тик шатлыклар гына...—Ул ишеккә карады.—Ничек шулай инде бу, ә, улым?

—Берни аңламыйм, берни аңламыйм!—дип коридор буенча йөренде Кыям абый, куллары белән чигәләрен тотып.

—Минем зәңгәр күлмәгем кайда?—дип ачу белән сорады Александр бүлмә түреннән.

—Әле юганнан соң үтүкләнмәгән ул, улым,—дип жавап бирде Роза апа, кулын битеннән алып.—Хәзер, бер генә минут көтеп тор.—Аның тавышында өмет яңгырады, үтүкләнмәгән күлмәк аңа аның ярдәме белән малаен өйдә тотып калырга ярдәм итәрдәй салам шикелле булып тоелды. Чөнки ул—аның күкрәгендә ике кесәсе булган һәм погонлы яраткан күлмәге иде бит. Ансыз ничек китсен ул? Ул йөгереп кенә үз бүлмәсенә барып килде дә, инде зәңгәр күлмәкне ниндидер талисман сыман күкрәгенә кысып, малаен акылга килергә үгетләргә тотынды.—Син яшь әле, Саша, сиңа әле башта институтны тәмамларга кирәк, ә өйләнергә өлгерерсен әле. Безнең бу жәннәттәй тормышыбызны сагынырсың әле син... Их, әнинең канаты астында яшәргә иде, диярсең, ләкин соң булыр... Без мәңгелек түгел бит, китеп барырбыз, әниең, бабаң, әтиең барда кадерләрен бел!..

—Әтиенме?—дип бүлмәсеннән атылып чыкты кече Пичугин.—Син моны әти дип атыйсыңмы?—Ул, учын өскә әйләндергән килеш кулын

сузып, буш урынга күрсәткән шикелле, Семён Васильевичка төртеп күрсәтте.

Моннан бер секунд кына элек Семен Васильевич кабинетыннан коридорга чыккан Профессор исә, ярсуыннан үз-үзен белештермичә:

—Чыгып кит! Хәзер үк чыгып кит минем өемнән, корчаңгы!—дип аяк тибә-тибә акырды һәм кулы белән шундый ук, ләкин төгәлрәк һәм арттан төртеп куярдай ишарә ясады. Ул коридор ахырындагы, бигенен җаен таба алмыйча, янында Шәех маташкан ишеккә таба төртеп күрсәтте. Шәех исә, көтелмәгән бу гаилә давылын ишетмәс-күрмәс өчен, бу минутта җир тишегенә төшеп китәргә әзер иде, ләкин, үч иткәндәй, ишек биге һаман бирешмәде. Кулына чемодан тоткан килеш атылып чыккан Пичугин бер селтәнүдә ишекне каерып ачты да, алар икесе дә фатирдан атылып барып төштеләр.

—Ник шайтаныма олакмыйлар!—диде Александр, ачу белән. Ул баскыч буенча беренче булып йөгереп төшеп китте һәм шундук аста шартлап ябылган ишекнең яңгыраулы кайтавазы бөтен подъезд буенча чарлакка кадәр таралды.

Шәех уйга калып, адымын әкренәйтте. Юлия белән Кыям абыйны көтәргәме икән, әллә көтеп тормаскамы? Чөнки алар бергә Ышанычлыны барып карамакчылар иде бит. «Кирәкми, мөгаен,—дип уйлады ул аннары,—хәзер аларда күгәрчен кайгысы түгел бугай».

Аның чыгып китүен Пичугиннар сизми дә калды, чөнки ул вакытта алар бары тик туган йортын ташлап китүче, кулына чемодан тоткан Александрны гына күрәләр иде шикелле.

Роза апа, китеп баручы малаена таба тавышсыз-тынсыз гына кулын сузып, аны туктатырга, тоткарларга, кире кайтарырга теләп, аның артыннан атларга талпынган иде дә, ләкин Семён Васильевич аның юлына аркылы басты.

—Аяк атлыйсы булма!—диде ул хатынына, нык итеп.

Роза апа—чын татар хатыны—ирен тыңламыйча булдыра алмый иде. Ул ана йөрәге кушканча эшли алмады, борынын малаенының кесәле һәм погонлы күлмәгенә төртте дә елап җибәрде.

—Үстерден сөрхәнтәйне,—дип өстәде Семен Васильевич,—менә хәзер шуның җимешен таты инде.—Ул тәрбия өлкәсенә кагылышлы тагын нәрсәдер әйтмәкче иде, тик шул вакытта гына кирәкле афоризм башына килмәде, аннары көтмәгәндә генә башларына төшкән бу хәлгә ясалган кыска, катгый нәтиҗәне артык сыекларга да кирәк дип тапмады. Әлбәттә, барыбер кире әйләнеп кайтачак ул, чөнки бер студент стипендиясенә генә озак яши алмас. Әлбәттә, аның хәлендә: «Кәләше Раечка үзенең сөяркәсе һәм кияве итеп кемнең башын—гади кияүнекен генә түгел, ә күренекле профессор малаенықын!— акылдан яздырырга кирәклеген бик яхшы белгән!»—дип тә өстәргә мөмкин иде. Әмма ул чагында сүзләрдән генә торган бу өстәмә, үзенең күнел ярсуын басасы, нервыланып алган хатынын бераз тынычландырасы урынга, күбрәк ниндидер үз ялгышларын акларга теләүгә охшап калган булыр иде. Һәм ул, шуның белән үз миссиясен тәмамланганга санап, үзенә кирәргә, ниндидер аңлатып булмаган гарьлекне сүзсез һәм ирләрчә үзе белән алып китәргә теләп, бүлмәсенә таба борылды. Ходай шаһит, ул авызын да ачып өлгермәде, малаена бердәнбер дөрес сүзләр белән, юк, ташлама ясарга түгел, күп кенә йокысыз төннәр аша чыгарылган хаклык белән килгән эти кеше шундук үзенең туган малаеннан «янагына» алды. Ул керергә дип борылган гына иде, ләкин әле бу сюжетлы төендә і өстенә (профессорның яраткан тәгъбирләренең берсе) бар нокталар да куелып бетмәгән булып чыкты. Кинәт моңарчы дәшми генә торган Юлия

тавыш бирде. Һәм бу инде яңакка сугу гына түгел, ә йөрәгенә үк кадау иде.

—Саша бернинди дә сәрхәнтәй түгел!—дип кычкырды ул.—Сез, әти (кинәт ул аны «сез» дип атады), бер нәрсәдә генә хаклы: аны әни берүзе һәм бабай үстерде, сездән башка... Һәм мине дә алар үстерде, ә сезнең һаман вакытыгыз булмады, чөнки сез гомерегез буе үзегезне генә яраттыгыз һәм, күпләр уйлаганча, фән белән түгел, гел үзегез белән генә, фәндә үз шәхесегезне раслау белән генә шөгыльләндегез.

Семён Васильевич басып торган урынында багана шикелле катып калды.

—Сез бер мәртәбә профессор дустыгыз алдында Сашаның мәктәпне тәмамлаганда алган алтын медале, математик олимпиадалардагы уңышлары, аның университеттагы беренче уңышлы адымнары белән мактанган идегез. Кем әле ул? Мин онытканмын, сез хәтерлисездер. Болар сезнең хезмәт түгел бит, ә әнинеке. Безнең белән көннәр һәм төннәр буе ул һәм бабай шөгыльләнеп килде бит һәм хәзер дә алар шөгыльләнәләр. Ә сез... ә сез... ә мин балачакта үземне бер мәртәбә дә тезегезгә алганыгызны яисә безнең эшләр белән кызыксынганыгызны хәтерләмим. Сез йоклар алдыннан бер генә әкият булса да укыдыгызмы безгә? Бөтен гомерегезне кабинетыгызда утырып үткәрдегез. Безнең өйдә һаман:«Әкрен, балалар, әтиегез эшли, әкрен, балалар, әтиегез эшли, әкрен, әкрен...» Ә кайда соң ул әти кеше, кем ул, нинди тереклек иясе? Нининдер серле гудвин, зөбәрҗәт шәһәрнең тылсымчысымы? Ләкин теләсә нинди тылсымлы күзлекләр дә гомерлек түгел.

—Ни сөйлисең син, кызым!?—диде Роза апа, коты очып.—Бу бит синең әтиең, туйдыручың, ул бит безнең өчен башын да күтәрмичә эшли, ул безне ярата...

—Ул беркемне дә яратмый, әни, мине дә, Сашаны да, хәтта сине дә!.. Ул—чит кеше. Аның безнең белән булуы безнең теләсә нинди бәйрәмебезне аксым һәм углеводларны сагышлы рәвештә кабат-кабат чәйнәүгә кайтарып калдыра. Кайдан килә бу ваемсылык? Без фарфор статуэткалар түгел ләбаса, без—күз алдыгызга китерегез!—тереләр. Менә, бер генә мәртәбә булса да тотып карагыз, ышанырсыз...

—Әти белән алай сөйләшмиләр,—дип Роза апа кызын тынычландырырга тырышты. Ләкин Юлия үзен-үзе белештерми иде инде.

—Ана Сашаның язмышы бөтенләй барыбер, ул аны бөтенләй кызыксындырмый. Сорагыз аннан, үзенең малае белән яхшы итеп, күңел биреп сөйләшкәне булдымы? Кешеләрчә кызыксынып кына булса да, аның Раечкасын күрдеме ул, карадымы аңа? Бәлки, монда малаеның чын мәхәббәттер, бәлки, аның өчен чыннан да шул Раечкадан башка якын кеше дөньяда юктыр, бәлки, ул аның һәркем хыяллана торган бердәнбередер? Юк, юк, әтикәй, сез беркемне дә яратмадыгыз һәм яратмыйсыз. Мин дә яратмыйм сезне. Мин сездән куркам, балачактан бирле курка идем, хәзер дә куркам. Кур-р-кам!..

Юлия күкрәге белән көзән җыергандай тирән итеп сулап куйды, башын селкеп, үзен кая куярга белмәгән сыман, тирә-ягына каранып алды. Аннары бабасына ташланды, балачактан ук шатлыкта да, хәсрәттә дә күнегелгән гадәте буенча, аның күкрәгенә сыенды.

Оныкасының менә шушылай шартлап киткәнчегә кадәр коридор буенча мингерәү сыман йөренгән, ә аның үз әтисен каты итеп орышкан чакта тартышу, авыру дәрәҗәсенә җитәрдәй хәлдә булган Кыям абый, Юлиянең кагылуыннан соң кинәт үзендә нининдер үҗәтлек, бетми торган көч, бу дөньяда үзенең әһәмиятлелеген һәм кирәкле кеше икәнен сизеп алды.

Ул үзенең тормышында иң кадерле булган бу затны кулы белән сыйпап куйды, бер-бер артлы йомшак, тыныч сүзләр мыгырданды һәм, мизгелне тотып, оныкасының күз яшьләренә каршы сыналган дәвасын кулланды. Яшь тамчыларыннан бөтенләй читт булган хәлгә гаҗәпләнеп:

—Туктале, Юлия, ә безнең Шәех кайда соң әле, мин аны ишек янында күргән идем түгелме соң?—дип куйды.

Һәм шунда сискәнеп киткән Юлия, борынын тартып:

—Чыннан да, кайда ул?—дип башын күтәрде.

—Мин дә кайда дип сорыйм ич. Әйдә, әйдә куып житәбез аны!

«Барысы да ничек тиз алмашына аларның!»—дип уйлап алды Семён Васильевич, ашыгып китеп барган каенатасы белән кызы артыннан карап калып. Кызының театраль монологы барышында ул бер сүз дә чыгармады, гаҗәпләнүдән тәмам телсез калды, чөнки бу бөтенләй көтелмәгән, искә дә килмәгән хәл иде. «Юк, театраль түгел»,—дип төзәтте үзен Семён Васильевич һәм, кыяфәте турында онытып, бөкреләнеп калды.

—Тынычлан, әтисе,—дигән тавышын ишетте ул хатынының,—синең йөрәк өянәгең кузгалырга мөмкин.—Ул аны, икесе генә ялгыз калган чакларда, шулай, әтисе дип йөртә иде. Иренә ошый иде бу, ә менә хәзер нигәдер бу сүз ана бик ошап житмәде, ләкин ул ризасызлык белдермәде, ә бая хатыны елаганда уйлаган уен гына әйтте:

—Борчылма. Ярый, ярый...—Инде күп еллар болай булганы юк иде, ул хатынының беленнән кочаклап алды һәм аны төп бүлмәсенә, ягъни кухняга тикле озатып куйды.—Чәй кайнат әле, зинһар, катырак итеп. Мин әлегә үземә керәм... Чакырырсың.

«Нәрсә килеп чыкты соң әле бүген?—дип уйлады Семён Васильевич, язу өстәле янында әллә нинди формулалар язылган нинндидер кәгазьләрен актара-актара.—Малай да, кыз да, үзара килешмичә, мәгънәсе буенча бер үк нәрсәне әйтеп бирделәр. Юк, юк, Юлиянең фаш иткеч өянәге ясалма түгел, бу чын мәгънәсендә хакыйкатьне ачып биргән яңалык, күңелдә җыелып килгән һәм менә, ниһаять, ургылып-ташып чыккан нинндидер башка нәрсә. Ләкин һәр хакыйкать дөреслек дигән сүзме соң? Нинди куркыныч сүзләр ташлады ул бүген әтисенә! «Сез, әти, беркемне дә яратмадыгыз һәм яратмыйсыз!»янәсе. Башка кешенең күңелендәниләр барын, житмәсә, моны әле үзе дә белмәгәндә, сиңа кайдан белергә ди, кызым? Ә бәлки ул читтән күренәрәк төшәдер, ә? Бәлки, кызы аның нәкъ авырткан җиренә кагылгандыр, шуңа күрә җавап та бирә алмагандыр, менә хәзер йөрәгем дә шуңа көйдерәдер?».

Семён Васильевич өстәлдән валидол кабын алды да, аннан бер таблетканы селкеп төшерде һәм тел астына салды. Валидол ана булыша иде.

*Дәвамы киләсе саннарда*



Клара
Булатова

# ФАНИ ДӨНЬЯ—МИҢА ҮЗЕ ҖӘННӘТ

## Мин рәхмәтле

**Шагыйрьләрнең туган көне була,
Үлгән көне булмый бит аның.
Шагыйрь яши, тик бер генә кеше
Укыса да аның китабын.**

**Тик бер шигырь бер күңелгә керсә,
Шагыйрь өчен бу аз түгелдер.
Әгәр шигырь җырга әверелсә,
Икеләтә арта ул гомер.**

**Мин рәхмәтле шигъри сүзләремне
Көйгә салган якташларыма;
Мин рәхмәтле алар язган көйне
Җырлар дусларымның барына.**

**Кеше китә, җыры кала,—дибез...
Җыр калдырсак үткән гомердән,
Җиргә, димәк, юкка килмәгәнбез,
Эзсез югалмабыз бу җирдән.**

***

**Мин нишләргә белми изаланам,
Кемлегемне белми интегәм.
Бер карасаң, елап шигырь язам,
Бер карасаң, җырлап җөй тегәм.**

**Мин котылу эзлим гөнаһлардан,
Арынырга телим языктан.
Урын тапмый йөрим оҗмахлардан,
Урын тапмый йөрим тәмуггтан.**

**Мин—шагыйрә. Шулай булгач әле
Ник калырга тиеш оҗмахсыз?**

Гөнаһларым булса ялгыш кына,
Ялгышларым минем гөнаһсыз.

Фани дөнья миңа үзе җәннәт,
Җырлап яшим җирдә шуңа да.
Тәмугына салмасалар бәйләп,
Мин ашыкмыйм оҗмахына да.

* * *

Күрәчәкнең барын күрдек бугай,
Шулай киләм синең каршыңа.
Тәкъдирдә ни язган булса Ходай,
Кичерергә кирәк барсын да.

Үргә күтәрелгән чоры да бар,
Түбән төшкән чак та онытылмый.
Онытылган арзан җыры да бар,
Кыйммәтлесе дә бар—ул тынмый.

Кыйммәтлесе сөзелеп яшәп кала,
Шөкер, җырым кала. Һәм шуңа
Мин ашыкмыйм әле сиңа таба,
Соңлабрак, үлем, каршыла.

Ашыктырма мине!..

***

И очына күңел, очына.
Әллә нинди дөнья бардыр кебек
Ерактагы юллар очында.

Күк капусын хыял ачып куйган,
Күтәрел дә менеп җит кенә!
Әллә ниләр көтеп тора сыман
Күз күрмәгән дөнья читендә.

Еракларда зәңгәр һава төсе...
Хыялларда йөзеп чыгарлык.
"Берни дә юк анда",—дигән төсле
Итәгемнән тоткан чынбарлык.

## Мин аларны җырга гына салам

Мин кайгымны каеннарга бирмим,
Уйларымны әлмим усакка...
Моңнарымны кертмим миләшләргә—
Урман корыр иде ул чакта...

Исәбемне салмыйм имәннәргә,
Серләремне чишмим сиреньгә.
Мин аларны хәтта сиңа ачмыйм,
Гомереңне саклыйм синең дә...

Сыешмаган чакта үз җаныма,
Кысанлыкка түзми алар да...
Мин аларны салам җырга гына,
Җырларымда алар тарала.

***

И Ходаем! Фани дөньяларда
Ил чуалган чакта,
Сыгыныр-сыеныр өчен кеше жаны
Төрле якка тарта.

Кайсынадыр өмет-терәк булган
Диннәр тора сакта.
Кемдер табыш эзли беркатлыдан,
Шарлатаннар арта.

Кемдер тыштан изге битлек кигән,
Эчтән аза гына...
Шайтан туе—гасыр башы белән
Гасыр азагында.

***

Әгәр берәү мине алдый икән—
Алланың каһәре аңа кунсын,
Икенче кат әгәр алдый алса—
Каһәр икебезгә уртак булсын,
Өченче кат алданганда инде—
Каһәр суксын тик үземне-мине.

***

Учактагы ялкын теле кебек,
Җанны айкый хәтер телеп-телеп.
Йөрәк актарыла тибеп-тибеп,
Кинәт-кинәт киселер, өзелер кебек.

Җанны айкый хәтер телеп-телеп,
Әле төшеп китеп, әле менеп.
Аста юшкын, комы, өстә—күбек,
Зилзиләгә тарган дәрья кебек.

Актарыла йөрәк илереп тибеп,
Туктап калыр кебек кинәт төелеп...
Яшәргәме һаман иелеп-бөгелеп,
Китәргәме җирдән?—Булмый белеп.

Кинәт-кинәт киселеп өзелер кебек
Бәргәләнә йөрәк тартылышта.
Бар да үтә, бетә...
Ахыр килеп,
Хәтер генә кала бу тормышта.

***

Асылы шул без кавышкан кичнең:
Гомеребез бергә кушылып ага.
Бер үк кошлар сайрый безнең өчен,
Бер үк фәрештәләр канат кага.

Тигезләтеп яшьләр аермасын,
Кан тибеше бер үлчәүдә бара.
Нинди генә җилләр кагылмасын,—
Бу бергәлек бөтенлектә кала.

**Кемнәр генә селтәнмәсен аңа—**
**Йомшарта алмый хак бәйләнеш көчен.**
**...Бер үк фәрештәләр канат кага,**
**Бер үк кошлар сайрый безнең өчен.**

***

**Соңгы җырым, оя типмәс коштай,**
**Юл адашып йөри һавада—**
**Барып җитә алмый иясенә,**
**Көен тапмый яши һаман да.**

**Мин бит аны күккә чөйгән идем,**
**Иңнәреңә синең кунар дип...**
**Иясе син булсаң, моңлы җырдан**
**Кушма бәхет җыры туар дип.**

**Ә ул сиңа барып җитә алмый,**
**Көен тапмый яши һаман да...**
**Каһәрләнгән, оя типмәс коштай,**
**Юл адашып йөри һавада.**

***

**Әвәләде дөнья кемне таштан,**
**Кемне комнан, кемне балчыктан.**
**Өлешенә тигән көмеше шул—**
**Безнең буын өчен аз чыккан.**

**Булатлары ялтырасы чакта**
**Җир сарысы өстә тирбәлде.**
**Терекөмеш тәгәрәде читкә,**
**Тимерләре иртә күгәрде.**

**Калыкса да, күтәрелә алмый,**
**Югалалар башлар дигәннәр.**
**Дөньяларның кемгә мохтаж чагы?**
**Кайларда соң яңа Пәйгамбәр?**

**Редакциядән:**

*Март аенда танылган шагыйрә, педагог, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, күпсанлы китаплар (шигырь, проза әсәрләре, истәлекләр) һәм популяр җырлар авторы, Сәҗидә Сөләйманова исемендәге премия лауреаты Клара Булатовага 75 яшь тула. Каләмдәшебезне, журналыбызның күптәнге авторын ихлас котлыйбыз; аңа яңа иҗат уңышлары һәм сәламәтлек телибез.*



Нурислам
Хәсәнов

# ЗОЛЫМ[1]

РОМАН

*Сәбәпле дә, сәбәпсез дә
Йөрәгем яна.
Бар өметем синдә, заман,
Ярамны яма.*

Мостай Кәрим

## Төнге манзаралар

Нәфис, манма тиргә батып, яткан җиреннән сикереп торып утырды. Өй эче дөм караңгы иде. Тышта төн, шыксыз җил исә. Тәрәзәләргә бәреп яңгыр ява. Бар җир томаланган. Ул үз-үзенә аптырады: бу ни хәл? Нинди шомлык? Нигә мин яман төшләр күреп бастырылам? Әллә яңа нигезем зәхмәтлеме?.. Әллә мине хакимияткә чакыртып сүгүләре ярамадымы. «Нигә Шәмсиевнең фельетонын газетта бастырдың?» Имеш, Байтирәк елгасына май заводыннан шакшы сөт ага, анда хәзер бакалар да үлеп беткән. Һава тынчу... Сәгать ничә икән?

Ул, вакытны белергә теләп, караватыннан торды, линолеум җәелгән салкынча идәнгә басты, ут кабызырга теләп, стена читенә килде һәм кабызгычны капшап тапты. Ут янмады, бу җил-давылда тагын электр линиясенә зыян килгәндер инде. Трансформаторлары янып чыкмаса ярый, юкса ут тиз генә булмас та... Аннары ул өстәл почмагындагы шырпыны эзләп тапты, аны кабызып стена сәгатенә карады. Төнге унбер иде. Кире караватына килеп ятты. Инде, кәефе кырылгач, йокысы качты. Ут булса, ни дә булса укыр, йә булмаса, газетаның киләсе санына бирәр мәкалә язар иде. Ул нишләргә дә белми аптырап ятты, төшенә кергән мәхшәр күңеленнән китмәде. Нәрсә турында гына уйларга тырышып караса да, күз алдына әлеге Аждаһа килеп басты. Күзен йомды исә, ул һаман да аның каршына сузыла-сузыла килә, зәһәрен чәчә, яный, мыскыллап көлә:

«Ха-ха-ха!.. Син—корбан!.. Районга Тук-ба-ев-лар хуҗа!..»

Ни гаҗәп, ул ачыктан-ачык район башлыгының фамилиясен атый, аның иярченнәренә ишарә ясый. Әгәр Аждаһа сүзләре рас килсә? Юк, юк, мона

[1] Журнал варианты

Нурислам ХӘСӘНОВ (1941) — *прозаик; «Энҗеләр балкышы», «Бәхилләрме йөрәк», «Сагыш», «Хакыйкать хакы» һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

ышанасы килми... Мине районга Тукбаев үзе чакыртып кайтартты ич. Райондашлар буларак, яна районның үз газетасын оештырып җибәрергә дип кодалады. Мин ризалаштым. Гәрчә ул минем яшьлек мәхәббәтемә, Акъяр кызы Иркәгә өйләнсә дә. Бу турыда ул үзе беләме-юкмы, тәгәл генә әйтү кыен. Беләдер, мөгаен. Ә кара, елтыр күзле Иркә очрашуларны онытырга тиеш түгел. Түгел! Ни хикмәттер аның үткен, сизгер күзләре, кояштай елмайган йөзләре әле дә Акъяр болыннарын чәчәкләрдәй яктыртып җибәргәндәй итә, очраган саен карашлары күзләрне камаштырып ала, оныттырмый. Кем белә, бәлки, язмыш мине кибетче Янгул кызы Иркәне күрәсе килүдән шушы Байтирәккә алып кайткандыр... Тукбаев гаярь кеше, сәүдәгәр, Иркә белән Абага районы райпосында эшләгәндә танышкан иде һәм ул аны үзенеке иткән... Бәлки әле, Тукбаев дигәнең, тора-бара, үзгәреп тә куярга мөмкин. Һәм сине, вакыты җиткәч, бер заман әнә шул еландай сагалап торыр-торыр да тотып ашарга да мөмкин. Алдагысын Алла белгән инде...

Нәфистә үзара килешә алмаган «мин» бер-беренә каршы төште. Үз сүзен сүз итәргә теләгән эчке «мин» өстенлек алды: «Юк, син һаман да беркатлы булма. Күрдең, күрдең бит инде, районга кайтып эшли башлау белән Тукбаев сиңа ничек «теш» күрсәтеп алды. Үзеңне беренче тапкыр хуҗалык җитәкчеләре алдында ничек итеп таныштырды? Оныттыңмы әллә? Онытсаң, исеңә төшер, Тукбаевның район хакимиятендәге утырышлар залына килеп керүгә, походка ашыккандай, төптәй кыска юан гәүдәсен алга бөгеп, арлы-бирле йөренде дә, санына ук тоташып торган йомры башын кырт борып, саллы йодрыгын болгый-болгый, китте сөйләп:

—Җә, адәм рәтле итеп эшләргә уйлыйсызмы сез? Әрәмтамаклар!..

Ул кызганнан-кыза барды, әле берсен, әле икенчесен сүгеп ташлады. Кайсы хуҗалыкта сөт кимегән, кемдер итне аз тапшырган, «запчастька» дип сыерын суеп ашаган. Артыгын кыланган, рөхсәтсез үзенә машина сатып алган... Кемдер исә Ындыр совхозында сыерын сугышта һәлак булган каһарманнар истәлегенә салынган һәйкәлгә арканлаган...

Торган саен җен ачулары чыга барган Тукбаев кем нинди «гөнаһ» кылган шуларны кабат исләренә төшереп узды. Тукмактай йодрык һавада туктаусыз уйнап торды. Аның татлыдан-татлы ризык ашап түгәрәкләнеп шомарган ялтыравыклы йөзе тәмам тирләп-пешеп чыкты. Ул кабартмадай кызарган битендәге тир бөртекләрен кул аркасы белән генә сөртте дә идәнгә селекте. Юк, әле сөйләгән кадәре белән генә чикләнәсе итмәде, инде тагын кемгә чират җитәр, кемне утка тотар дип уйлап торган арада, аның акайган күзләре сиңа төбәлеп калды. Син инде үзеңне менә хәзер ул яңа редакторын хуҗалык җитәкчеләре белән таныштырыр дип көткәндә генә аның власть көчен сизгән тукмак йодрыгы һавада аккорд ясап алды да сузылган юан имән бармагы сиңа текәлеп калды.

—Менә бер редактор китте,—диде ул, тәкерек чәчеп,—икенчесе китсә, өченчесен дә табабыз...

Һәм син бу сүзләрдән соң, гарьләнүеңнән, түбәнсетелүдән кая керер җир тапмадың, идән белән бергә убылырга әзер идең. «Мин кем белән, кемнәр янына эшләргә кайттым соң?»—дип үкендең. Шулай да, үзеңә нәтиҗә ясап, түзәргә булдың. Районга бер кайткач, эштән кире китәргә теләмәдең. Сиңа кадәр өч ай гына эшләп калган беренче мөхәррир кебек китеп баруны кулай күрмәдең. Син шул көнне үк район җитәкчелегенә кем килгәнлеген, Тукбаевның эчке культурасы дуңгыз көтүчесе дәрәҗәсеннән дә түбәнлеген яхшы төшендең, дәшмәскә булдың. Шунда беренче тапкыр, хатының Сәрия сүзләренә колак салмыйча, Байтирәк районына кайтуыңа үкенеп тә куйдың.

Әйе, күңелең рәнжеде. Юкса син, шушы район идеологы буларак та, баш түрәң белән кулга-кул тотынып, үзара аңлашып эшләргә, фикердәш булырга тиешле идең. Ул исә синең белән исәпләшүне кирәк санамады. Әллә район газетасы аның өчен бишенче хәсрәт кенә идеме? Бармы газета? Бар. Чыгамы? Чыга. Ничек чыга? Анда аның эше юк. Аңа югары күрсәткечләр мөһим: ит, сөт, иген уңышы мул булсын. Югарыдан шуны сорыйлар, аның эшчәнлеге шуңа бәйле, ул моны яхшы белә. Ни генә булмасын, Тукбаевның кешеләрне болай кимсетеп, түбәнсетеп сөйләшүе сиңа һич тә ошамады...

Әкренләп шул кадәресе дә ачыкланды: бирегә, яңа районга килгән белгечләрнең күбесе тегеннән-моннан куылган кадрлар икән. Ниятләре тизрәк яхшы эшкә урнашу, яңа фатирлар эләктереп калу. Абага райпосы рәислегеннән килгән Тукбаевның сәүдәгәрлеге исә аларга нык таяныч булган.

Яңа җирдә эшең авырдан барды, корреспондентларың барлы-юклы, редакциягә хат-хәбәрләр аз килде, бар язмаларны үзеңә эшкәртәсе, язасы. Берүзең тырышып кайнашкан чак. Редакцияң иске мәктәп бинасының бер ташландык классында урнашкан. Матчалары терәүле, телефон юк. Газета Абага районы типографиясендә басыла. Әзер материалларны шунда илтеп бирәсе. Газета басылгач, аны автобуста алып кайтасы. Шулай машинасыз ике арада йөрисең, кайда кирәк шунда кунасың. Шул интеккән көннәрнең берсендә син район хакимиятенең кабул итү бүлмәсеннән, газета басылып беткәнме-юкмы дип, Абага районы типографиясенә шалтыраттың. Тукбаев бүлмәсенә колхоз рәисләрен җыйган икән. Ул, синең тавышны ишеткәч, «Икенче кат ишекне ябып куегыз әле, редактор ишек төбендә сүз җыеп йөриме әллә?» дип кычкырган. Киңәшмәсенә чакыру юк, ә редакторына карата үз шиген калганнарга да белгертеп куя. Икенче көнне үзеңә барып ирешкән бу сүз дә күңелеңә бәлзәм булып ятмады... Аннары менә шушы җилләр уйнаган өеңә балтасы суга төшкән кешедәй кайттың да аптыраганнан иске газета-журналларны актарырга тотындың. Шулчак газеталар арасыннан моннан ун ел элек басылган «Юану» дигән бер фельетоның килеп чыкты һәм син аны яңабаштан укып чыктың. Анда болай дип язылган иде: «Динар Нәҗипович! Динар Нәҗипович!.. Зинһар өчен, мине дөрес аңлагыз. Бүтән болай эшли алмыйм. Җитәр!.. Заманалар үзгәрде, кемнәр генә фаш ителми. Җиде бабаңны актарып чыгарырлар, балаларың алдында рисвай итәрләр. Кешеләр күзенә күтәрелеп карый алмассың... Юк, юк... Мондый алдашуга бара алмыйм, кирәкми. Хәзер колхозның ике дуңгыз баласын дүрт итеп язып булмый. Сөтне дә һәр сыердан уналтышар килограмм саумыйбыз, моңарчы намусыбызга хилафлык кылдык. Соң, гади акыл белән уйлап карагыз, сыер елга бер-ике ай сөтне ташлатып тора, бер ай бозавы имә. Ел әйләнәсенә исәпләгәндә, каян килсен ул уналтышар килограмм сөт? Инде бүтән рәисләр миннән көләләр. Янәсе, сезнең сыерларыгыз сигезәр имчәкле, безнекеләр дүртле генә, аларын да саварга кеше юк, диләр. Сизәләр бит, күрәләр. Юкса аларда да шул ук нәселле сыерлар. Баш санын киметеп күрсәтмәсәк, уналты түгел, сигезен дә ала алмас идек. Сез моны бик яхшы беләсез, Динар Нәҗипович. Бөртекле культуралар белән дә шулайрак килеп чыкты: безнең шартларда, безнең туфракта гектарыннан иллешәр центнер уңыш каян килсен ул?! Әгәр дә җирләребез дөрес күрсәтелгән булса, тегеләй-болай кайнаштырмасак.

Хәзер теләсә нишләтегез, андый алдашу юлына баса алмыйм, намусым кушмый. Орденнарыгызны (мин аларга лаеклы кеше түгел) кире кайтарып бирәм, алыгыз!..

—Син нәрсә, җүләрләнденме әллә? Акылыңа кил, тинтәк! Орденнарыңны

кемгә бирергә телисең, ә?..

Хатыны Фирүзә тавышын ишеткәч Динар кинәт көзге каршында сөйләшүеннән шып туктап калды, аннары, гафу үтенгәндәй, йомшак диванга барып утырды. Пеләш башын сыпыргалады, маңгай тирләрен сөртте, керфекләрен каккалады, хәл алды. Берничә минуттан, әйтәсен әйттем дигәндәй, тынычланып, хуҗалыкларга алдынгы урыннарны бүлешергә дип, район хакимияте утырышына ашыкты».

Бу фельетон әле бүген дә актуальлеген югалтмаган дип, син аны газетаңа—«Байтирәк хәбәрләре»ндә материалларың җитеп бетмәгәч, бастырасы иттең. Әмма шушы «Юану»ың өчен алда үзеңне ниләр көткәнен белмәдең. Кемнәргәдер «Юану» юаныч кына булып калмаган. Газетаны район авыл хуҗалыгы идарәсе начальнигы Ишкәев иртә таңнан ук Тукбаев өстәленә кертеп салды. Һәм, кызышкан канын басарга тырышып: «Менә редактор безнең турында нәрсәләр язып ята,—дип тезеп китте.— Монда ул миңа ишарә ясаган, мыскыллап, пеләш, фәлән дә фәсмәтән дигән...»

Кеше сүзенә шактый тиз ышанучан Тукбаев монологны юмор әсәре икәнен искәрми җентекләп укып чыкты һәм Ишкәев сүзләре белән килешми булдыра алмады, тукмак йодрыгын өстәлгә сукты.

—Мин аның иманын киям!..

Шул көнне үк район хуҗалык җитәкчеләре «Чулпан» колхозы клубына чираттагы семинар-киңәшмәгә җыелды. Анда син дә чакырылдың. Алда ниләр буласын белми идең әле.

Клуб сәхнәсенә куелган өстәл артына Тукбаев белән Ишкәев утырган. Башын як-якка боргалап залны күзәткән Ишкәевнең пеләше ялтырап-ялтырап китә. Тамак асты, җимен яңагына җыйган әрләннекедәй, салынган. Икенче ияк хасил иткән. Күзләре челт тә мелт килә, гүя ул әйтәсе уйларын тәртипкә салырга кабалана, хуҗаның сүз башлавын көтә.

Менә Тукбаев урыныннан торып басты, алгарак чыгып, залда утыручыларны янә бер күздән кичерде дә саллы кулларын хәрәкәткә китерде.

—Җегетләр!—диде ул.—Бу сүзләрне туктатырга кирәк!.. Имеш, Краснодардан бодай сатып алганнар, имеш, монысын Мари иленнән кайтартканнар... Җегетләр, бу уму не постижимый әйбер. Байтирәк районында егерме сигез мең гектар мәйданда зерновой бар, егерме сигез дә бер йөз. Бөртеклеләрне бер центнерга күтәрер өчен безгә кирәк ике йөз мең тонна икмәк. Ул икмәк бер миллион сум дигән сүз. Шулай бит?..—Залда тынлык, дәшүче юк. Әлегә киңәшмәнең нәрсә турында барачагын беркем абайламый. Җавап булмагач, Тукбаев түгәрәк башын туп чөйгәндәй итеп өскәрәк күтәрде дә сүзен дәвам итте:—Кайда ул минем бер миллион акчам? Юк ул, юк! Кемнеке бар? Кайсыгыз бирде бер миллион акча? Маннур, биргәнең бармы?

Җәелеп, изрәп утырган «Тулпар» колхозы рәисе Маннур көтелмәгән сораудан киң җилкәсен сикертте, янәсе, каян килсен акча. Һәм ул көр тавыш белән җавап кайтарды.

—Бездә андый акча юк...

—Юк шул,—диде Тукбаев кызып китеп һәм дәвам итте:—«Сельхозтехника», бирдеңме?—«Сельхозтехника начальнигы Салих Сәлахиевичтан җавап ишетелмәде, аннары ул сиңа таба төбәлде.—Редактор! Син үзең биргәнең бармы?

Син гаҗәпләнеп җавап кайтардың:

—Бездә акча юк...

—Юк шул. Миндә дә юк. Әгәр дә син болай иттереп кешеләрне мыскыл

итеп ерунду яза башласаң, «приписка» дип, әй-йеме, мы с тобой не сработаемся.

Син аптырап урыныңнан торып бастың да сорадың:

—Рәсим Юлаевич! Ә кем язган «приписка» дип?

—Син язган.

—Нәрсәне?

—Анда «Байтирәк хәбәрләре»ндә Нәфис Хаков дип куелган.

Шуннан соң гына син сүзнең «Юану» монологы турында барганлыгын аңладың.

—Куелса, ул бит әдәби шаян язма, фельетон.

Тукбаев каршы дәшүеңне ошатмады. Бәлки сиңа да, бүтәннәр кебек, дәшми генә баш иеп утыру кирәк булгандыр. Болай сөйләшүең аның канын кыздыра гына төште.

—Юк,—диде ул, аңларга да теләмичә,—анда син алай иттереп язып ятсаң... Монда бар кеше дә дурак түгел, син акыллы булгач та. Миңа менә монда утырганнарның илле проценты—ничә колхоз рәисе, җитәкче генә керде.

—Нәрсә дип?

—Почему болай язалар?—дип.

—Рәсим Юлаевич! Беләсегез килсә, моннан ун ел элек басылып чыккан язма ул.

—Юк, белмим, белергә дә теләмим.

—Бу хакта аерым сөйләшербез.

—Аерым сөйләшмибез. Син монда кончай, син теге, язам дигәч тә... язарга әйбер күп ул. Кайбер кешеләрнең целлофан пакет белән күмер урлаганнарын да язып була, аңа китсә. Этлеккә тәһарәт кирәкми...

Син аңышмыйча, «Кем урлаган? Минме?» дип сорамакчы идең, тыелып калдың. Гайбәтчеләрдән өстен буласың килде. Салкын өеңне җылытырга бервакыт урамга бушаткан өемнән бер-ике брикетны сорап алып кайткан идең, димәк, шуны урлаган дип, Тукбаевка төрләндереп җиткергәннәр. Сиңа суыкта катып үлсәң дә ярый икән. Ә алар урланган дәүләт акчасына, йорт өстенә йорт җиткерсеннәр, хан сарайлары салсыннар. Син берни күрмә. Салкын өеңдә бөкшәеп утыра бир, мактап мәкалә яз, газетаңны матур итеп чыгар... Нинди кабахәтлек!..

Тукбаев моның белән генә туктарга теләмәде, дәвам итте:

—Әйе, син давай тегеләй иттереп, болай төрттереп минем урынбасарларны мыскыл ит, шунда мине дә таптап кит хәзер...

«Урынбасарлар» сүзе чыккач, өстәл артында әрләндәй утырып торучы Динар Ишкәевнең пеләше янә дә ялтырап китте. Тук чырае мөхәррирне сүккәнгә канәгать иде, шул кирәк сиңа дигәндәй, ике катлы ияген селекте. Димәк, ул «Юану» монологындагы колхоз рәисе Динар Нәҗиповичны «мин» дип үзенә кабул иткән. Каракның бүреге яна дигәндәй, монда да шул хәл килеп чыккан. Тик бу минутта Тукбаевны туктатырлык түгел иде.

—Син уйлама,—диде ул, бармак янап,—яза башласам мин дә синнән ким язмыйм. Авторучка миндә дә бар. Мужыт минем почерк синекеннән матурырактыр да әле. Бик акыллы булсаң... Монда бөтен кешегә шик тудырып... Имеш, машиналар бүләк иткән... Биш ел тому назад бер кеше дә машина бүләк итмәде. Машинаны узган ел гына бүләк иттек. Менә быел бик бүләк итәр идек тә, пока мөмкинлек юк. Казанга баргач, тегесенә дә, монысына да кереп тезләнәбез. Акчаны бик бирергә тормыйлар аны. Ә син анда «приписка» дип... Безнең бер әйберне дә яшереп эшләгән юк. Да, быел Краснодардан биш мең тонна бодай сатып алдык, биш мең тонна бодайны сдавать иттек. Бернинди планга кермәде ул. Планга кертә торган

әйбер түгел. Ну, ярты миллион акчасы районга кайтты. Дөрес, әле тагын да кайтачак, яртысын алып кайттым. Миллион акча кесәне тишми, ул мина түгел, районга, колхоз-совхозларга. Аны мондагы бөтен колхоз рәисләре, бухгалтерлары да белә. Берсе дә яшереп эшләнгән эш түгел... «Приписка»... Кайда, сөттәме безнен приписка? Бик приписать итәр идек, юк ул, юк. Юк сөтне приписать итеп булмый аны. Менә сөт минус белән бара...

Тукбаев карлыга төшкән тамагын кырып дәвам итте:

—Жегетләр!—диде.—Монысы информация өчен. Менә шуннан анализ ясагыз. Аны бөтен кеше дә приписать итәр иде. Оренбурга терәлеп торучы районнар бар. Алар аны, дөрестән дә, сатып та алдылар. Ну, аның белән генә урожайны арттырып булмый. Урожайны арттырып була түлке чын хезмәт белән, вакытында агротехник чаралар кулланып, ашлама кертеп, сортлы симәнә чәчеп. Районда урожайны бер центнерга күтәрер өчен алты мен тонна икмәк кирәк. Алты мең тонна икмәк йөз вагон ул. Аны республика гына түгел, бөтен дөнья күрәчәк шулай иттерә башласалар. Аны эшләп булырга мужыт, гектарына бер-ике центнерны.—Ул башын Ишкәевкә таба борды:—Шулай бит, Динар Хамаевич?—Ишкәев сак кыланды, жавап кайтармады.—Без, наоборот, киметтек. Безнең быел, беләсегез килсә, урожай гектарыннан кырык сигез центнер чыкты. Аны кырык бер центнер итеп бирдек. Икенче елга да эшлисе бар. Монда какой приписка? Отписка әле безнең. Анда син, Нәфис абый, язгансың «илле центнер урожай бирә торган жирләр бармыни?» дип. Бар. Житмеш центнер бирә торганнары да бар. Тәжрибә-житештерү хужалыгының солы басуыннан алтмыш жиде центнер чыкты. Балан авылында арпа күпме чыкты әле? Илле алты центнермы?

Сорауга Ишкәев жавап бирде.

—Илле ике.

—Илле ике генә булдымыни?—диде Тукбаев, бераз гажәпкә калып.—Бу приписка түгел, Нәфис абый...

Һаман бер балык башын чәйнәү, исемеңне төрләндерү синең гайрәтеңне чигерде, түзмәден:

—Рәсим Юлаевич! Вакланмыйк, юморны да кабул итә белергә кирәк инде. Анда «приписка» сүзе юк, Байтирәк районы диелмәгән. Аңа китсә, арттырып күрсәтергә тырышу кайда юк ул? Әзмени бездә пеләш колхоз рәисләре. Нәрсәгә үпкәләргә кирәктер, белмим. Юкка баш катырабыз.

Шушы сүзләрдән соң Тукбаев, Динар Ишкәевкә тел-теш тидерәсе килмәүдәнме, күкерт кебек кабынды:

—Ты кончай, безнең газетада ник басылган ул? Кайбер кешеләрне шиккә төшереп, рәнжетеп. Чөнки анда...

Ул әйтәсен әйтеп бетерми Ишкәевкә карап алды. Күп нокталар урынында яшерен сер барын соңыннан гына аңладың. Анда монолог героеның хатыны Ишкәев сөяркәсенең исеме белән туры килгән. Ишкәевкә шул ярамаган. Вөт комедия!

Сүз бүтән юнәлеш алгач, янәшәңдә утырган автотранспорт хужалыгы башлыгы Чумзариф колагыңа иелә төшеп пышылдады:

—Син аңа каршы дәшмә. Жүләрне котыртсаң, дөньяга сыймас, ди. Синең юмор-шуморыңны аңлыймыни мондагы урам командасы. Башыңны жүләргә сал да йөр, ул сәүдәгәр белән сүз көрәштермә. Шамакай бит ул...

Тукбаев, кемне дөмбәсли башларга дигәндәй, иң артта сөйрәлүче «Тулпар» хужалыгы рәисенә төбәлде.

—Маннур! Кая сөтең?

Маннур Мансуров дәшмәскә булды. Эре гәүдәсен чак күтәреп йөргән рәиснең пошмаганлыгы Тукбаевны бүртендерде.

—Нәрсә, үзеңне саваргамы?—диде ул аңа.—Басуыңа керсәң, бодаен

үсмәгән. Кырларың пеләш... Әнә күрше совхозныкына кереп кара, нинди озын, билдән бит.

Маннур дәресен белмәгән мут малайдай торып басты. Тукбаев аңардан сорады.

—Әйдә җавап бир!

—Рәсим Юлаевич, озын әйбәт түгел ул,—диде Маннур, бераз аптырап торгач.—Озынга бер дә кызыкмагыз сез.

—Ник?

—Озын шәп түгел бит ул. Озынны бер дә мактамыйлар аны. Үз тәҗрибәмнән чыгып әйтә алам, әйбәт түгел ул озын.

—Тукта әле, ник әйбәт түгел озын?

—Ни бит, Рәсим Юлаевич, озын... озын сыек була бит ул. Утырып тормый, җил ега бит аны.

—Ярар, син кысканы макта. Ә менә Идрис Юнысович үзе дә озын, аңа карап җил екмый бит үзен.

—Әйтәм бит, Рәсим Юлаевич, озынга кызыкмагыз. Шәп түгел ул озын... Чылануы житсә, Идрис Юнысович та егыла...

—Нахал син. Ул егылса да синең кебек сыерларыннан бер стакан сөт алмый.—Тукбаев җитдилеген югалткан рәискә кабарынды, бүртенде.—Җитте сиңа, сыердай күбенүең җиткән, әле акланып маташасың. Үзең мәче кебек йокларга яратасың. Эшләсәң эшлә, эшләмәсәң, кулыңа чиста кәгазь ал да гаризаңны язып калдыр!..

Аннары гына Маннур телен аркылы тешләде.

Авыр тынлыкны хуҗа үзе бозды.

—Утыр! Һәйкәл түгелсең...—диде һәм ул, сводка кәгазенә күз төшереп, рәисләргә хуҗалыклары исеме белән генә мөрәҗәгать итте.—«Калач»! Бу атнада сөтеңне ундүрт ярым литр бирәсеңме?

Залдан рәис Әюпнең куштан тавышы яңгырады.

—Бирәм...

—«Үзәк!» Ундүрт тә алты йөз граммга күтәрәсеңме?

—Күтәрәм...—диде әвен гәүдәле «Үзәк» сохозы директоры Идрис Юнысович үзен җитди һәм эшлекле тотарга тырышып, калын иреннәрен шапылдатып ялаштырып алды.

Сөт күрсәткечләрен арттыру «эшчәнлеге» шулай дәвам итте. Болар синең өчен еш кабатланып торган гадәти күренеш булса да, алдашу, күз буяулар һаман да ризасызлыгыңны арттыра гына барды... Ул көнне семинар «Чулпан» колхозының бәрәнге подвалында әзерләнгән мәҗлес белән тәмамланды. Син анда җитәкчеләрнең җыеласын белмәдең...

Ул көнне син дә байларча тук кыяфәттә әйдәп атлаган Тукбаев һәм Ишкәевләр артыннан ияргән җитәкче белгечләр өеренә, ялгыз ала каргадай, арткарак калып бардың. Вожаклар үз маршрутларын ялгышмый, Чулпан колхозы фермасының әле бер, әле икенче утарына кереп чыктылар. Сыерлар семинар-киңәшмә уңаеннан бәйрәм кичерде: азыклар мулдан, ферма эчләре чиста, улаклар силос белән тулган, хәтта тегендә-монда ылыс ботакларына кадәр эленгән. Син, төркемнән арткарак калып, газетаңа бер-ике уңай материал алып кайтырга исәпләдең, савымчы кызларга сүз каттың. Алар синең район газетасы мөхәррире икәнеңне белүгә, үз зарларын түгә башладылар:

—И-и, абый, хезмәт хакын күргән юк та юк инде ул еллар буена...—диде сәнәгенә таянган зәңгәр халатлы ханым һәм, төшкән тешен күрсәтүдән оялгандай, башын читкәрәк борды.

—Менә бу улакларга су килми,—дип элеп алды аның янәшәсендә басып торганы һәм, калку түшен киерә-киерә, алгарак чыгып басты.—Ыстырам

бит, сыерлар бер-берсенең сидеген эчәргә мәҗбүр...

—Эчмичә, яларга куярдай тозы да юк бит аның,—диде тимер тешен күрсәтеп һәм авызын ялт кына сыпырып.—Без монда «юк»ка тук инде. Сәнәк дисәң сәнәк, резин итек дисәң, ул да юк. Өйдән алып килгән итекләр белән саз ерабыз. Беркемгә берни кирәкми. Кешем кешесемени без?!

Сүзгә сәнәгенә таянган ханым кушылды.

—Ике стакан сөт савып, безне газетага мактап чыга күрмәгез тагын. Мактау—начальникларга гына килешә ул. Барлы кешегә бар да бар, йорт өстенә йортын да салалар. Ә безгә—шымытыр...

Бу хәлләрдән соң сиңа, блокнот чыгарып, кулыңа каләм алырга туры килмәде. Фермадан чыккач, «вожак»лар артыннан кара күләгәдәй иярган өер күздән югалган иде. Адашкан сарык сымак, як-ягыңа карандың. Җиргә убылдыларммыни!

Шулчак, якыннан гына җигүле ат арбасына бер-ике буш сөт бидоны салып, дырык-дырык узып баручы арык кына санлы бер агайдан сорыйсы иттең.

—Карагыз әле, абзый, монда семинарда катнашучылар күренмәдеме?—дидең.

Йөзен сары сакал-мыек баскан агай, сиңа таба борыла төшеп, башын ары табан изәде:

—Бер төркем кешеләр әнә теге бәрәңге подвалына таба узып баралар иде...—диде.

«Кызык, анда нием калган?» дидең дә бәрәңге базына таба юл тоттың. Терлекчелеккә багышланган семинарның бәрәңге базына ни катнашы бар икән?

Подвалга төшеп, беренче ишекне үтүгә, каршыңа ике каравылчы килеп чыкты.

—Кая барасың?

—Мин киңәшмәдә катнашучыларны эзли идем.

Картузын кырын салганы, шикләнеп, кан сауган шар күзләрен уйнатып алды.

—Син кем соң?

—Районнан килгән кеше.

—Районнан килгән кеше күп булыр ул.

Шунда икенчесе, куш ияклесе сүзгә кушылды.

—Анда һәркемгә керергә ярамый, абый.

—Ник?

—Председатель кушмады.

Шар күз тамагын кырды.

—Әйе, чит кешене кертмәгез, диде.

—Мин чит кеше түгел, алардан арткарак калган идем.

—Ә-ә, алайса узыгыз, абый. Алар теге башта, подвал түрендә утыралар.

—Ничек утыралар?

Куш ияк авызын ерырга мәҗбүр булды.

—Кергәч күрерсез инде...

—Ярый, рәхмәт.

Син подвал түренә үтеп, чак кына ачык калган ишек ярыгыннан күз төшерүгә шаклар каттың. Подвал дигәнең тыштан гына подвал икән. Эчтән евроремонт ясалган ресторан диярсең. Өстәлләр сый-нигъмәтләр белән тулган. Команда әгъзаларының йөзләре инде балкып, яктырып киткән. Әйтерсең алар бүген туй мәҗлесенә җыелганнар. Бәллүр бокаллар аракы, шәраблар белән тулы. Дөнья түгәрәкләнгән. Син, соңгаргач, эчкә үтәргә

базмадын. Түр башында Тукбаев белән Ишкәев утыра.

Телгә беткән Ишкәев, хәмер тулы стаканын күтәреп, нотык сөйли.

—Иптәшләр! Без хакимият башлыгы Рәсим Юлаевич житәкчелегендә Байтирәк районын республикада иң алдынгы районнар рәтенә чыгарырга тиешбез. Терлекчелек продуктлары житештерү буенча да, иген уңышын алуда да үрнәк күрсәткечләргә ирешик, иптәшләр! Күреп торасыз, иптәшләр, күз алдыгызда, Рәсим Юлаевич Байтирәк районын аякка бастыру өчен бар көчен кызганмый, йокы дими, ару-талуны белми, көне-төне чаба, районга акча ташый. Аңлаган кешегә аның кадерен белерлек, иптәшләр. Ул булмаса, иптәшләр, районда һәр кинәшмә, семинармы болай үрнәк төстә уза алмас иде. Без мондый мәжлесләрне күрмәс идек. Әйдәгез, иптәшләр, бу бокалларны Рәсим Юлаевич хөрмәтенә, аның исәнлегенә күтәрик!..

Соңаргач, син подвалдагы «мәжлес-кинәшмәгә» керми кире киттең.

## Этлеккә тәһарәт кирәкми

Нәфис иртән телефон тавышына сикереп торды.

—Әйе, тыңлыйм...—Теге яктан ишетелгән тавыш хакимият башлыгы сәркәтибе Ләйсәннеке иде.—Нәфис абый! Сезне глава, Рәсим Юлаевич чакырта.

—Ә-ә, тагын кемнәрне?

—Сезне сәгать сигезгә килеп житсен, диде.

Тавыш өзелде. Инде жиде тулып узып бара иде. Ул йокысы туймаганнан, аңына килергә теләгәндәй, башын дерелдәтеп куйды, гәүдәсен язып тартылды-сузылды да... Тагын нәрсәгә чакырта икән?—диде уйга калып.— Әллә Ишкәев астыртын гына ыскытып, аның күңеленә янә берәр коткы салды инде? Жен ачулары белән тагын тузынырмы? Рәсим холкына Иркәсе ничек түзә, ияләшә алды икән?..»

Шушы минутта кылт итеп аның хәтерендә яшь чактагы Иркә гәүдәләнде. Нәфис, армиядән кайтып, Казанда эшкә урнашты. Берсендә туган авылы Акъярның тау ташыннан салынган кибетенә килеп керүгә, ул шушы кыз карашында, ни әйтергә белми, ымсынып калды. Уйнап-сыгылып торган нәзек билле кара кыз үтә дә тере иде, елтыр күзләре белән аны елмаеп каршы алды.

—Абый! Сезгә нәрсә кирәк иде?—диде.

Кызның мөлаем елмаюы кибеттән нәрсә аласын да онытырды.

—Абый димәсәгез дә ярый инде,—диде Нәфис, кибеттә чит-ят кеше булмаса да як-ягына каранып.—Шундый үсеп житкән кызлар өчен...

Кыз куанып көлде генә.

—Билләһи, исемегезне дә белмим, кай арада шулай үсеп життегез.

—Мин Иркә булам,—диде кыз, горур гына.

Нәфис, исенә төшерергә тырышып:

—Янгул абый кызы бит син?—диде.

—Әйе.

—Болай кем бәхетләре өчен үстегез икән?

Иркә, оялгандай итеп, янә көлде.

—Белмим инде...

—Ничек белмисен?! Әллә егетен дә юкмы?

—Егетләр белән йөрергә миңа иртәрәк әле.

—Берәрсенә гашыйк булсаң, мәхәббәт иртәне, сонны белми ул.

—Әй абый, оялтмагыз әле.

—Ә син оялма, мин... мин чынлап әйтәм. Кибеткә килеп керүем булды, нурлы йөзен, ничек дип әйтим, бар дөньямны яктыртты да жибәрде.

—Шаяртмагыз инде.

—Чынлап, нәрсә аласымны да оныттым. Дөресрәге, оныттырдың...
—Әй, көлмәгез лә...
—Һич юк...—Ул витринага күз салды.—Менә мина бу шоколадны алып бирегез әле!
Нәфис Иркә кулыннан шоколодны алуга, аның үзенә кире сузды.
—Бу миннән сиңа бүләк, очрашу хөрмәтенә...
—Рәхмәт...
Аларның танышулары шушы очрашудан башланып киткән иде...
Нәфис чәйләп алуга, район хакимиятенә җыенды.
Ул кара дипломатын кулына тотып чыккач, ишегалдында туктальп калды. Төнге янгырдан соң һава чистарып, сафланып калган иде. Күк болытлардан арынган, аяз. Офыктан елмаеп күтәрелгән кояш җирне парландырып кипшетә. Урамнарда ара-тирә ачылып ябылган капкалардан чыккан кешеләр парлашып та, бала-чагаларын ияртеп тә район үзәгенә таба эшкә ашыга. Нәфис, тирә-ягына карана-карана, йорт-җирен, бакча биләмәләрен күздән кичерде. Хуҗалыгында—тәртипсезлек, эшлисе эшләре әле монда, әле тегендә ярылып ята. Коймалары да тотылып бетмәгән, көтүдән кайткан мал-туар бакчага керә, таптый, утырткан агачларны кимерә. Әнә күршесе Чутый Бараевның бар җире житешкән, өен ак кирпеч белән тышлаткан, мунча, гаражларын салдырган. Прокуратурада эшләгәндә һәммәсен бер сызгыру белән өйделәр дә киттеләр. Ә син аның ишегалдына караган, күзәтү объектына әйләнгән тәрәзәсен дә каплый алмыйсың, сала башлаган сараең да төзелеп бетмәгән, түбәсе ябылмаган килеш тора. Булышыр кешеләрең булмагач, нишлисең? Берүзең ни генә кырасын? Редакция коллективын оештырасыңмы, газетага мәкалә язасыңмы, колхозларга чыгасыңмы, кулыңа балта аласыңмы? Газета вакытны да, энергияңне дә тартып чыгара шул. Әле шуның өстенә акча соранып, хезмәт хаклары кирәк дип, райфин, банк бусагаларын күпме таптыйсың...
Нәфис, төрлечә уйланып, үз-үзен юата-юата, урамга чыкты. Күңелендә янә шул сорау туды. «Тукбаев нигә чакырта икән? Әллә берәрсе, сүз житештереп, күңеленә шик салдымы? Саллы йодрыгы белән өстәл биетеп, һаваларны төя-төя сүгәр микән? Соңгы чыккан газетада ярамас фикер дә ычкындырмадым шикелле. Берәрсе минем өстән әләкләсә генә инде...»
Нәфис районның үзәк урамына кермичә, турыдан, бакчалар артындагы сукмактан гына узды, май заводы янына килеп чыкты. Заводка якынлашуга, борынына әчегән сөт исләре бәреп керде. Аннан агып төшкән җыен пычрак, шакшы сулар башта елга буендагы зур чокырга җыела. Ул чокыр тулгач, кояшта җылынып исләнгәч, Байтирәк авылы уртасыннан аккан бердәнбер елгага ташый. Шуның галәмәт зәһәр исләре һаваны шәһәрнекеннән дә болай боза. Байтирәк елгасы тоныкс, сипарат сөте төсе шикелле тоник. Су төпләрендә чүплек оясы! Чүплекләрне дә чистарта алмыйбыз. Алардан таркалып, химик реакцияләрдән бүленеп чыккан хуш-исләр як-якка тарала. Шуңа да Нәфис завод яныннан борынын җыерып кына узды. Арырак киткәч, сулга, элекке ДОСААФ бинасына кереп урнашкан район хакимиятенә таба борылды. Бу ике катлы бинаның янәшә-тирәсе яшел чирәмлек. Ул агач рәшәткәләр белән тотып алынган. Чирәмлек мәйданы уртасында «Кунак йорты була» дип төзелгән Тукбаев йортыннан калган кирпеч ватыклары аунап ята...
Кабул итү бүлмәсендә, гадәттә, район хуҗасына керергә торучылар. Бүген дә ике хуҗалык рәисе чиратка баскан, ике пенсионер карт та бар. Берсе сугышта катнашкан—күкрәгендә орден-медальләре. Икенчесе, пөхтә генә киенеп, башына матур түбәтәен кигән, кыска гына сакаллы. Ул мәчет картына охшап тора.

Сары чәчләрен бөдрәләтеп купшыткан сәркәтип Ләйсән, бердәнбер алтын тешен ялтыратып, Нәфис сәламен алуга, компьютерда баса башлаган нииндидер хат язуын дәвам иттерде. Аны тиз генә тәмамлауга, әлеге бабайларга мөрәҗәгать итте:

—Шәхси йомыш белән килгәннәрегез, абыйлар, сезгә әйтәм, башта менә бу бүлмәгә, аппарат җитәкчесе Мәхмүт Талиповичка керегез,—диде, юк-бар йомыш белән главаның башын катырмаска ишарәләде...

Ләйсән сүзләрен каршы як бүлмәдә утыручы, ишеген ярым ачык калдырган аппарат җитәкчесе Мәхмүт Тәкәевкә ап-ачык ишетелерлек итеп әйтте. Тәкәев холкы белән кылчык бәндә. Бирегә кем килгән, ни өчен килгәнен күзәтеп, һәр тавышка колак салып утыра. Шымчылыкның аргы ягына чыккан. Кашлары төксе генә җыерылган, карашлары аска текәлгән. Үзе нииндидер кәгазьләр актаргандай итә. Мин кем дигәндәй, түшен киергән, уклау йотканмыни. Аның тикшерү органнарында эшләгәнлеге әллә кайдан күренеп тора. Ул бирегә килгәнче район прокуратурасында тикшерүче, аннан бераз прокурор ярдәмчесе булып та эшләп алды. Аңа шунда эшләгәндә Кылчык дигән кушамат тактылар. Күрәмсең, төксе карашларын җыера-җыера, допрослар алып, кемнәрнеңдер йөрәгенә кылчык булып кадалгандыр. Прокурорлыктан Чутый Бараев пенсиягә киткәч, аның урынына калырга өметләнеп йөрсә дә, планнары барып чыкмады, аннары, үте сытылган кешедәй, кара көеп, монда килеп утырырга мәҗбүр булды. Кызыл рухта тәрбияләнеп, дөньяга кызыл яссылыкта гына карарга иялэнгән Тәкәевкә карьера бик кирәк иде. Ул, сәркәтип кыз тәкъдименнән соң, бабайларны үзенә дәште.

Нәфис, хәзер минем чират җитте дип кенә торганда, кабул итү бүлмәсенә зур кара дипломатлар тоткан ике төрек егете килеп керде. Аларны Ләйсән елмаеп каршы алды. «Рәсим Юлаевич үзендәме?» дип сорауларына, бик теләп, «Әйе. Әйе!» дип җавап бирде. Төрек егетләре түшәм почмагына элен гән сыңар «күз» аша Тукбаев өстәлендәге телевизорда да ачык чагылды. Шунда ук селектор төймәсенә басылды, Тукбаев Ләйсәнне үзенә дәште. Ишектән тиз генә кереп киткән Ләйсән минут эчендә әйләнеп тә чыкты, һәм төрекләргә «Керегез!» дип ишарәләде.

Дипломатлы егетләр Тукбаев янында озаклагач, Нәфис, эшкә—редакциягә барырга сонга калына инде дип, арлы-бирле йөренә башлады, аннан, үзенең кайдалыгын белдереп, эшенә шалтыратты.

Көтү озакка сузылгач, ул коридорга чыгып басты. Шулчак хакимият урынбасары бүлмәсеннән автотранспорт хуҗалыгы башлыгы Чумзариф килеп чыкты да Нәфиснең кулын кысып исәнләште.

—Нишләп йөри редактор?—диде.

—Хуҗа чакырткан иде,—диде Нәфис.—Һаман кереп җитеп кенә булмый. Төрекләрне кабул итә.

—Төрекләр?—дип сорады Чумзариф, нидер исенә төшергәндәй һәм өстәде.—Алар Байтирәк мәчетен салырга акча китергәннәрдер.

—Ярдәмнәре тигәч, безгә начар булмас инде ул,—диде Нәфис.

—Ярдәм?—дип елмайды Чумзариф, тинтәк кешегә карагандай.—Алардан сиңа, миңа ярдәм тияр дип уйлыйсыңмы? Тегенәрдән,—ул Тукбаев бүлмәсенә таба ишарәләде,—артмый ул, үзләренә тотып бетерәчәкләр...

Чумзариф шулай диде дә, ризасызлыгын белдереп, китеп барды. Ул аякларын карт аюдай алпан-тилпән атлады. Алтмышка җитеп килгән элеккеге көрәшченең центнерлы гәүдәсе таушалган иде. Артыннан карап калган Нәфис аның ишарәсен ничек дип тә аңларга белмичә аптырап торды-торды да чират көтүен дәвам итте.

Башлык бүлмәсеннән төрекләр чыгып киткәч, Тукбаев янына тиз-тиз генә

башта Ишкәев, аның артыннан икенче урынбасары Фаил Минһаҗовичлар кереп китте. Күрәсең, алар әчке телефоннан хәбәрләшкәндер. Мөһимрәк эшләре беткәч кенә хуҗа Нәфисне бүлмәсенә чакырды.

Тукбаев зур бүлмә түрендә бүкәндәй утырып тора. Ян стена кырыйларына урындыклар тезелгән. Бер якта Динар Ишкәев, аның янәшәсендә ашказаны чиреннән интеккән, ябык чырайлы урынбасар Фаил Минһаҗович утырган. Аларга каршы якта, Нәфис белән янәшә, Ишкәевнең бертуган энесе, кабак башлы Ибәт кунаклаган. Ибәтнең район хакимиятендә вакытлыча беренче урынбасар вазифаларын үтәп торган чагы, сынау вакытын үтсә дә, исәбе урынбасарлыкта бөтенләйгә калу.

Бүлмәдә тынлык. Һәркем, бер-беренә күз йөртеп, сынап карады. Нәфис биредә ни буласын, сүз нәрсә турында барачагын әлегә абайламый. «Ишкәевләр икесе дә монда булгач, мөгаен, хәерлегә булмас» дип тә юрады ул. Шул вакыт Тукбаевның көр тавышыннан бүлмә әчләре дерелдәп китте.

—Динар Хамаевич!—дип башлады ул сүзен, өстәл артыннан торып китеп.—Менә хәзер шуны уйлап торабыз, акчаны теләнеп, сорап алганда жалко түгел иде. Монда кесәгә кергәч...—Ул кулын ботына шапылдатты.—Жалко була башлады... Ну, түлке, теге типография... Моны Хәниф Хәйриевич та, мин дә беләм, өч тиенгә дә тормый. Менә кулымны болай кистереп әйтәм, өч тиенгә дә тормый ул. Газета чыгару өчен ровно өч айга әйбәт, аннан соң буявы бетә, ту әллә нәрсәсе. Ну, өч ай газетаны гөрләтеп чыгарырбыз, әй-йеме, өч айдан соң бетте...

Нәфис, сүзнең типография җиһазлары өчен алынган акчалар турында барганына сизенгәч, тынычлана төште. Редакциягә компьютерлар алырга дип, Министрлар кабинетына, Хәниф Хәйриевич исеменә хат юлланган иде. Димәк, Тукбаев хатка кул куйдыртып, ул акчаларны районга кайтарткан. Башлык бер токтан дилбегәсен ычкындырмый сөйләвен белде:

—Аннары,—диде ул,—аның ту краскасына акча кирәк, ту тегесенә, ту моңа. Абага районына кайтканы типография түгел ул, ксерокс... Аның икенче төрлесе дә бар, ул цветной да чыгара ала, зуррак та, күбрәк программалы, газетаны да күбрәк баса торганы. Анысы кыйммәт. Ну тегесе, жегетләр, өч тиенгә дә тормый. Минем советым менә болай: алыйк типография, дип әйтәсез икән, аны кая куясын? Рәтле бинабыз юк. Ыштансыз күткә каеш бумыйлар. Компьютерларга дип алган акчага матур гына бер редакция бинасы төзеп куюга ни житә! Не лучше ли, бер матур гына бинаны дөбердәтеп төзеп куярга? Как считаешь, Нәфис абый?

—Билгеле, редакция бинасы да, типографиясе дә шунда була инде аның, компьютер җиһазлары да кирәк...—диде Нәфис.—Теге сез әйткән күп программалы газета басу машинасы кыйммәт, анысы...

Шушы урында Нәфисне Тукбаев бүлдерде.

—Тукта, башта бер фикергә килик. Типография җиһазларын алабызмы, әллә яңа бина төзибезме? Типография алдык ди, ладно, әйбәт, прекрасно, ди. Аны кая куябыз? Куярга урыныбыз юк. Не лучше ли, мин әйтәм, сиңа, пока бер бухгалтериясе белән урынын билгеләп, бина төзеп куярга? Аннан соң «Менә бинасын төзедек, Хәниф Хәйриевич, анда бер әйбер куярга кирәк бит инде» дип тегесен, монысын сорап алып була. Шулаймы, Нәфис абый?

—Әлбәттә...

—Как думаете?—диде Тукбаев, һәммәсен күздән кичереп, дәшүче булмагач, үз фикерен куәтли төште:—Я считаю, төзелеш начальнигы Хәбиб Хаевичны чакыртырга да: «Менә сиңа өч йөз илле миллионлык вексель, илле миллионы зарплатага, өч йөз миллионы материаллар алырга. Син

безгә, ун да унике метрга бер матур гына бина төзеп куясын,—диярга.

Өстәлдә телефон шалтырады. Тукбаев трубканы күтәрде.

—Алло! Әйе. Исәнмесез... Юк, икенче тапкыр шалтыратырсын...

Ул трубканы куюга сүзен дәвам итте:

—Главный редакторга бер бүлмә кирәк инде, кешеләрне кабул итәргә приемный. Хатлар бүлеге, архивы. Аннан соң ике машина сыярлык кына гараж склады белән. Компьютерлар бүлмәсе, бер белгеч алырга... Ну, главное определиться...

Инде сүз шушының белән тәгәлләнгәндер дип, Нәфис сорап куйды.

—Рәсим Юлаевич! Миңа китсәм ярыймы?

—Утыр!—диде аңа Тукбаев, катгый гына.—Менә нәрсә, Нәфис абый, хет шунда чукынып китегез, әй-йеме, жир йөзендә башымны кисәргә бирәм, власть она не победима! Неужели син шуны аңламыйсың? Ее никто не отдаст. Неужели сез аңгыра?

Нәфис берни аңышмый гажәпләнеп сорады.

—Нишләгән?

—Ник Шәмсиевнең фельетонын бастырдың? Аның яңа сайланачак президентның ничек булырга тиешлегенә өйрәткән ул язмасы нигә кирәк иде? Мин сине кисәттем... Газетага аннан да кабахәтрәк нәрсәне басып буламы?

—Минемчә, анда бернинди сәяси хата юк, сайлаучы үз фикерен белдерергә тырышкан гына.

—Син тик кенә тор!—Тукбаев кызды.—Абаганыкылар ник бастырмый андый кабахәт нәрсәне?

Нәфис уңайсызланды.

—Тегесен язарга ярамый, монысын,—диде ул.—Тагын ничек кенә язаргадыр инде, белмим...

—Юк, юк, Нәфис абый, бөтен әйберне язарга ярый. Ну, түлке, иртәгә-бүген сайлау дигән көнне шундый әйберне бастыралармы? Хотя бөтен республиканың, районның политикасы демократия өчен булганда. Ник кирегә сукаларга?

Бүлмәгә сәркәтип кыз килеп керде.

—Рәсим Юлаевич! Сезне Чабаксардан сорыйлар.

—Киңәшмәдә диген...

Кыз чыгып китүгә, Тукбаев Нәфисне сүгүен дәвам итте:

—Нәфис абый!—диде.—Нишләп аңламыйсың, нәрсә житми сиңа, нәрсә житми? Ну бит, бу Елесевка каршы бару... Ну что, Юганов килсенме? Укыдык, белдек без аның кем икәнлеген. Анда намуслы бер кешене дә куймыйлар. Бөтенесе пычрак. Политика—пычрак ул. Елесевтан алып алар бөтенесе бер шайка. Югановы да. Аңлыйсыңмы? Безнеке бит Елесев белән контакта эшли. Көне буе... Без әле районга, музыка коралларына, дип, утыз миллион акча алып кайттык. Республикада без генә түгел, башка районнар да бар. Менә хәзер гел соранып йөреп булмас... Һаман да что-то хотят. Ну, что докажем? Чебен дулап тәрәзәнең ватылганын күргәнең бармы?—Ул, тәрәзәгә карап, йодрыкларын күтәрә-күтәрә, Нәфискә ишарә ясады:—Син—чебен! Минем белән бергә. Без синең белән бергә чебен. «Без-з-з-з» килеп шунда бәрелеп үләргә можем. Что вы доказываете? Что? Ну, что мы доказали, Динар Хамаевич? Кичә бер шәһәр главасы,—Алла Максимовна Президент аппаратыннан елап чыкты. Үземнең газиз күзләрем белән күрдем. «Все, идите туда...» гына дигәннәр. Кем сайламаган, аңа берни юк, дигәннәр. Никаких акча! Власть—не победима! Власть дядя Эльста. Аларда бөтен корал. Көт, сул кулы белән, менә болай иттереп, чыгарып тоттырыр Елесев Югановка. Ботка ясап бетерә, власть не отдадут.

Неужели мы этого хотим?

Шушы урында, ниһаять, кипкән тараканга жан кергәндәй, Фаил Минһаҗович калкынып куйды, аның ябык, төссез чырае көлсулана төшкән.

—Шул мәкаләне бастырып,—диде ул, Нәфискә чекрәеп карап,—как будто, в мировом масштабе проблема чишәсез инде... Сезнең ул карт корреспондентыгыз хәзер ничә яшьтә? Житмештәге пенсионер, беләм, газететага күптәннән языша, шизофреник бит ул, аңа ничек тә ярый...—Ул, ризасызлык белдереп, мыскыллы көлде. Шушы мәлдә аның шыр сөяк яңаклары, төссез чырае жирәнү хисе тудырды.

—...Этлеккә тәһарәт кирәкми,—диде Тукбаев Нәфискә. Теләсәң әллә нинди нахал юлларны эшләп була. Беләсенме? Мин аны эшләмим бит. Эшләргә жыенмыйм да. Шуңа күрә злоупотребляете. Потому что, кто не с нами, аны чорнап, болгап атмыйбыз. Монда минем гаеп. Әз генә кеше шыпырдый, кирегә сукалап йөри башласа, Абага районында бу кешене юк итәләр... Шуңа күрә аларның редакцияләрендә дә тәртип. Бездә алай түгел, без тәрбиялибез. Нәфис абый кирегә сукалый, ә без аңа яхшылык эшлибез...

Ишкәев сүзгә кушылды:

—Шуның хәтле дә акыллы фикерле редактор инде ул Хаммат Камилович,—диде ул Абага районы мөхәррирен искә алып,—аның да колхозга баргач күргәне күп була, әллә нәрсәләр күрә, тирескә «утырткан» чыршыларны гына түгел, башкасын да белә инде ул. Сез монда да урынсыз, «кеше үз фикерен белдерергә хокуклы...» дип барасыз. Рәсим Юлаевичның дөрес әйткәнен дә аңлагыз. Сезгә бит аңларга вакыт. Бу Мин Мулловичны язмагыз дигән сүз түгел. «Инеш» кооперативын язганга бернәрсә әйтмәдек. Миңа Мин Муллович әле бүген әйтеп торды зарланып...

Тукбаев урманнан киселгән чыршылар мәсьәләсендә гадел булырга тырышты.

—Юк, Мин Мулловичның бу кыек эшен язып дөрес эшләде ул,—диде.—Анысы, наоборот поправляет... Монда бит күпкә китте. Менә хәзер, Динар Хамаевич, ике миллиард акчаны алып булмый, ничәнче көн барам Казанга. Кичә Фәрзи Морзаевичка кердем, әйтәсе сүземне әйтә алмадым. Настолько анда проблемалар күп. Утырдым-утырдым да чыгып китә башладым. Ул миңа: «Син нәрсәгә кергән идең соң?»—ди. Мин: «Хәлегезне белергә кергән идем»,—дидем дә чыгып киттем. Хәзер бит шушы безнең газетаны Абага главасы Гыйльфанов алып бара да бирә. «Нәрсә соң сез безне сүгәсез? Сайлауларда Байтирәктә дә кире эшләделәр бит, бөтен жирдә кире эшләделәр»,—дип, газетаны әкрен генә референтка төртә. Кәшиф Галиевич белән дус алар. Әкрен генә төртә дә, шуннан Кәшиф Галиевич, кош тоткан кеше шикелле, аппарат житәкчесенә керә дә: «Фәрзи Морзаевич! Монда бит әнә йөри ул әйбәт булып Байтирәк главасы, оказывается, ул безгә каршы эшли, менә алар нинди газета чыгарып яталар»,—дип. Шәмсиев мәкаләсен өстәленә китереп сала. Менә шул сүз мине Президент аппаратына кертмәскә житә. Минем кермәү—безгә минус ул. Мин үземә бернәрсә сораганым юк. Аңлыйсыңмы?.. Бүтән мондый разговор не будет...

## Зар

Редакциядә ул эшен яңа килгән хатлар белән танышудан башлады. Бер хатны янә дә пенсионер хәбәрче Шәмсиев язган. Әлеге дә баягы Байтирәк паркын кисеп, аны ялангач калдырулары турында. Халыкның онытылмас хатирәләренә балта чабу, күнел күрке булып торган паркны юкка чыгарудан зарлану.

Нәфис хатны укып чыккач, аны читкәрәк алып куйды, Шәмсиевнең бер мәкаләсе өчен бүген ничек «мунча» кертүләрен исенә төшерде.

Икенче хатта Балан урта мәктәбе укучысының мәхәббәт шигыре, аны эшкәртеп бастырырга була. Өченче хатта «Байлыкка табынмагыз!» дигән язма, ул газетаның «Мәхәббәт тажы» сәхифәсенә адресланган, хатта авторның төгәл адресы күрсәтелмәгән, «Х. Байтирәк авылы» гына диелгән. Җавапсыз мәхәббәттән зарланучы кызлар гыйбрәт өчен моң-зарларын түккәндә, нишлисең, торган җирен, исемнәренең баш хәрефен генә куялар, әмма төгәл исемен, адресларын яшерәләр. Нәфис хатның эчтәлегенә игътибар итте:

«...Бәхетсез мин. Үзем җитеш дөньяда, байлыкка күмелеп яшәсәм дә. Кемгә тәтегән ул байлыклар?! Кадерен белеп кенә яшә диярсез. Әйтүе генә ансат. Ирем хыянәтеннән соң, арабызда бернинди мәхәббәт, бернинди җылылык калмады. «Ташлап чыгып китим микән әллә?» дип уйлаган чакларым аз булмады. Китәр идем, балам кызганыч, ул әтисез үсәчәк...»

Нәфис шушы урынга житкәч, «Әллә бу хатны Иркә яздымы икән?» дип уйлап куйды, хатны укуын дәвам итте һәм бүтән фикергә килде.

«Мин аңа институтның беренче курсында укыганда кияүгә чыктым. Җүләр булганмын, яшьлек тилелеге белән байлыгына кызыкканмын... Янәсе, дәрәҗәле кеше малае... Дөрес, торган җиребез ташпулат, ашаганыбыз—бал да май, кигән киемнәребез зиннәтле. Барам дисәң—ишегалды тулы машина, маркалары да чит илнеке генә. Әмма минем өчен иң кирәклесе, кадерлесе юк... Ходай мине яшерен газапларда яшәтергә язган икән. Язмыштан узмыш юк, дигәннәре шушыдыр инде...

Казанга барган саен, шәһәрдә югалып, бер тынычланып, иркенәеп кайтам. Бераз гына булса да нәсел-нәсәбен, төс-кыяфәтләрең чырайларын күрмичә торам. Декрет ялыннан соң, «кодрәтле әти»ебез үземне дә әйбәт эшкә урнаштырды югыйсә. Малаен да гел үстереп кенә тора... Дәрәҗәгә табынганнар, ә кешелеклелек дигән нәрсә нуль... «Әйдә!» дип чакыручы булса, ике дә уйлап тормас идем, ияреп чыгып китәр идем...

Кызлар! Минем кебек, байлыкка кызыгып, гомерлек имгәк булып кала күрмәгез...»

Нәфис, хатны укып чыгуга, каршы як өстәл артында мыштым гына язып утыручы хәбәрче егеткә дәште.

—Факил! «Мәхәббәт тажы» сәхифәсенә материалларың җитәрлекме?—диде.

—Җыештырсаң бар инде,—диде Факил, сары чәчле башын иренеп кенә күтәреп.—Ул сәхифәне бу санга планлаштырыйкмы?

—Планлаштыр, шунда менә бу хатны да кертеп җибәр әле. Болай ярыйсы күренә...

Нәфис, хатлар белән танышып чыкканнан соң, район администрациясеннән килгән телефонограммаларга күз салды. Сишәмбе көнне ул клубта уздырыласы икътисад конференциясенә чакырулы иде.

Бүлмәдә, колакны тондырып, Гөлсунның «Любава» машинкасы тыкылдый. Ул яңа номерга материалларны басып бетерергә ашыга. Нәфис, өстәлгә ачып салган кесә блокнотына язылганнарны укый-укый, газетаның беренче битенә кыска хәбәрләр язды-язды да, бертын тукталып, уйлана калды. Ихтыярсыздан, Тукбаевның Шәмсиев мәкаләсе өчен колакларны ертып акырганын исенә төшерде дә: «Ярар, сезненчә булсын...»—дип, «демократия»не яклаган мәкаләне язарга керешге. Мәкалә авторы итеп үз исемен куярга күнеле карышты, Байтирәктән уйлап табылган имзаны гына сырлады.

Номерга багышланган материаллар укылгач, аларны Абага районына

кайта-килә эшләп йөрүче Гөлсуга тапшырды, ана кайтышлый типографиягә кертеп чыгарга кушты.

Көндәлек газета эшләре төгәлләнгәч, Нәфис кайтырга кузгалды. Ишек янына житкәч, тукталып, тәрәзә кырыенда утырган бухгалтерына дәште.

—Фәнзия! Иртәгә эшкә килгәнче райфинга кереп чык әле, хезмәт хакына акча бирәләрме-юкмы инде?!—диде.

—Ярар,—диде Фәнзия.—Белешермен.

Ишектән чыгып киткәндә Нәфис үзе белән кара дипломатын да алды.

## Кайту

Борнаш иртәгә, жәза срогын тутырып, иреккә чыгачак. Анын шушы таш казаматта биш ел гомере әрәмгә узды. Уйлый калсаң, шул вакыт эчендә күпме иза чигүләр, күпме түбәнсетүләр башыннан кичмәде?! Һәммәсе хәтергә онытылмас булып уелып калган, жанга сеңгән. Төрмә төрмә шул инде ул. Кунакка барып, бәлеш ашау түгел. Анда ашаганынны да костыралар...

Монда, шушы соргылт стеналар эчендә, ярсуларын нишләтергә белмәгән тоткыннарның күпме нәфрәте кайный. Тоткыннар өере өнендә хөкем сөргән халәт үзенә бертөрле—чит-ят, тискәре корылмалар белән корылган, ул синең рухыңны үзеннән-үзе бетерә, үзенә бөтереп ала да сине даими киеренкелектә тота һәм, сиздермәстән, әкрен-әкрен жаныңны талкый. Монда исән-имин калу өчен туктаусыз көрәш бара... Өзлексез бер ачылып, бер ябылып торган тимер ишекләр тавышы, сиңа яманлык, жәбер-золым алып килгәндәй, йөрәгенә чаң суга, миеңне тондыра. Чалт та чолт кистереп бикләнгән тимер келәләр үзәгенне өзеп телеп-телеп ала, жирсетә, авыр уйларга сала, каһәрле...

Ул бу ирекне бик көтте. Байтирәктә яшәүче рәхим-шәфкатьле хатыны Резеда сагындырды. Анын күңелне күтәреп чәчәк аттырган мөлаем йөзе үзенә гел ымсындырып торды, назлы йомшак карашлары жанына шифа бирде... Тагын әтиләрен зарыгып көткән, берсеннән-берсе матур улларын—Азатны, Ихтыярны түземсезлек белән күрәсе килде анын.

Борнашның уй йомгагы, ул үзен белә башлаган көннәрдән үк, туптай атылып, туган авылы Сушырмә урамнарына тәгәрәп килеп чыкты да, сүтелә-сүтелә, аны үз артыннан ияртеп алып китте...

Буйчан, ябык ялантәпиле егет яшел чирәм өсте буйлап түбән очка таба чапты да чапты. Ана авылның һәр тыкрыгы, һәр сукмагы таныш, якын. Уң якта, аларның бакча артыннан гына, тау астыннан югары оч чишмәсе ага. Анын ике таш арасыннан ургылып аккан мул суы бүтән чишмәләрнекенә караганда икеләтә тәмле, ә шифасы турындагы сүзләр, бабайлар теленнән күчә-күчә, безнең көннәргә кадәр килеп житкән. Тешләрне энжедәй саф саклый, бөер ташларын эретә, диләр. Шулай булмаса, олы юлдан Байтирәккә баручы-кайтучылар ул чишмәгә тукталырлар идеме?! Ул да бит сагындырган шул чишмә суларын эчеп үсте, егет булып ныгыды. Мөлдерәмә тулы чиләкләрне тау астыннан күтәреп алып менде, суын терлекләргә дә эчертте. Ә жәйнең матур көннәрендә, Аксу буе әрәмәлекләренә кадәр сузылган тау битләрендә күпләп үскән, кызарып пешкән жир жиләкләрен чиләкләп жыйды. Алар, хуш исләрен таратып, ымсындыра-ымсындыра, мине өз дә, мине өз дип, әле моннан, әле тегеннән «күз» кыстылар. Жыеп өлгер генә! Өлгерде Борнаш, ул тәжел, житез, булган. Бүтәннәр кебек мыштым, үшән түгел. Кармакларын күтәреп, Аксуга төшсә дә балыкны күп тота, кәжәләренә әрәмәлектән яфрак та жыя, каенлыкка барып, мунча себеркеләре дә әзерли. Нәрсәгә генә тотынса да эшкә кулы ятты анын,

булдырам дип ябышып эшләде. Сугыштан соңгы хәерчелек, ашарга ризык булмау, ертык, ямаулы киемнәр ары чаптырды, бире йөгертте. Аның ябык беләкләре иртә ныгыды, ничек тә көн күрү кирәк иде. Шактый картайган, күп михнәтләр кичергән әтисе Шәех нык таушалган иде...

Беркөнне алар кабинетта райпо рәисе Тукбаев белән икәүдән-икәү генә калганнар иде.

—Син беләсеңме хәзер бәрәңгедән күпме акча эшләп була?—диде Тукбаев, урынбасары Борнашка кәкре бармакларын өстәлдә биетә-биетә.—Бездә бәрәңгенең килосы өч тиен булса, Кырымда ун тиен ул. Мин иртәге көннән Сочига китәм. Бүген андагы база директоры Миша белән сөйләштем. Бәрәңгене бер сумнан кабул итәбез, ди. Монда ул ун тиен. Берәр колхоздан дүрт «КамАЗ» төятербез дә, әйдә, вәссәлам!..

Сәүдәгәр Тукбаевның янә кәкре бармаклары биеште.

—Акчасы бише белән кирәчәк,—диде.—Бер иномарка алырсың үзеңә... Мин Сочидан хәбәр салуга, син машиналарга төятеп, оештырып җибәрәсең. Буламы?

—Манчырбыз...—диде Борнаш, килешеп.

—Алайса булды. Мин «Алга» колхозы рәисенә шалтыратып әйтермен. Оптом оформим, дүрт машина төят тә санаторийга озаттыр. Мин каршы алырмын. Анда кемнәрне җибәрәсең, анысы синең эш...

Тукбаев әмерен ул карусыз башкарды. Кырымга озатылган бәрәңгеләр кыйммәт бәядән сатылып беткәч кенә, районнан алып барып сатучылар ОБХС кешеләре кармагына килеп эләкте. Шуннан китте тикшерүләр, сату-алу кәгазьләре чагышмый. Әле Кырым базасындагы завхозлар, үз файдасына янә накрутка ясап, бәя арттырганнар, бер тәңкәдән алган бәрәңгене тагын илле тиенгә күтәргәннәр. Ун тиенлек бәрәңге бер сум илле тиенгә житкән. Акчалар кайда, аларны кем үзләштергән?.. Төгәл белүче юк... Бу астыртын эш турындагы хәбәр районга тиз кайтып житте һәм райпо документларына арест та салынды. Инде нишләргә? Бу бәладән ничек котылырга? Теңкәгә тигән сораулар аның йокысын качырды...

Тукбаевның да мие кайнады. Ул да үзенчә уйланды, тегендә чапты, монда чапты, кемнәр беләндер сөйләште, киңәште. Ахырда, бер карарга килеп, иртә таңнан Борнаш белән очрашты, аңа туып өлгергән фикерләрен бәйнә-бәйнә аңлатты: «Борнаш!—диде.—Бу эшне син үз өстеңә ал, мине бутама... Эшне групповойга җибәрмик. Син үз өстеңә аласың и... Хатыныңа, гаиләңә ярдәм итәчәкмен...»

Ул Тукбаев сүзләренә ышана калды, аннары бар кыек эшләрне үз инициативасы белән башкарган булып чыкты. Тик уйланган эшләре барып чыкмады Борнашның. Соңгы чиктә таянып, калын кесәле яклар кешесе табылмады...

Бүген дә йокысыз интеккән Борнашның шул изоляторлардагы хәлләрне кабат исенә төшерүдән кысылган күз төпләренә кара күләгә сарды. Җанын җәберләү шуннан башланды да инде. Карангы, салкын камера. (Анда сиңа беркем дә райпо сыен, райпо мөмкинлекләрен әзерләп куймаган.) Тузанга баткан тонык лампочка яктысы күңелне күтәрә алмый, рухыңны изә. Күңел дәрьясын соры томан сарган... Көненә берничә тапкыр чакыртып сорау алалар. Аңа бик мөһим җинаять эшләрен тикшерүче Соткин дигән кешене билгеләгәннәр. Аның калайланган күзләре аеруча зәһәр, карашы җаныңны айкап бораулый иде. Ул синең уй-фикерләреңне һаман да бутарга, эздән яздырырга тырыша. Аңа теләсә нинди ысул белән, рухыңны сындырып булса да, үз максатына ирешү—җинаятьне ачу, раслау өчен саллы дәлилләр кирәк.

Утыз биш яшьләр тирәсендәге Соткин кылыч борынлы, яңак сөякләре

калку, карашы чәнечкеле. Ана, иң мөһиме, ахыргы уңай нәтиҗә зарур. Ул йөзен кырык төрлегә үзгәртә, хәленне чын күнелдән «анларга» да тырышкандай итә. Анын ясалма кыланышларыннан ике каш өстендәге маңгай тиресе, вак-вак сырлар ясап, баскычлы пирамида хасил итә.

Һәм ул, көттерми, чираттагы соравын бирә:

—Йә, Шабаев, эшнең дөресен сөйләргә уйладыңмы?—ди.

—Мин дөресен әйттем бит инде.

—Ялган, мин сиңа ышанмыйм.

—Анысы сезнең эш...

Соткин чыгырыннан чыкты.

—Син бик чәпчемә, кикригең шәлперәймәсен? Синең кебек әтәчләрне бик күп күргән без.

—Анысына шикләнмим.

Соткинның йөнтәс бармаклары өстәл өстендә биеп алды. Анын терекөмештәй ялтыраган күзләре Борнаш артында үрә катып басып торган сакчыларны да күзәтте, алар әледән-әле үрә катып тураяя төште.

—Тәк-тәк,—диде Соткин, сүзен дәвам итеп:—Син, Шабаев, бәрәңге сатып акча үзләштерүне бер кеше генә башкармаганны яхшы беләсең. Башыңны тилегә салма. Әйт, кем боерыгы белән башкарылды бу эш? Тукбаевныкы беләнме?

Борнаш бер үк сүзләрне кабатлады.

—Бәрәңгене мин төяттердем, машиналарны мин озаттым...

—Ялганлыйсың... Биш меңлек табыш кем кесәсенә керде.

—Белмим. Миндә юк...

Борнаш кесәләрен какты.

—Тукбаев белән бүлештегезме? Нигә дәшмисең? Дөреслекне тану авырмы сиңа? Без бит барысын да беләбез.

—Белгәч, сорашып та торасы юк.

—Нәрсә, мине өйрәтергә телисеңме? Миңа чынбарлык мөһим.—Соткин өстәлдә яткан кәгазьләренә ишарәләде.—Расланган фактлар шушы кәгазьләргә төшеп рәсмиләштерелергә тиеш.

—Минем имзам белән беркетелепме?—диде Борнаш.

—Әлбәттә...

—Мин, ялганга кул куеп, үз-үземә хөкем карары чыгара алмыйм бит.

Шушы сүздән соң Соткин кабарынды-бөртенде.

—Белдекле булма. Монда закон тәртипләрен өйрәнергә дә өлгердеңме инде? Урлашканчы белергә иде аларны. Хәзер үҗәтләнәсеңме? Каян килгән каты чикләвек! Сынмам, ватылмам дисеңме? Безнең тешләр үткен, көч җитәрлек...

—Ышанам, көч сезнең якта, власть власть инде ул.

—Шулай булгач, нәрсәгә исәп тотмакчы буласың? Дөресен сөйлә! Үзеңне җинаятькә этәргән каракларны яшерәсеңме?

—Мин яшермим, мин үз акылым белән эш итәм.

Соткин Борнаш күзләренә текәлде.

—Яшерәсең...—Сабырлыгы төкәнеп, утырган урынында калкынып-калкынып алды. Бу хәлгә арттагы сакчылар колакларын торгыза төште.—Шабаев! Мин синең ялганлавыңны күзләреңнән күрәм. Гаепне үз өстеңә алырга телисең. Срокны әзрәк алырмын дип уйлама. Хәзер син безнең капкында. Моннан тиз генә чыгармын димә. Инде сине адвокатың да коткара алмас. Ирегең белән саубуллашырга туры киләчәк сиңа, Шабаев. Бер ун елга. Ә шул вакыт эчендә синең чибәр генә хәләл җефетең, сылу хатының...—Соткин, эчтән мыскыллы көлеп, юри пауза ясады, Борнашның нервыларында уйныйсы итте. Борнаш исә, нигә бет чәйнисең әле дигәндәй,

каш астыннан аңа төбәлде, авырткан җиренә тисә дә дәшмәс булды. Соткин мәсхәрәләвен дәвам итте:—Әйе, әйе, ул чагында чибәр хатының синнән ваз кичәчәк. Ул инде, «минем Борнашым!» дип, синең төрмәдән чыкканыңны көтеп тормаячак, үз эшен, үз хаҗәтен башкарачак. Шул син яклап маташкан Тукбаевлар белән дә...—Соткинның нечкә иреннәре янә мыскыллы елмайды.—Ул инде төрмәдән чыккан төшенә синә бер малай да алып кайтып бирсә, аны син, минем малай, дип җитәкләп тә йөрергә тиеш буласың...

Шушы урында Борнашның түземлеге төкәнде. Ул берни белештерми, мизгел эчендә, Соткинның якасыннан эләктереп алды да, аны үзенә таба тартып китереп, чүкечтәй башы белән дөңгелдәтеп, мыскыллы чыраен җимереп ташлады, канга батырды. Арттагы сакчылар Борнашны ике ягыннан эләктереп алганда, Соткинның җирәнгеч елмаюы йөзеннән качкан иде инде.

Көтелмәгән бу хәлдән шау-шу, акырыш-бакырыш китте. Тиз арада Борнашның кул-аякларын як-якка аерып бәйләделәр дә түшәмгә астылар, һәм, типкәләп, кабыргаларын саный башладылар. Ахыр чиктә, аңын югалта башлагач кына, тәннәрен кара яндырып, камерага кертеп аттылар...

Иртәгесен янына кергән адвокаты аны орыша башлады: «Нишләдең син? Эшне менә-менә җайлыйм, җиңеләйтәм дигәндә генә...—Ни булганын инде ишеткән адвокат Сергеевның бөтенләй гайрәте кайткан, сөмсере коелган иде.—Бөтен эшне боздың да куйдың бит...».

Уйсыз-өнсез кешедәй кәлимә сүз дәшмичә, башын аска иеп, бер ноктага карап утырган Борнаш, эчке киеренкелегенә чыдаша алмый, кинәт башын калкытты да күлмәк изүләрен ачып җибәрде.

—Ә менә мондагы хәлләрне аңлыйсызмы?—диде, кара янып беткән тәнен күрсәтеп.

Саргылт чәчен бер якка шомартып тараган Сергеев аның каты кыйналганын күреп аһ итте. Кабыргалары да сынган. Адвокат, күп уйлап тормастан, шунда ук медицина экспертизасы ясатырга булды һәм бу эшне үз өстенә алды. Аннан соң гына, үзара сугышу очрагы буларак, аерым кануннарда каралмыйча үз әһәмиятен югалтса да, бәрәнге очрагы төп эш булып калды. Аңа шулчак биш ел биргәннәр иде...

—Нигә йокламыйсың?—диде тоткын Хәйдәр, янәшәсендә уйланып яткан Борнашка таба борылып.

—Күзгә йокы керми.

—Аңлашыла...—диде каратутлы Хәйдәр.—Иртәгә чыгасы булгач, уйларың иректә йөзә булыр...

—Әлбәттә.

Борнаш тагын бер ел утырасы Хәйдәрне аңларга тырышты, үзара адреслар алыштылар. Биредә бер гаилә булып яшәделәр... Хәйдәр Чаллыда үз кибетен ачкан булган.

Бер Келәй кушаматлы «мент», аның «крышаң» булам дип, моңа сөлек кебек ябыша. Торган саен күбрәк акча таләп итә башлый. Аңардан майлы калҗа ала алмагач, үчләнеп, өенә кайтканда саклап тора да, кулына тимер беләзек кигертеп, кесәсенә наркотик сала. Аннары, шаһитлар чакырып, акт төзи, милициягә илтеп тапшыра. Келәйгә ышаналар, Хәйдәр шул «гөнаһы»сы белән монда килеп эләгә...

Бу минутта ул инде тынчу һавалы төрмәнең шыксыз, пычрак таплы стеналарын гүя күрми, йоклаган тоткыннарның гырлаган тавышларын да ишетми. Аның уенда—Сушырмә авылында берьялгызы яшәп ятучы җитмеш биш яшьлек әтисе Шәех карт. Аңа хәзер аерата читен, ул моннан ике ел элек кенә дөнья куйган газиз әнисе белән бәхилләште... Борнаш әнисе

Гөлзаданы соңгы юлга озата алмады, фәкать төрмә стеналары арасында бәргәләнеп үкседе генә. Таш диварларны тишеп чыгардай үкенеч-сыкрауларын, кайгы-хәсрәтләрен эченә йотты...

Борнаш, күңеленә килгән киеренке уйларын куарга теләп, икенче ягына борылып ятты. Аны мең төрле сораулар борчыды. Моннан чыккач нишләргә? Кая барып эшкә керергә? Хәзер райпога юл ябык инде. Райподан Тукбаев та кыяклаган. Ул, йомры баш, Байтирәккә кайтып, район башлыгы булырга да өлгергән. Димәк, ул акчасыз яшәмәгән. Хәзер акчасыз беркем дә ныклап аякка баса алмый. Үтте андый заманнар. Хәзер элеккеге куркак, мескен тычканнар да, явыз күселәргә әйләнеп, тазарып үсте, тешләкләнде, битлек алыштырып, биек кәнәфиләргә менеп утырды. Андыйлар бүгенге шартларга оста, тиз яраклашып өлгерде. Инде бүтән көй көйлиләр, бер партиядән икенчесенә, аннан өченчесенә күчеп, башкача сайрыйлар. Яраклаштылар. Акча кирәк! Акчасызны тану юк. Тукбаев Борнашны аңлармы соң? Кем өчен тәмуг газаплары кичергәнен белер микән ул? Эш мәсьәләсендә, бәлки, аңа мөрәҗәгать итми булмас әле. Юк, ул аны төртеп егып, белмәмешкә салынырга тиеш түгел, түгел...

Иртәгесен, тиешле срок сәгате суккач, Борнаш Шабаев артыннан тимер ишекләр чынлап ябылды, ул, урамга чыккач, күкрәген тутырып бер иркен сулыш алды һәм әкрен генә тимер юл тукталышына таба атлап китте. Аны тимер ятьмә аша күренгән тоныкъ тәрәзәләрдән тоткыннарның монсу карашлары озатып калды...

## Килен сәфәре

Нәфис шимбә көнне дәртләнеп хуҗалык эшләренә керешге: сул як күршеләре Чутый Бараев ягындагы ачык урынга баганалар утыртты, араталар юнып, тигезләп рәшәткәләр тотты. Башкарган эшләренә карап сокланды: «Кемнән ким? Иң мөһиме—кеше көлкесенә калырлык булмасын...» Ул, хур булмаска тырышып, бар көченә эшләде. Яшьтән өйрәнеп үскәнгәме, кулы эшкә ятып тора иде. Моңа заводта станоклар ремонтлавы да, аннан инженерлык белеме дә ярдәм итте. «Болай итсәң, монысы, тегеләй итсәң, тегесе ничек булыр?» дигән уйлар аны аптыратмады, ул үзенчә эшләде, үзенчә тырмашты. Әлбәттә, аңа ялгызы гына эшләү читенрәк, вакыты да җитми. Байлар кебек, осталар кушып, эшләтергә мөмкинчелеге юк, кесәсе сай һәм тишек тә. Вакытында бирелмәгән юк-бар хезмәт хакы белән ни генә эшли аласың? Бар булганы белән канәгатьләнәсен. Ул Тукбаев, Ишкәевләрдән ярдәм сорап түбәнсенмәде. Хан сарайларында алар яшәсен, барыбер ике гомер килмәгән дип уйлады.

Койма тотылгач, ул кулына балта алып такталарны эшкәртә башлады. Шул вакыт аның аяк астыннан ике шәүлә үсеп чыкты. Артына борылып караса, анда өлкән яшьтәрәк бер апа белән бер кыз басып тора иде.

—Исәнмесез!—диде борчулы кыяфәттәге апа.—Редактор йорты шушы буламы?

—Әйе,—диде Нәфис сагаеп һәм балтасын бүкәнгә чапты.

—Сез Нәфис Хаков буласызмы?

—Нәкъ үзе.—Нәфис, өлкән апа янында сүзсез генә басып торган кызның да сөмсере коелганлыгын күреп, аларга нидер булганлыгын аңлады.—Әллә миңа берәр йомышыгыз бармы?

—Бар иде шул,—диде апа, эчтән көенеп.

—Алайса, әйдәгез, өйгә кереп сөйләшик...—диде Нәфис, ишегалдында, прокурор Чутый Бараевларның тәрәзә каршында сөйләшүне өнәмичә.

Әңгәмә өйнең кечкенә бүлмәсенә үткәч башланды.

—Менә карагыз инде бу балага,—диде хатын, янындагы кызга ишарәләп.—Коры сөяккә калган, чыкмаган җаны гына бар...

—Без башта танышыйк әле,—дип бүлдерде аны Нәфис.—Сез кем буласыз соң?

—Мин Ламига апаң булам, бу минем кызым Хәтирә, Динар Ишкәевләр килене. Алар шушы Байтирәктә бер йортта торалар. Без үзебез Курбаш авылыннан.

Динар Ишкәев исеме аталуга, Нәфиснең кан басымы күтәрелеп киткәндәй булды.

—Ярар, ни булды соң?—диде ул, эшне ачыкларга теләп.

Хатын, борчуын басарга теләгәндәй, кул аркаларын ышкып алды һәм:

—Ул хатны кем язды икән?—диде.

—Нинди хатны?—диде Нәфис, гаҗәпсенеп.

—Сезнең газетада «Байтирәк хәбәрләре»ндә басылган бит.

Сүзсез утырган Хәтирә аптырап калган Нәфиснең исенә төшерде.

—«Байлыкка табынмагыз!» дигән хат.

—Әйе, бар иде андый материал, басылды. Шуннан ул хатка ни булган?

—Тегеләр,—диде хатын.—Кодаларны әйтәм, ул мәкалә безнең турыда дип, менә шушы баланы нахакка рәнҗетәләр.

Ниһаять, эшнең нәрсәдә икәнлегенә төшенгән Нәфис мәсьәләнең асылын аңлатасы итте:

—Мәхәббәт турында андый хатлар безнең редакциягә дә күп килә. Адрессыз да, исемнәре ачык күрсәтелмичә дә. Кайберәүләр исемнәрен махсус күрсәтмәскә кушалар. Аңлашылганча, кияүгә чыгып, уңышсыз мәхәббәткә юлыкканнар үкенүләрен, кичерешләрен яза. Йөрәк серләрен әнә шундый хатларда ачып салалар да, бүтәннәргә гыйбрәт йөзеннән, кинәш бирәләр. Минемчә, монда кемнедер рәнҗетеп, гаеп ташларга урын юк.

Әни кеше кызына кызганып карады.

—Моны шулай иткәннәр шул...—диде.—«Байтирәктә бүтән мондый кеше юк, мондый ул син генә» дип әйтәләр, ди.

Хәсрәткә баткан, йөзе сула төшкән Ишкәев килене фикерен әйтергә ашыкты.

—Әти әйтә: «Байтирәктә төзелеш нәчәлниге Шәйхелисламның да андый малае юк, энем Ибәтнен дә»,—ди. Байтирәк авылында бөтенесен санап чыкты. Бер кеше дә юк бит андый, ди. Бер мин ул, ди...

Ламиганың җыерчыкланган йөзен тирән борчу басты.

—Хәзер бу бала ни кылырга да белми инде. Кода минем үземә әйтте: «Аклансын!..—диде.—Редакцияне судка бирсен, мин олы башым белән мондый хәлне күтәрә алмыйм...»—ди.

—Динармы?

—Әйе, үземә әйтте. «Редакцияне бик әйбәтләп судка бирсен» диде. Кода хәзер ул хатны килен үзе язган дип бара...

Хәтирә әнисе сүзен раслады.

—Шулай диләр инде...

—Кызым язган дип бара бит ул,—диде Ламига, баласының фикерен хуплап.—Бу бит әле ул вакытта Казанда сессиядә укып йөри иде, бернәрсә дә белми иде. Шулай булгач, моның кай җирендә гаеп? Нахак сүзне чыгарганнар моның кайткан төшенә... Кода тора-тора да: «Судка бирегез...»—ди.

«Вәт тешләк әрлән!..—дип уйлады Нәфис, Ишкәевне күз алдына китереп.

—Судка биргәнче тагын бер кат уйлашыгыз,—диде ул:—Билгеле, бу эш

сезнең ихтыярда. Әле гаризагызны алалармы?.. Уйлавымча, суд киленнең гаебе юклыгын, билгеле, хатны ул язмагач, расларга да мөмкин, андый хатны бастырган өчен редакциягә дә ташлама ясап булмый һәм сезгә бу безнең турыда икән дип әйтү дә урынсыз. Хат ахырында «Х» хәрефеннән башка фамилия дә, исем дә юк. Бу уңышсыз кияүгә чыккан бер кызның күңел бушатуы, башкаларга мәхәббәтне байлыкка алыштырмагыз дип кинәш итүе генә. Судта да юкка баш катырып йөрмәгез дип әйтергә мөмкиннәр.

Һич тынычлана алмаган Ламиганың калын иреннәре тибрәлде.

—Кода әйтә,—диде ул.—Редакция табып бирсен язган кешесен, ди. Тапсын!.. Аннары үзен аклый ул, ди. Киленне әйтә.

—Килен язмаса дамы?..

—Шулай ди шул... Кияү үзе шул хатны редакциягә барып сораган, аңа әллә кемнең кулъязмасын биргәннәр, ул хатны язган кешенеке белән туры килми, ди.

Нәфис гаҗәпләнеп сорады.

—Ул хатны минем рөхсәттән башка чит кешеләргә кем бирер икән? Ул бит вакыты, сәгате житкәнче редакция сере.

—Атнакич барган иде ул бер иптәш милиционеры белән. Сез инде киткән булгансыз. Анда бер егет кенә утырган.

Нәфис хәбәрчесе Факил шуны эшләгән булса, бик ялгышкан дип уйлады һәм:

—Алай булгач, хат киленнең үз кулы белән язылганмы соң?—диде.

—Юк шул. Аны безнең авылда Раилә язган дип тә чыгарганнар. Хакмы, нахакмы?

—Раилә?! Безгә хәбәрләр язышып торучымы?

—Әйе, ул гына язган аны, диләр. Бер дә бүтән кеше түгел, дип әйтәләр.

Нәфис шунда ук аның фикерен кире какты.

—Бу мөмкин түгел, мин ул кызны беләм, ул андый әшәкелеккә бара алмый...

Шулчак уйларына баткан Хәтирә әнисенә каршы:

—Ул түгел лә...—диде.

—Алай димә, кызым, кырык төрле итеп язалар аны... Әллә кемнәр отправить итә...

Нәфис фикерен куәтләбрәк аңлатырга тырышты.

—Алайга китсә, миңа да әйтергә мөмкиннәр: махсус эшләгән бу моны, дип. Әйтәм ич, хат конкрет шәхес турында түгел. Монда фәлән итәм, төгән итәм дип борчылып йөрисе юк.

Хәтирә, төрле-төрле буталчык уйларыннан арынырга теләгәндәй, юка иреннәрен тешли-тешли, сүзгә килде.

—Менә мин аны, ул язган кешене, ничек тә судка бирсәм, сезне судка чакырдылар ди. Ул кеше табылмый бит... Ә каенатам, сезне судка биреп, язган кешене эзләп табарга куша...

«Мине судка бирергә?! Вәт бәдбәхет! Нәрсәгә дип миңа үчләнә икән ул? Бу кадәр серкәсе су күтәрә алмас икән» дип уйлады Нәфис. Ул бу минутларда аптыраулы уйлар эчендә иде.

Ламига кызы сүзен җөпләде.

—Әйе, кода, язган кешене тапсыннар, ди.

«Анысы тикшерүчеләр эше... Без хат авторын, белгән очракта да, әйтергә тиеш түгел, үч алудан, яңа җинаять эшеннән сакланып». Нәфис шулай уйланса да, хатынны сүзеннән бүлдермәде.

—Кода бит кызга ышанмый,—дип дәвам итте Ламига.—«Ник судка биреп булмасын?!» дип бара. Алар ирле-хатынлы икесе дә килен шулай

язган дип уйлыйлар.

Хәтирә әнисе сүзен хуплады.

—Ирем Габит та шулай ди. Син язган аны, башка кеше түгел, ди...—Ул, чарасызлыгыннан котылырга ярдәм эзләгәндәй, Нәфискә карады.—Нәрсә булса да эшләп карыйк инде, кул кушырып утырып булмый бит, милициягә тикшертергә мәллә?—диде, авыр сулап.

—Анысы сезнен ихтыярда,—диде Нәфис.—«Ник андый хат бастырдыгыз?» дип редакциягә дәгъва кыла аласыз. Мине рәнҗеттегез, мин сезне судка бирәм, төгән итәм, дип. Ул очракта без сезгә газета аша җавап бирергә тиеш булабыз.

—Менә шундый нәрсә кирәк, ди кода,—дип әйтте Ламига.—Син түгел дигән әйбер кирәк, ди.

—Болай эшләгәндә, бу үз-үзеңне фаш итү була. Каракның бүреге янгандай, гаепне үзеңә алу, аны тану була. Аннары әйтерләр, чыннан да үзе язган икән, житешле тормышы да туры килеп тора, диярләр...

—Шул шул,—диде Ламига,—тормышы белән туры килүе начар. Юкса мәкалә эчтәлеге анын үзенә туры да килми. Минем кызым беренче курста кияүгә чыкмады. Ул хатта: «Беренче курста кияүгә чыктым» дип язылган. Бу бала өченче курста кияүгә чыкты.

—Сон, шулай булгач?

—Аңламыйлар бит менә, аңламыйлар...

«Аңласалар кеше дә була ул. Бик аңлыйлар, шулай кеше каһәрләүдән тәм табалар»,—дип нәтиҗә ясады Нәфис.

Ламига, кулларына урын таба алмагандай аптырап, әле бер, әле икенче кул аркасын кашыды һәм тирән итеп сулыш алды:

—Газетта безне мактаганнар, ди, ул кеше безне яманламаган, ди. Без, ди, тормыш иткән, ди.

—Кем әйтә алай дип?

—Кодагый. Ике-өч машина да булгач, шуңа мактаулы без, ди. Язган кеше безне түгел, үзен генә хурлаган ул, ди.

—Аларча шулай булып чыга инде ул...—диде Хәтирә, әнисе сүзләренә кушылып.—Тик бу хатны язган кешене кем дә булса беләме? Кем икән ул? Аны кем дә булса язган бит, үчлек белән... Ничек менә шулай тик торганда язарга мөмкин? Бу бәндәне миңа табарга язмасын...—Хәтирәнең күз карашлары очкынланды, ул, хат авторын күрергә тырышкандай төкселәнде, йөзенә үч алу, усаллык хисләре ташып чыкты.—Әгәр дә мин аны тапсам...

Анын нәфрәт катыш үч белән сугарылган бу сүзләре Нәфистә тискәре йогынты уятты. Тынлыкны Ламига бозды.

—Кияү шул кешене таба да, белгәч, аннары кызга: «Син яздырдың, хәзер баланны күтәр дә чыгып китәсен»,—дип әйтергә тиеш икән.

—Әгәр тапмаса? Әгәр ул кеше юк икән?..

—Әгәр юк икән, белмим, анысын әйтмәде.—Ул бертын уйга калды һәм өстәде:—Барган инде ул күрәзәчегә дә.

—Кем?

—Кияү.

—Нәрсә дигәннәр?

—Киленнең гаебе юк, дигәннәр.

—Һәм юк та инде.

—Мин әйттем инде аңа шулай дип.

Хәтирә үзен аклады.

—Минем гаебем юк та инде. Мин бит беренче курста түгел. Миңа кеше килеп әйтте. «Менә шундый нәрсә язган икәнсен «Байтирәк хәбәрләре»нә,—

дип. Булмаган нәрсәне.

—Булмаган нәрсә өчен баш катырып йөрисе дә түгел,—диде Нәфис, бу сөйләшүгә нокта куярга теләп.

Шул вакыт Нәфиснең ишегалдына килеп кергән күршесе Чутый Бараев, тәрәзә каршына килеп басты да, кулын изәп аны тышка чакырды.

—Чыгып кер әле?—иде.

Нәфис артыннан, килгән кунаклар да тышка чыкты. Аннары алар, кәефсез генә хушлашып, китеп барды...

Ахырдан сәфәр кылган кунаклар артыннан күзәтеп калган Чутый кызыксынып сорады.

—Болар кемнәр?—диде.

—Әй килгәннәр инде,—диде Нәфис, теләр-теләмәс кенә.

—Әллә нинди хатын-кызлар килә үзеңә,—диде Чутый, үзенең профессиональ күзәтүчәнлеген эшкә җигеп.—Ялгыз яшәвенне сизәләр.

—Юк, аларның үз мәшәкатьләре... «Газетаны судка бирикме?»—дип килгәннәр.

Нәфис артык сүз ычкындыруына офтанып куйды, әмма соң иде инде.

—Ни өчен?—дип элеп алды прокурор.

—«Байлыкка табынмагыз!» дигән бер хат өчен. Болар ул хатны, безнең турыда язганнар дип, үзләренә кабул иткән. Дөресрәге, кемдер күңелләренә коткы салган.

—Байтирәктәнме соң алар?

—Әйе.—Нәфис китеп баручы кунакларга ишарәләде.—Динар Ишкәевнең килене белән кодагые.

Чутыйның батынкы күз төпләрендәге күләгәдә очкыннар уйнап алды.

—Ә-ә,—дип сузды ул, беразсакаулыгын төзәтергә тырышкандай.—Алар бу мәсьәләдә район судьясына да кереп чыкканнар инде. Моның нигезе юк, дип аңлатканнар үзләренә...

Нәфис «менә ничек?» дип уйлап куйды. Һәм ул артык сүз ычкындырудан сагайды.

—Нәфис!—диде Чутый, үзенең «йомыш» белән кергәнлеген исенә төшереп.—Синдә бер ДВП кисәге юкмы? Рамга, рәсем артына куярга кирәк иде.

—Булыр,—диде Нәфис һәм әйтелгән үлчәүдә Чутыйга ДВП катыргысын кисеп тә бирде.

Чутый чыгып китәргә ашыкмады. Ишегалдында аунап яткан такта, рәшәткәләргә ишарәләп:

—Боларны каян алдың?—диде.

—Китерделәр,—диде Нәфис, тыныч кына.—Урман бай бит...

Чутый ясалма елмайды.

—Ну, булдырасың да инде үзең, тегесен табасың, монысын... Ял көне дә тик тора белмисең. Мин синең урыныңда булсам, шушында бер чәчбине алып кайтып рәхәтләнер идем...

Нәфис дәшмәде, көлемсерәде генә. Ул Чутыйның читкә, яшь кызлар янына йөргәнлеген яхшы белә иде.

Шул вакыт Чутый нәрсәгәдер кысылу нәтиҗәсендә кәкрәеп калган бармагын «Т-с!» дип өскә күтәрде дә:

—Нәфис! Мин синең телефоннан гына бер җиргә шалтыратып алыйм әле?—диде.—Өйдән булмый, сөйләшкәнне хатын тыңлап тора.

—Рәхим ит!—диде Нәфис.

Өйгә үткәч, Чутый телефон номерын җыйды. Нәфис, аның сөйләшкәнен тыңлап торырга арусынмый, кухня ягына узды. Барыбер дә Чутыйның сөйләшкәне аңа ишетелеп торды:

—Привет, ягодка! Бу—мин. Сине сагындым. Ә-ә, син дәме? Бик әйбәт. Сагындырып, мине акылдан яздырасың инде... Әйе, ничек кенә! Шашарсың да.... Көл инде көл. Сиңа килешә ул... Әле ни эшләр башкарасың? Вак-төяк? Әйдә, вак-төякләреңне калдырып тор, табигать кочагына чыгып керик, Аксу буена... Олы юл чатында очрашабыз. Иске урында, син заправка ягына чыга тор. Мин бер ярты сәгатьтән килеп житәм... Пока, ягодка моя!..

Чутый чыгып, бер ун минут узуга, аның киенеп-ясанып, тулы сумкасын кулына тоткан хәлдә, бәрәңге бакчасы артыннан китеп барганы күренеп калды. Артыннан болдырга чыгып баскан хатыны Гөлия аны кара көеп, рәнжүле караш белән озатып калды.

Нәфис, кулына балтасын алып, такталарны эшкәртүен дәвам итте. Аның уеннан Чутый тиз генә чыгарга теләмәде. Йә ул элекке Байтирәкнең заманында гөрләп торган базарлары турында мәкалә язган да шуны, татарчага тәржемә иттереп, газетада бастырыйк әле, ди. Аны чәйгә дә дәшә... Ахырга таба сүзе тикшерү эшләренә кайтып кала. Элек прокурор булып эшләгәндәге районнар искә алына: янәсе, аңа ничек кенә ялынып килмәгәннәр дә, ул нинди генә жинаять эшләрен ачуда катнашмаган... Ә кызлар турында әйтәсе дә юк, үзләре муенга сарыла торган булганнар. Прокуратурада бергә эшләгән Таня исемлесе, кияүдә булса да, аны үлепләр яраткан. Ул аны кая дәшсә дә шунда барган, мунчалар кергән... Берсендә эштән соң бүлмәдә икәүдән-икәү генә калалар... Таняга ире шалтырата. Ул аңа: «Мин әле эштә тоткарланам, берәр сәгатьтән кайтып житәм, бәгырь кисәгем»,—ди. Үзе Чутый кочагында, аңа сарылган, ожмах рәхәтен кичерә... Ягодкам да менә дигән! Мин синең урында булсаммы...

Нәфис Чутыйның шуның ише үгет-нәсихәтләрен кабул итә алмады. Байтирәккә кайтып-китеп йөргәндә, Сәриясе Чутыйны беренче күрүдә үк ошатмады. Күрәмсең, ул аның кемлеген,ниндилеген йөзеннән үк таныган... Ул Нәфискә: «Син бу кеше белән якыннан аралашма, эч сереңне чишмә,—диде.—Сүзеңне «Исәнме?» «Исәнме!» белән бетер. Ахыры жүнлегә алып бармас...

Нәфис үзе дә Чутыйның мин-минлеген, шик-шөбһәгә баткан күңеле кешенең кечкенә генә гаебен дә кичерә алмавын, холкының үчкә, жәзага тартуга корылганын сизде, хатыны сүзләре белән дә килеште.

Бәлки, Сәриясе бүген шәһәр кучтәнәчләре белән кайтып төшмәсме? Ял көннәре бергә-бергә күңелле узар иде...

Нәфис шулай уйлады һәм урам башына күтәрелеп карады. Һәм, ни күрсен, урам уртасыннан аның үзе бүләк иткән аклы күлмәкне киеп, Сәриясе кайтып килә. Шунда ук аның кулыннан балтасы төште. Ул, хатынын каршы алырга дип, капка төбенә чыгып басты, Сәрияне елмаеп каршы алды. Һәм алар, күптән күрешмәгән кебек, сөйләшә-сөйләшә өйгә уздылар.

Бүген Нәфисләр өендәге моңсу тынлык, нидер житмәүдән, ялгызлыктан туган караңгылык почмакларга кереп посты, күңел тәрәзәләре яктырып китте...

## Әжәл саташтырган

Нәфисләр капкасыннан чыгып киткәч тә, Ламига белән кызы Хәтирә жанына тынычлык инмәде. Борчу, рәнжүләре күңелне тырмап торды.

Вакыт-вакыт алар сүзсез атладылар. Ламига кызы өчен башын кайгыга салды: «Кем язган шул мәкаләне? Ул хатны газетада бастырмасалар ни булган? Кодага котырынырга шул житә калды. Газетаны судка бирегез, шул чагында гына үзегезне аклый аласыз, ди. Газетаны судка бирүдән нинди

жинеллек табадыр. Редакторга этлек эшлисе киләме? Исе китәр, әллә ул миллионнарны урлаганмы? Бер дә андый кешегә охшамаган, хәерче кебек яшәмәс иде. Арты-алды чиста булмаса, үзен алай горур тотмас иде. Безнең кода кебек комсыз түгел, туры кеше күренә. Ул читләтеп кенә кызына күз салды. Бу гаепсез балага ни дип аклану кирәк инде? Хатны ул язмаган бит. Килен мина ошамый дип, алай ук кыланмыйлар инде. Малаена ярагач, сиңа соң ни житмәгән? Кешедән кер эзләп, һаман үч алып яшәү нигә кирәктер... Җүнле эш түгел инде бу, баланы нахакка рәнжетеп чиргә сабыштыру... И-и, бу кадәр дә атасы Хамайга охшар икән. Әй Аллам, мондый яманлыклардан үзең саклый күр! «Мин кем!» дип күкрәк суккан кешедән ни өмет итәсең?! Байтирәктә берәү дә шул хат өчен күтәрелеп сугылмады, кизәнеп бармак янамады. Әллә район үзәгендә бар да машинасызлармы? Хәерчеме, ачмы?..»

Хәтирә сүзсез атлаган әнисенә дәште:

—Әни! Син нәрсә уйлап барасың?

Хатын кызына кызганып карады.

—Һаман да шул коданы уйлыйм әле. Гомергә үчле булды. Кешене гафу итә алмый, шайтан коткысына бирелеп яшиләр. Аларныкы гына дөрес... Бер түбә астында яшәгәч, түзүләре сина да кыендыр инде.

Хәтирә, акланып:

—Ирем башка чыгабыз дип әйтә әйтүен.

—Аңарчы менә хәзер яшәргә кирәк бит әле.

Хәтирә җавап кайтармады. Бераз тын гына барганнан соң сорады.

—Хат язган кешене табып булмас микән?

—Әйтә алмыйм.

—Ну, тапсак...

Хәтирә күзләрендә янә усал очкыннар уйнап алды. Ул үзенә җан ярасы китергән кешене белә калса, аны өзгәләп ташларга, иң соңгы сүзләр белән хурларга, аны яманрак газапларга дучар итәргә әзер иде.

Ламига кызының бу халәтен яхшы сизде, акылыңа кил, балам дигәндәй, киңәш итте:

—Кирәкми, кызым,—диде.—Тыныч, сабыр була бел. Үч саклау чир саклау ул. Үченең чиге яман... Кичерә, оныта белсәң уңарсың...

—Мондый хәлне ничек онытасың, әни? Эчтән борчып, талап тора бит ул.

—Барысын да аңлыйм, балам...

Ламиганың кара кашлары тагын нидер әйтергә теләгәндәй биеп алды. Күңеленнән кызына төшендерәсе уен кичерде: «Әй, кызым, беләм, эчтән җаның көя булыр, аларның яман сүзләрен кабул итәрлек түгелдер шул, ул чир булып йога, үзенекен эшли... Үзеңне бер үк кулга алырга тырыш инде, болай да коры сөяккә калып барасың бит. Авырып-нитеп китә калсаң, мантый да алмассың. Балаң бар, борчуларың аңа да чир булып күчәр. Син тыныч булсаң, ул да сау-сәламәт үсәр...»

Хәтирә әнисенең уйларын сизгәндәй сорап куйды:

—Нишләргә соң мина, әни?

—Тыныч бул! Сабыр төбе—сары алтын, диләр. Аларны син генә үзгәртә алмыйсың. Нәсел-нәсәбе бар, булдыклары шул—тешләк. Уена салганны ун елдан соң да онытмыйлар... Кода, минемчә, редакторга үч саклый булыр.

—Ник?

—Ник дип, теге вакытта газетада бер мәзәк нәрсә бастырган иде ич ул. Ни, бер колхоз рәисенең күзгә каршында үз-үзе сөйләнүе турында. Шул көлкене укыгач, нишләргә дә белмәгән. Мине мыскыллап язган, дигән, «мин аны редакторлыктан барыбер кудыртам» дип жикеренгән. Моны мина кодагый үзе әйтте. Ул чакта редакторны глава гына яклап калган.

Тукбаев эшеннән китсә, шундый хәбәрләр дә йөри, редакторга районда көн бетәчәк, диләр.

—Бетсә,—диде Хәтирә, әнисе сүзен элеп алып.—Газетада андый хатлар бастырып ятмас...

Ламига каршы төште.

—И-и, кызым, бу дөньяда берсе китсә, икенчесе табыла ул. Редактор китеп кода үзгәрәме? Бер бәйләнчек—гел бәйләнчек булып кала, моңа аның сәбәпләре табылып кына тора. Үзен хөрмәт итә белмәгән башканы да хөрмәт итә алмый... Бер сөйкемсез—гел сөйкемсез инде ул...

Ламига, артыгын ычкындырдым, ахры, дип кызына карады.

Хәтирә, ни дип уйларга да белмичә:

—Хәзер өйгә кайткач нәрсә дип әйтәбез инде?—диде.

—Нәрсә дисең? Редактор, юкка баш катырып йөрмәгез әле, дип әйтте диярбез.

—Әтинең тагын ачуы кабарыр инде.

—Кабарса кабарыр...

—Олы башымны кече итеп сөйләшмим дияр.

—Дисә дияр.—Ламиганың ачулы йөзенә кызыллык йөгерде.—Ул әйтә дип үлеп булмый бит инде. Каян килгән патша! Әллә кем булганнар...

Кызы эндәшмәде. Ламига янә уйларга чумды: «И-и Алла, шушындый көннәргә калып, Байтирәк урамнарында ыстырам булып йөр инде... Тормышларының башы ук ниндидер ризасызлыктан, өнәмәүдән башланган иде, ахыры ничек булыр тагын?! Янәсе, алар абруйлы, дәрәҗәле. Киленнең бар яктан килгәне, акыллы булуы, үзләренә тиңе кирәк. Эчләре поша, җае чыккан саен, кызны кимсетергә, рәнҗетергә исәпләре. Минем кызым әрәм әле аларга, үзләре адәм рәтле булсалар иде. Янәсе, алар бай, дәрәҗәле гаилә. Кай төше мактаулы Хамайныкыларның?.. Ул дәҗҗал гомере буе кеше каргышы җыйган, гөнаһсыз кешеләрне тереләй күмдереп, бар, мактаулы, изге булырсың. Аңа каян килсен изгелек? Мулла битлеген киеп, кеше хакын аша, суширмәлеләрне дер селкетеп тор да аңардан миһербан-шәфкать көт, булмаганны. Намуслы бәндә сугыштан качып Үзбәкстан далаларына китеп котылмый ул. Сугышлар тынгач, монда кайтып, авыл советына кереп ояла да тагын әллә кемнәрне җәберлә, тол калган хатыннарның артын чәбәкләп йөр... Җирбит! Хәзер туксанга җитеп үлә алмый, урын өстендә каһәрләнә. Әле ул да шушы килен хәстәрендә тора, кимсетерлек кызмы ул? Әрәм әле ул аларга, әрәм...»

Бу вакытта алар Байтирәк ашханәсе турына килеп җиткәннәр иде. Тукталышта күрше Укчы авылыннан Нәзирә очрады. Ул больницадан дәваланып чыгып килә икән. Ябык чырайлы, нечкә гәүдәле Нәзирә тагын да тартыла төшкән, йөзе көлсу төскә кергән иде.

—Исәнмесез, Ламига апа!—диде ул, танышларын үз итеп.

—Исәнмесез, Нәзирә.

—Авылга кайтасызмы?

—Юк әле, соңрак кайтам. Монда кызларыма килгән идем... Син автобус көтәсеңме?

—Әйе, нишләптер килми. Бер автобус туктамый узып китте. Гомер-гомергә шушында булган автовокзалны сүтеп, әрмән килмешәкләренә кафе салдырдылар да халыкны кырга җәяү титакларга калдырдылар...

—Әйтмә инде.

—Түрәләргә акча җитми... Хәерченең актык ыштанын салдырмасалар ни булган?

Нәзирәнең төртмә сүзе район хуҗаларына кагылды. Чынлыкта барысы да үзара килешеп эшләнелә бит. Бу төртмәне ишеткән Ламига артык тукталып

торасы итмәде.

—Без җәяү генә атлый торабыз инде,—диде.—Кайтып житәргә күп тә калмады.

—Ярар, ярар…

Саубуллашкач та, саулыкка туя алмаган Нәзирә Ламиганың күз алдыннан китмәде. Курбаш клубында булган бер вакыйга исенә төште. Ул чагында булачак кода Динар Ишкәевнең, парторглыктан чыгып, колхоз рәисе булып эшләп йөргән чагы иде. Беркөнне ул колхозның урмандагы умарталыгында Казан кунаклары белән шәп кенә сыйланган, эчеп шактый гына кызган. Кунакларын урман буеннан озатып кайтышлый, Динар Хамаевич машинасында бер егетне таптата, аның аягы сына. Бу хакта колхозчыларның гомуми җыелышында гауга чыккач, ана дәгъва белдерелгәч, ул:

—Рульдә мин түгел идем, шоферым иде,—дип, гаепне гаепсез егеткә аударып калдырырга тели.

Шулчак арткы рәтләрдә утыручы әлеге Нәзирә, аның ялганына каршы төшеп:

—Ник кеше өстенә ягасын?—диде.—Үз гаебеңне танprincip килмиме әллә?

Ишкәев, күрше Укчы авылыннан килгән бу хатынның кемлеген танырга теләп, кызыл эскәтерле өстәл артыннан муенын сузып дәште:

—Кем анда башын калкыта? Фамилияң ничек әле синең?

—Нәрсәгә сиңа минем фамилиям?—диде Нәзирә, тешләкләнеп.—Әллә малаеңны өйләндерәсең бармы? Мин кияүдә инде.

Ишкәевнең күзләре челт-мелт килде, пеләш маңгае ялтырап-ялтырап китте.

—Ә-ә, синмени әле ул, мин беләм синең турыда,—диде.—Кияүгә чыкканыңны да, аерылып кайтканыңны да беләм…

—Белсәң соң, шуннан ни булган?

—Тик ятмый торгансыңдыр инде дим…

Шулчак Ишкәевнең мыскыллап көлүе Нәзирәнең ачуын чыгарды.

—Нәрсә, күргәнең бармы әллә?—диде ул, җикеренә төшеп.—Тәрәзәмне килеп чирткәнең юктыр бит? Чирткән булсаң, бүтән берәүнеке белән бутыйсыңдыр. Теге җырчы сандугачың белән саташкансың, син «сандугачлар»ны оста сайратасың бит… Бераз дөресен сөйләргә өйрән, гаебеңне таный бел, ичмасам. Мин председатель булдым дигәч тә…

Моны көтмәгән Ишкәев кара көйде, бүтән сүз куертырга теләмәде.

Ул көнне җыелыштан чыкканнар Нәзирәнең турылыгын хуплап: «Ну әйбәт тә иттең инде үзен, Ишкәевнең кирәген бирдең…»—диделәр. Тик, шушы хәлләрдән соң, Укчы авылы хатыны Нәзирә якын-тирәдә үзенә юньле эш таба алмады. Байтирәк тегү комбинатында аз гына акчага җыештыручы булып йөрде.

Ишкәев барыбер судан коры чыкты, машина белән кеше бәрдерү гаебен шоферы үз өстенә алырга мәҗбүр булды, эш судка барып җитмәде. Хәер, бәлагә таручы тапталып үлгән очракта да Ишкәевнең моңа җавабы әзер иде: «Ул үзе исерек килеш машина астына килеп керде…» Шуның белән бетте-китте. Аңа ышаналар. Ул экспертиза үткәрүчеләрне дә сатып ала белә. Ә сатылмаган кеше аз бит ул, аеруча хуҗаларга. Хөкемдарлар да иң элек түрәләр мәнфәгатен кайгырта. Бизнес ясый. Ул чагында Нәзирә карга күзен карга чукымаганлыгын аңлап җиткермәгән иде.

Алар урам буйлап тын гына атлый бирделәр. Ламига кызының сагышлы, моңсу йөзенә карап-карап алды, кызгану хисе кичерде. Ул бу халәтен сиздерергә тырышмаса да, Хәтирә күнеле сизенде. «Минем өчен аңа да борчу килде» дип уйлады. Бу хәлнең нигә болай килеп чыкканлыгына

аптырады, сорауларына җавап эзләде. Юкса ул ире Габит белән мәктәп елларыннан ук таныш, бер-берсен белеп, күреп, яратып өйләнештеләр кебек. Килен булып төшкәч кенә кайбер вак-төяк низаглар, «төчкерешеп» алулар булгалады анысы. Кадерле малайга әнисе сүзе дә, әтисе сүзе дә тәэсир итми калмады. Хәтта туксан яшьлек Хамай картның да оныгына карата үз фикере, үз киңәшләре бар иде. Өй эшләрен башкарганда иренең диванда телевизор карап ятулары, юк-бар сәбәпләр табып, өйдән чыгып киткәләүләре, сөяркәләре белән күнел ачып эштән соңгарып та, салгалап та кайтулары ешайды. Габите отыры үз эченә бикләнә барды, туры сораулардан читләште. Андый минутларда Хәтирә авыр, рәнҗүле хисләр кичерде. Шулай күзге көннәрнең берендә алар яхшы гына эләгешеп тә алдылар. Бакча бәрәңгеләрен алып кына бетергәннәр иде.

...Габит кая киткәнен әйтми-нитми капкадан чыгып барганда, ачуы килгән Хәтирә аның юлына каршы төште, кулына күтәргән яшь баласын иренә тоттырды да:

—Мә баланны, теләсә нәрсәнне имез, мин сиңа бала белән килмәдем,— диде һәм капкадан чыгып ук китте.

Хәтирә әнисе янына бармады, бераз тәпиләгәч, бакча артыннан күренми генә әйләнеп кайтты да, бүген дә сүтелмәгән агач йортның (алар башта шунда яшәгәннәр иде) тәрәзәсен ачып керде, бәрәңге салынган идән астына шыпырт кына төште, артыннан капкачын ябып куйды, өйгә барысы җыелгач ни булырын көтте.

Озак та үтмәде, килennнең чыгымлап китү хәбәре барысына да тиз җитеште. Күршедә генә яшәүче бертуган апалары да, яшелчә бакчасына кояш җылысына чыгып кунаклаган Хамай да өйгә кереп җитте. Ул, үзенең терәксез урындыгын алып, мич буендагы идән асты капкачы өстенә үк килеп утырды. Өйдә шау-шу, каенана кулына күчкән яшь бала елый да елый, һәммәсенең эче поша, ачулары йөзенә чыккан. Аеруча киң гәүдәле Сәлимә ханым калку түшен күркәдәй киергән. Аның түземлеге озакка бармады, ул, шартлап ярылыр дәрәҗәгә җитеп:

—Бу нинди тамаша?—диде.—Нигә чәпчи ул чебеш, рәхәтенә чыдый алмаган нәмәстәкәй?—Аның ярсулы карашы Габитка төбәлеп калды.—Бераз ир була бел, санлат хатынынны. Нәрсә җитми аңа? Ачмы ул, ялангачмы? Кадереңне белеп торасы урынга кеше мыскыллап йөри...

Габит каршы дәшмәде, әтисенекедәй түгәрәкләнеп килгән чырае, чебен кунганны да сизмичә, үзгәрешсез калды. Әллә хатыннар белән читтә чуалгалаганын уйлапмы, үз гаебен таныгандай, мыштым гына утыруын белде.

Кодагыенның күршедә генә яшәгән кыз туганы Халисә аларны тынычландырырга тырышты.

—Бераз үзегезгә дә катырак торырга кирәк,—диде ул, күзләрендә ут уйнатып.—Хатын-кызны бер дә азындырма аны... Шушындый мул, зиннәтле тормышта чүкердәшеп кенә яшисе урында киленегез җүләр сата... Нигә кәҗәләнеп йөргән була әле ул?.. Кайгырмагыз, беркая да китмәс, сыер да ашаган җиренә кайта. Бер дә юкка түгелдер, ялындырмакчы була торгандыр...

Идән астында барысын ишетеп торган һәр чәнечкеле сүз Хәтирәнен йөрәгенә уктай барып кадалды. Караңгыда бәрәңге өстенә чалкан яткан җиреннән ул әле бер, әле икенче ягына боргаланды, авыр сүзләрдән иреннәрен чәйнәр дәрәҗәгә житеште. Идән асты капкачын очырып җибәрәсе, шуннан атылып чыгасы килде, әмма сабырлыгын җыеп түзеп калды, үз өстенә атылган пычрак, гайбәт сүзләрне тыңлавын дәвам итте.

Менә көтмәгәндә Хамай да телгә килде.

—Әй-й,—дип сузды ул, ризасызлык белдереп, әле дә батынкы күзләрендә сакланган зәһәрлеген чәчеп.—Хатын-кызны кем шулай азындыра инде?.. Ир көен дә көйли белмәгәч... Безнең заманда чәче белән идән себерергә дә әзерләр иде. Хәзергеләр аягыңны җылы су белән дә юмыйлар. Кайтканыңны капка төбенә чыгып көтеп алалармы?.. Әй-й, безнең заманда булмаган хатын-кызның җенен чыгарырга чөйдә аркан эленеп торыр иде... Аларны соң башкача санлатып буламыни... Хәзергеләр бозылды, майларына чыдаша алмый. Узыналар. Чөнки рәхәткә чыгардык...—Хамай, тукталып, күзләрен челт-мелт китерде, фикерен туплап азапланды да дәвам итте:—Әй-й, җүнле хатын үз баласын иренә ташлап чыгып китәмени ул? Башта ук ялгышлык булган, малай кешесенә туры килмәгән. Алар җүнле нәселдәнмени соң?.. Җүнле булса, әтиләре гаиләсен ташлап чыгып китмәс иде...

Шушы урында битләре уттай кызышкан Хәтирәне «Алар җүнле нәселдәнмени?..» дигән сүзләр чыгырыннан чыгарды. Ул, бу хурлыкны күтәрә алмыйча, кушаяклап, бар көченә идән капкачын тибеп очырды. Урындыкта утырган Хамай урындыгы-ние белән, шампан бөкеседәй атылып, идән уртасына барып төште. Бертын ни булганын да аңламый тордылар. Аннары идән астыннан чәчрәп чыккан Хәтирәгә акаеп калдылар.

—Кем җүнле нәселдән түгел? Безме?—диде Хәтирә, Хамай каршында ярсынып.—Безнең нәселгә ни булган? Минем әти синең кебек Әҗәл елгасында сугыштан качып ятмаган ул, кабахәт... Бүре ерткычлыгы йокkандыр сиңа. Син, син бит...—Ул кирәкле сүзен әйтә алмый азапланды.—Минем әти гөнаһсыз кешеләрне терелəй күмдертмәгән... Монда кеше тикшергән буласыз. Үзегез кем соң?

Хәтирә ярсыды-ярсыды да, каенанасы кулыннан баласын алып, өйдән чыгып ук китте, туп-туры әнисе янына авылга юнәлде...

Бер атна чамасы узгач, Хәтирә янына Габит килде, тормышын җайларга теләп, аның кире кайтуын үтенде, үгет-нәсихәт итте. Аптырашта калган Хәтирәне үсеп килгән баласы уйландырды: «Ул әтисез үсәргә тиеш түгел!..» Аннары гына күнәргә, ризалашырга булды. Шуннан соң алар, үзара аңлашып, матур гына яшәп киткәннәр иде шикелле. Аяк астыннан шушы бәла—газетада басылган хат килеп чыкты да гауга кубарды. Каенатасы Динарга шул житә калды. Имеш, шундый дәрәжәле кешене газетада мыскыллап язганнар. Аның данлы-шанлы исеменә тап төшергәннәр...

Кияве белән кызы арасын һич тә суытырга теләмәгән Ламига күбрәк кодасы Динар Ишкәевкә рәнжеде...

Икәүдән-икәү җәяүләгән ана белән кыз, ак калай капка төбенә килеп җитәрәк, адымнарын акрынайта төште. Матурлап, фасонлап эшләнгән бу капканың як-якка ачылып ябылган олы ишекләреннән шәп машиналар керә-чыга тора, кечесеннән рөхсәт ителгән кайбер туган-тумачалар, таныш-белешләр генә йөри. Зур ике гараж капка читенә терәлеп, берничә машина сыярлык итеп салынган. Ак калай түбәле, тыштан ак кирпеч белән тышланган ике катлы нарат йорт капка өстеннән чыгып кукраеп тора... Өй эче кыйммәтле җиһазлар белән тулы. Шунда керү белән байлыкка табыну башлана. Әллә шуңамы, бу йортка керер алдыннан, Ламиганың аяклары тартышкандай итә, аңлашылмас карышу күңелендә төрле шик-шөбһәләр тудыра, нигәдер сагайта. Аны бирелә һаман да чит итеп, адашып кергән бер мескенгә карагандай түбәнсетеп каршы алалар сыман. Шул хис йөрәген кыбырсыта, аякларын тышаулый, ихтыярын чикли. Әнә теге кырыйда сүтелми калган гади агач йортларына килеп-китеп йөргәндә алай булмый торган иде. Ул йортта хәзер ялгызы гына яңа йортта сыеша алмаган туксан яшьлек Хамай яши. Аның янына хәл белешеп кереп-чыгып кына йөриләр. Ул инде шактый бетеренгән, акылы алышынып саташкалый. Ламига:

«Гомерләрне белеп булмый, авылга киткәнче анын хәлен белеп, янына кереп чыкмыйча булмас»,—дип тә уйлады, үзе кызы артыннан калмый капкадан эчкә узды.

Өйдә аларны чәйләрен әзерләп куйган Сәлимә кодагый каршылады.

—Кайтып та җиттегезме, әйдәгез, әйдә, чәйләр әзер,—диде ул, ачык чырай күрсәтергә тырышып.

—Көчкә арып-талып... Җәяү күп йөрелде,—диде Ламига.

—Хәзер Байтирәк зурайды шул. Әйдә утырышыгыз әле...

Өстәл артына килеп утырган Сәлимәнең бүселә төшкән калку түше анын бу йортта чын хуҗабикәлеген сиздерде.

—Кайларда булдыгыз соң?—диде ул, кызыксынып.—Редакторны күрә алдыгызмы?

Ламига, авыр сулап куйды да, теләр-теләмәс:

—Күрүен күрдек...—диде.

—Нәрсә ди соң?

—Нәрсә дисен, юкка баш катырып йөрмәгез, ди.

Сәлимә, гаҗәпләнеп, башын калкытты.

—Ничек юкка? Безне шулай мыскыл итеп язсыннар да...

Ламига аптыраганнан янә кул аркаларын ышкыштырды, аннан:

—Кодагый!—диде, үзенекен төшендерергә тырышып.—Редактор әйтә, ни, ди, монда беркемне дә мыскыл итү юк, ул хатта бернинди конкрет кеше турында язылмаган, андый хатларны без газетада еш бастырып торабыз, нигә сез гаепне үз өстегезгә аласыз, ди. Бер ялгансыз менә.

—Сон, Динар шулай дип бара бит, безнең турыда язганнар, ди. Бер дә белми генә әйтмидер инде ул. Әле кичә генә пәри кебек котырган иде.

Ламига уфтанып куйды.

—Белмим инде, нигә дип котырынырга кирәктер,—диде һәм өстәде:—Кодагый! Редакторга берәр үче бардыр коданың.

—Бар, бар. Булмыйча,—дип элеп алды Сәлимә.—Ул бит, аны мыскыллап, бер юмор да язган иде.

—Шул шул менә! Алар арасындагы мөнәсәбәтне белеп тә бетерә алмассың. Монда, кодагый, кызның бер гаебе юк. Редактор үзе дә шулай дип бара. Гөнаһлы булмагыз, ди. Үзләре теләгәнчә тыныч кына яшәсеннәр, ди. Судлашып йөрү беркемнең дә дәрәҗәсен күтәрми ул, ди. Һәм дөрес тә инде.

Хәтирә үз сүзен әйтергә кирәк тапты:

—Монда судлашып йөрергә минем ни гаебем бар?—диде ул.—Әйтәм бит, мин язган хат түгел ул.

Ламига кызы әйткәннәрен хуплады.

—Баланы нахакка рәнҗетү була күрмәсен инде, Ходай гөнаһсыннан сакласын...

Бу сөйләшүдән соң Сәлимә, йомшаргандай:

—Анысы шулаен шулай да инде,—дип килешкәндәй итте һәм, чынаякларга кайнар чәй өсти-өсти, ризыклардан авыз итәргә кыстады.

Чәен эчсә дә, Ламиганың тамагыннан ризык үтәрлек түгел иде, ул чемченде генә. Табын түгәрәкләнүгә, ул Хамайның хәлен белеп чыгарга булды, үзе белән алма согын алды.

Караватында бөгәрләнеп яткан Хамайны күрүгә, Ламиганың тәннәре чемердәп китте. Карт, вакытсыз өзелгән алма кояшта саргаеп бөрешкәндәй, бетәшкән иде. Сан-гәүдәсе, сүтелгән йомгактай, кечерәеп калган. Чыкмаган җаны гына бар диярсең. Барыбер дә төс-кыяфәтенә, эчкә баткан күзләренә карап, анын Хамай икәнен белеп була. Түгәрәк башының пеләш «аланы» улы Динарныкына караганда арткарак чигә төшкән. Юкарган баш тиресе

жыерылып-жыерылып сырланган, йөзе сулыгудан ияк асты тиреләре салынып тора, тамырланган нәзек муены сураеп калган. Күзләрендә ялтыраган сүрән очкыннар әле дә анын шул Хамай икәнлеген, тискәре холкындагы авыр халәтен чагылдыра. Торып утырыр өчен, тимер карават башына бау бәйләнгән. Күрәмсен, кече йомышын үтәр өчен аска чиләк куелган. Янәшәсендәге кечкенә өстәл өстенә төрле дарулар, ризыклар тезелгән.

Карт янына килеп баскан Ламига, тын алырга да куркып, авыр хисләр кичерде. Аны өй эчендә хөкем сөргән шомлы тынлык биләде. Хамай, янына кемдер кергәнлеген абайлагандай, башын ишек ягына таба борды да бер ноктага төбәлеп бакты. Шулчак анын колакка да саңгыраулыгы сизелде. Карт сәер халәт кичерде. Кинәт сыны тартышкандай дерелдәп-дерелдәп китте һәм ул курку катыш үз-үзенә сөйләнә башлады:

—Әнә ул тагын килгән... Хәйбул ул, Шабайның сугыштан кайткан бандит энесе. Исереп килә дә рәшәткә башларын сындыра башлый, тәрәзәләргә таш ыргыта... Миңа яный: «Әҗәлең миннән булыр, хаин!..»—ди. Миңа Суширмәдән китеп югалырга куша... Ул бандитны тагын төрмәгә утыртырга кирәк... Тотыгыз аны, ул мине үтерәчәк...

Анын бөрешкән гәүдәсе калтыранды-калтыранды да туктап калды. Ламига ана дәште.

—Хамай бабай! Нигә борчыласың? Синә беркем дә тими бит...

Хамай тавыш килгән якка борылды. Өненә килгәндәй аптырап сорады.

—Син кем?

—Мин Ламига булам.

—Ламига?

—Әйе, Ламига кодагый.

—Син каян килеп чыктың?

—Курбаштан.

—Анда безнекеләр исән-саумы?

—Кемнәр ул?

—Мәрьям...

Хамай моннан ун ел элек җирләнгән хатыны исемен атады. Моңа Ламига тагын гаҗәпсенде. Алар Курбаш авылына илленче елларда ук күченеп килгәннәр иде. Теге 1924 елгы вакыйгалардан соң Суширмәдә яшәп кала алмадылар. Шабай гаиләсен тереләй күмдерткәннән соң, авылдашларының каргышлы карашы аны туктаусыз эзәрлекләде. Ул еллар хатирәсен ишетеп кенә белгән Ламига үзалдына «Кеше каргышы төшми калмыйдыр шул...» дип уйлап куйды һәм Хамайны эзәрлекләгән Шабай энесе Хәйбулның ачы фаҗигасен күз алдына китерде...

Абыйсын, анын гаиләсен кызганган Хәйбул җан газаплары кичерә. Бераз салып алса, Суширмә белән Акширмә арасында бәргәләнеп бутала, Хамайны эзәрлекли...

Ламига үз-үзенә нәтиҗә ясады: кара күләгән, кая гына барсаң да, артыннан каламыни! Курбашка күченеп килгән Хамайнын яманлыгы да артыннан иярде... Инде томаннар артында калган ул вакыйгалар кемнәр өчендер онытылган, кемнәр өчендер юк. Ә Хамай күңелендә бикләнеп саклана, әледән-әле исенә төшеп, тынгы бирми, газаплый, бәгырен көйдерә... Көдрә башлы Шабай, кара толымнары билләренә җиткән Сәрмәния, күз яшьләренә тулган, җаннарына үлем куркынычы сеңгән уллары Шәйхулла, Шәех та анын күз алдыннан китми газап чиктерә... Күрәсең, ул, фани дөньяда кылганнары өчен, кыямәт көнендә ничек җавап тотудан куркып калтырана... Вакытсыз гүргә кергән Мәрьямен дә онытмый...

Уйга баткан Ламига, ихтыярсыздан: «Исән чагында хатыннарының кадерен белмиләр дә, аннары, исләренә төшкәч, соң була. Бер йотым су бирер кешең дә калмый...»—дип куйды. Аның хатыны Мәрьям, бүре янына бәйләп куйган сарык хәлендә, Хамай өрәгеннән гомер куркып яшәде. Хатынны иренең буйсындыручан карашы изде, сытты һәм иртәрәк дөнья куярга мәҗбүр итте...

Ламига алып кергән алма согын Хамай өстәленә куйды да сорады.

—Саулыкларың ничек соң, Хамай бабай?

—Үлеп булмый бит...

—Үләргә ашыкма әле...

Хамай дерт итеп уянып киткәндәй, башын тибрәтеп алды. Шушы минутта аның миенә якты нур үтеп кергәндәй итте.

Ул акылына килгәндәй тынып торды һәм:

—Ламига!—диде.—Хәл белеп керүеңә рәхмәт... Миңа инде күп калмады... Мине Курбашка Мәрьям янына алып кайтып җирләсеннәр, яме.

Баш очында ниндидер авыр рух бөтерелеп алганын сизгәндәй, Ламиганың күзләре тартышып куйды.

—И-и, Хамай бабай, үләргә ашыкма әле син...

Җавап булмады. Хамай Ламигага сәер генә карап куйды да, хәлсезлеген сиздереп, башын читкә борды... Ламига аны бүтән борчырга теләмәде. Шушы авыр тынлыкта Хамайны кинәт кенә ташлап чыгып китәргә аяклары тартышкандай итте. Аннары ул, читенсенеп кенә, ишеккә юнәлде.

Ламига ишегалдына чыккач, иркен сулап куйды. Киявенең капка төбенә кайтып туктаган «девятка» машинасы аны Корбашка илтергә көтә иде...

### Эт оясы

Тукбаев күңеле тантана итте. Ул әле Австралия, Төркия җирләрен аркылыга-буйга гизеп, ял итеп кайткан тәэсирләреннән арынып җитмәгән иде. Бүген исә шатлык өстенә шатлык: чит илдәге шәхси счетына бер миллион акча күчерә алды. Төрек егетләренең, районга килеп, мәчет төзергә дип тапшырган валюталары аңа ярап куйды. Ул берьюлы ике куянны атты: Абага районының төзелеш оешмасы белән килешү төзеп, Байтирәктә мәчет төзү мәсьәләсен валютасыз гына хәл итте, мәчетне якын араларда аякка бастырырга дип, куллар кысышты...

Аны мин барысын да булдыра алам дигән хис канатландырды. Чөнки ул югарыдагы кайсы ишеккә барып керсә дә, максатына ирешми чыкмый, түрәләрне үз вәгъдәләренә ышандыра, аларны районга кунакка да чакыра. Аныңча, тормыш тәгәрмәчен майлый, олуг кунагыңны сыйлый алу да зур осталык. Яшәү рәвеше шуңа корылган. Тапшырган бүләгең дә икеләтә файда китерсен. Бүләк тә акча! Ә акча, үз чиратында, акча эшли. Аның өчен башыңны эшләтергә кирәк, башыңны! Шулай булмаса, ул шушы өч катлы коттеджны бушка салдыра алыр идеме? Районда мондый байлыкларга кем ирешкән? Юк, беркем дә!

Ул хан сараедай йортында рухланып йөрде, туктап-туктап алды, күзләрен кояш нурлары чагылдыргандай, авызын колакларына кадәр җиткереп елмайды. Тәмле ашаудан кабартмадай кызарып пешкән шома битләре ялтырап-ялтырап китте. Аны күтәренке хисе бүлмәдән бүлмәгә йөртте. Эчтәге нарат бүрәнәләрдән хуш ис таралды. Өй җиһазларын гына күр, күз явын алырлык! Аларны ул кайсын Төркиядән, кайсын Италиядән кайтартты. Барысы да заманча, зиннәтлеләр. Тукбаев үзен бер дә чит ил байларыннан ким сизмәде. Ә нигә?! Теләсә, «Тойота», «Мерседес» машиналарына утырып элдертә ала. Тагын ни кирәк?

Ул шулай, үзен бөек хис итеп, зур йодрыгы белән шыкылдап торган юан бүрәнәләргә сугып-сугып алды. Мондый йортта яшәүләре үзе бер бәхет, жанга шифа. Жәннәт инде! Юкка гынамы ул бу агачларны Себер урманнарыннан ук кистертеп кайтартты? Һәм дә бик дөрес эшләде, дәрәжәсен төшермәде. Бирегә кемне генә кунакка чакырсаң да, хет Дәүләтхан Бариевичның үзен, абруең төшми, йөзен ак. Бергә-бергә, затлы ризыклардан сыйлана-сыйлана, үзенне дә ана тиң санап, фикер алышасың… Кунак чакырып сыйлауның да сәнгати төшенчәләрен белергә кирәк. Һәркем тәмлене ярата, берәүнен дә татлы ризыктан йөз чөергәне юк. Кешене тәмлегә ияләндерү, яхшылап сыйлау зарур, һәм үзен дәрәжәгә ия бул! Аннары дәрәжә үзенекен эшли. Әле берәүнен дә югарыдан мәтәлеп төшәсе килми, һәркем кәнәфиенә тешетырнагы белән ябышкан. Үзенә жил-янгыр тидермәс өчен өстән кушканны үтәргә генә тора. Чөнки власть иреген югалтасы килми, аның сүзе—закон булырга тиеш! Түрәлек ул синең арка терәгең дә, менә шушы байлыкларың да, тормыш дингезендә рәхәтләнеп йөзәр жилкәнен дә…

Аның бу уй-фикерләрен бүрәнәләрдән чекерәеп карап торган ботак «күзләр» дә «синеке дөрес, синеке дөрес» дип раслап торган күк тоелды. Ә хуш исле бүрәнә ярыкларыннан сыпылып чыккан сагызлар, күз яшьләре сымак, кеше хакын хакла дигәндәй, дәгъва да белдерәләр иде сыман. Әмма аңа барысы да хәләл булып күренде, тиеш саналды. Үзен Алланың кашка тәкәседәй санап, ул йомшак кәнәфигә килеп утырды. Аннан, бишектә тибрәнгәндәй, урындык күчәрендә әйләнә-әйләнә як-ягына каранды һәм яшьлек хатирәләренә бирелде…

Ул үскәндә үк, буйга кечерәк булса да, төптәй нык, көчле иде, батыр булырга омтылды, иптәш малайлары белән туптай тәгәри-тәгәри көрәште. Үсә төшкәч, техника тирәсендә чуалды. Күршедәге Әхми абыйларының капка төбендәге ташландык «Запорожец» машинасы эченә кереп утырыр иде дә, мәктәпкә дә бармыйча, көннәр буе аның рулен әле уңга, әле сулга боргалап мәш килә, өйгә әнисе чыгып дәшкәч кенә керә торган иде… Инде көчкә-көчкә жиденче классны тәмамлагач, колхозда ат көтәргә теләми, район үзәгенә—Байтирәккә менде, шунда буталып йөри-йөри киномеханик һөнәрен үзләштерде. Бар нияте ничек тә машина алырга иде. Кинодан калган тиеннәр машинага житмәгәч, тотты да шабашкага китте. Шунда, кулы бик эшкә ятмаса да, шактый шомара төште, бригада туплады, бүтәннәрне эшләтә алды. Өйдәгеләргә кесә тутырып акча алып кайта башлагач, ана, урлашмый микән бу малай дип, башта ышанмый тордылар. Юк, баксаң малай булдыра торган егет икән… Тора-бара тракторист-комбайнер да булды ул. Аннары, иптәш егете ярдәме белән, авыл хужалыгы институтының агрономнар хәзерләү факультетына барып керде. Институтны тәмамлагач, агроном акчасына эшләп йөрисе килмәде, озын беләкләр аны сәүдәгәрлеккә алып килде. Райпода эшли башлагач, «кемнең кулында—шуның авызында» дигән төшенчәне яхшы үзләштерде. Әйе, һәркемнең авызы бар, ул үз кирәген сорый. Тукбаевтан да сораучылар күбәйде, ул кирәкле кешесенә карап кына бирергә өйрәнде. Шуны чамаламаса, ул мондый дәрәжәгә ирешә алыр идеме соң? Тот капчыгыңны!..

Ул, үз фикерләрен хуплагандай, кәнәфиендә тибрәлә-тибрәлә елмайды. Һәм кинәт, нидер исенә төшереп, урыныннан сикереп торды да хатынына дәште.

—Иркә! Иркә, дим!

Аш-су ягында кайнашкан хатыны, кара бөдрә чәчләрен тибрәтеп, ире каршына килеп басты.

—Нәрсә булды?

—Әйдә бер утырып шампан эчик әле.

—Нәрсә уңаеннан?—диде Иркә, гаҗәпсенеп.
—Кәеф шәп бүген, көн удачный булды.
—Нәрсә оттың?
—Отмадым, просто миллион «заработал» һәм аны чит ил чутына салып та куйдым.
Акчага, байлыкка хирыс Иркә канәгать елмайды.
—Син молодец минем...
—Шампан эчә-эчә, шахмат та уйнап алырбыз.
—Миңа җиңеләсең бит,—диде Иркә, аңа сынап карап.
—Җиңелсәм җиңелермен, мин шахматта синең кебек район чемпионы түгел түгелен дә... Шахмат миңа шушы миләрне,—ул бармакларын чигәсе турында бөтерде,—яхшырак эшләтергә ярдәм итә, логик ходлар ясый белергә өйрәтә. Ә главаның башы начар эшләргә тиеш түгел. Беләсеңме шуны?
Иркә килешкән булып көлде.
—Беләм, беләм...
—Минем бу башны бутарга теләүчеләр болай да җитәрлек.
—Кемнәр инде ул?
—Авылдашың Нәфис абый да кирегә сукалый... Куам мин аны районнан. Моңарчы түздем, синең сүзне тыңлап та...
Иркә Рәсименә текәлеп калды. Күңеленнән «Әллә көнчелек саклап син аннан үчеңне алмакчы буласыңмы?» дигән уй узды. Һәм ул тыныч кына сорады.
—Нигә?
—Әйткәнне анламый... Динар Хамаевич та, кергән саен, редактор кирәкмәгән материалларны бастыра, дип яманлый. Әле киленнәренең ниндидер мәкаләсен бастырганмы?
Иркә тере күзләрен ялтыратып сорады.
—Син ул мәкаләне үзең укыдыңмы соң?
—Минем гәҗит укырга вакыт бармы?
—Ә мин укыдым. Ул алар турында түгел. Бер кыз баланың мәхәббәттә ялгышудан үкенгән зары гына. Башкаларга гыйбрәт өчен язылган адрессыз хаты. Аны кем ничек кабул итә бит. Синең Динарың чит кул белән утлы күмер чүпләмәкче, шул гына.
—Нәфисеңне яклап үлдең инде...—диде Рәсим, кинәт килешмичә.
Иркә аптырап калды.
—Ничек Нәфисеңне?—Ул аның күзләренә керердәй булып текәлде.—Әллә мин аның белән уйнашып йөргәнме? Мине үзең белән чагыштырма. Яшьлектә кем кем белән очрашмас...
Рәсим артыгын ычкындырганын абайлады.
—Ярар, ярар...—диде, Иркәне тынычландырырга тырышып.—Баш-күз чыкмаган, әйдә бу шампанны тотып куйыйк әле.
Тукбаев, шампан эчә-эчә, шахматта ике тапкыр оттыргач, уеннан тукталды. Аннары ул, көне буе чабып арганнарын юып төшерергә теләп, йөрәк сурәтендәге төрек ваннасы эченә кереп ятты. Сабын күбекләре өстендә түгәрәк башы гына торып калды. Ул, үз-үзенә кызык тапкандай, аяк асларына үрмәләгән сабын күбекләрен читкәрәк өреп куды. Шул вакыт телефон шалтырады. Аның судан чыккан юан кулы стенага ябыштырылган телефон трубкасына таба үрелде.
—Ал-ло! Кем әле бу? Кем, кем? Борнаш?.. Ә-ә, Борнаш Шәехович... Каян килеп чыктың әле син? Чыгардылармы? Шәп булган. Ирекә чыгуың белән! Яхшы, яхшы. Очрашыргамы? Әйдә, иртәгә минем кабинетка сугыл. Иртәнге якта. Шунда сөйләшеп бетерербез... Булды, килештек...
Ул трубканы элгәч, уйлана калды: «Борнаш минем белән нәрсәгә

очрашасы итте икән? Берәр эш-мазар кирәктер инде... Аны кая куярга соң? Тагын райпога тыксаң, тоткынны үз эшенә кайтардылар дип уйлаулары бар... Ну и что? Кеше нәрсә уйламас, барысын да исәпкә ала башласаң... Бу дөньяда бер генә яшисе. Районга пока мин хуҗа! Минем сүзгә каршы килмәсләр, аңлатырмын. Борнаш эш рәтен белә диярмен. Белүен дә белә инде. Хәзергә райпо рәисе урынбасары булып эшләп торыр, аннары күз күрер... Борнашны поддержать итми ярамый, юкса оятыңа көч килер. Теге вакытта нинди акыллы поступок ясады бит, бөтен гаепне үз өстенә алды...»

Тукбаевның колагына тышта эт өргән тавыш ишетелгәндәй булды. Ул хатынына дәште.

—Иркә! Иркә, дим!..

—Нәрсә тагы? Тыныч кына юына да алмыйсың, һаман мин кирәк.

Иркә ванна ишеген ача төшеп җавап көтте.

—Барсны ашаттылармы бүген?—диде Тукбаев, күбекле башын суза төшеп.—Эт өргән кук, ач түгелдер бит ул?

—Нишләп ач булсын, райподан Чуртан каравылчысы Кәрим килеп этеңне ашатып китте. Ашханәдәге калдык-постыкларны тутырып килгән иде.

Тукбаевның ачуы чыкты.

—Тукта әле, син нигә дип Әхәт Хәбировичны Чуртан дип атыйсың. Кешене мыскыл итеп. Давай, кончай это...

—Мин кеше сөйләгәнне генә әйтәм ич,—диде Иркә, акланырга тырышып.

—Оныт ул сүзне!

Иркә дәшмәде, борылып китеп барды.

Тукбаев тынычлана төшкәч, корт чаккандай кабаланып, телефон номерын җыйды.

—Ал-ло! Динар Хамаевич! Бу мин әле. Минем яңа эт оясы ни хәлдә? Аны шушы көннәрдә ясап бетерәсе иде бит. «Сельхозтехника» начальнигы белән уртак фикергә килдегезме соң? Салих Сәләхиевич тоткарлый?.. Ну, вәгъдә биргәч, ни җитми аңа? Әллә тимер уголоклар, калай таба алмыймы? Тапсын, аның эше шул... Тыңламый икән, чарасын күр. Ә-ә? Ты как считаешь, анысы синең кулда. Давай, бу мәсьәләне иртәгә ачыклап бетерик...

Ул трубканы элүгә, авыз тутырып борычлы сүзләр әйтте. «...Вәт тинтәкләр, бер эт оясын ясый алмасыннар инде,—диде, чит илдән самолетта алып кайткан нәселле этен кызгангандай.—Эте эт кенәме! Бер елда бозау кадәрле булып үсте. Бер каптырып алса, ычкынырмын димә! Шушындый йорт-дәүләтеңнең сакчысы булган эткә оя да кора алмасыннар инде. Барска аерым игътибар, яхшы шартлар кирәк...»

Ул ваннадан чыкты да, сөртенгән сөлгесен иненә салып авыр үлчәмдәге көрәшчедәй атлап, икенче катка—йокы бүлмәсенә юнәлде. Баскычның урта бер җиренә җиткәч, хәл алгандай, фасонлап станокта кырдырылган тирәкләргә таянып, янә үз-үзенә куанып йортын күзәтте. «Шәп бит, шәп!» дип тел шартлатты. Аннан шул шәплек рухы аны янә җиңелчә генә өскә күтәрде. Йокы бүлмәсендә аны Иркәсе көтә иде...

* * *

Иртәнге эш, гадәттәгечә, телефоннар шалтыраудан башланды. Тукбаев иң элек хуҗалык, оешма җитәкчеләре белән элемтәгә керде, кемнәрнеңдер үтенеч-зарларын тыңлады, аерым күрсәтмәләр бирде. «Инеш» кооперативында узачак семинарда төп игътибарны нәрсәгә юнәлтергә кирәклеген, аерым алганда, сөт күрсәткечләрен ничек арттыру турындагы

кайбер фикерләрен туплады. Шул вакыт югарыдан кызыл телефон шалтырады. Телефонда министр Сөнгатов үзе иде. «Рәсим Юлаевич!—диде ул.—Менә нәрсә, «Россельмаш» заводының генераль директоры Савельев Петр Анатольевич килә. Без аны Республиканың берәр районында кунак итеп җибәрергә планлаштырган идек. Абага районы главасы белән сөйләшенгән иде дә, ул отказ бирде, рәсми делегация белән чит илгә китеп бара. Син Петр Анатольевичны, безгә кирәкле кеше инде ул, Байтирәктә кабул итә алырсыңмы?.. Кайчан дип, бүген кичкә. Әйе, вакыт аз калды анысы. Җавап хәзер кирәк. Уйла, уйла... Нәрсә, оештыра аласыңмы?

Бер мәлгә тынып калган Рәсим Юлаевич башын алай да, болай да эшләтте һәм, исәп-хисабын тотып, тәвәккәлләде:

—Була, Фәрһад Акаевич,—диде.

—Алайса килештек...

Тукбаев трубканы куйгач, тәвәккәл таш яра дигәндәй, башын өскә чөйде һәм боргаланып, кабаланып эшкә кереште. Иң элек аэропорттагы танышы Тимәш белән элемтәгә керде, вертолет белеште. Ул моны унай хәл итте. Ашау-эчү якларын оештырырга, мунча хәстәрен күрергә дип, райпо рәисен чакыртты, калган кирәкле кешеләрне кисәтеп чыкты. Ишкәевкә дә тиз генә кереп чыгарга хәбәр салды.

Бу вакытта Ишкәев сәгать сигездә башланачак «Инеш» кооперативы семинарына әзерләнә иде. Эт оясын ясап бетермәгән «Сельхозтехника» башлыгы Салих Сәләхиевичны ничек тукмакларга кирәген алдан ук планлаштырды. Аны тәнкыйтьләп чыгу өчен үзенә якын колхоз рәисләре белән элемтәгә керде. Рәисләр әлегә аның сүзен тыңламый калганнары юк, юкса эшнең ахыры ни белән бетәчәген яхшы төшенәләр иде. Ул, Тукбаев чакыруын ишетүгә, икенче катка кабалана-кабалана менде. Алгы бүлмәдә Тукбаевның кабул итүен көткән бер көдрә чәчле кешене күргәч аптырап китте. Ул аны кайда күргәнлеген, кемлеген хәтерләргә тырышты. «Әйе, әйе, Абага районы райпосында эшләп, ирегеннән мәхрүм ителгән Борнаш бит ул... Ул бандит монда ничек килеп чыккан тагы? Әллә тоткынлыктан качканмы?»

Ишкәев шулай уйланып, Борнаш белән исәнләшми генә, Тукбаев бүлмәсенә узды.

—Менә нәрсә, Динар Хамаевич,—диде Тукбаев, Ишкәевкә бик тә җитди проблема барын сиздереп.—Әле генә министр Сөнгатов шалтыратты. Аның тәкъдиме буенча без Казанга киләчәк «Россельмаш» генераль директорын үзебездә яхшылап кабул итәргә тиеш булабыз. Моны йөзгә кызыллык китерми генә эшләргә кирәк. Директорны матур табигать кочагына алып чыгарга, мунча кертергә!.. Кыскасы, татарча күңелен күреп, яхшылап кунак итәргә!.. Калган «ский»ларын уйлашып бетерербез. Мин вертолет заказал... Ничек яхшырак булыр, Аксай урманы аланлыгындагы мунчаны сайлыйбызмы?

—Иң кулай урын шул булыр дип беләм, Рәсим Юлаевич,—диде Ишкәев, килешеп.

—Аннары,—дип сүзен дәвам итте Тукбаев,—килгән кунактан безгә дә файда тиярлек булсын инде ул. Син беләсеңме, безгә бит яңа «ДОН» комбайннары житми, ә алар шушы генераль директор Петр Анатольевич карамагында.—Ул учын учка шапылдатты.—Безгә аңа кул куйдырасы хатларны алдан әзерләп куярга кирәк, күчтәнәчләрен дә хәстәрләргә кирәк. Мунчада бераз җебеп, йомшара төшкәч, гадәттәгечә, әкрен генә аңа хатларны төртергә... Аның бер имзасы ничә миллионга төшкәнен чамалый белергә кирәк!..

Ишкәев җавап тотмый гына тыңлады, хуҗаның һәр сүзен күңеленә

сендереп барды. Ахырдан:

—Мин сезне аңладым, Рәсим Юлаевич,—диде, җаваплылыкны үз өстенә алырына ышандырып.

Ишкәев бүлмәдән чыгарга әзерләнгәндә сәгатенә күз салды. Инде җиде тулып килә иде. Ул ишеккә таба бер-ике адым атлауга борылып сорады:

—Рәсим Юлаевич! Бүген «Инеш» кооперативы семинарында катнаша алырсыз микән?

—Катнашырмын!—диде Тукбаев, уйлана калып.—Аны озакка сузмабыз инде. Минем әбәткә кадәр каладан да әйләнеп кайтасы бар.

—Яхшы...

Ишкәев килешеп сөйләшеп бетергәч, пеләш башын кагып чыгып китте. Кабул итү бүлмәсендә чиратта торучылар янына райпо рәисе Әхәт Хәбирович та килеп баскан иде.

Тукбаев, кемне кабул итәргә дигәндәй, өстәл читендәге күзәтү телевизорына карады. Ишек артында аппарат җитәкчесе Борнаш юлына аркылы төшкән дә: «Сез кем буласыз? Главага нинди йомыш белән керергә йөрисез? Мин башта ачыкларга тиешмен,—дип, аңардан сорау ала иде.

Тукбаев шунда ук Борнашны чакыртты, аны урыныннан торып каршы алды, ике куллап күреште һәм урын тәкъдим итеп сорады:

—Ну, исән-сау гына кайтып җиттеңме?

—Күргәнеңчә, сау-сәламәт, зарланмыйм,—диде Борнаш.

—Яхшы. Кәефләр ничек? Нинди планнар белән?

Сүзгә сак Борнаш, ничегрәк әйтергә дигәндәй, бераз тынып калды һәм, иләнгән гадәтенчә, каш астыннан сөзеп карады.

—Планнар шул инде минем,—диде ул.—Миңа берәр эш тәкъдим итә алмассызмы дигән идем. Үзең беләсең, мин эшсез яши торган кеше түгел.

—Аңлыйм, аңлыйм...—Тукбаев торып йөреп китте, аны башы тулы эшләре ашыктыра төште һәм ул Борнашка таба борылды.—Үзең ничек уйлыйсың соң, берәр конкрет теләгең бармы?

—Әлегә юк...—диде Борнаш, иң башын кагып.—Кинәшми булмый бит.

—Яхшы,—диде Тукбаев, үз карарына килеп һәм сигнал төймәсенә басты.

Сәркәтип кыз Ләйсән шунда ук ишекне ачып башын тыкты.

Тукбаев аңа:

—Әхәт Хәбирович керсен!—дип боерды.

Райпо рәисе Әхәт керүгә баш кагып исәнләште дә ни өчен чакырткannarын төшенмичә катып калды.

—Утыр!—диде аңа Тукбаев, аннан Борнашка ишарәләде:—Син бу кешене беләсеңме?

—Юк,—диде Әхәт.

—Белмәсәң, таныш бул! Борнаш Шәехович Шабаев була ул. Райпо системасында үз кеше. Эш рәтен яхшы белә. Син аны үз ярдәмчең итеп алып тор.—Ул пауза ясады һәм өздереп сорады:—Буламы?!

Тукбаев карышканны яратмый.

—Сез әйткәч була инде,—диде Әхәт, теләсә-теләмәсә дә.

Тынгысыз Тукбаев чорсызланып кабаланды, ашыкты, аннары, Борнашка борылып:

—Ярыймы шулай?—диде.

—Мин риза,—диде Борнаш, тәкъдимнән канәгать калып.

—Алайса, бу сөйләшүне тәгәлләп торыйк, калганын икенче очрашкач хәл итеп бетерербез.

—Аңлашылды,—диде Борнаш һәм саубуллашып чыгып китте.

—Син ашыкма,—диде Тукбаев Әхәткә.—Бүген «Россельмаш» заводының генераль директоры Байтирәккә киләчәк. Аны бик яхшылап каршы алырга, кунак итәргә туры киләчәк. Маршрутлар билгеләнер... Район ашханәсендә дә, Аксу урманындагы кунак йортында да иң затлы ризыклар, эчемлекләр әзер булып торсын. Бер яхшы гына бүләк турында да уйла. Мунчадан башлап, һәммәсен тәртипләп бетерәсең, отсечку не дать!..

Райпо рәисен озаткач, иртәнге ыгы-зыгылар кими төште, Тукбаев, сигез тулырга егерме минут кала, «Джип» машинасына утырып, «Инеш» кооперативына элдерде. Аны болында, җәйләүдәге терлекчеләр йорты янында, хуҗалык, оешма җитәкчеләре көтеп алды.

Машинасыннан чыгып, җитәкчеләр янына килүгә, ул Ишкәевкә боерды:

—Әйдә башлагыз!..

Хуҗалык җитәкчеләре, Тукбаевтан тәнкыйть тукмагы эләгә калса дип, терлекчелек тармагындагы үз күрсәткечләрен өйрәнеп, ничек җавап тотарга алдан әзерләнеп килгәннәр иде. Ни гаҗәп, Ишкәев сүзен сөт-савымнан башламады, турыдан-туры «Сельхозтехника» башлыгына мөрәҗәгать итте:

—Салих Сәләхиевич! Эт оясын эшләп бетердеңме?—диде.

Еш кына баш өянәге чиреннән интеккән Салихның көтелмәгән сораудан йөзе агара төште. Күп еллар идеология эшендә калыпланган холкы аңа әдәп саклау кирәген оныттырмады.

—Юк,—диде ул, тыныч кына.

—Ник?

—Калай табып булмады.

—Шул бер эт оясын да ясый алмагач, син нинди начальник инде?—диде Ишкәев, ярсый төшеп.

Каушый төшкән Салих Сәләхиевич:

—Соң,—диде, Ишкәевкә карап,—үзегез, калайга кумәм, дидегез, калайны май заводыннан да, Калачтан да, Акъярдан да вәгъдә иттегез, берсендә дә юк, бирмәделәр.

Ишкәевнең хәйләле күзләре майлы таптай ялтырап алды.

—Булмагач, юк инде ул сездән, үзем тотынган булсам...

Түбәнсетү сизгән Салих Сәләхиевич сүзеннән кире кайтмады.

—Ул эт оясына күпме тимер уголоклар гына китте,—диде.—Бәләкәй генә булса иде ул, аның размеры дүрт метр киңлектә, алты метр озынлыкта. Әле биеклеге никадәр! Гади генә эт оясы булса иде, өч машина сыяр гараж зурлыгында бит ул. Аның түбәсенә генә бер йортлык калай кирәк...

—Булса соң?!—диде Ишкәев, зарлануны ошатмый һәм Тукбаев алдында сүзен өстенгә чыгарырга тырышты. Артислыгын эшкә җигеп, Салихның баш өянәге чире килгәндәгечә, аны мыскыллап, башын кырын салып, калтырана-калтырана йөреп китте, тилегә сабышкан кешедәй, селәгәйләрен агыза-агыза, түгәрәкне әйләнеп чыкты һәм:

—Иптәшләр, менә шушындый кешедән нинди эшлеклелек көтеп була инде?—диде.

Җитәкчеләр алдында үзен хурлауга түзә алмаган Салих Сәләхиевич, берике адым алга чыкты һәм, бер ботын тотып, Ишкәевчә аксый-чатанлый йөреп китте. Ишкәев колхоз рәисе булып эшләгәндә, исерек килеш машинасында әйләнеп, тез капкачын авырттырган иде. Шуннан бирле аның вакыт-вакыт бер аягы аксаклап киткәли, аннан уколлар белән рәткә килә. Аксаклап киткән Салих, ниһаять, тукталып, Ишкәевкә борылды.

—Син дә бит кеше шикелле генә йөри алмыйсың,—диде.—Чатанлыйсың,

кешене мыскыл иткәнче, үзенне бел...

Бу кадәресен көтмәгән Ишкәев пеләш башын як-якка боргалады.

—Иптәшләр!—диде ул, эчтән ачуын баса алмыйча.—Безнең арада шушындый җитәкче кеше булырга тиешме?.. Кемнәрдә нинди фикерләр бар?—Аның күзләре алдан сөйләшеп куелган Калач рәисенә төбәлеп калды, тегесе «мин әзер» дигән ым какты.—Әйдә, Әюп, әйт үз фикереңне?

Әюп, маңгай читенә салынган берничә бөртек чәчен артка чөеп, кин түшен киерә төште дә:

—Егетләр, гафу итегез, болай бала-чага уены уйнап кына эш бармый ул. Без авыл хуҗалыгы профессорына тиң Динар Хамаевичның дәрәҗәсен шушылай түбән төшерә башласак нәрсә була ул? Мин шуны беләм, дөрестән дә, «Сельхозтехника»га бирелгән комбайннар рәтләп ремонтланмый, ә ремонтланган техниканың сыйфаты начар. Моны мин ничек итеп тә аңлата алмыйм. Тиздән урып-җыюга төшәбез...

Әюп сүзләреннән соң, «Балан» хуҗалыгы рәисе Газиз кабынып алгарак чыкты.

—Безнең «Сельхозтехника» тырма тешләрен дә рәтләп ясый белми...—дип тезеп китте ул.

Аның сүзен Ишкәев үзе күтәреп алды.

—Иптәшләр! Ана тырма теше нәрсәгә? Ул безгә, әнә күрәсез, үз тешләрен генә күрсәтә белә. Шәп бит теше, үткен...

Җилнең каршы яктан искәнлеген чамалаган Салихның сабырлыгы төкәнде.

—Кайсыгызының «Сельхозтехника»га әҗәт акчасын күчергәне бар?—диде ул.—Без бушка эшләргә тиешме? Оятсызлар икәнсез. Район бюджетыннан бүленгән акчалар иң элек сезгә китә.—Ул Ишкәевкә төбәлде.—Ул акчаларны син ничек кирәк, шулай бүләсең. Кая синең намусың? Көнгә ничә төрле битлек киясең?..

Моңарчы түзеп торган Тукбаев, шушы урынга җиткәч, Барс этедәй чәйнәп атарга җитешеп, Салих Сәләхиевичка җикеренде:

—Ничек син начальнигына шулай «син» дип әйтә аласың?

—«Сез» дияргә ул аны не заслуживает...—диде Салих, дулкынлануын яшерә алмый.

Хәлнең мондый юнәлеш алуын көтмәгән Тукбаев, урынбасары Ишкәевкә тел-теш тидертәсе килми, мунча ташыдай кызды, Салихка җикеренде:

—Бар, кайтып кит моннан, үзеңне бүгеннән эштән азат дип сана...

—Ярар...—диде Салих, рәнҗүен эченә йотып һәм борылып китеп тә барды. «УАЗ» машинасына утырып кайтырга чыкты.

Салих машинасы сикертмәле юллардан доңгыр-доңгыр барды, барган саен аның ачуы кабарды, офтанды: «Эх дөньясы, дөньясы—эт оясы... Эт оясын кормасаң да, гараж ишеген ясамасаң да башыңа тукмак төшә... Өстәвенә әле теге «дуска», әле бу «танышка» дип бүләген ал!.. Байтирәктән тәмам эт оясы ясадылар... Эт оясында нинди гаделлек көтәсең? Аларга синең тырма тешең кирәкме? Эх дөнья, дөньясы...

Байтирәккә кайтып җитәрәк, Салихның «УАЗ» машинасын Тукбаевның «Тойота»сы выжылдап узып китте. Аның семинар эшләрен Ишкәевкә тапшырып, Салих урынына «Калач» колхозы рәисе Әюпне куярга кушып, Казанга китеп барышы иде.

Салихның чигәләре кысты, уйларыннан башы чатнар дәрәҗәгә җитте. Машинасы Байтирәк урамына барып керүгә, унга борылды, балтасы кулыннан төшкән кешедәй, тизрәк кайтып караватына егыласы гына килде...

## Имза аулау

Байтирәк өстеннән әйләнеп очкан вертолет урам кешеләрен гаҗәпкә калдырды. Ул бер әйләнде, ике, аннары, ээәрлекләнгән качкынның эзенә төшкәндәй, кыйгачлап, болын-басулар, урман өсләреннән очып бара-бара, Аксу урманы аланлыгына барып чыкты. Канатларын зырылдатып, алан уртасына төшә башлады. Әйләнгән калаклар җиленнән, бу нинди корыч чикерткә дигәндәй, янәшәдәге ак каеннар чайкала-чайкала дулкынланды. Юкә, имән агачлары да, яшел яулыкларын болгап, тартыша-тартыша бөгелеп-сыгылдылар. Вертолет җиргә якыная барган саен, аландагы яшел үләннәр, ялтырый-ялтырый, җиргә посып шуышты. Арырак алан култыгындагы умарталыкта ояларыннан керә-чыга очкан бал кортлары да, кинәт чыккан «җил-давыл»ны сизеп, мәтәлә-мәтәлә тайпылып очтылар.

Алан уртасына төшеп утырган «канатлы чикерткә» ишегеннән иң элек Тукбаев ялтырап чыкты, үзен шушы янәшә-тирә биләмәләренең хуҗасы икәненә нык ышанып, як-ягына каранды, күнел көрлеген чәчеп елмайды. Аның артыннан таза, юан гәүдәле генераль директор Петр Анатольевич Савельев күренде. Тукбаев кунакка, рәхим итегез дигәндәй, башын ия төште. Савельевнын бүлтәйгән корсагы алгарак чыкты һәм ул бертын яшел аланны күздән кичерде. Байтирәк җирлегендә үскән ак каеннар аның күңеленә хуш килде, «Русские березы!» дип, эчтән горурланып алды. Аннары лап-лоп атлап җиргә төште. Ул, алан матурлыгына сокланып, башын як-якка боргалады һәм агачтан салынган кунак йортына таба атлады. Килеп җитәрәк, агачлар арасына кереп поскан райпо «КамАЗ»ының тәрәзә пыялалары кояшта ялтырап алды. Димәк, олуг кунакка хәстәрне Әхәт алдан күрә белгән. Шик тә юк, мунча да ягылган, атаклы мунчачы Рибаб та биредә булырга тиеш...

Гөрләшеп күлле кунак йортына уздылар. Биредә йокы, ял бүлмәләре аерым-аерым, һәммәсе зәвык белән эшләнгән, кирәгенчә җиһазландырылган. Теләсән, бильярд уйна, теләсән, телевизор кара...

Аланлык белән танышып чыккач, беренче эш тамак ялгаудан—сый-хөрмәт күрсәтеп башланды. Өстәлдәге тәм-том, ризыклар күз явын алырлык. Райпо рәисе—Чуртан Әхәт француз шәрабларына кадәр тапкан. Кабымлыклар бихисап!.. Балык уылдыклары, тозлы гөмбәләр ялтырап нур чәчә, тәлгәш-тәлгәш, «күз-күз» виноградлар, баллы кәрәзләр жемелдәшә. Кызарып пешкән виктория җиләкләре дә күңелләрне ымсындырып тора.

Өстәлләр артына утыруга, Тукбаевның гаярь кулы шешә башларын шалт-шолт борып ачты:

—Петр Анатольевич!—диде, олуг кунакка хөрмәт күрсәтеп.—Коньякнын кайсын телисез?

Петр Анатольевич саллы, саргылт йөнтәс кулын күтәрә төште дә:

—Пас!—дип, коньякны кире какты, чекерәеп утырган аракы шешәләренә ым какты:—Только водку давай, «Ханскую» или «Старый Казань»,—диде.

—Байтирәк җирендә хәерле сәгатьтә булсын!—диде Тукбаев, беренче рюмкаларны чәкештереп.

—Так и быть!..—диде кунак.

Аннан мактаулар китте. Сүзгә райпо рәисе Әхәт тә, данлыклы мунчачы исемен йөртүче «Сельхозхимия» начальнигы Рибаб та кушылды. Рибабнын гөрләп торган көр тавышы үзенә бер өстенлек, эшлеклелек сиздерде. Центнерлы гәүдәсе аракыны да шәп сеңдерә, кайберәүләр кебек исереп җебеми. Аның алай булуы Тукбаев өчен кулай. Ана да кунак алдында эчми утыру яхшы түгел, ә Рибаб аны коткара, кунакны шәп итеп чабындыра да. Шунын өчен дә исереп китүдән сагайган Тукбаев аны читтә калдырмый. Әхәт исә

табын остасы, кирәксә, кыз-кыркынны, чибәр чәчбиләрне таба белә. Бүген дә, олуг кунакны хөрмәтләп, чибәркәйләренә чәкчәкләр тоттырып чыгартты. Байтирәк гүзәлләренең кояштай балкыган йөзләре Петр Анатольевичта да соклану тудырды...

Аракы шаукымы әңгәмәне җанландырып җибәрде. Башта сүз яна оешкан Байтирәк районының үсеше, аның киләчәге, газ кертү, асфальт юллар салу турында барды. Гомумән, район күрсәткечләрен күтәреп алдынгылыкка чыгару.

Тукбаев эчен кытыклап торган «ДОН» комбайннары мәсьәләсе турында сүз кузгатырга иртәрәк дип санады. Петр Анатольевичның бераз йомшара төшүен көтте.

Эчкә хәмер сеңдереп, матур гына утырганда, өйгә кереп калган бер бал корты өстәлдәге кәрәзле бал тирәсендә безелдәп оча башлады. Бал корты кунакны чага күрмәсен тагы дип, Тукбаев нишләргә дә белмәде, як-ягына каранды, күрше бүлмә ишеге артындагы иярченнәренә дәшәргә арусынмый, кунакка мондый тәкъдим ясады.

—Петр Анатольевич! Безнең монда шәп кенә мунчабыз бар бассейн белән. Теләсәгез, күлендә дә коена аласыз...

Кунак риза булды. Аны мунча белгече Рибаб үз артыннан ияртте.

Шул вакыт Тукбаев күрше бүлмәдәге аппарат җитәкчесе Тәкәевкә дәште.

—Мәхмүт Талипович! Хат-документларың тәртиптәме?

—Барысы да әзер, Рәсим Юлаевич, менә шушы папка эчендә,—диде Тәкәев, каш астыннан сөзеп карап.

Папка Тукбаев кулына күчкәч, Тәкәевне аш-су өстәле янына алып килде дә:

—Слушай!—диде, табын өстендә хуҗа булып очынган бал кортына ишарәләп.—Куып чыгарыгыз әле шуны, чага күрмәсен тагы...

Тәкәев, кулына бер тастымал алып, бал кортын куарга керешә. Кагына торгач, корт тәрәзәгә очып килде, иреккә юл эзләп, пыялага бәргәләнде, аны бораулап тишәргә теләгәндәй безелдәде. Тәкәев кортны кулы белән тотып иреккә чыгарыр теләде, әмма чагар дип курыкты, кашын җыера-җыера, тастымалны җилпи-җилпи тәмам үчләнде. Ул бал кортын фатир басарга кергән җинаятьчедәй күрде, аны бәреп үтерергә теләде... Прокуратурада эшләгәндә никадәр гаепсез җаннарны газап чиктерде...

Тастымал астында калырга теләмәгән бал корты бер тәрәзәдән икенчесенә очты. Әйтерсең ул Тәкәевнең яманлыгын, кара рухын сизде, шулай үзен эзәрлекләүчене үчекләргә, аның ач йөзен кояш яктылыгында чагылдырып калырга тели, тәрәзәгә шап-шоп бәрелгән тастымал астыннан оча да чыга, оча да чыга. Аннан тагын икенче тәрәзәгә күчә, «без-з-без-з» килеп пыяланы бораулый... Иреккә омтылган бал корты әллә онытылып китте, әллә Кылчык Тәкәевнең сөңгедәй кадалган керфекләре арасыннан агылган чәнечкеле, зәһәр карашын сизеп бетермәде, көтмәгәндә тастымал астында калды да, нечкә биле белән бөгәрләнеп, тәрәзә төбенә килеп төште. Тәкәев җан биреп тиберченгән кортка: «Бал урларга кермиләр аны...»— дип мыгырданды...

Ул кире бүлмәгә узганда, түр өстәл артында Тукбаев белән райпо рәисе Әхәт әңгәмәләрен дәвам итте:

—Әхәт Хәбирович!—диде Тукбаев.—Ак кала хуҗасы Өметбаев белән сөйләштем. Ул безнең районга утыз «КамАЗ» машинасы вәгъдә итте. Машиналарның бәяләре артканчы, биргәндә алып калырга кирәк. ОКСтан төзелеш фондына дип бирелгән акчаларны күчереп торырбыз. Так что, киләсе атнада райпога машиналар кайткан булсын...

Бу вакыт Рибаб, мунчада ах-ух килеп, кулына тоткан ике каен себеркесе белән, шап та шоп иттереп, ләүкәгә сузылып яткан юан корсаклы Петр Анатольевичны тәгәрәтә-тәгәрәтә чабындырды. Кунак эссегә шактый чыдам, шактый калын тиреле булып чыкты. Бүселә төшкән корсак тиресе, җәя сымак тартылып, кендеген калкыткан. Киң йөнтәс җилкәсендәге көмешсу тамчылар, каен себеркеләре чапылдап килеп төшкән саен, чәчрәп очты. Олуг түрә мунча ләззәтеннән ах-вах килде, «как хорошо!..» дип пошкырынды. Рибаб парны кызганмады, суны кызган таш өстенә чүмечләп сипте. Бөркелеп чыккан эсселек кунакның җилпучтай кин җилкәсе өстеннән шуыша, Рибаб, пар таралып беткәнче дип, себеркене уплап та, суллап биетә, үзе җитмәсә «ха-ха-ха»лап көлеп шаярта.

—Петр Анатольевич! Арканны ышкырга кызлар кирәк түгелме?—ди, аннан идән почмагында флягасы белән торган балга ишарәләп өсти:—Тәнеңә бал сылап юындырырлар, безнең кызлар баллыны ярата төшә. Ха-ха-ха....

Петр Анатольевич Рибабның көлүенә кушылып шаяртты:

—Картайдык инде... Яшь кызлар белән хурлыкка калуың бар.

—Сезнең яшьтәме? Әле дөньясын җимертергә була. Ха-ха-ха...

Петр Анатольевич дәшмәде. Аннары, житәр инде дигәндәй, әкрен генә ләүкәдән идәнгә шуышып дигәндәй төште дә бассейнга кереп чумды...

Мунчадан чыгып, кабат өстәл артына утырышкач, Тукбаев уңай моментны ычкындырырга теләмәде, дилбегәне үз кулына алды.

—Петр Анатольевич!—диде ул, тәвәккәлләп.—Безгә яңа «ДОН» комбайннары кирәк иде...

Аны тынлап бетергәннән соң, Петр Анатольевич болай дип белдерде:

—Без быел сезнең республикага йөзгә якын комбайн кайтартырга планлаштырдык.

—Анысы яхшы,—дип өтәләнде Тукбаев.—Ни, безгә шуның бер утызын, именной итеп, Байтирәк районына, дип кайтартсагыз иде, Петр Анатольевич. Тегеләй булганда.... Безгә кимендә утыз кирәк. Без инде сезгә хат та әзерләп куйган идек.—Ул ялт кына папкадан хат чыгарып сузды.—Менә ул!..

Петр Анатольевич, кәгазьгә язылганнарны күздән кичерә-кичерә, бераз битарафлык күрсәтеп, көрсенеп куйды. Тукбаев, аның бу халәтен яхшы шәйләп, кунакның кәефен күтәрү өчен бар осталыгын эшкә җикте.

—Бик тә үтенеп сорыйбыз, Петр Анатольевич! Без сезгә бөтен Байтирәк халкы исеменнән мөрәҗәгать итәбез, аңлый күрегез инде...

Ни булырын көтә торгач, ниһаять, Петр Анатольевичның калын иреннәренә елмаю кунды. Шуны гына көткән Тукбаев кунакка зур хөрмәтен сиздереп елмайды, аннары:

—Очень, очень прошу Вас, Петр Анатольевич...—дип ялагайланды, акча кәгазьдән башланганын яхшы белеп.

Ниһаять, кодрәтле имза сырланды... Имза аулау мәҗлесе гөрләп кичкә кадәр дәвам итте...

## Мин дә депутат...

«Кеше хәлен кеше белми, үз башына төшмәсә» дип көрсенде Нәфис. Редакция эшләренең авыр баруы, район башлыкларының газета эшенә тиешенчә ярдәм итмәве, булышмавы аның кәефен кырды. Аларга синең газетаң кырыгынчы хәсрәт, үз мәнфәгатьләре мөһим. Чынлыкта «Джип»ларга утырып чапкан түрәләрнең ачыктан-ачык кылган гамәлләре, кара эшләре күнелне рәнжетте, күрә торып аларны мактарга теле бармады.

Ул, каршылыклы уйлар кичереп, чираттагы газета санының соңгы җөмләсенә нокта куйды. Яна хәбәрләрдән аның игътибарын туксан яшьлек Хамайның вафат булуы җәлеп итте. Ишкәевләр гаиләсенең, туганнарының кайгысын уртаклашкан бу язманы редакциягә иртән генә китереп киткәннәр иде. Үлем һәркем өчен кайгы дип фикер кылды ул. Бу фани дөньядан кылган гөнаһларын юып китә алган һәр кешенең урыны җәннәттә булсын!.. Кем генә булуга карамастан. Адәм баласы тәкъдиренә язганны үзгәртә алса икән...

Өстәл өстендәге папка эченнән «Тагын сайлаулар турында» дигән язма—Тукбаевның клубта ясаган чыгышы килеп чыкты. Аны хәбәрче Факил диктофонга яздыртып кайткан иде. Бу турыда газетада кыскача гына мәгълүмат бирелгән иде. Аның тулы эчтәлеге Нәфисне кызыксындыра төште, бер укый башлагач аннан аерыла алмады: «В нашем районе выдвигается кандидатом в депутаты в Госсовет Нишанов Фарзи Мурзаевич, который вновь порадует нас. Он еще не выдвинулся, кандидат только. Две неделе прошло, уже за эти две недели он оказал значительную поддержку. Вот, например, он приезжал в наш район, чтобы встретится с труженниками колхоза «Балан». Был он там и уехал. Ему мы задали один депутатский запрос. Говорили, вот телевизор не можем смотреть из-за отсутствия дорогостоящего трансформатора. Он этот вопрос решил, выделел нам денег на ретранслятор...—Ул татарчага күчеп сөйләвен дәвам итте:—Алла боерса, шул ретрансляторны алып кайтсак, телевизордан дүрт каналны да чиста итеп карыйбыз...—Тагын русча сөйли башлады.—Настолько он пунктуальный человек, он в районе Балыклы был депутатом, там больницу построил, газ провел и дороги построить помог. Значительные поддержки от него были. Он еще по нашему району только кандидат, поймите меня правильно, вот вчера мы приехали с коммунальщиками в Казань «Жилькомхоз». Нам нужно КТП, трансформатор для электростанции. Он тоже дорого стоит, у нас работает два водонасоса. Приезжали мы туда, а денег нет и нет... Если не было бы депутата, мы повернулись бы и ушли. Я от его имени говорю, так-то так, такой будет, он у нас был... Вообщем, туда-сюда... И те сразу задумались. Сами начали искать деньги. Посидели, посидели и раз нашли деньги. В понедельник мы поедем забират ретранслятор уже. Вот, что значет депутат Фарзи Мурзаевич!.. Я рад очень, что он есть. Здесь я хочу сказать, что он пройдет, не пройдет вопросов нет. Он на два района один. У нас избирателей десять тысяч, а в районе Балыклы дватцать пять тысяч. В Балыклах, там за него голосуют сто процентов, потому, что настолько его значимость поняли, они уже его не отпускают никуда. Но и мы даже все, если не проголосуем—он пройдет. Пятьдесят и плюс один процентов он набирает, вопросов нет. Но надо больше процентов голосов иметь, чем в Балыклы. И мне легче было бы Даулятхан Бариевичу сказать от имени народа!..

Говоря о себе, я тоже кандидат... Наш район, честно говоря, административно-территориальный... Для выбора глав районных администрации—так решили... Раз я главой работаю, может я еще так не заслужил, но меня выдвинули. Ну, поймите, меня выдвинули, раз выдвинули, пройдем не пройдем, у нас район хороший. Алла боерса, тут вопросов нет не пройти. Любой человек, по моему, пройдет, тем более без альтернативы. Но, есть но. Допустим, я пройду шестьдесят восьми процентным голосованием, и я приду скажу от имени народа Байтиракцев. «Вот, Давлетхан Бариевич, избрали меня... А тут нам надо, допустим, новый клуб. Я от имени народа буду говорить. А он скажет или подумает: «Народ ведь за тебя шестьдесят процентов только голосовал». И от ворот поворот

будет. А для того, чтобы процентов больше надо... Алтмыш процент белән үтеп, халык исеменнән сөйләп булмый...».

Шушы урынга житкәч, Нәфис язманы читкә этәрде, кашларын жыерып гажәпләнде. «Тукбаев ишеләр парламентта йоклап утырырга, кушканны үтәргә генә кирәк инде...» дип уйлады, аларны жимгә, «кормушка»га борынын төрткән балыкларга тиңләде.

Нәфис депутатлыкка кандидат Фәрзи Морзаевич белән район үзәгендә булган очрашуларның берсендә үзе дә катнашкан иде. Аны шунда район мәшгульлек үзәге башлыгы купшы Алия Тутаевна чыгышы шаккатырган иде.

—Кемнәр чыгыш ясарга тели?—дигәч, ул белдекле кыяфәттә торып басты да сөйләп китте:

—Сез, Фәрзи Морзаевич, безнең өчен бик зур кеше. Алай гына да түгел, безнең өчен күктән төшкән бәхет. Без сезнең тырыш хезмәтегезне Байтирәктә яшәп тә, бик ерактан да күреп-тоеп торабыз, ярдәмегезне һәрчак сизәбез. Монда, Рәсим Юлаевич әйтеп узганча, сүз сезнең Байтирәк районыннан депутатлыкка узу-узмавыгыз турында барырга тиеш тә түгел. Сезнең кандидатура безнең районнан йөз дә ун процент белән узачак. Безгә Сезне Аллаһы Тәгалә үзе биргән. Мин, алдагы көнебезне кайгыртып, болай дип тә уйлыйм: менә сез, Фәрзи Морзаевич, киләсе сайлауларда да шушылай безгә килеп, безнең Байтирәк районын сайлап алырсыз микән? Ә мин шуны бик телә идем...

Нәфис ихтыярсыздан Үзән клубындагы отчет-сайлау жыелышында бер сыер савучы хатынның чәчрәп чыгуын да искә төшерде:

—Нигә сез терлекчеләр йорты янындагы мунчаны бардакка, фәхешханәгә әйләндерәсез?—диде ул, Тукбаевка карап.

Мондый сорауны көтмәгән Тукбаев аптырап китте.

—Кемнәр бардак ясый?..

—Сез!—диде хатын, тәтелдәп.—Үзегез дә киләсез бит шунда.

—Минем хатын-кызлар белән килгәнем юк.—Ни дип тә әйтергә белмәгән Тукбаев авызыннан ычкынган сүзнең мәгънәсен абайламыйча калды:—Хәзер анда килмибез инде, икенче мунчабыз бар...—Ул акланырга мәҗбүр булды:—Соң, килгән кунакны мунча кертми булмый бит инде... Без бит аны районга акча алыр өчен эшлибез.

—Акча да биргәнегез юк...—диде хатын үҗәтләнеп, төшкән теше арасыннан зәһәрлек бөркелде.

Тукбаев аны тынычландырырга тырышты.

—Ну, шулай эшләмәсәң булмый бит. Түрәләрнең бер имзасын куйдырыр, печатен суктырыр өчен дә бер пот тоз ашарга кирәк. Аңлагыз, башны тилегә салып йөреп кенә бирмиләр ул акчаларны...

Сәхнәдә өстәл артында Тукбаев белән янәшә утырган «Үзән» совхозы директоры Идрис Юнысович шушы әкәмәтне күреп кызарды, чырае бүртенде, әлеге хатынга ачуы чыгып, әвен кадәр гәүдәсе белән торып басты.

—Ярар,—диде ул, бу турыда сүзне бетерергә теләп.—Ул мунчаны иртәгә үк бульдозер белән төрттереп аударырбыз...

Жыелыш ахырдан, Тукбаевның тәкъдимен искә алып, Идрис Юнысовичны бертавыштан янә директор итеп сайлады...

## Шашлык таптап бию

Кояш иртәдән юмарт елмайды. Тирә-юнь бәйрәмчә хозур.

Бүген Иделгә сәфәр кылучы район житәкчеләренең дә күңелләре күтәренке. Алар сабан туеннан соңгы бу сәяхәткә, ял сәфәренә үзләре

белән хәләл җефетләрен дә иярткәннәр. Район башлыгы Тукбаев: «Ял итү, күнел ачу бергә-бергә булсын!»—дигән. Шуңа да аеруча хатын-кызларның йөзе шат. Алар бу сәфәргә киенеп-ясанып килгән, үзара таныш-белешләре белән ачылып сөйләшәләр. Юкса кайчан болай бергә очраша алырлар иде. Йөзләрендәге куанычлары яшьлектәге мәхәббәт хисләрен уяткан диярсең, күңелләрендә җилкенү, рух күтәренкелеге. Алар шушы сәяхәтне оештыручы хакимият башлыгы Рәсим Юлаевичка изге теләкләр телиләр, рәхмәт сүзләрен ирештерәләр. Алар шул рәхмәтләрен Иркә аша да җиткерергә теләгәндәй, хатынын әйләндереп алганнар да аеруча хөрмәт белән ачык йөз күрсәтергә тырышалар... Нәфис тә көлеп торган Иркәнең ачык йөзен, читләтеп-читләтеп кенә булса да, күзәтмичә булдыра алмады... Әйтерсең алар, элеккеге кебек, Иркә белән икәүдән-икәү Акъярның инеш ярындагы юан талга сөялеп калганнар... Ул кулларына урын таба алмый, чая кызның дугаланып килгән сылу билләренә тартыла, аңа сыешканнан-сыеша бара, аннан, аның кайнар сулышларыннан кабынып киткәндәй, йөрәге леп тә леп тынгысыз тибә башлый, шул мәл кызның җылы кочагында эреп онытыласы да килә... Әмма кыз ай-һайлап ялт кына кочактан шуып чыга. «Тынычлан! Алай ярамый...»—ди, шашкын хисләрен йөгәнләргә ишарә ясый, үзенең тәрбиядән килгән әдәплелеген саклый... Нәфиснең аны үпкән саен үбәсе килә, кочагыннан әзгә дә һич тә чыгармас иде. Иркә: «Җитәр инде...»—дигәч кенә туктап кала... Аның матур-матур хыяллары әнә шул яшьлек хисләре белән үрелеп үсә генә барды. Ул аңа көннәрдән бер көнне өйләнергә дә тәкъдим ясады. Ул Иркәдән: «Белмим шул, әни нәрсә әйтер... Мин бит яшь әле...»—дигән җавап алды. Аннары аларның бер-берен яратуларын белгән әнисе аңа үз кинәшен биргән. «Ярлыга кияүгә чыксаң, гомереңхәерчелектә үтәр, син шуны телисеңме?» дигән. Риза-бәхиллек булмагач, аралар өзелде, өзелсә дә хәтердә сакланып калган яшьлек хисләре, юк-юк та, үзен искә төшерттереп куя шул...

Нәфис, инеш буендагы тал хатирәләрен исенә төшерүгә, төркемдәгеләр белән исәнләшеп, Казаннан кайтартылган ике зур автобусның берсенә узып, тәрәзә кырыена килеп утырды. Озак та үтмәде, салонда гөрләшү-шаярулар китте. Нәфис Сәриясе янында булмагач, кәефе кырылды, эче пошты. Кичтән ул аңа шалтыраткан да иде. Коллектив белән калада тамак ялгап аласын әйтеп, «Акчарлак» ресторанына янына килеп торырга да кушты. Тик Сәрия ризалашмады, үпкәләде.

Сүзнең ахыры һаман да шул юк-бар көнләшүгә кайтып калды:

—Кичә син кайда булдың?—диде ул аңа телефоннан тикшерүчедәй сорау алып.—Өеңдә ник кунмадың?..

Янәсе, Нәфисе, төнлә шалтыраткач, телефон трубкасын алмаган, димәк, ул өйдә кунмаган, ятлар янында булган... Кая барсын инде ул?! Өйдә иде югыйсә, өйдә. Бакча эшләре белән мәш килеп, соң гына кереп яткан иде. Күрәмсең, талчыккач каты гына йоклап киткән, телефон тавышын ишетмәгән. Бәлки, хатыны шалтыраттым дип юри шыттырадыр аны, гадәттәгечә, тикшереп, сынап кына карагандыр. Ничек кенә булмасын, янәсе, Нәфиснең «ялганын» тавышыннан, тел төбеннән тота, шуны ачыкламыйча йокыга да китә алмый... Ярый ла аның бу гамәлләре чын ратуга гына корылган булса. Тик Сәриянең вакыт-вакыт бер дә кирәкмәгәнгә шикләнүләре Нәфистә рәнҗү хисләре дә тудырды, аның шикле карашлары, гөнаһсызга әйтелгән төртмә сүзләре—һәммәсе җанына тиде. Шуңа да карамастан ул бу хәлләргә күнегергә, урынсыз сүзләргә игътибар итмәскә, хатынының җан тынычлыгын саклап калырга тырышты. Әмма, ни хәл итәсең, бер тузган нервлар бирешә, Сәриянең үзен дә авыр халәткә куя, ахыр чиктә тынгысыз уйларга били. Нәфис тә, кулыннан балтасы төшкән

кешедәй, бимазалана. Гаеп нидә?.. Җавап табылмый. Юкса Сәриясенә ире күңелен күреп җибәрсә ни булган? Бар булган эшләрен тизрәк башкарыр, хыялларын тизрәк тормышка ашыра төшәр иде. Хатыны янына да, назларга сусап, мәхәббәтен чәчәк аттырырга теләп, канатланып кайтыр иде. Ә юк, холык дигән нәрсә син теләгәнчә генә үзгәрергә тормый. Аның сине һаман хыянәттә гаепләгән рәнҗүле карашлары йөрәкне җәрәхәтли, аннары күңел кояшынны кара болытлар каплап киткәндәй була. Түзмәгәч, ачуы тышка бәреп чыга:

—Сиңа нәрсә җитми?—дип сорый.

—Син...

—Мин бит беркая да китмәгән, Байтирәктә генә.

—Мин кемгә кияүгә чыктым?

—Миңа...

—Сиңа шул, ә син минем янда юк...

—Байтирәккә кайтмагач, мин нишлим соң? Һәм мин ни эшләгән?

—Үзең беләсеңдер...

—Мин белмим, син белгәч әйт соң? Нишләгән мин? Минем турыда берәр яман сүз ишеткәнең бармы?

—Син мине күрмисең, мин синең өчен юк. Син үзеңне генә кайгыртасың...

Нәфис сабыр итте, туктап калган Сәриясен юатырга тырышты:

—Алай ярамый бит инде. Мин дә кеше... Бергә ни гомер кичергән, инде кызыбыз үсеп җиткән, син һаман шул бер нәрсә турында кирәкмәгәнне тукыйсың... Мин кая, нинди чит кеше янына барган? Син болай уйланып үз-үзеңне генә бетерәсең. Йөрәк белән алай шаярмыйлар. Кан басымың күтәрелү, «стенокордия» дигән нәрсә ул сиңа уен эш түгел...

—Аңа син гаепле... Бөтен саулыгымны бетердең...

—Тагын мин. Мин булмасам, нишләр идең икән?

—Син бар бит, бар...

Аптыраган Нәфис уйга кала. Аны Сәриясен үз сүзләренә ышандыра алмау бимазалый. Нигә аңлашу юк? Юкса бәхет, мәхәббәт—бер-береңне аңлаудан башлана... Берең авылда, икенчең шәһәрдә туып-үсүгә дә карамый.

Нигә дип кайтырга булды соң ул Байтирәккә? Үз-үзеннән качаргамы, әллә күңеле авылга, туган якларына тарттымы? Йә булмаса, Сәриясенең тиктомалга үпкәләүләре аны шушы адымга этәрдеме? Байтирәккә кайтса да, ул тынгысыз халәтеннән котыла алмады, бар булган борчулары артыннан иярде. Сәриясенең шикле карашлары аны Казаннан торып та эзәрлекләде, дәгъвасын белдерә килде. «Сиңа Казанындагы уңай фатирында яшәп, заводта инженер булып эшләсәң ни булган? Бәлки инде, югары дәрәҗәгә дә ирешкән булыр идең...»—диде ул, аның китүе белән ризалашмый. Ә Нәфисне редакторлыкка чакырып кодалаулары ымсындырды... Байтирәккә кайтып эшли башлау белән планнары чәлпәрәмә килде. Ул үзенең хакимият түрәләренә яраклаша алмавын тиз тойды. Табан ялау аның эше түгел иде. Аңа дуслардан битәр дошманнары арта баруын күтәргә генә калды...

Автобуслар кузгалып калага юл алды. Нәфиснең уйчан күзләре тәрәзәгә төбәлде. Юл буенда артка шуышкан басулар, артка чабышкан каеннар аның уй йомгагын сүтте. Ул Сәриясенә дәгъва белдерде. Ярар, мин «Акчарлак» рестораны янына килеп торырмын дисә, аңа ни булган соң?.. Беренче тапкыр очрашып танышып киткәндә уртак телне тиз таптылар югыйсә. Алар цехташлары белән завод клубына концертка барганнар иде. Урыннары янәшә туры килде. Шунда якыннан сөйләшеп китәргә җай чыкты. Шул кичне ул аны озата да кайтты... Шимбә-ял көннәре заводның ял базасы—«Атлашкино»га бардылар. Урман эчендәге саф һавада рәхәтләнеп чаңгы

шудылар, пар каенга сөялеп, иркен сулыш ала-ала, туктап ял да иттеләр. Күзләр күзләргә төбәлде. Нәфис, тора-бара, кызның өйләренә дә кереп йөри башлады. Аңа кыз тәртипле күренде. Әтисе сугыштан кайтмаган, тол калган әнисе өч бала белән авырлыкның бар михнәтләрен татый, ачлык кичерә... Берсендә әнисе, Атлашкинодан ял итеп кайткач, аңардан болай дип сорап куйды. Нәфис ул сүзләрне ачык калган ишек аша ишетеп торды. «Бар жирен дә исән-саумы, кызым?»—диде. Шулчак Сәрия: «Исән әни, исән...»—дип көлде. Ул Нәфискә ышанганлыгын сиздерде. Сәрия аңа ошады, ул чибәр дә... Нәфис, вакытны озакка сузмый, өйләнергә тәвәккәлләде... Матур гына яшәп киттеләр, уртак куаныч, кызлары Көләч туды... Нәфис кызын үлеп яратты, аның өчен барысын эшләргә әзер торды.

Нәфис, ни генә уйласа да, Сәриясен юксынды, хатыныннан башка күңел ачып йөрүне килештермәде, аның алдында үзен яман эш кылгандай сизде. Ул бер үк вакытта сәяхәткә бармый калуны житәкчеләр белән санлашмау дип тә кабул итте.

Шау-шулы, жырлы-моңлы автобуста житәкче ролен Тукбаев урынбасары Фаил Сибгатуллин башкарды. Аның янәшәсендәге Фәнис—көрәшче егет—оста комментатордай, чәпчеп ботка пешерүеннән туктамады, Байтирәк районын мактады. Район данын атаклы көрәшчеләре, фәлән-фәләннәр күтәрә дип санап китте һәм үзен дә кыстырып куярга онытмады. Сафка баскан төзелешләр саналды, аерым күрсәткечләргә басым ясалды, главаның кайгыртучанлыгы, тырышлыгы искәртелеп узылды. Баксаң, анынча, Тукбаев белән Ишкәев авыл хужалыгы профессорларына тиң икән...

Купшы Алия Тутаевна сүз алгач, һәммәсенә ошарга тырышып, килде-китте шигырен сөйләде. Аннары ябык чырайлы урынбасар Фаил Сибгатуллин, сытык йөзенә ачыклык кертергә тырышып, белдерү ясады: «Товарищи! Урманга житкәч, бер ун-унбиш минутка тукталып алабыз. Аннан соң до Казани туктап тормаячакбыз».

Сибгатуллинның чытык чырае Нәфискә Тукбаев бүлмәсендәге сөйләшүне исенә төшертте.

Ул көнне Нәфис башта, сабан туенда уйнатылачак лотереяларны алырга дип, Сибгатуллин бүлмәсенә кергән иде. Бүлмәдә алар урамында яшәүче олы яшьтәге Маша түти утыра иде.

—Нәфис абый! Нигә урамыгызга газ кертмисез?—диде Фаил, төксе генә.—Менә монда Мария Сергеевна көн саен килеп утыра да, газ кертмисез дип, мине аптырата... даже газ өчен акчасын да бирергә тели, ә аннан акча алучы юк...

Көтелмәгән тәкъдим Нәфисне аптырашта калдырды һәм ул, көлемсери төшеп:

—Мин урамыбызга газ кертүдә жаваплы кеше түгел ич,—диде.—Бу—газовиклар эше.

Жавап урынбасарга ошамады.

—Син—редактор, житәкче кеше...—диде.

—Шуннан ни булган?

—Ни булганын күрәсең бит, менә көн саен бер вопрос белән килә дә утыра, килә дә утыра. Нишләтим мин аны?

—Ә мин нишләтим? Ул сезгә мөрәжәгать итә, мина түгел. Ул урамда мин старший түгел.

—Эш старшийлыктамы?!—Сибгатуллин тавышын баса төште.—Знаете, газ трассасы салу өчен йөз мең акча сорыйлар. Смета буенча аны район администрациясе түләргә вәгъдә итте. Газ начальнигы Исаев, акча түләмичә, шәхси йортларга газ кертми.

—Мин нишли алам?

Җавапны ошатмаган Сибгатуллин янә кабарды.

—Ну, Нәфис абый, сезнең урамга газны мин кертергә тиешме инде?

—Юк, билгеле. Ул газовиклар эше.

—Әнә бит ул утыра.—Ул Маша түтигә ишарәләде.—Өннән чыккандай килә дә утыра. Көн саен...

Нәфис аның мәгънәсезлегеннән янә көлемсерәп куйды.

—Сез җитәкче кеше... мин әбине бүлмәгездән куып чыгара алмыйм, ә газ кертү мәсьәләсен хәл итү сезгә ачыграктыр дип беләм.

—Әйтергә җиңел ул...

—Районга газга дип акчалар кайтадыр бит?—диде Нәфис, акчалар, торбалар кайтуын, аларның башка кирәк-яракка тотылуларын белә торып.

Сибгатуллин шунда ук корт чаккандай сикереп торып кабынып китте.

—Ну, Нәфис абый, синең белән сөйләшә торган түгел... Бар чыгып кит әле моннан...

—Яхшы...

Нәфис чыгуга, аның артыннан Сибгатуллин коридорга атылып чыкты да туп-туры башлык бүлмәсенә кереп китте. «Димәк, әләкләргә,—дип уйлады Нәфис.—Ул анда ниләр ялганламас». Шушы уй аны да башлык бүлмәсенә алып керде. Анда райпо рәисе Әхәт белән аның урынбасары Борнаш да утыра иде. Ә Сибгатуллин, үте сытылган кешедәй, бер читтәрәк урын алган, әле зарын сөйләргә өлгермәгән икән. Ул Нәфисне күрүгә торып ук басты.

—Рәсим Юлаевич!—диде дә Нәфискә ишарәләде.—Или мин, или ул китә...

—Туктагыз әле, нәрсә булды?—диде Тукбаев, берни аңламый.

—Мин редактор урамына газ кертә алмыйм бит инде... теге карчык, Мария Сергеевна тагын килгән. Редактор аны котырта, газ өчен районга миллионнар кайткан иде, дип...

Нәфис бу кадәресенә түзмәде.

—Ник ялганлыйсыз?..—диде.

Тукбаев Нәфисне бүлдерде, урынбасары сүзен куәтләп, күктәге Ходайга табынгандай, ике кулын өскә күтәрде дә Нәфискә җикеренде.

—Кая, кая ул миллионнар?! Газга өч ел акча кайтканы юк... Ә син, великий редактор, юмор-шумырың белән әллә ниләр уйлап чыгарасың. Паразит син...

—Рәхмәт...

—Мин башка сүз таба алмыйм... Сез журналистлардан кроме вреда файда юк. Партия заманы булса, сине уникe сәгать эчендә районнан куарлар иде.—Аның тукмактай йодрыклары һавада уйнаудан туктамады.—Бар!—дип артыңа тибәрләр иде. Ә бу дядя,—ул үзенә ишарәләде,—алай эшләми... Обнаглели. Мин сезнең өйгә газ кертеп бирергә тиешме? Өен биргән, миннән тагын ни кирәк? Тагын нәрсәгез эшләнмәгән?

Каршы дәшү файдасыз иде. Нәфис Тукбаевның суынганын көтте һәм:

—Рәсим Юлаевич! Дөрес аңлагыз,—диде,—мин дә сезгә үз эшемне эшләргә кушмыйм бит һәм сорамыйм да...

Тукбаев аны ишетергә дә теләмәде.

—Хәлим кайда?—дип акырды.—Чакырыгыз әле аны монда! Газ начальнигы Исаевны да табыгыз!..

Исаев табылмады. Администрация тирәсендә еш чуалган көрәшче егет, урам старостасы Хәлим көттерми кереп тә җитте.

—Мин нишлим инде, Рәсим Юлаевич,—диде Хәлим сүзнең нәрсә турында барганына төшенгәч һәм үзен кулга алып акланырга тырышты:—Газ

чокырын казыттым, кирәгенчә проектларын үзгәртеп эшләттем. Бездән ни тора соң? Урамның бер ягында газ яна, икенче ягында юк...

Тукбаев тынлап-тынлап торды да тавышын баса төште.

—Ничә кеше бар сезнең урам рәтендә?—диде.

—Унике,—диде Хәлим.

—Барыгыз, редактор белән икәү урамыгыздагы һәр кешедән менәр сум акча җыеп мина алып килегез!.. Аннары карармын, на что вы способны? Калган сумнарын үзем хәл итәрмен...

Нәфис белән Хәлим килешеп газ кертүче хуҗалыклардан акча җыярга чыгып киткәндә, Сибгатуллин кабинетта кара көеп утырып калды...

Кичен газга дип җыйган акчаларны китергәндә, Тукбаев бүлмәсендә ялгызы гына иде. Төрле мыскыллаулар аша узган Нәфис аның өстәленә, эштән азат итүләрен сорап, гаризасын китереп салды.

—Нәрсә бу?—диде Рәсим Юлаевич. Һәм гаризаны укып чыгуга, урталай ертып ташлады.

—Паразит гаризасы,—диде Нәфис, тыныч кына.

—Давай, ты кончай!.. За нами Байтиряк, на переправе лошадей не меняют... Минем икенче редактор эзләп йөрисем килми. Эшлә!..

Тукбаев Нәфиснең өч кешелек эшләвен дә, эшкә сәләтен дә яхшы белә иде. Тик аның турылыгын, тәнкыйтен генә яратмый. Ул мөхәррирен кызып-кызып орышса да, соңыннан кайтып төште.

—Менә, мәсәлән,—диде ул, сүзне борып алып,—без главалар Гарәп Эмиратыннан кайтканда башка район хуҗаларының йә замнары, йә кемнәре чәчәк тотып каршы алды. Безгә, Абага районы главасы белән икебезгә, килүче булмады... Менә шуннан күренә инде минем команданың дәрәҗәсе. Ярар, мина кирәк тә булмасын ди, теге район хуҗалары алдында шәп түгел. Главага әз генә булса да хөрмәт булырга тиештер бит инде. Җүнле кадрларны каян аласың? Бар булганы белән эшләргә туры килә. Син, Нәфис абый, великий булгач та минем бу башта ми әзрәк, башка ат типкән дип белдеңме әллә? Ми күбрәк анда, белеп тор! Анлый ул барысын да...

Нәфис аның ишарәләренә бераз ышанган да кебек булды. Урамнан җыелган урынбасарларының эшсезлеген дә, мокытлыгын да яхшы аңлый иде ул. Тукбаев аны сүксә дә, кеше коткысына бирелеп, аны башкалардан.кактырырга, бөтенләй читләштерергә ирек бирмәде. Бу очракта ул аның гөнаһсына кермәде. Бу кадәресен Нәфис яхшы аңлады...

Автобуслар урман аланы читенә килеп тукталгач, һәммәсе саф һавага чыгып, тирә-як яшеллегенә, июнь чәчәкләренә сокланды. Май заводы директорлыгыннан чыгарылган Таһир, шактый гына кызып алса да, гармунын шәп итеп тартып җибәрде. Хатын-кызлар биешеп, күмәкләп җырлап та алдылар. Әйтерсең урман буенда кечкенә генә сабан туе! Хәмергә хәвәсләр автобустагы аракы әрҗәсен бушата-бушата, затлы кабымлыклардан авыз итеп, кәеф-сафа кордылар. Бу төркемнең үз осталары бергә җыелган: «Үзән» совхозының директоры Идрис Юнисович, мактаулы мунчачы, юан корсагының кендеге күлмәк сәдәфен чишеп төртеп чыккан «Сельхозхимия» башлыгы Рибаб һәм алар белән бериш гәүдәле «Алпар» хуҗалыгы рәисе Маннур Мансуровның йөзләре помидордай кызарган...

Автобуслар кузгалып киткәч, янә шаярулар, мәзәк сөйләүләр, җырлар дәвам итте. Сүзсез генә барган Нәфистән янәшәсендә утырган ревизор Тажи сорап куйды:

—Нигәдер күнелсез әле син бүген, Нәфис абый?—диде.

—Нишлим соң? Җырлый белмим, биергә оста түгел.

—Берәр юмор сөйлә.

—Юморыңны тагын тәнкыйть дип кабул итсәләр нишләрсең?

—Юмор—йомры тукмак, башка сугарлар дип уйлыйсынмы?—Тажи, үз сүзеннән кызык табып, күзләрен кыса-кыса, зур авызын җәеп көлде. Нәфис дәшмәгәч, сүзен янә дәвам итте:—Сезнең редакция эшен тикшереп аласы бар әле,—диде ул, җитди итеп.

—Ник?

—Безнең план буенча шулай каралган.

—Тикшерегез, бездә акт язарга кәгазь җитәрлек.

—Анлык кына кәгазь үзебездә дә бар...—Тынып калган Тажи өстәп куйды:—Бу круиз турында яхшылап язып чык инде. Байтирәклеләр ял да итә беләләр дип.

Нәфис, анысын карарбыз инде дигәндәй, башын гына какты. Аннары Тажи игътибарын мәзәк сөйләүчеләр җәлеп итте. Нәфистә Тажига карата булган тискәре хис яңарды һәм ул, тирәнгә үтеп, тамыр җәйде.

Бервакыт аның автобуста Казаннан Байтирәккә кайтып килеше иде. Кайтучылар арасында район коммуналь хуҗалыгы бухгалтеры Гөлүсә дә бар иде. Шыгрым тулы автобуста аны күргәч, ул баш кагып кына исәнләште. Кайта-кайта автобуста халык азая төшкәч, Гөлүсә янындагы буш урынга килеп утырды, аның талчыккан, борчулы йөзен күреп, сүз башлады.

—Казанга барган идегезме?—диде.

—Әйе, больницадан кайтып киләм әле,—диде Гөлүсә, өздереп кенә.

Гөлүсәнең борчылуы, авырганлыгы аксыл йөзенә чыккан иде.

—Кайсы больницадан?—диде Нәфис, кызыксынып.

—Психбольницадан...

Нәфис аптырый төште:

—Нәрсә булды?—дип сорады.

—Менә шулай инде... авырып киттем.—Ул турысын әйтергә кыенсынды, бераз тынлыктан соң өстәде:—Нервы бозучылар күбәйгәч, шулай була инде ул.

—Кем боза?

—Кем булсын, ревизор Тажи, беләсең ич инде аны,—диде ул, шөбһәләнеп.

—Беләм, билгеле.

—Ул безнең коммунальныйга ревизия ясарга килгән иде. Бар булган бәяле җиһазларны, финанс кәгазьләрен, керем-чыгымнарны тикшереп чыккач, миннән художник ясаган плакатларны таптырта башлады. «Йөз меңгә төшкән плакталар кая соң, алар складта булырга тиеш бит»,—ди. Тагын шундый вак-төякләр... Гаеп табасы, мине үз кармагына эләктерәсе килә. Исәбе: куркытып ришвәт алу. Мин: «Ул плакатларга киткән акчаларны кесәмә салмадым»,—дидем. «Салмасаң да, ул плакатлар булырга тиеш бит»,—ди бу, үҗәтләнеп. «Мин аларның кая киткәннәрен каян белим, плакатларга тотылган акчаларга расходный язылган бит»,—дим. Дөресен әйтеп булмый бит, ул акчаларны Дәүләтхан Бариевичның туган көненә алдылар дип. Чистый бәйләнде, бу хәл мине борчуга салды. Мина үзе боерган нәчәлнигем белмәмешкә салышып читтә калды. Хәзер барысына мин гаепле... Нервылар какшый төшкәч, психбольницага килеп эләктеп менә...—Гөлүсә бертын сүзсез калды.—Соныннан бу хәлне главага ирештергәннәр. Ул бер җыелышта Тажига яхшылап әйткән: «Тычкан тота белмәгән мәчене нишләтәләр?.. Белмәсәң, бел! Капчыкка салалар да урманга алып барып адаштыралар. Так что, думай...»—дигән. Тажи үзенә кирәк «тычканны» безнең коммунальныйдан тотмакчы иде...

Гөлүсә дулкынланырга ярамаганлыгын сизеп тынып калды. Бераз баргач, ризасызлыгы янә ташып чыкты:

—Җыен шунын эше шухыр-мухыр эшләрне безнең оешма аша

кайнаштыралар да... жавабын бухгалтерга тотарга кала. Каршы килсән, эшеңнән колак кагасың... Ул кунакханә төзибез дигән йортына ничәмә миллионнарны коммунальный аша уздырмады инде.

—Тукбаевмы?

—Кем булсын инде? Ул йортның бер тәрәзәсе генә ничә меңлек. Өч катлы йортта утыз тәрәзә генә. Аларның акча уйнатып кайнаштыруларына чыдаган кешегә рәхмәт...

Гөлүсә ханым, кинәт акылына килгәндәй, артыгын сөйлим бугай дип шикләнә төште, як-ягына каранды һәм тынып калды. Нәфис, авыруны борчыйсы килми, аңа бүтән сорау бирмәде, аның шушы хәлгә төшүен кызганып куйды.

Әлеге вакыйганы исенә төшергән Нәфис янәшәсендә утырган Тажига кырын гына карап алды. Тажи, чепи күзләрен кысып, көрәшче-комментатор Фәниснең «әкият» сөйләвенә жавап итеп; авызын ерган иде. «Бу адәм кеше рәнжеше турында каян уйлый белсен? Аны ришвәт көткән кәкре бармаклары эчтән кытыклап тора»,— дип фаразлады Нәфис. Аннан ул үз-үзенә сорау бирде: «Нигә Тукбаевның нәфесе туймый? Нигә ул, кәнәфиеннән сикереп торып: «Акча, акча, акча!» дип шар яра!..». Сорауларына жавап табарга аңа эчке мине ярдәмгә килде: «Тинтәк син, Нәфис,—диде.—Әйт әле, кайсы дөньяда, нинди гасырда яшисең син? Илләр белән дә акча идарә итә. Ришвәт, коррупция булган жирдә сәясәт юк, гаделлек, намуслылык төшенчәсе онытылган. Акча бездә һәммәсен эшли, ачылмас ишекләрне ачтыра, кызыңны институтка кертә, кандидатлык, докторлык диссертациясен дә яклата, карьера баскычларыннан житәкләп алып менеп китә. Беләсең килсә, акча карак бандитлардан депутат та ясый, бал-майда йөздереп хан итә, сине төрле жинаять афәтләреннән йолып кала, төрмәләрдән коткара... Акча Тукбаев өчен жиңелмәс власть та ул!.. Ә власть, кирәксә, үзенең закон инструментын жигеп, синең өстән золым да кора... Син уйлап кына кара, илдә барган төрле ызгыш-талашлар, үтереш, террорчылык каян, ни сәбәпле килеп чыга? Гөнаһсыз жаннар нигә вакытсыз кыела? Бар да шул гаделсезлек чиреннән, йөрәк бунтыннан...»

Бу юлы Нәфис эчке мине белән бәхәскә кермәде, тәрәзәдән тирә-якны күзәтте. Кояш жир өстен мең төрле төсләргә бизәгән. Әйтерсең ул бар адәмнәрне дә тигез күреп, дөнья матурлыгына сокланырга, жир кадерен саклый белергә ишарәли...

Әнә зәңгәр офык читендә шәһәрнең шакмаклы таш йортлары шәйләнә башлады. Торна муенындай озын борынлы краннар баш калкыткан, күккә ашкан торбалар «тәмәке» көйрәтә. Бу—Казан, меңьеллык тарихи сәхифәләрен үзенә сыйдырган, миллионнарның шау-шулы тормышы белән гомер кичерә...

Автобуслар «Акчарлак» ресторанына янына килеп туктагач, Нәфис, урамда ялгызы калып, Сәриясен көтте. Ул күренмәгәч, өенә шалтыратты, трубканы алучы булмады. Аннары, бер киреләнгәч килмәс инде дип, ресторанга юнәлде. Ашау-эчү залына узгач, бер читтәге буш урынга барып утырды. Өстәлләргә ризыкларны алдан ук әзерләп куйганнар иде.

Түр өстәл артына утырган Тукбаев белән Ишкәев тирәсендә официантлар ешрак буталды. Баксаң, монда эшләүчеләр Чуртан Әхәтнең күрсәтмәләрен берсүзсез үтиләр, аны яхшы беләләр икән. Затлы шәраблар, ризыклар түр өстәлне билэп алган, урындыкка утырган кунакларның йөзләре ачык. Нәфис шуны аңлады: Чуртан Байтирәк «күленә» очраклы гына йөзеп чыкмаган, өстә дәрәжәле кешеләре бар икән...

Нәфис, ашап-эчеп урамга чыккач та, як-ягына каранды, узган-барган кешеләр арасыннан үзенең кара чәчле, кара күзле Сәриясен эзләде. Әмма

ул күренмәде.

Елга портында Байтирәк сәфәрчеләренә ял итүчеләрнең күнелен ачарга дип, килешү буенча җырчылар Галия белән Харис килеп кушылды.

Ак пароход, дулкыннар ярып, агымга каршы юл алды, җыр-моңнар Идел өсләренә таралды. Салмак кына тибрәлгән дулкыннар өстендә энҗе нурлар уйный. Гомер агышларыдай салмак кына аккан сулар үз артыннан Нәфис уйларын да ияртте... Ул Сәриясен шушы сәяхәткә чыгарга күндерә алмавын авыр кичерде. Күзенә роза чәчәкләренең уттай янып Идел өстендә агып барганы күренде. Ул кем чәчәкләре икән? Бәлки, кемдер аларны үз кадерлесенә бүләк итәргә теләгәндер? Сөеклесе очрашуга килмәгәч, үпкәләп, аларны суга ташлагандыр? Ә бәлки... ә бәлки ул Идел суларында югалту кичергән сөйгәнен көткәндер?.. Белмәссең. Ә Идел дәшми, юатырга теләгәндәй, гашыйклар серен саклап, тын гына, сабыр гына ага да ага...

Менә Галиянең җырлавы сәфәрчеләрне тын калдырды. Анын күңелгә хуш килгән моңы аеруча хатын-кызларны әсир итте. Кош канатыдай сузылып киткән кашлары биеп тора, сөрмә тарткан күзләре юмарт елмая. Нәзек билләре камыштай сыгыла-сыгыла тибрәлә. Чибәрлегенә мөкиббән киткән ир-атларның күз-карашлары анын биеп торган нечкә билләрен, алтын нурлар балкыткан ярым ачык айлы түшен капшый. Тәненә сыланган үтә күренмәле зәңгәрсу күлмәге әйтерсең кояш нурларыннан эреп юкка чыккан, Иделдән генә күтәрелгән су кызыдай, сыгыла-сыгыла бии, гүзәл сынындагы энҗе балык тәңкәләре нур чәчә. Кызның үткен карашы, баскан җирдән ут чыгарып биюе «Инеш» кооперативы рәисе Мин Миннуловичны да таң калдырган. Ул, түземсезләнеп, тиз генә видеокамерасын эшкә җикте, яшь артистның әле бер, әле икенче ягына чыкты, сокландыргыч мизгелләрне төшереп калырга ашыкты. Камера үз ягына таба юнәлгәч, Тукбаев нигәдер тартылып, кыенсынып куйды. Әмма ул Мин Мулловичны бу изге эшеннән тыярга җөрьәт итмәде.

Менә икенче җырчы—озын гәүдәле Харис тамашачылар каршына йолдызларга үрелгәндәй үсеп чыкты да сикерә-сикерә, кулын кулга чабып, алкышлар көткәндәй җырлый башлады. Пөхтә киенгән төз, ыспай гәүдәсе хатын-кызлар йөзендә җанлану уятты. Харис, җырына куәт биреп, очына-калкына сикергәләде, моң дигән нәрсә тамагыннан ташып чыкмаса да, ихласлыгы, төс-кыяфәте күңелләрне җәлеп итте. Егетне һәммәсе дә ошатты, алкышлар белән котлады.

Пароход Ослан тавы ярына борын төрткәч, халык куана-куана ярга ашыкты, тау битендә яшел агачлар үсеп утырган аланлыкка күтәрелде. Күңелләр күтәренке. Һәркем җәйрәп яткан Идел өсләрен, тирә-як матурлыгын күзәтте. Казан порты күренешләре, борыннарын суга таба юнәлткән краннар шактый еракта калды. Яшел табигать кочагында берәүләр, йөз нурларын балкытып, фотога төште, икенчеләре, чишенә-чишенә, Иделгә су керергә юнәлде.

Биредә бәйрәм хәстәре алдан ук күрелгән: учаклар яна, каен күмерләре өстендә шашлык пешә, һәр тарафка тәмле ис таралган. Чирәм өстендәге җәймәләр ризык белән тулды, чекрәеп басып торган шешәләр башы гөлт тә гөлт килеп чытырдап ачылды, исәнлеккә-саулыкка стаканнар, рюмкалар чәкеште.

*Ахыры киләсе санда*



Әхмәт
Рәшит

# ЯШӘҮ ДИҢГЕЗЕНДӘ...

## Гомер мантыйгы

**Менә без дә килдек җир йөзенә—
Үтәр өчен сәер чор аша.
Менә без дә тудык,
Яшәр өчен
Фәлән елдан фәлән елгача.**

**Менә без дә тудык.
Яшәешкә
Булмаса да шартлар әлләни;
Ләкин язмыш безнең гомерләрне
Җир тормышы белән бәйләде.**

**Беренче кар яуды җир өстенә,
Беренче кат күкләр күкрәде,
Беренче кат имдек үҗәтләнеп
Әниләрнең назлы күкрәген.**

**Янар таулар утлар чәчә иде
Һәм шашына иде диңгезләр...
Алмашынды бишек тирәсендә—
Җәйләр-көзләр узды... яз-көзләр.**

**Аңлаптырмы, аңламыйчадырмы
Елмаюлар кунды йөзләргә,—
Ә шулай да иллә рәхәт иде
Яшәү диңгезендә йөзәргә.**

**Без ул чакта уйлап эш иткәнме,
Уйлаганмы башын һәм... соңын,**

Бездән алда ниләр булганын да,
Һәм бездән соң нәрсә булырын.

Тарих безгә бишек җырларын да
«Сез—бәхетле» диеп көйләде,
Тарих безгә чынын, ялганын да
Катыштырып—алдап сөйләде.
Без ышандык.
Матур әкиятләргә
Без күнеккән инде—
Түземнәр!
Без—сабыйлар.
Башка кереп тулды
Әллә нинди серле «изм»нар.

Тарих шундый инде.
Битләреннән
Аерып булмый чыннан ялганны,
Шундый ысул белән, яраклашып,
Дәвам итте сүзнең калганы.

Үткән—беткән.
Ә киләсе чорлар
Ялгышларга безнең дәвамы?—
Мәңге яшәр өмет булып кала
Тарихларның серле дәвамы.

Ә Җир оча—
Кояш кая барса,
Артка калмый аның артыннан–
Миллиардлаган йолдыз арасында
Кай тарафка шулай талпына?!

Илаһи көч әллә хыялларны
Калкан булып тыеп торамы?
Без яшибез.
Чөнки яшәештән
Бушап тормый тормыш урамы.

Без башы да түгел яшәешнең,
Азагы да түгел түгелен,
Тик беләсе килә алдагы көн
Безгә ниләр алып килерен...

Ашкынабыз һаман:
Җир йөзендә
Яшәүнеңме шундый хөкеме?!
Ә билгесез ерак тарафларда
Әллә ниләр бардыр шикелле...

## Балачак төшә искә

Айлы төн. Эңгер урамда.
Җил калын көртләр өйгән.
Мең төрле хәйлә табып, без
Ычкына идек өйдән.

Хәер, ул чак, салкын, диеп
Ятасыңмыни өйдә—
Ун яшьлек Ислам гармунын
Көйләгән безнең көйгә.

Әтиләр дә, абыйлар да
Ул чак сугыш кырында,
Без-үсмерләр җырлар суздык
Чибәр кызлар турында.

Булгандыр рәтле җырлар да,
Рәтсезе дә булгандыр.
Кызларның, тыңлап шуларны,
Күңелләре тулгандыр.

Без-малайлар рәт белгәнме—
Тәртипсез идек. Шуңа
Үрелер идек кайчакта
Апалар куенына...

Көткәндер алар тилмереп
Вәгъдәле сөйгәннәрен.
Кульяулыгы бүләк иткән
Бердәнбер дигәннәрен.

Сирәге кайтты аларның,
Күбесен алды... кабер...
Кызлар да шулай картайды,
Күрми наз, хөрмәт, кадер...

Чыланды күз, саргайды йөз—
Ак өметләр алданды;
Яшь килеш алар ярларын
Көтеп ала алмады.

Ничә кат язлар елмайды,
Ничә кат килде көзләр,
Ничә кат яшерен елады
Саф килеш калган кызлар...

Хәзер менә аңлыйбыз да...
Тиргибез үзебезне:
Елап, һаман кыз-әбиләр
Каргыйдыр сыман безне...

## Алмаштылар

Түбәтәйне, кәләпүшне
Без кия-сөя идек;
Фасон өчен аны шулай
Янтайтып кия идек.

Без ул чакта—чын мөселман,
Мөселманча исемнәр...
Фуражка, кепка дигәнен
Керәшеннәр кисеннәр.

Ике дин иде авылда—
Кунакка йөрешмәде,
Аерым үтте туйлар да—
Киленнәр бирешмәде.

Үтте еллар—ят диндәге
Авылдашлар аңлады.—
Керәшеннәр диеп кенә
Өстен чыга алмады.
Карамый поплар сүзенә,
Хөкемнең кыйммәтенә,
Кайтты элекке Иваннар
Мөхәммәт өммәтенә.

... Тик хәзер мәнфәгать үзгә:
Чыгып кибет артына,
Күккә чөеп берсен-берсе,
«Табына» да яртыга,

Түбәтәйне шул кепкага
Алмашып, рәхмәт әйтеп,
Оныклары алпан-тилпән
Өенә китә кайтып...

Заманалар үзгәрә шул—
Язмадым болай, юри;
Түбәтәй һәм кепка бүген
Бер «максат» белән йөри...

## Татар угылы... татармын

*Татарлыктан татар һич гарь итәрме,*
*Кеше үз исмене инкарь итәрме?*
Дәрдеменд

Дөньяның бар кыйтгасыннан
Җыйсаң һәммә татарны,
Бөтенесе үзен-үзе
Татар диеп атармы?

Кушамат санап ул сүзне,
Монголча... диеп, шуңа—
Мин татар түгел, болгар дип
Язмакчы паспортына.

И надан бала! Тарихның
Кемне бар зурлаганы?!
Бергә көн иткән күршесен
Юк кемнең хурлаганы?!

Кемнәрдер сөйли, дип кенә
Үзгәртеп торсаң исем,
Кемнәрдән яклау табарсың,
Югалтып дуслык хисен?

Иманым камил—белмәсә,
Белмидер кире генә;
Үз милләтеннән баш тартыр
Ничәнең бере генә.

Ничә икәнен белгән юк,
Төрлечә саный-саный,
Булгәләп йөздән артыкка,
Киметеп була аны.

Нишлисең, без Җир шарына
Таралган—бүленгәнбез,
Кайчандыр бергә булганбыз,
Кайчакта... тибелгәнбез.

Гасырлар буе яшә дә,
Көндәшләр булмыймыни?!
Кайчакта дус яшәсәк тә,
Бер этлек килмимени?!

Шуңадыр шул—Европа да
Һәм Азия ягы да
Кылычын тоткан үткенләп,
Татар көчле чагында.

Шуңа гына тарихларда
Исеме аның хәтәр.
Кимсенмим... Татар улы мин,
Милләтем минем—татар!

**Редакциядән:**

*Бу айда танылган шагыйрь, публицист, күпсанлы китаплар авторы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Г. Исхакый исемендәге әдәби премия лауреаты Әхмәт Рәшиткә 75 яшь тула.*

*Журналыбызның күптәнге авторы булган каләмдәшебезне күпсанлы укучыларыбыз исеменнән котлап, аңа сәламәтлек, яңа иҗат уңышлары теләп калабыз.*



## Мөхәммәт Мирза

# АДӘМ БАЛАСЫ

ЯҢА БИШЬЮЛЛЫКЛАР

***

**Исә җил, кисә җил,**
**чүл күчә, күл кибә...**
**Адәм баласына—**
**кылмасын ни генә,—**
**кисәткән көн килә...**

***

**Чүлнең—үз чәчәге,**
**сазның—үз җиләге...**
**Адәм баласына**
**ничек тә бер чыгар**
**шуларның кирәге...**

***

**Бер баскыч менүгә,**
**икенчесе баса...**
**Адәм баласының**
**үтәчәк юлында—**
**мәңгелек куласа...**

***

**Куаныч—күтәрер,**
**хәсрәт—төпкә тартыр...**
**Адәм баласының**
**кайчан, кайда, ничек**
**шул халәте артыр?..**

***

**Күзен йомып үтә**
**гомренең яртысы...**
**Адәм баласына**
**тигез хаҗәттәме**
**караңгы, яктысы?..**

***

**Төсе хәбәрендә**
**җисме үзгәлеге...**
**Адәм баласының**
**күзе алмасында**
**үзгә гүзәллеге...**

***

**Киек каз юлында**
**тынгысыз мәңгелек...**
**Адәм баласының**
**зәгыйфь иманында**
**мәҗүси тәңрелек...**

***

**Итәген кисәр дә,**
**җиңен ямап куяр...**
**Адәм баласының**
**шул һөнәрен хәтта**
**кемдер мактап куяр...**

***

**Мәңгелек юлдашы—**
**атыннан бизенгән:**
**Адәм баласының**
**нәсел кәсебендә**
**хәлсезлек сизелгән...**

---

Мөхәммәт МИРЗА (1953) – *шагыйрь; «Киек каз юлында», «Тере су», «Адәм баласы» һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

***

Күбәләк күреп тә
бәйдәге эт өрә...—
Адәм баласының
коллыкка күнеккән
төренә бер кинә...

***

Яндырып өшетер
газап, әрнүләре...
Адәм баласының
үз башына төшәр
нахак рәнҗүләре...

***

Күккә терәп корган
пирамидалары—
Адәм баласының
җил хөкемендәге
каберлеге бары...

***

Дөнья тотканына
хәйран каласың да:
Адәм баласының
йорты-малы һаман
арба-даласында...

***

Мең чакрым таш дивар,
кемнән кем сакланган?..—
Адәм баласының
бу чарасызлыгы
мең елдан акланган...

***

Мәктәбе, мәзһәбе...
Йоласы, кыйбласы...
Адәм баласына
туа-тумышыннан
шуңар сыенасы...

***

Дүрт ягына карап
гыйбрәт ала белгән
Адәм баласының
иманенә Тәкъдир
чикләвеген элгән...

***

Чигенмәс бер чире,
үтмәс үкенече...
Адәм баласының
тәүбә итми торып
бетмәс үтенече...

***

Кайчан килеп, кайда
алып китсәләр дә
Адәм баласының
ике фәрештәсе
калыр иңсәләрдә...

***

Ялган да ялгана,
яла да ягыла...—
Адәм баласының
нәсел-ыруына
ярлыгы тагыла...

***

Җанисәп алганда
теленнән язмаган
Адәм баласын үз
нәсел-нәсәбеннән
беркем сызалмаган...

***

Коткарса коткарыр
тик тәүбәсе генә...
Адәм баласының
гөнаһсыздыр, бәлки,
тик шәүләсе генә?!.

***

Бер калак—бер өлеш,
Бер табак—ун өлеш...
Адәм баласының
табагындагысын
калагыңча бүлеш...

***

Сынау газаплары
үлгәч тә үтмәстер...
Адәм баласының
сыныкка сылтавы
анда да бетмәстер...

***

Милләтең, телең ни—
уе йорт-курада...
Адәм баласының,
шөкер, бәрәңгесе—
туп-тулы бурада...

***

Арасы якын да,
юллары ерактыр...
Адәм баласының
монда туфрак, анда
көл буласы хактыр...

***

**Шайтан—бер, җен—башка,**
**бүген ни күргәне:**
**Адәм баласының**
**шайтаны котырып,**
**җенләнеп йөргәне...**

***

**Корылык җәһәннәм**
**җиленнән яралган...**
**Адәм баласына—**
**күнегә торсын дип,**
**күрәсең, каралган...**

***

**Тәкъдир биләмәсен**
**вакыт киртәләгән...**
**Адәм баласының**
**кайсы соңарган, йә**
**кайсы иртәләгән?!.**

***

**Барып җитәренә**
**кул сузымы бары...**
**Адәм баласының**
**туктап калганы бар**
**үз-үзеннән арып...**

***

**Көлеп кинәнгәне,**
**көлкегә калганы...—**
**Адәм баласының**
**һәр ике халәтен**
**өлгертә ялганы.**

***

**Кем йогынтысына**
**юлыгып торыр гел?..**
**Адәм баласының**
**нахак яласына**
**сулыгып корыр гөл..**

***

**Язмыш дәрьясының**
**калыр кай ярында?..—**
**Адәм баласының**
**туфрак булыр төше**
**күк ихтыярында...**

***

**Камиллеккә өлге—**
**самим гадилеге...**
**Адәм баласының**
**ана сөте белән**
**сугарылган гөле...**

***

**Бөек Рух—мәңгелек,**
**чиксез яралышта...**
**Адәм баласының**
**тәнендәге җаны**
**шуңар бәйләнештә...**

***

**Җирнең бөтен сере**
**су төбендә калган...**
**Адәм баласының**
**Коръәнле кавеме**
**ачар шуны алдан...**

***

**Кан белән языла,**
**сан белән саклана...**
**Адәм баласының**
**ак таплы тарихы**
**тәкъдир дип аклана.**

***

**Бүрәнә аркылы**
**бүре куганы бар...**
**Адәм баласының**
**бүрене буардай**
**тугры туганы бар.**

***

**Сабагына төшсә,**
**тамырына күчәр...**
**Адәм баласының**
**канын бутаганы—**
**ахырына дучар...**

***

**Тукран тәүбәсенең**
**сәбәбы үзенә...**
**Адәм баласының**
**соңарган тәүбәсе—**
**соңарган көзенә...**

***

**Тартайның тапканы**
**тиктормас теленнән...—**
**Адәм баласына,**
**тик телен тешләгәч,**
**шул хәбәр беленгән.**

***

**Төлкенең койрыгы**
**әҗәленә илтә...—**
**Адәм баласының**
**алтын җыйганы да**
**җәһәтерәк китә...**

**Автордан:**
*Миңа тиешле каләмхакны "Яңарыш" тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне торгызу республика фондына күчерүегезне сорыйм.*

Печән базары

*Сатирик әсәрләр конкурсы*

Ләбиб
Лерон

## ШАДРА ЮМОРКАЛАР ЯКИ НОРМАЛЬНЫЙ РОБАГЫЙЛАР

*Бу такмакчы килеп чыкты кайдан дип,*
*Робагый дип, ниләр яза, надан, дип*
*Көлмә, шагыйрь. Бу әкәмәт дөньяда*
*Үз-үземә шулай кызык табам бит.*

Туфан Миңнуллин.

*Үз-үземә шулай кызык табам, диеп,*
*Робагыйлар язган Туфан агам, диеп*
*Мин дә беркөн тотындым бу күркәм эшкә—*
*Бәлкем, кемдер язганыма багар, диеп.*

Ләбиб Лерон.

**И татарым, хәлләр беркем кызыкмаслык:**
**Бер үк тырма тешләренә кырык бастык...**
**Үзебезчә сөйләшергә һич юк вакыт:**
**Кияү—урыс, килен—марҗа, онык—манкорт!**

* * *

**Көндәшен ул чөеп атты баш аркылы...**
**Чү! Нәрсә бу, и инәңне корт чаккыры?!**
**Җилкәсенә тәкә... дисәм... чучка салып...**
**Кайтып килә сабантуйның баш батыры.**

***

**«Түрәләрдә бернинди дә милли аң юк!»—**
**Дип мин әйтәм, син әйтәсең, сөйли халык...**
**Тещасының юбилее уңаеннан**
**Шәһәр мэры табын корган—миллионлык!**

* * *

**Яшь чакта гел кызлар булды телебездә,**
**Хәмердән дә баш тартмадык беребез дә...**
**Бер гөнаһсыз әүлиягә әвереләдек**
**Анализлар биреп йөргән көнебездә.**

* * *

Сөбханалла, күкрәкләрең бигрәк күркәм!—
Тефү-тефү, күз тимәсен берүк, иркәм.
Ни диярсең, әгәр әрсез кулларымны
Шул тирәндә тыйнак кына сыйпап йөртсәм?!

* * *

Быел тагын алмакчылар җан исәбен.
Шул хакта шәп шигырь язу бар исәбем...
Минем хакта яз, әйдә, дип кинәт кенә
Килеп керден шигыремә, җанкисәгем.

* * *

Иртән сайрыйм:»Син бит—минем табышым»,—дип,
Кичен сайрыйм:»Син бит—минем язмышым»,—дип...
Бүген тагын йоклап китсәм, әйтмәссеңме:
«Каян килде бу табигать ялгышы?»—дип.

* * *

Күп ашаудан йокы баса—оета, дип,
Булмый хәтта ботинканы киеп тә, дип,
Айлар буе өйдә ни бар шуны состым—
Дүшәмбедән тота башлыйм диета, дип...

* * *

Сәхнә тулды яулык чөйгән ирләр белән,
Колак тонды шырдый-бырдый җырлар белән.
Бетсә бетсен татар җыры, юморы, дип,
Сәхнәләргә мин дә чыгып мырлар булам.

* * *

—Синең өчен мәңге утка кермим мин!
Синең өчен мәңге суга кермим мин!—
Дип ярсыгач, ялгыш өстәп куйды ир:
—Синең өчен... лутчы... «сулга» йөрим мин!

* * *

Өметләрем (мөлдерәмә ташыганда!)
Челпәрәмә килде гүя таш идәндә:
Үзәгемне өзеп-өзеп үтеп киттең
Спонсорың алып биргән машинаңда.

* * *

Бу Рәсәйне ваклап сатып эчтеләр, дип
Кемдер анда, кемдер монда сөйләнә бик.
«Монда минем өлеш тә бар!»—дип уйласаң,
Кысылмыйча кала күрмә син дә, Ләбиб.

* * *

Көнләшеп тә, кызыгып та әйткәннәрдер:
«Күп укыган, күп белгән шул әткәләре...»
Марсель, Илфак, Лемон, Роберт, Ким, Ркаил...—
Бездә инде исемнәрнең кәттәләре!

* * *

**Бер табында утырдык без Башлык белән,**
**Мәҗлес—күркәм: сый-хөрмәтләр—шашлык белән!..**
**Өйгә кайткач, шул турыда язмак булдым...**
**Шигырь язып булмый икән... кашык белән.**

* * *

**Күлмәгемнең кире ягын кидем мин дә,**
**Шомбай булып йөрим әле, дидем мин дә...**
**Кинәт кенә башкаема китереп сукты:**
**Әйләндереп кигәннәр бит бу илне дә!**

* * *

**Кырыктан соң мин дә бераз үзгәрдем, дим.**
**Әллә нишләп начар күрә күзләрем, дим.**
**Китап-мазар укымаган чакларымда**
**Бик шәп күрәм матур кызлар йөзләрен мин...**

* * *

**Чынга ашмас уй-теләкләр миндә инде:**
**Космонавт булырмын, дип йөргән идем...**
**Китап укып, көтмәгәндә шагыйрь булдым...**
**Автогонщик буласым да килгән иде.**

* * *

**Булды заман: вакыт узды чиратларда—**
**Чират торды хатын-кыз да, ир-атлар да...**
**Күпме мәһшүр татар улы китеп барды**
**Чират саклап тормый гына зиратларга.**

---

Мөнирә
Сафина

# ТЕГЕ ДӨНЬЯГА ХАТ

Әссәламегаләйкүм, Зөләйха түткәй!

Сиңа күптин-күп, чуктин-чук сәламнәр күндереп, ахирәтең Бибигайшә кызы Бибигөлсем хат яза.

Зөләйха түти, нихәлләр анда? Ирең кыйнаганнан соң рәтләнә алмадың бит, ә? Шул вакытта үлмәгән булсаң, әле дә яшәр идең, иеме? Юк шул, айга бер кыйналуга түзә алмадың.

И, Зөләйха түти! Әллә нишләп кенә сиңа хат язасым килде. Югыйсә моңарчы ике ятып бер төшемә кергәнең югые. Үпкәләмә инде, мин шулай дөресен әйтергә яратам.

Сагындырасың соңгы вакытларда. Хәзер күршегә күрше керми бит. Ә син көнгә өчәр юллый идең, әй, сөйләп китәр идең яшь чакларыңны! Хәтерлисеңдер, яшь чакта ГТО нормалары тапшырып йөргәнеңне. Хәзер

аны намаз алыштыра, әбиләр ярышып шуны өйрәнә.

Әй, Зөләйха түти! Яшь чакта кычыткан, алабута кебек чүп үләннәре ашавыгызны кызганыч итеп сөйли иден. Юкка кызганганмын икән! Сез бит витамин ашагансыз! Хәзер бик ашар идек, тик басу-кырларда чүп үләннәрен елап эзләсәң дә таба алмыйсың. Үзләрен «инвестор» дип атаган яэҗүс-мәэҗүс калдыклары басып алды хәзер дөньяны. Башта бөтен басу-кырларны агуладылар, хәзер нурландыралар.

Син инде боларны аңлап та бетерә алмассың, мин сина аны прастуй гына итеп аңлатыйм әле. Нурландырып үстерелгән икмәкне ашагач, мутант кешеләр туачак икән. Тагын аңламассың инде. Зур колаклы, акай күзле, мөгезле-койрыклы балалар туачак дигән сүз бу, Зөләйха түти, җаным! Менә шул, агу-нурга чыдый алмый чүп үләннәре бетте, без калдык. Адәм заты чыдам икән, әй! Беркөнне кибеттән помидор алган идем, шуның берсен кичтән күсе кимергән булган, иртәнгә үлгән иде бахыр. Ә безгә чуртым да булмады. Карап карыйк инде, кая барып чыгарбыз?

Әй, Зөләйха түти, җаным! Җәяүләп дөньяның әллә кай җирләренә барып җитүегезне сөйли торган идең, имеш, без машинага утырып йөрибез. Ә беләсеңме син хәзер адәм баласының көннәр буе бөкедә утырганын? Белмисең шул. Самолет төшеп кунарлык киң урамга сыеша алмыйча ике машина сөзешә дә, утырасың инде аннары. Әле бөкедән ычкынгач та, исән кайтып керә алсаң ярый, берәр наркоманга юлыгып, «аварияга» очрамасаң. Наркоман кем икән дип аптырарсың инде. Ата-анасының гомер буе халыкны талап җыйган малын бер елда туздырып, җилгә очыручы ул.

Әй, Зөләйха түткәй, җаным! Хәзер бөтен эшләгәнебез ашауга китеп бара. 105 килограмм булганмын инде, диетага утырмый хәл юк. Диетаның нәрсә икәнен дә аңламассың инде син, сезнең вакытта мондый проблемалар булмаган шул.

Сез бит өйдән  чыгып киткәндә ишеккә бер таяк терәткәнсез дә, шул җиткән. Ә хәзер? Ишекләр тимердән, сигнализацияләре бар! Әмма кайтып керешенә—ишек ачык, фатир буш. Менә шундый хәлләр бездә, Зөләйха түти, җаным-бәгырем!

Юк инде, ни генә дисәң дә, сезнең вакыт белән чагыштырганда, тормыш шактый авыр, Зөләйха түти. Урыныңнан кузгалмыйча шыпырт кына ят инде, яме! Урын димәктән, ә беләсеңме син хәзер урыныңның күпме торганын? Белмисең шул. Бер бүлмәле, бөтен унайлыклары булган фатирда ятам дип бел үзеңне, Зөләйха түткәй, җаным! Бездән шуның өчен күпме коммуналь түләү ала хөкүмәт, ә синеке бушка! Рәхим итеп, ничә ел ятсаң да, пропискадан төшерүче дә, урыныңнан куып чыгаручы да булмаячак. Валлаһи дип әйтәм, үлгәнеңә куан, түткәй—чын оҗмахта ятасың бит син!

Әле дә хәтердә, син үлгәч, авыл халкы атна буе елаган  иде. Хәзер алай итмиләр инде. Үлгән кешенең йортын бер күршесе сүтеп алса, икенче күршесе җирен ала. Менә шундый-шундый эшләр бездә, Зөләйха түткәй.

Әй, күнелле иде элек, име! Без бала чакта әбиләр капка төбенә чыгып утырырлар иде, узып баручы бала-чагага кәнфит, прәннек биреп калырлар иде. Хәзер алырсың әбиләрдән берәр нәрсә! Акча җыялар оек балтырына. Шуннан, шул акчаларны алырга кереп, үзләрен үтереп чыгып китәләр. Әйтәм бит, тегеләй дә, болай да, барыбер үләсе, иртә киттем дип, анда бик бетеренеп ятма инде син, Зөләйха түти, җаным!

Болар һаман кайгырышып яшәп яталар икән дип уйлама тагын син. Тормышның бик күнелле яклары да бар. Мәсәлән, кияүгә ничә тапкыр чыксаң да ярый хәзер. Берничә тапкыр өйләнергә мөмкин. Рәтең булса, кәнишне. Сезнең замандагы спекулянтларны да икенче төрле атап йөртәләр. Хәзер бөтен кеше эшмәкәр, бизнесмен, кем нәрсә сата ала

инде! Көчлерәкләре җирен, илен сатса, ваграклары ата-анасын, баласын, намусын сата. Кызыгып куйма тагын, син барыбер берни дә сата алмаган булыр идең. Хәтерлисеңдер, ирең сугышка киткәч, колхоз рәисе төнлә синең янга килгән, ә син аны кертмәгәнсең. Икенче көнне үк бер кесә ашлык урлаган өчен үзеңне 15 елга төрмәгә япканнар. Шулай булгач, бу тормышка яраклаша алмас идең барыбер, Зөләйха түти, җаным. Шыпырт кына ят инде, яме. Ә без... Ә без ялганларга, алдарга, куштанланырга, сатылырга тәмам өйрәнеп җиттек инде, ягъни бу тормышка яраклаштык! Ачу килсә, тотып тукмыйбыз, бирмәсә—талап алабыз, икенче төрле итеп әйткәндә, закон безгә нипачум!

Хуш, Зөләйха түткәй! Тагын бер кат әйтәм, үлгәнеңә шөкер итеп, тар кабереңнең киңлегенә куанып, караңгы гүреннең яктылыгына сөенеп, шыпырт кына ят, яме!

---

# РӘСЕМ БЕЗДӘН—ҖАВАП СЕЗДӘН



12нче санда басылып чыккан фотога күп кенә рәсем аслары килде. Менә аларның кайберләре.

**Җаның бик-бик сыкраса да**
**Түзәргә тырыш, Гаффар!**
**Бәлки әле мичкә сине**
**Гөнаһларыңнан саклар...**

**Зинфирә ГАБДРАХМАНОВА,**
*Мамадыш районы, Үсәли авылы.*

* * *

**Диогеннан соципотекага фатир алдым...**

**Мәсгут ИСХАКОВ,**
*Әгерҗе, Гагарин урамы.*

* * *

**Ишек ачып керсәм, түшәм**
**Башыма төшүе бар.**
**Бер кичкә кер мичкә, диләр,**
**Бер кичкә бу да ярар.**

**Рәис ГАЙНЕТДИНОВ,**
*Әлмәт шәһәре.*

* * *

**Алтын балык үзенә дәште, утын кисәсе бар, ди.**

**Лидия ШАКИРОВА,**
*Яңа Чишмә районы,*

***

**Әлегә башны калкытып**
**Дөньяны күзләп була.**
**Кисмәк тә буш, кесә такыр—**
**Күзләргә яшь тыгыла.**

**Гайдан**
*Казан*

* * *

**БАТУЛЛА**дан берьюлы унөч җавап килде.

**Тотса мәскәүләр якаң!**
**Язарга тема калмагач.**
**Никадәр генә яшерсәң дә нишләп утырганыңны беләбез.**
**Кризис вакытында язучының хәле.**
**Сез белмисез әле минем кайда эшләгәнне!**
**Мичкәне миннән тартып алалмыйсыз,**
**патаму што мин депутат, быррат.**
**Кара мичкәй эчләрендәй кара мыек мүчкәдәй.**
**Монда җылы, монда рәхәт, диде Гаффаров Әхәт.**
**Оям булды, берәр хатын табасы гына калды.**
**Җүнле хатын мине мичкәм белән күтәреп алып китәр...**
**Бай курасына әхрәнгә урнаштым.**
**Кыш көне кайда торыр микән бу бичара?**
**«Татмедиа»ның татар авторы.**

***

**Иркен мәйданнарга чыккан чакта**
**Татарныкы иде «мөшкә»дә...**
**Пушкин әкиятендәге карчыктай,**
**Утырып калдык... ярык мичкәдә.**

**Мөдәррис МӨХТӘСИПОВ**

***

**Әкәм-төкәмнең өе гел үзе белән.**

**Марс АХУНОВ**


---

*Хөрмәтле укучылар, сезнең игътибарыгызга*
*тагын бер фото бирәбез...*

***Сездән тапкыр җаваплар һәм хикмәтле***
***фотосурәтләр көтәбез!***



## ТАТАРНЫҢ БӨЕК ШӘХЕСЕ ИСМӘГЫЙЛЬ ГАСПРИНСКИЙНЫҢ (ГАСПРАЛЫ) ТУУЫНА 160 ЕЛ




*Соңгы чирек гасырда фикер, сүз һәм язу берлә бөтен төркиләргә иң күп хезмәтләр иткән зат — Исмәгыйль бәк Гаспринскийдыр.*

Ризаэддин Фәхреддин.



*Исмәгыйль Гаспринский. XX гасырның 90нчы еллары.*



*«Тәрҗеман»ның юбилее уңаеннан Кырым татарлары тезелеп газетаның исемен ясаганнар. 1908 ел.*



*И. Гаспринский Йосыф Акчура белән Гурзуфта (Кырым). 1908 ел.*



*И. Гаспринскийның хатыны Зөһрә Акчурина. XX гасырның 90нчы еллары.*



*И. Гаспринский. 1910 ел.*



*И. Гаспринскийның кабере. Кырым. Бакчасарай. 2006 ел.*

Фәнис
Яруллин

# ХӘТЕР ТӨПЛӘРЕНДӘ УТЛЫ КҮМЕР

КӨНДӘЛЕКЛӘР

## 1981

**6 гыйнвар.** Тагын больницага кердек. Бер палатада Нурсөя белән икәү генә. Ансы әйбәт. 7нче палатага салдылар. Палата врачы Нэлли Узбековна Камалова, сестра Зәйтүнә Мөхәммәтовна, юантыграк гәүдәле, кара чәчле, 55ләр тирәсендәге кеше.

Бүген көн бик буранлы, тәрәзәләр зыңлап тора, күңелсез. Стена штукатурлары купкан, идәннәренең плитәләре какшаган, йөрсәң абынып аягыңны сындырырлык. Ярый әле мина ул куркыныч янамый. Йөри алмауның да файдасы бар икән. Краннары рәтләп ябылып житми. Больницада ятудан бөтенләй бизгәнмен, ахры. Кырыйда Нурсөя булмаса, үләсең.

**7 гыйнвар.** Анализлар алдылар. Кан алучы сестра Тәнзилә исемле. Сары гына. Маржага ошаган татар кызы.

Көндезге сестра Дамира. Кара, чибәр генә. Беренче көнне бик тупас сыман күренгән иде, бүген ачылган әле. Моның белән любовь крутить итеп булыр иде.

Няня Люба әйбәт няня, диде врач, тегенди-мондый эшләрне алар сменасында башкару яхшы, диделәр. Икенче няня Настя.

Ашау:

Иртән: эремчек, чәй, бәрәңге белән сасыган диңгез балыгы. Балыгын монда кереп-чыгып йөри торган песигә биргән идек, иснәп тә карамады.

Көндез: токмачлы аш, итсез. Икенчегә кәбестә белән тавык боты. Бусы ярый.

Кич: манный боткасы белән әллә нинди тәмсез котлет. Яртысын ашадым.

Процедура сестрасы Венера исемле. Ашказаны өчен ниндидер таблетка биргәннәр иде, эчмәдем әле. Нинди икәнен белгәч, язып куярмын... Сирокал икән.

**8 гыйнвар.** Галина Александровна—уролог карады. Ике жирдә пролежень бар. Вишневский мае белән перевязка ясыйлар. Исе сасы. Перевязка ясаган май сап-сары булып урынга чыга.

Венадан кан алдылар.

Кардиограмма ясадылар. Йөрәктә ишемия.

Көн матур гына. Кар явып тора. Эре. Берәр матур кызга кар йомарлап атасы килә.

Невропатолог—Ольга Ивановна. Элек Баулыда медсестра булып эшләгән булган. Озынрак буйлы, бакыр чәчле, ачык йөзле. Баулыда чагында минем кайсы урында ятканны да хәтерләде.

Аһ, ул Баулы больницасында күргәннәр.

Мине бит Красноярскиның хәрби госпиталенә салганнар иде. Анда 18 июльдән

*Дәвамы. Башы узган санда*

(1958 ел) 9 майга кадәр яттым. Үкчәдән муенга кадәр бөтен жир чи яра. Матрасның өстендә клеенка. Шунда бер җәймә өстендә арка белән селкетмичә яткыра торгач, тән череп акты. Үләр хәлгә җиткәчтен врачлар «гуманлылык» күрсәтеп: «Туганнарың янында үләрсен»,—дип, мине Ютазы районы Урыссу больницасына озаттылар. Мин армиягә киткәндә безнен авыл Ютазы районына керә, район больницасы Урыссуда иде. Чынлап, монда үләр өчен мөмкинлек бар. Врачлар: «Синен кебек авыруларны Мәскәүгә җибәрергә кирәк иде»,—дип ачуны китерәләр. Мәскәүгә түгел, Баулы больницасына кучәр өчен дә әллә кайларга язарга туры килде. Баулы безнен авылдан 10-12 чакрым гына, ә Урыссу 35-40 чакрым ераклыкта. Туганнарга килеп йөрергә якынрак булсын дип, 1959 елның сентябрендә Баулыга күчтем. Монда да мине сөенеп каршыламадылар, билгеле. 6 кешелек палатага салдылар. Бар да авыр хәлдәгеләр. Сестра яки няняларны чакырырга сигнализация кнопкалары юк. Куллы кешеләр алюмин кружкаларына тимер кашык белән сугып няняларны чакыра. Ә минем куллар да эшләми. Үземнен бер туганымнан сигнализация куйдырткан идем, хирургия бүлеге мөдире А. Рябов аны алып ташлаттырды.

Йә, ярый, Баулы турында туктап, янадан бүгенге хәлгә кайтыйк.

Бик тә көтелмәгән бер очрашу булды.

М. Җәлилнең беренче хатынының кызы Люция белән таныштык. Үзенен исемен генә әйтте, кем кызы икәнен күпләргә әйтми икән. Күзлек киеп йөри. Төссезрәк кыяфәтле, конгырт (сыеграк конгырт) чәчле, урта буйлы. Кызы бар икән. «Кызым, кызым», дип сөйләшә еш кына.

Ныклабрак таныша төшкәч, үзенен Мәскәүдә кинематография факультетын бетерүен, диплом эше итеп әтисе турында фильм төшерүен, ләкин М.Җәлилнен хатыны Әминә моны экраннарга чыгарттырмавын ачынып сөйләде. «Ә бит минем әнием Зәкия М. Җәлилнең законлы хатыны. Аерылышканнар икән, анда минем ни гаебем бар?!»—диде ул.

Әйе, бездә кешене күтәрәләр икән, башка хатыннары турында белгертмиләр инде. Ә бит аерылышу, башкага өйләнү гомер-гомергә булган.

**11 гыйнвар.** Узган төнне дежур булган сестра—Фәридә Фатыйховна. Кыргыз кыяфәтле, беренче карашка кырысрак төсле күренсә дә, үзе яхшы кешегә ошый. Без анын белән 18нче эшче-яшьләр мәктәбендә бергә укыган булып чыктык. Йөзенә караганда үз яшеннән яшьрәк булып күренә. 36нчы елгы икән. Ике кызы бар. Олысы Илсөяр КДУнын тарих факультетында 1 курста укый. Икенче кызы Гөлфия 17 яшьтә. Аягына юктан гына шеш чыгып, аягын кисканнәр. Тездән өстә. Өенә килеп укытып йөриләр икән. Унынчы класста. Отличница. 30нчы мәктәптә укый.

Фәриденен ире инженер-конструктор.

Гөлфиягә «Упругие паруса»ны автограф язып бирдем.

**20 гыйнвар.** 1. Ритобалил уколы ясадылар. Атнага бер тапкыр гына ясый торган укол. Өчне билгеләделәр.

2. Кокарбаксилаз—кергән көннән бирле ясыйлар. Башта көн саен ясаганнар иде, хәзер $B^6$ витамины белән аралаштырып ясыйлар.

3. Төнлә температура 38 булды. Уролог Галина Александровна уротропин (венага) кадарга булыр дип китте. Иртән 37,2 иде.

4. Көненә өч тапкыр бер бал кашыгы кардиомин эчерәләр.

5. Ашказаны өчен бер таблетка. Церукал.

6. Бөерләр өчен көненә дүрт тапкыр апельсин төсендәге таблетка бирәләр. Нитроксалин.

Укол кадаучы сестра—Венера.

Сестра Зәкия, мишәр кызы. Власть яратучанга охшый. Читтән торып пединститутнын 1 курсында укый. Ярый әле врачлыкка укымый, бәлки, укытучылык сәләте бардыр.

Адилә Нургалиевна, таза гәүдәле мишәр хатыны. Йомшак күнелле кеше, ахры. «Упругие паруса»ны бүләк иткән идем, елый-елый укыдым, диде.

Яшь Дамира кара чәчле, яшькелт күзле. «Минем күзем төрле чакта төрле төскә керә»,—ди. Икенче Дамира безнен белән бер яшьлек. Күп сөйләнә. Нәрсә сөйләгәнен онытkалап та җибәргәли. Хәрәкәтчән, һәрвакыт чабып йөри, ләкин эше бетми. Түшәмгә карап күтенә укол кадап чыгып китәргә мөмкин. Игътибарсыз.

Валя дәвалау гимнастикасы буенча инструктор. Җәлләүчән. Кайчандыр травматологиядә эшләгән, балалар бүлегендә. «Балаларның газапларын күрү минем өчен газап иде»,—ди, шуңа күрә аннан киткән.

Роза, массажистка. Апас ягыннан. Йомшак куллы, салмак хәрәкәтле.

**18 февраль.** Больницадан чыктык.

**25 декабрь.** Бөеремә инфекция эләкте бугай. Температура 39,6 булды. Көндәлекне дәвам итеп Нурсөя язып куйган.

## 1982

**4 гыйнвар.** Фәниснең температурасы тагын 39,4. Врачлар бөердән диләр. Белмим! Барлык анализларын биргәннән соң өйгә хирург Хәлим Галимович, уролог Галина Александровна, янадан терапевт Флорина Сергеевна килде. Соңгы елларда нык кына йөрәге борчый. Быел тагын АТФ уколлары билгеләде 30 шт.

**14-15 гыйнвар.** Укол—сульфокамфокаин, 10%. Беренче уколны врач үзе барында ясатты. Хәлен тикшереп торды. Фәниснең хәле авыраеп китте, пульс нормальный, бит очлары кызарып чыкты, тәне кызыша башлады. «Күкрәкне ниндидер авыр әйбер баскан кебек булды»,—ди. Кабат врач пульсын санады. Мин күзәтеп торам. Нык куркытты аның хәле авыраю.

АТФ аптекаларда юк икән. Кокарбаксилаз бирә башладылар 20сеннән. Барлыгы 15 укол кадарга тиешләр. Сульфокамфакаинны алты укол алгач туктаттык. Бик ошамады әле ул. Ярты сәгать буе күкрәктә ниндидер авырлык сизелеп тора.

**1 февраль**дән грамурин эчә башладым. Цистит, пиелонефрит һәм башкалар өчен диелгән. Быел яңа елга чыкканнан бирле рәт юк әле. Хәлсезлек, тирләү, кинәт кенә эчне борып-борып алулар. Ябыктым да шикелле. Хәзер мине үлчәп карасаң, 30 кг дан артык түгелмендер. Үлгәч, мине күтәреп баручылар: «Бу әллә төшеп калдымы икән?»—дип артларына борылып-борылып карарлар инде.

Ике көннән уколлар бетә. Ләкин файдасы шуның кадәр генә.

**8 февраль**дә Грамуринны эчүдән туктадым. Житеп торыр.

**16 февраль**дә беләк мускулларының юанлыгын үлчәдек. Уң кулныкы 18 см, сул кулныкы—19 см. Уң кулның мускулын Нурсөя сыңар кулы белән кысып тотса, бармагы бармакка тия. Сулъяк бераз көчлерәк тә, юанрак та. Утырырга күттә ит юк, чөй өстендә утырган шикелле. Ярты сәгать утырсаң, «чөй» өсләре кып-кызыл булып чыга. Пролежьлы урыннары менә-менә ачылырга торалар. Өф-өф итеп тотканга гына кеше рәтендә йөрим. Әгәр мине чишендереп постаментка бастырып куйсаң, медицина институтында укучыларга әйбәт кенә скелет булыр идем. Шунда берәр чибәррәк кыз скелетны өйрәнеп маташканда күз кысып алсаң, теге мескен мединститутка бүтән әйләнеп тә карамас иде.

Февраль аенда берни дә язган юк диярлек. Үземә ял бирдем әле. Тютчев хатларын укып яттым. Байронның «Дон Жуан»ын укып чыктым. Бик оста кул белән язылганы сизелеп торса да, артык җәелеп китүләре туйдыра башлый. Тасвирлауларына караганда лирик чигенүләре акыллырак тоелды. Андый җирләрдә гомумиләштерүләр көчле.

**25 февраль.** Быел туган көнне ике атна бәйрәм иттек. 12 февральдә элекке күрше Самат абый килгән иде, кулы (аягы) җиңел булды. «Синең туган көнең 13 февральдә бугай,—ди,—иртәгә кешеләр күп булыр дип, бүген килдем»,—ди. Туган көн кызык бит минем: паспортта 9 февральдә дип язылган, язучылар турындагы белешмә китапта, каян алыптыр, 13 февраль дип куйганнар. Үзем, әни әйтүгә таянып, 23 февральдә дип йөри идем. Шунлыктан төрле кеше төрле вакытта килә.

13е көнне Айтуган абыйлар, 14е көнне Арчадан Халидәләр килде. Халидәнең кызы Алсу бик тере нәмәрсә икән. Өч яше дә тулмаган, чип-чиста сөйләшә. Житмәсә, татарча. Элек русча сөйләшә белүчене күрсәк шаккатып, сокланып тора идек, хәзер татарча сөйләшә белгән балага исебез китә. Вәт дөньялар кайсы якка таба борылды. Әле бүген Наилә апалар (мине 18нче мәктәптә укыткан укытучы) белән 5нче класста укучы ике кыз да килгән иде. Татарча белүләренә ышанып житмичәрәк торганлыгымны күргәч, берсе татарча шигырь сөйләп

күрсәтте һәм минем «Язмышлар язылганда» дигән повестьның бер абзацын укыды. Ул китапка автограф язып бирдем. Бүген алты автограф яздым: Наилә апага, Люзиягә, Фәүзиягә (мехкомбинат училищесында укучы кыз) һәм Әминә исемле 11 класста укучыга, шулай ук теге 5 класс укучыларына. Берсе минем «Язмышлар язылганда» дигән повестьны алып килгән, каян тапкандыр. Ул китап минем бик тиз таралып бетте, укучылар яратып кабул итте, тәнкыйтьчеләрнең генә күзенә чалынмады.

21е көнне Кояш Тимбикова, Вафирә Гыйззәтуллиналар килгән иде, җырлашып утырдык. Вафирә минем ике җырны җырлады. Телевизордан караганда ничектер салкынрак кешегә ошата идем Вафирәне, мәҗлестә бик күңелле кеше икән. Узган җәй дачада Кояшның ире Рейнның туган көнендә дә Вафирә бар иде. Больницадан яңарак чыккан вакыты, озак җырламаган. Җырлый алырмынмы дип куркып кына башлаган иде, тавышы ачылып китте, сипте генә. Анекдотлар сөйләргә дә, башка кеше роленә кереп сөйләшергә дә оста. «Кечкенә вакытта урамнан төрле әшәке җырлар отып кердә идем дә, өйдә җырлый идем,—ди.—Шунда бервакыт әти минем авызга кундырды да: «Ай, юньсез, рәтле бала булмассың, бәлат булырсың»,—дип әйтте, ди. Ә артист булып танылганнан соң Илһам Шакиров белән безнең авылга кайткач: «Кара әле, Вафирә, сина теге вакытта әтиең дөрес әйткән бит, нәкъ өстенә баскан»,—дип әйтте, ди. Үзе турында үзе шулай юмор белән сөйләгәнгәме, гайбәткә урын калмады. Көлештек тә бетте.

Язучылар союзыннан туган көн белән котлап шалтыратучы булмады. Әйтерсең, мин бөтенләй юк. Ярый әле укучыларым күп. Өч букет китерделәр. Кыш көне бит бу.

Бер букетны һәм Шукшин рәсемен тактага ясап 38нче мәктәп укучылары китерде. Алар үзләренең мәктәпләрендә корчагинчылар почмагы ачканнар. Минем «Упругие паруса»ны укыганнар да танышырга килгәннәр. «Первая борозда» китабына автограф язып бирдем. Карточкага төшерделәр. Фотоны алып килгәннәре юк әле. «Тагын сезнең кебек язучылар бармы?»—дип сорадылар. Илгиз Кәлимуллинны әйттем. Безнең бер группа укучылар аңа барып йөри инде, диделәр.

Икенче букетны Кояшлар, өченче букетны Равилә (Кама Тамагы кызы) алып килде. Равилә Хәбибуллина житен комбинатының комсомол секретаре. Бик эшчән, кешене олылый белүче кызга ошаган. Хәзерге яшьләрдән минем аның кебек кыз күргәнем юк әле. «Нурсөя апа, нәрсә эшлим?»—дип кенә тора. Ялт савытлар юа, кирәк икән, теләсә нинди ашны пешерә белә. Иренми. Заочно университетның тарих факультетында укый. Үзбәкстанда үскән кыз балалар ничектер өй эшләренә оста булалар. Күрәсең, хатын-кызның төп вазифасын анда дөрес аңлыйлар һәм балаларны шуңа әзерлиләрдер.

Көтмәгәндә Үзбәкстаннан кунаклар килеп төште. 1977 елда Янгиюль шәһәрендә үзебез Ямал апаларда кунакта булган идек, шулар безгә күчтәнәч җибәргәннәр, туган көн белән котларга кушканнар. Расих абыйлар (Ямал апаларның туганы) шул миссияне үтәү өчен безгә килгәннәр. Алар белән бер шампанскийны салып, акны башлап кына утырганда 1963 елда Бәкер курортында эшләгән бер сестра—Рәйсә килеп керде. 19 елмы күрешмәгән идек. Хәер, 19 ел түгел икән, 1965 елда безгә килгән булган. Элек аның квартиры Лениногорскида иде, аннан Тольяттига, Тольяттидан Казанга алыштырган. 13 метрлы, өлешчә уңайлыклары булган бүлмәдә яшим ди. Тугыз семьяга бер туалет. Шәп түгел. 49 яшькә җитеп, тыныч кына, үзеңчә итеп яшәрлек урынның булмау авыр нәрсә, билгеле.

**15 март.** Мәдинә Маликова әдәби ел йомгакларыннан кайтышлый кереп, кемнәр нинди докладлар белән чыгыш ясавын сөйләде. Мансур Вәлиев проза турында сөйләгән икән. Минем ике хикәяне, «Кияү сайлау» («Социалистик Татарстан»да чыккан иде) һәм «Фаҗига»не («Казан утлары»нда) уңай яктан телгә алып киткән. Берничә көннән М. Вәлиевнең проза турындагы чыгышын радиодан тыңладым, минем шул хикәяләрне атады һәм «Хикәя жанрында боз кузгала башлады»,—диде. Шулай ук Р. Вәлиев тә шигырьләр буенча сөйләгән докладында узган ел «Казан утларын»да басылган шигырьләр циклымны уңай бәяләгән.

Әле менә «Казан утлары»ннан (3 сан) Ринат Мөхәммәдиевнең «Язлар тагын килер» дигән мәкаләсен укып яттым. Анда ул яшь шагыйрьләр турында сүз алып

бара һәм Ямаш Игәнәй дигән шагыйрьгә тукталып, аның бер шигыреннән өзек китерә:

*Менә шушы якка таба*
*Барам мин, барасы бар.*
*Әнә шул офык ташыннан*
*Бер кала саласы бар.*

*Менә шушы якка таба*
*Барам мин, барасы бар:*
*Яшен чаткысын яшьлеккә*
*Өлгегә аласы бар.*

Бу китерелгән өзек минем 1976 елда ук язылган һәм 1978 елда «Сулыш» китабында дөнья күргән иде. Ямаш Игәнәй минем «Гомернең һәрбер көнендә» шигыренә унышсыз вариант кына язган. Ә тәнкыйтьче аны яшь шагыйрьнең табышы итеп күрсәтә. Минем ничә шигырьне урладылар... Әле күптән түгел генә «Социалистик Татарстан»да Нәби Дәүлинең «Нәни доктор» хикәясе чыкты. Бу да шулай ук минем моннан ун ел элек язылган һәм «Азат хатын» журналында, «Яшел утрау хуҗалары» дигән җыентыкта басылып чыккан «Тавышым калсын билгегә» хикәясенең гаять примитивлаштырылган күчермәсе. Вакыйгалар һәм сюжет тулаем минеке, бары тик персонажларның исемнәре генә үзгәргән. Бу хикәямне бик ошатуы турында Ф.Хөсни миңа хат та язып салды. Ул хат саклана әле.

Кызык кына хәл: минем шактый гына әсәрләрнең язмышы фаҗигагә дучар була. Әле күптән, моннан 15-17 еллар чамасы элек минем бер шигырь «Яшь ленинчы» газетасы үткәргән конкурста бүләк алды, анда девиз белән басылып чыкты һәм аңа бер композитор көй язды. Ул җыр озак кына вакытлар радиодан җырланып йөрде. Ә бервакыт телевизор карап утырам, минем җырны тапшыралар. Сүзләре шул ук, ләкин шигырьнең авторы башка. Дөрес, аның ахырында бераз өстәмәләр бар барын. Композитор аны кантата дип атаган. Бу турыда Ш. Галиевкә әйткән идем, ул: «Син моңа сөен генә, димәк, урларлык әйберең бар,—диде һәм,—барыбызныкын да урлыйлар»,—дип, мине тынычландырды. Мин бу җырның исемен дә, шулай ук композиторын да атамыйм. Алар, бәлки, киләчәктә зур шагыйрь һәм танылган композитор булып китәрләр. Дөнья бит бу. Юк-бар өчен кешене оялту ярамас. Бәләкәй чакта үзебез дә бит кеше бакчасыннан кыяр урлап ашый идек.

**22 март.** Бүген көтмәгәндә нәфис сүз остасы Әзәл Яһүдин килде. 74 яшьтә булуга карамастан хәрәкәтчән кеше. Килеп керүгә үк мышный-мышный минем «Өлгермибез» дигән шигырьне сөйләргә тотынды. Күптән килергә әзерләнеп йөрдем, ләкин монарчы килергә вакыт җиткерә алмадым, ди. Сүзен раслау йөзеннән минем шул шигырьне укыды. Моннан 5-6 еллар элек ул миңа бер хат та язган иде, ничектер хатына җавап бирелмәде. Күңелле кеше икән. Минем күп кенә шигырьләрне яттан белә. Үзенең репертуарында минем шигырьләрне даими йөртә. «Шешәләр җыры» дигән сатирик шигырьне гармун белән башкара. Хәтта шигырьгә берничә юл да өстәгән. «Чылтыр-чылтыр» дип, шешәләрнең җырын гармунында чыңлатып җибәрә, бик шәп чыга. Гармуны да ни аккордеон түгел, ни тальян түгел бер нәрсә. 51нче елда кулдан алган идем ди. Әзәл абый белән күңелле итеп утырганда 35нче мәктәпнең 8нче класс укучылары килеп керде. Алар, килергә мөмкинме дип, алдан белешеп киткәннәр иде инде, артистка әйбәт тамашачы булдылар. Миңа сөйләгән шигырьләрне Әзәл Яһүдин аларга да сөйләде. Тегеләр мөкиббән китеп тыңладылар. Артист артист инде: тыныч кына тавыш белән укымый, сәхнәдәге сыман бөтен көченә кычкырып, кулларын һәм гәүдәсен хәрәкәтләндереп, төрле мимикалар кушып сөйли. Бу мәктәп балаларын ике студент-практикант алып килгән. Берничәсе минем шигырьне ятлап килгән. «Упругие паруса»ны укыганнар. Кайбер сораулар бирделәр. Хәзерге балаларга карап-карап торам да, әллә хәзерге балалар акыл ягыннан безнең чордагы балалардан түбәнрәк торалар микән дип уйлап куям. Гадәттә без хәзерге балаларны бик акыллыга саныйбыз, аларның һәрбер сүзеннән

зур мәгънә эзлибез. Әбисенә-бабасына, әтисенә-анасына бер бала булганга, аларның һәр сүзенә игътибар итеЛә, акыллы тоела. Ә без үскәндә һәр семьяда 6-10 бала, аларның сүзенә кем игътибар биргән дә, кем җөпләп утырган. Туган көнне үк әллә нинди романслар җырласаң да сине тыңлап утырырга ата-ананың вакыты булмаган. Хәзерге балалар бик күп информация ала дибез. Ә ныклабрак төпченә башласаң, берсе-бер китап укымаган, аннан-моннан телевизор караган һәм шуның белән вәссәлам. Дөрес, аларның безнең чордагы балалардан кайбер өстенлекләре дә бар. Мәсәлән, кайсы музыка мәктәбендә укый, кайсы балет түгәрәгенә йөри. Һәрберсе сәнгать кешесе булып китмәсә дә, сәнгатьне аңлаучы булып үсәләр. Аңсы ярый.

Шушы араларда Ги де Мопассанның «Жизнь», «Милый друг» дигән романнарын укыдым. Дөрес, алар элек укылган әйберләр. Бик заманча язылган, әле дә үрнәк алырлык әсәрләр. Җиңел укыла, мавыктыргыч. Сюжеты, вакыйгалары безнең заман өчен ятрак булып тоелса да, психологик нечкәлекләре күңелдә ятып күгәрә башлаган хисләр кылын өр-яңадан уята, дәртләндерә. Мин үзем дә бик яшьли гашыйк булган малай. «Тылсымлы таякчык»ка җан керүгә кызлар артыннан чаба башладым. Ә эзләгән кеше барыбер үзенә кирәген таба тора. Безнең чорда да бөтен кыз фәрештә булып, ак канатта гына очып йөрми; җиргә төшә, үлән арасына кача, йөгергәндә итәкләрен җилләр ача һәм алар берәр аулак урында «ялгыш» егылалар. Син «ялгыш» егылган кызга «ялгыш» абынасың…

**27 март.** Дөнья кемнәр белән генә таныштырмый! Өченче көн Нурсөя кибеттә бер кыз белән танышкан: КамАЗдан монда әйберләр алырга килгән идем, кунарга урыным юк дип тора икән. Нурсөя: «Давай, тот та безгә кайт»,—дигән. Артык ялындырып тормастан әйберләрен күтәреп кайтып керде бу. Бик кыю кыз. «Менә паспортым,—ди,—исемем Гөлия, фамилиям Вильданова»,—ди. Китереп тоттыргач, паспортына күз салырга туры килде. 21 яшьтә. Октябрь районы Кизләү авылы кызы. Тәскә-биткә әлләни чибәрлеге юк. Буйга Нурсөядән озынрак. Шаярганны аңлый һәм үзе дә шаярып сөйләшә белә. Шул ягы белән күптәнге танышың сыман булып китә. Тавышы да ярыйсы. Бөтен яңа җырларны белә. Минем «Бар ул син эзләгән кеше», «Каз кычкыра», «Чык юлларга» җырларын җырлап күрсәтте. Телевизордан кино карап утырган җирдән генә. «Мин бу җырларның кем сүзләре икәнен белми идем, сезнекемени?»—дип бик шаккатты. «Бар ул син эзләгән кеше» җырын мин шыңшып йөреп бүлмәдәге кызларны туйдырып бетердем инде»,—ди.

Минем «Җилкәннәр җилдә сынала» повестен да укыган булып чыкты. «Бу китап бездә бар,—ди.—Апам китаплар җыярга ярата, ул алып кайткан иде»,—ди. Ә бусына җыр гына булсын. Шигырьләрнең берәр куплетын гына укый да: «Бу җыр түгелме?»—дип сорый. Җыр түгел дигәч, китапны тагын актара башлый. Бер кичтә минем бөтен китапларны «укып» чыкты.

**12 апрель.** Бүген космонавтика көне. Гагарин космоска очкан көнне, ягъни моннан 21 ел элек мин Баулы больницасыннан авылга кайттым. Урамнар инде кипшергән, ишегалларын себереп куйганнар иде. Ә быел әле бик пычрак, салкын. Яз нык сонарды.

«Азат хатын» журналының 4нче санында минем «Яшь белү» хикәясе чыкты. Журнал чыгып житү белән хикәяне укып, М. исемле бер апа килде. Бик дулкынланган. Сүзен башлый алмый озак кына азапланды. «Хикәяңне укыгач, түзмәдем, күңелемне бушатырга килдем»,—дип сүзен башлады. Мин, ди, хатын-кызны 18 яшьләрдә генә рәнҗетергә буладыр дип уйлый идем, аны олыгайгач та рәнҗетеп була икән, ди. Сезнең хикәядәге сүзләр, ди, миңа карата әйтелгән, ди һәм дәфтәренә хикәядән күчереп алынган менә бу юлларны китерде: «Кешегә ышану—сафлык билгесе. Саф күңелләргә вак-төяк пычрак йокмый, алар үзләренең ышанычлары, кешеләрне олылый белүләре белән югары булалар. Тик егылганда каты егылалар».

Бу апа сүзен шактый буталчык сөйләде. Башта Вакыйф Нуруллинның «Һәлакәт» дигән повестен пыр туздырып ташлады. Хатын-кызны бөтенләй юкка чыгарган, ди. Хатын-кыз андый була алмый ул, ди. Повестьтагы Гасимә образын Вафирә Гыйззәтуллина дип әйтәләр, ди. Шулай микән, ди? Мин, әлбәттә, әдәби образлар белән чынбарлык кешеләрне бер итеп карарга кирәк түгел икәнлеген, хәзер Гасимә кебек кешеләрнең чынлап та күбәя баруын һәм аларны әдәбиятта күтәреп чыгу

кирәклеген ана аңлатырга тырыштым. Ул минем белән килеште дә шикелле. «Их,—ди,—мин авторны сүгеп хат язган идем шул инде»,—ди. Үзе тагын: «Ярый әле исемемне язмаган идем»,—дип сөенеп куйды.

Ә аның рәнжетелүе шуннан гыйбарәт икән. Бер кешегә ышанып өенә баргалаган, алыр дип уйлаган. Теге кеше язучы икән. Хатыныннан аерылган. Башта аның кем икәнлеген әйтмәгән иде, ләкин соңыннан миңа ычкындырды үзе... «Мин аны бик инсафлы, әйбәт кеше дип уйлый идем, ә ул әнә нәрсә эшләде—өенә китереп йөртте-йөртте дә пычрак аягы белән күңелемне таптады,—ди.—Әгәр син миңа ошамыйсың дип туры үземә әйткән булса, болай үртәлмәс идем, ә ул ниндидер иптәшенә хат язган булып, ул хатны туалеттагы чүп чиләге өстенә язылган ягы белән өскә каратып куйган, ди. Анда ул минем турында болай дип язган, ди: «Ко мне ходит одна женщина, но она мне не по душе».

Бу апаның инде ике җиткән малае бар. Ире 13 ел элек үлгән. «Җиткән малайларым алдында мин көн саен кая барганымны әйтмичә төннәрен чыгып китә алмыйм бит»,—ди. Малайларына да әйткән, эшләгән җирендәге кешеләргә дә. Хәзер менә эшләр болайга киткәч ана бик оят.

Әгәр ул танылган кеше булмаса, бу апа артык рәнҗемәс иде. Ләкин апа шуны аңламый: һәр дәрәҗәле кеше дә олы күңелле була алмый. Алар эчсә дә, хатыны белән аерылышса да шунда ук күренә. «Язган шигырьләренә караганда ул бик әйбәт, кешелекле кеше булырга тиеш дип уйлаган идем. Ә ул бөтенләй киресе икән»,—ди.

Алдану, әлбәттә, бик авыр нәрсә. Алдануыңны белү ул үзеңне башкалардан ким итеп тану дигән сүз. Кемнең инде үзен башкалардан ким итеп күрәсе килсен ди.

Бу апа минем «Әнә килә автомобиль»не 7 мәртәбә караган.

**15 апрель.** Температурить итә башладым. Кич белән 39,3 кә җитте. Нәрсәдән башланды? Тарихы болай: хәзер минем торган саен тышка чыгу яклары авырая бара. Эчне йомшарта торган дарулар эчәргә туры килә. 15е көнне сенна яфрагы кайнатып көндезге сәгать 12дә бер аш кашыгы эчтем. Дүртенче яртыларда эчне авырттырып йөри башлады, көтәм, ләкин кузгатырга исәбе күренми. Бишенче яртыларда тагын бер аш кашыгы эчеп куйдым. Бераз вакыт үткәч, авырту басылгандай итте. Кичке унынчы яртыларга хәтле көттем, нәтиҗә юк. Тагын бер кашык җибәрдем. Ә аңарчы инде бөтен тән калтырый, өшетә башлаган иде. Температура күтәрелде. Чөнки тизрәк бәреп чыксын дип, шул өченче кашыкны эчтем. Тик бәреп чыгарга һаман уйламады. Шул килеш йокларга яттык. Корсак барабандай тартылган. Аяк сенерләре тартыша, аякларны сузып булмый. Ярты таблетка баралгин һәм бер седуксин эчтем. Йоклап булмады. Нурсөя нервыланып бетте. Бер төндә генә биш-алты тапкыр торып кара әле. Аннары кешегә ярдәм итә алмавың үзе үк нервыга бәрә торган нәрсә. Кешенең җәфаланганын карап тору беркемгә дә рәхәт түгел.

Ниһаять, 16сы көнне сәгать алтылар тирәсендә чыгарга «заявка» килде һәм Нурсөя ярдәмендә эчне бераз җинеләйттек. Температура да төшкән сыман итте. 8ләрдә чәй эчтек. Аннары Нурсөя минем чәчне алды, ваннада юындырып чыгарды. Төш җитте. Ләкин юынып чыккач өр-яңадан калтырата башлады. Яңадан температура 39дан узып китте. Шунсы кызык: бер сәгать торгач үлчисен—35,5, ә тагын бер сәгатьтән үлчәсәң, кире күтәрелгән була. Кешенең кайнарлыгы гел үзгәреп тора икән.

Температура өч көн дәвам итте. Ул көннәрдә грамурин эчтем.

**19 апрель.** Врач чакырттык. Флорина Сергеевна Чуприна килде. Һәммәсен сөйләп бирдем. Хирург чакыртып карарга булыр дип китте. Иртәгә хирург килергә тиеш. Чуприна но-шпа эчәргә кушты.

Бүген кичке сәгать тугызларда беренче яшен яшьнәде. Бәлки, бу мин күргән яшеннең генә беренчеседер. Һәрхәлдә, язның беренче яшенен үз күзем белән күрдем дип уйлыйм. Күк тә күкрәде. Күк күкрәгәндә җиргә ятып аунарга кушалар кушуын, ләкин минем чирәмдә аунарга мөмкинчелек булмады. Урын өстендә бик каты «ауный» торган чакка туры килде быелгы беренче яшен. Нинди хәлдә булма, яз барыбер төрле хисләр уята. Киләчәктән нидер көтәсең. Яз—өмет, яз—дәртләнү, яз—балачакка кайтып килү.

Кызык кына: утыз тугыз температура белән ятканда ике шигырь язып куйдым. Лирик шигырь булса, үлемеңне сизеп күңелең нечкәргән дип уйлар иден,

публицистик шигырьләр бит. Теге вакытта Рәдиф никадәр сорап бер юл яза алмаган идем. Шигырьләре дә ярыйсы гына булды тагын. «Табыну» җыентыгын төрләндерергә әйбәт булыр.

СССРның 60 еллыгына «Ялкын»да уздырыла торган конкурс өчен бер хикәя яза башлаган идем, менә бу чирләр туктатты әле. Әгәр язучыларның берәрсе минем кадәр чирләсә, бер юл да әйбер яза алмас иде, мөгаен. Минем бөтен чиремне алар бары тик йөрмәүдә генә күрәләр. Барысын да язып тормыйм. Юкса и-и мескенкәй дип җәлли башлыйлар. Ә Нурсөя андый кызганучыларны гомумән күралмый. Шушы килеш 24 ел яшәп, һәм шуның өстенә иҗат белән шөгыльләнеп ятам бит әле. Монда, әлбәттә, Нурсөянең өлеше бик зур. Әгәр ул «өф-өф» итеп тотмаса, бер атнада череп аккан булыр идем. Курортка барсам—курортта, больницада ятсам—больницада гел иң мөһим, иң пычрак эш аның өстендә булды. Сестраларга гына калсаң, алар сине бер төндә 3-4 тапкыр әйләндереп яткырып йөрмиләр. Хәтта йокы даруы сорасаң да әҗәл даруы сорагандай акаеп карыйлар.

Йокы даруын нигә бирмәүләрен беләидем. Чөнки «Старая клиника» дип аталган Республика клиникасында ятканда бер сестраның бу даруларны астыртын гына наркоманнарга сатып ятканы беленә һәм аны күзәтә башлыйлар. Тотылмый торган карак юк диләр. Теге дә тотыла. 1962-63 еллар өчен бу коточкыч зур тетрәнү булды. Ил белән Н.Хрущев идарә иткән еллар. Әлбәттә, сестраны төрмәгә утырталар.

Укол белән кертелә торган көчле йокы дарулары гадәттә санап кына бирелә. Пломбалап куелган шкафта саклана. Андый уколларны авыр операциядән соң өч кенә көн бирәләр. Ничек шундый санаулы нәрсәне сатарга мөмкин? Хәйләкәр кеше җаен таба икән: авыруларга тиешле морфийны башка ампулага бушата да, авыртудан чыдый алмаган кешегә йә пеницилин, йә башка берәр дару белән укол ясый. Бичара авыру: «Нишләптер авыртуны укол да баса алмады»,—дип бәргәләнеп төн чыга. Ә иртән сестра морфийдан бушаган ампулаларны өлкән сестрага тапшыра. Буш ампулалар белән бергә фәлән-фәлән кешегә уколлар кадалды дигән исемлек тә куела.

Ил башында нинди генә сәясәтче утырмасын, карагы да, үгерүчесе дә бетми икән.

**21 апрель.** Хирург килде. Зуррак кешенең борыны кадәр генә бер малай шунда. Әллә сез студентмы, мәйтәм. Юк, ди. Минем инде институт бетергәнемә өченче ел дип тора. ГИДУВта ике еллык ординатураны бетергән. Белмәссең, берничә елдан берәр больницага доцент булып та урнашыр әле. Ә үзе умыртка сөяге сынган кешенең хәрәкәтләндерү нервлары эшләмәгәнлеген дә белми. Һаман бер сүзне кабатлый: «Эчәкләрнең эшләү системасы автономно»,—ди. Эченне тартып, һәркөн гимнастика яса ди. Бер генә әгъзаның да «автономно» эшли алмаганын, һәр орган бер-берсе белән нык бәйләнештә икәнен врач булмаган кеше дә белә югыйсә. Ул мине аңгырага санап әйтте, ахры, бу сүзләрне. Килеп керү белән русча сиптерә башлады. Татар икәнен белгәч: «Нигә миннән русча сөйләтеп, башымны катырасың?»—дим. «По привычке»,—дип тора. Сөйләшә торгач, Кукмара районыныкы, унъеллык татар мәктәбе бетергәнлеге, минем шигырьләрне укып үскән малай икәнлеге беленде. «Сез шигырьләр язасызмы әллә?»—дип сорамаса, сорашып маташмаган да булыр идем, бәлки. Үзеннең язучы икәнлегенне әйтү кыен ул. И-и, бу хәлдә яткан кешенең шигырьләре инде, дип әйтерләр яки уйларлар кебек.

Берничә көн но-шпа эчтем.

**24 апрель.** Быел беренче җылы көн. Моңа кадәр гел яңгыр, салкын булды. Нурсөя беренче тапкыр бакчага барды. Равилә белән. Агачларны чишкәннәр, хлорофос сиптергәннәр, кишер чәчкәннәр, гладиолус утырткannar һәм яшел килеш йолкып алыр өчен бераз суган төрткәннәр.

**25 апрель.** Бүген Нурсөя тагын бакчага китте. Суган утыртырга. Быел ярты кило гына алдык. Авылга кайтып китәргә туры килер, бәлки... Көн—Казанда 16-18, Татарстанда 15-20 градус була диде. Әле агачларда бөреләр яңа бүртә башлады. Шушылай җылы торса, яфраклар озакламый ачыла башлар.

Бу арада берни язган юк. «Иностранная литература» журналларын укып яттым. «Казан утлары»ннан Н.Фәттахның «Сызгыра торган уклар» романының башын укыдым. Искитәрлек булырга ошамый әле. Тарихи әсәр конфликты артык шәхси

нәрсәләр аркасында килеп чыга. Атасы белән улының бер кызны яратулары аркасында гына роман тикле романда халыкларның төркемнәргә аерылуы, төркемнәрнең дошманлашуы һ. б. лар.

**26 апрель.** Бүген тагын теге М. апа килде. Тукай һәйкәле янында үткәрелә торган шигырь бәйрәменә барган. Язучы халкына бик мөкиббән киткән кеше. Элек килгәндә минем «Җилкәннәр җилдә сынала»ны алып киткән иде, ярты китапны диярлек үзенең дәфтәренә күчереп алган. Ничек мин моны чыккан вакытта укымадым икән дип бик аптырады. Менә бит, ди, әгәр теге иптәш мине шулай рәнҗетмәгән булса, сезнең янга килмәгән булыр идем, ди. Сезнең әсәрләрегез кешеләргә карата югала башлаган ышанычымны кире кайтарды, ди. Минем кайбер шигырьләрне яттан белә. «Азат хатын»да чыккан «Яши белү» хикәясенә, «Җилкәннәр җилдә сынала»га гашыйк. Боларга карата әйтергә миндә сүз юк, ди. Нурсөягә әйтә: син нинди бәхетле кеше, ди. М. апа Нурсөягә чәчәкләр алып килгән.

**27 апрель.** Вак кына яңгыр сибәләп тора. Температура Казанда 15-17, Татарстанда 15-20 градус. Дүртенче көн инде температура шул чама саклана. Бүген «Бүректәге бүре баласы»н язып бетерергә кирәк.

**28 апрель.** Нурсөя бакчага китте, җиләк эшкәртергә. Иртән вак яңгыр сибәләп маташты. Температура 14-16, Татарстанда 23кә кадәр. Яфраклар әзрәк яшәрергә маташалар.

Бүген 10нчы интернат-мәктәпнең 6а классы укучылары очрашуга килделәр. Икенче курс студенткасы (педнең) Лилия исемле кыз алып килгән. «Былтыр группабыз белән без сезнең янга килгән идек, бик кызыклы, күнелле очрашу булган иде, шуны менә балаларга сөйләдем дә сезнең янга барасылары килде»,—ди. Укучылары минем әсәрләрне бик әз укыганнар. Берничә шигырьдән башканы исләренә төшерә алмадылар. Араларында бер бик кыю малай бар, Арча районыныкы. Әдәбиятны күп укыганлыгы сизелеп тора. «Берәр әсәрегезнең ничек язылуы турында сөйләгез әле»,—ди. Мин «Язмышлар язылганда» повестен язар алдыннан Балтач районына баруым, анда умарталыкларда булуым турында сөйләдем. Ул малай бу повестьны укыган булып чыкты. Эчтәлеген бик төгәл итеп сөйләп бирде. «Бишенче класста укыганда эләкте ул китап миңа»,—ди. Хәтере әйбәт. «Безгә Галимҗан Ибраһимовның «Тирән тамырлар»ы кебек, Габдрахман Әпсәләмовның «Алтын йолдыз»ы кебек романнар кирәк»,—ди. Әйе, нәкъ шушы сүзләр белән әйтә. Китапча сөйләшә. Берәр укытучы семьясыннан түгел микән. «Арабызда безнең бер Фәнис Яруллиныбыз да бар, ләкин шигырьләр генә язмый»,—диләр.

Студентка Лилиясе шигырьләр дә язгалый икән, ләкин барып чыкмый ди. Шагыйрь булу өчен нинди сыйфатлар кирәк, дип сорый. Моңа нәрсә дип җавап бирәсең инде? Образлы фикер йөртергә, фәлән-фәсмәтән дип аңлаткан булдым шунда.

Укучылар бик матур тюльпаннар алып килгәннәр. Быел чәчәктән өзмәделәр инде. Бүгенгесе көндә каршымда ике букет утыра. Берсе М. апа алып килгән нәркисләр. Ул Тукай каберенә куярга дип бер чүлмәк гөл дә алып барган булган. Тик зиратка барырга туры килмәгән, гөлен укучы балалар аша шигырь бәйрәмен алып баручыларга бирдерткән. «Үзем илтеп бирергә оялдым»,—ди.

Үзара сөйләнелә киткәндә «тел бетә» дип зарланышсак та, шигырьләребезне дә, шагыйрьләребезне дә яратучылар бар әле. Менә бу интернат-мәктәптән килүчеләр чеп-чи татар балалары. «Безнең монда көннәр бик күнелле үтә, һәр пәнҗешәмбе үзебезнең актлар залында кино күрсәтәләр, театрларга алып баралар, әле «Авылдашлар, акча кирәк» дигән спектакль карадык. Һәр класста телевизор бар»,—дип җиппәрәләр. Күбесе телевизордан алып барыла торган «Шигъри тәлгәшләр»дә катнаша, кайберләре телевидение хорына йөри икән. Минем янда сүз табалмый торсалар да, кайткач әллә нәрсәләр сөйләнерләр әле.

Акселерация чоры дисәк тә, гәүдәгә балалар бик вак. Әллә тагын без үскәндәгедән дә ваграк инде. Боларга үсәргә дә үсәргә бит инде югыйсә. Безнең кебек бәләкәй арба тартасылары да юк. Безне генә тәпи басу белән: «Арбага тотынсаң егылмаска әйбәт булыр»,—дип, шундук тәртә арасына тыкканнар. Алай да үскәнбез инде.

Гәүдәнең кечкенәлеге үскәч, ягъни олыгайгач та комачаулый бит кешегә. «Менә хәзер сезнең каршыгызга фәлән язучы чыга»,—дип берәр орчык хәтле

язучыны чыгарып бастырдылар ди. Әлбәттә, кешеләр ана: «И-и, монардан нәрсә көтәсең инде»,—дип караячаклар. Ә киресенчә, фил гәүдәле кеше килеп чыкса, аның авызына карап катачаклар. Юләр сүзеннән дә мәгънә эзләячәкләр. Бигрәк тә начальство өчен гәүдә зур роль уйный. Олы гәүдә—карьерага беренче адым.

**1 май.** Бәйрәм көннәре минем өчен ин-ин күнелсез көннәр. Эш эшлисе килми, аракы эчеп булмый. Көне буе телефон да шалтырамады. Хәтта берәр исерегә әҗәткә акча сорарга да кермәде. Ә бит телефон югында дус-ишләр гел шалтыратып торыр кебек иде...

Төштән соң быел беренче мәртәбә урамга чыктым. Көн жылы иде, 17 градус диделәр. Нурсөя машинаны кабызып карады, эчен-тышын көзге пычраклардан чистартты. Урам тулы исерек. Машина янына килеп селкенгәләп торучылардан гарык буласың. Өч сәгатькә якын урамда утырып кергәнгә, эт итеп арыткан. Күкрәкләргә хәтле авырта. Иртәгә көн матур булса, бакчага барып карарга исәп.

Быел жәй үзем генә авылга кайтам, Нурсөягә әзрәк ял бирәм дип бик батырайган идем дә, хәзер, кайтыр көннәр якынлашкач, кыенрак булыр төсле. Әле авылга үзем генә кайтсам, гайбәт тә таралыр: «Болар арасыннан да кара мәче йөгергән»,—диярләр.

Кичә теге М. апа үзенең олы малае белән килде. Тәки теге «иптәш» янына больницага барган. Тегесе чакырып язган. «Шулкадәрле ул мине рәнжетте, һич тә гафу итмәячәкмен»,—дип сөйләгән иде. Хәзер күңеле йомшаган, ахры. Бөтенләйгә кил дисә, бәлки, бөтенләй дә барыр әле. Малайлары әйбәт икән инде. Аналарының хыялланып йөрүенә юл куйдылар. Олы бит инде малайлары.

**7 май.** 2 майдан 7 майга хәтле бакчада булып кайттык. Көннәр жылы торды. 19-22 градуслар. Янгырлар булмады. Машина белән каравылчы йортына кадәр килә алдык. Юлда чуерташ өемнәре ятмаса, үзебезгә чаклы да кереп була иде. Килгәндә Рейн күтәреп кертте, кайтканда Әхмәт Рәшитов күтәреп алып чыкты. Ул да Казанга кайтты.

Бакчада М. Мәһдиев белән татар язучыларының яңа чыккан әсәрләре турында сөйләшеп тордык. «Торналар төшкән жирдә» дигән повестена кертергә (китап итеп эшләгәндә) бер идея бирдем әле. Татар халкының элек-электән иң грамотный халык икәнен кыстырып жибәрергә иде, дидем. Чынлап та, безнең халыкта карт-корыларның кайсын гына алма—укый-яза белмәгән кеше юк. Гарәп хәрефләре белән язылган теләсә-нинди әсәрне йөз яшьлек картлар да теттереп укый. Грамоталык—ул бит инде укый-яза белү дигән сүз. Мин, мәсәлән, үзебезнең авылда искечә булса да укый-яза белмәгән кешене белмим.

2 май көнне бераз бәрәнге утырттык. Әле жирләр кибеп житмәгән. Зесе көнне карлыган һәм кура жиләкләренең төпләрен йомшарттык. 4, 5, 6сы чәчәк төпләрен йомшартып, викторияләргә су сибеп, калган ярты стакан суганны утыртып һәм тагын бераз жиргә бәрәнге төрткәләп чыктык. Әле бераз жир казылмаган килеш калды, юеш, казырлык түгел. Икесе көнне бару белән кыш көне хулиганнар ваткан тәрәзәгә пыяла куйдырдык. 7се көнне кайтып керү белән «Социалистик Татарстан»га берничә публицистик шигырь жибәрдем. Ш. Маннапов бакчада күреп, давай, слушай, СССРның 60 еллыгына шигырьләр бир әле безгә, дигән иде. Үзем дә шунда жибәрергә дип берничә шигырь әзерләп йөри идем инде. «Ялкын»га конкурска дигән хикәяне конвертлап жибәрдем. Нурсөя аны әле монарчы укымаган иде. Жибәрер алдыннан укыды да, күзләре мөлдерәп китте. Ну, нәрсә, мин әйтәм, премия бирерлекме? Син бирерлек дисән, бөтенләй начар түгелдер, дим. Ул бит инде минем беренче тәнкыйтьче. Бүтән чакта ул минем әйберләрне машинкада басканда укый иде,бу юлы, аның эше күп булгач, мин аны үзем бастым. Гомумән, язга чыккач, ничектер, дәртләнеп киттем әле. Күңелдә әллә кайчаннан бирле бер хикәя сюжеты йөри, жәй көне язып булмас инде, пожалуй. Хәзер менә авылга кайтасы бар. Анда әбиләр белән сөйләшеп көн үтәр. Безнең авылда яшьләр бераз мәнсезрәк, хәл белергә килеп бик ваксынмыйлар. Шуңар авылга 8 ел кайткан да юк.

Бакчада хәзер карлыганнар яфрак ярды, сиреньнәрнең чәчәк бөреләре күренә. Болай жылы торса, майның 15ләренә алмагачлар чәчәк атар. Каеннар яфрак ярды. Гомумән, яз әлегә матур килә. Тора-бара нишләр.

**9 май.** Көндез матур гына янгыр явып үтте. Күк күкрәде.

Моннан 23 ел элек, нәкъ менә тугызынчы май көнне Красноярск хәрби госпиталеннән мине район больницасына озатканнар иде. Шушылай вак янгыр сибәли, ләкин бүгенгедән салкынча иде. Бәлки, мина шулай салкын тоелгандыр. Терелермен дигән бөтен өметләрнең челпәрәмә килгән чагы, туган ягына носилкада кайтасың. Хәтта безгә купега да билет алмаганнар. Минем кебек муены сынган бер егет (Маслов) та Уфага кадәр кайта. Икебезне озатырга бер сестра, бер солдат бирделәр. Вагонга кертеп салу белән минем эч китәргә тотынды. Ярый әле сестра мондый хәлне күздә тоткан: юлга списать ителгән простынялар алып чыккан. Пычранган саен икенчесен ертып сала да, тегесен вагон тәрәзәсеннән ыргыта. Теге Маслов дигән егетнең дә (ул Грозный шәһәреннән), минем дә аркадан күткә чаклы пролежьлар. Ужас! Йоклап булмый. Күнелне шомлы уйлар кимерә. Туган ягына бит ул герой булып кайту гына күнелле. 12 майда Урыссу стансасына килеп төштек. Анда әниләр, абыйлар, Баян җизниләр каршы алды. Ул чакта безнең авыл Ютазы районына керә иде, ә районның больницасы Урыссу эшчеләр поселогында иде. Шунда алып киттеләр. Больницаларның берсендә дә «Хуш киләсең!» дип каршы алмыйлар. Бигрәк тә минем кебек каты авыруны.

Аннан бирле исәпләсәң искитәрлек вакыт үткән. Менә тагын авылга кайтырга җыенабыз. Кайвакыт нindiдер бер эчке дәрт күнелне кузгатып-кузгатып куйса да, ашкыну юк. Яна әйберләр язарга нindiдер азык табылыр дигән өмет тә кабынмый. Чыгып йөрмәгәч, яналык өенә үзе килеп керми бит ул.

Нурсөягә 18 майдан Васильевога путевка алдым, әйдә, ул да миннән бераз ял итсен инде. Тормышның минем өчен бернинди ялы юк икән—аның өчен дә булмаска тиеш диелмәгән бит. Батырга да ял кирәк.

**10 май.** Машинаны техосмотр уздырып кайттык. Осмотр уза торган жир әллә кая—җәһәннәм почмагына күчкән. Быел машина белән йөри башлаганда спидометрда 3212 км иде. Җәй буе күпме йөрелер икән?

ГАИның Ленин районы начальнигы Мөбарәк Хәбибрахмановка «Первая борозда» һәм «Танышлар арасында» дигән китапны бүләк иттем. Һәр елны сорый иде. Шунда ГАИга баргач райсобес мөдире Габбас Яруллин да минем янга чыкты. Күргән юк иде. Озак кына сөйләшеп тордык. Ул да университетның татар теле бүлеген бетергән икән. Аннан соң экономическийны бетергән. Минем белән бер елгы. Ул гыйнварның 4ендә туган.

Көн бик аяз түгел. Болай үзе жылы гына. Машина эчендә күлмәкчән утырырлык. Тәрәзәләрне ачмасаң.

**12 май.** Бүген авылга кайтабыз. Төнлә бер сәгать тә йоклап булмады. Барыбер йоклап булмый дип сәгать 2дә үк торып утырдык. Нервылар беткән инде тәмам, ике көннән бирле эчләр чурылдый. Нурсөя дә минем аркада грамм да йоклый алмады, ә бит аңа 400 кмны рульдә кайтырга. Минем һәр чирем, һәр борылуымның юан башы аңа төшә. Бер төндә генә дә мин аны ничә тапкыр торгызам: йә дару бир дип, йә борып яткыр дип. Кеше кебек бер яткан килеш әйләнмичә 5-6 сәгатьне йокласаң иде, ичмасам. Шунсы да калмаган.

Сәгать 3тә каты гына итеп кофе эчтек. 4ләрдә кузгалырбыз, пожалуй. Йөрәк тә авыртып тора. Ничек кайтып житәрбез инде. Кәеф минутлап үзгәреп тора. Әз генә матурланса, кайтасы килә. Авылда әллә нинди яналыклар көтәдер кебек. Югыйсә, акыл белән уйлап карасаң, берни юк икәнен белеп торасың инде. Ну бер кайтмый да ярамый. Быел әнигә 75 яшь тула. Бәлки, шуны да үткәреп киләсе булыр. Башка туганнарның исенә төшерергә кирәк. Алар аның ничә яшьтә икәнен беләләрдерме әле? Әниләр шул безгә бәләкәй чакта гына кирәк. Йә чирләп, карауchысыз калганда.

Башка вакытта юлга чыгар алдыннан төш күрә идем, бүген, йокламагач, төш тә кермәде.

Көндәлек яза белмим икән мин. Узган ел «Блокадная книга»ны укыган идем, анда 14 яшьлек бер малай көндәлеге дә бирелгән. Әгәр исән калган булса, гениальный язучы чыгар иде аннан.

**25 июнь.** Авылдан кайттык. Мөслим китерешге. Көн артык кызу да, артык салкын да түгел иде. Кайтып төшеп атна чамасы узуга, ягъни 18 майда авыл мәктәбендә очрашу уздырдык. Мәктәпне авылда бик шәптән салып жибәргәннәр. Ике катлы,

кабинетлар, классլар иркен, якты. Керүгә кул юар өчен краннар тезелеп китқән. Очрашу бик күнелле булды. Ленинның университет каршында басып тора торган һәйкәленең кечерәйтелеп ясалган скульптурасын бүләк иттеләр. Аннары Баулы районының милиция һәм прокуратура работниклары белән очраштык. Милиция шигырь укыйдыр дип башыма да китермидер идем. Укыйлар икән. Гомумән, бер очрашуның да болай кызыклы үткәне юк иде әле. Сорауларны бик күп бирделәр. Очрашу татарча һәм русча барды.

Быел җәй салкын булганлыктан, урманнарга, Ык буйларына бик күп барып йөреп булмады. Ике тапкыр урманга менеп, мәтрүшкә дә тапмый кайттык.

5 июнь көнне Кызылъярда кар яуды. Гомумән, быел җәйнең сюрпризлары күп булды.

28, 29, 30 июньдә бакчада булып кайттык. Җиләкләр пешмәгән, кыярлар, помидорлар үсәр-үсмәс кенә утыралар. Бүген 1 июль, ә ныклап җәйнең җиткәне юк әле. Авылда бер-ике шигырьдән артык әйбер язылмады. Тәэсирләр шактый. Бәлки, соңрак язылса гына.

**20 сентябрь.** Бакчадан унысында кайттык. Сентябрь башларында 2-3 көн 30 градусларга кадәр җылылык торды, аннары кинәт салкынайта башлады. Өйгә быел җылыны да 13 сентябрьдә үк бирделәр. Хәзер менә тагын берничә көн инде әйбәт, җылы тора. 20-22ләргә җитә.

Бакчада уңышлар ярыйсы булды: 3 чиләк карлыган, 3 чиләк виктория, кыяр һәм башкалар. Помидор гына рәтле булмады. Өйдә генә кызартып ашыйбыз. Бәрәңгене 1 сентябрьдә үк алдык. Кабак әйбәт булды. Тагын берничә көнгә барырга исәп бар. Иҗат эшләре сүлпәнрәк бара. Бу арада бер-ике шигырь язылды. «Казан утлары»ның 9 санында чыккан шигырьләремне укыгач, үземә нигәдер ошамый башлаганнар иде, бүген М. Вәлиев шалтыратты: бик әйбәт шигырьләр, укып чыккач шалтыратмый түзә алмадым, ди. Күңел күтәрелеп китте. Башта төрле шигырь детальләре туа башлады. Шагыйрь күңеленә күп кирәкмени? 9 сентябрь «Татарстан яшьләре»ндә чыккан «Шулай да була» дигән хикәяне дә бик яратып укуын әйтте. Ул хикәяне ошатып укуы турында Нурсөягә нәшриятта эшләүче Зифа да әйткән. Бик тормышчан, әллә чын вакыйгамы?—дигән.

Быел август ахырларында телевизордан минем турыда тапшыру булды. Бикә Рәхимова сценариесы буенча. Болай, караган кешеләр, әйбәт тапшыру диделәр. Үземә дә башта шундыйрак тәэсир калдырган иде, соңыннан нәрсәдер җитми кебек тоелды. Хәер, бер кечкенә тапшыруда төрле жанрда эшләүче язучының иҗатын тулысынча колачлап булмыйдыр инде. Яхшымы, начармы—20 еллык иҗат бит инде. Татарстан (Казан) газета-журналларында чыга башлаганга быел нәкъ 20 ел. Район газеталарында басылган беренче шигырьләрне дә санасаң, тагын ике ел өстәргә кирәк. Ә авырый башлаганга 25 ел. Димәк, баштагы өч елда гына берни эшләми ятканмын. Таза булсам, хәзер минем гомуми эш стажым 28 елга тулыр иде. 1954 елның 9 сентябреннән эшли башладым.

Язылмаган вакытларда бөтен гомер бушка узадыр кебек тоела башлый. Моннан соң бернәрсә дә яза алмамдыр кебек була. Язучы өчен иң авыр чир—яза алмау чире. Әйе, бу чир йөрәкне киптерә торган нәрсә. Озаккарак сузылса, үзеңә ышанычыңны югалтып куюың да бар. Бигрәк тә кырыена кешеләр килмәсә.

Соңгы вакытта дуслар сирәгәя башлады әле. Сәбәбе?

Бер якын дустым телефоннан сөйләшкән чагында: «Хәзер, син эчә алмый башлагач, синең янга барып булмас инде»,—дигән иде. Шаярып әйткән сүздә бераз чынлык була диләр, шуннан бирле ул дусның килгәне юк. Телефоннан сөйләшәбез. Үзем шалтыратсам.

**29 сентябрь.** 4 кич бакчада куныш кайттык. Сентябрь ахырларында көннәрне җылытып җибәрде. 22ләргә кадәр. Дүрт көндә дә иртәдән кичкә кадәр тышта яттым. Үпкәләргә саф һаваны күбрәк тутырырга тырыштым. Озын кышка кирәсе бар бит. Бүген дә көн бик матур. 21 градуска чаклы күтәрелә дигән иде радио. Булгандыр, пожалуй.

Бакчада чакта М. Мәһдиев белән сөйләшеп тордык әле. «Синең теге ауган агачың шәп»,—ди. «Казан утлары»ның 9 санында чыккан «Мин бер агач» дигән шигырьне әйтә. Минем иҗатны мактаганы юк иде әле аның. «Бу шигыреңне һәм шушындый

тагын бер унлап шигыренне бик шәп тәрҗемәчеләрдән тәрҗемә иттереп Мәскәүдә чыгарасы иде»,—ди. Р. Гамзатныкы булса бу шигырьне бирә белерләр иде, ди.

Бакчадан китәр алдыннан песи балаларын кулга ияләштереп яттым. Кыргыйланып беткәннәр, һич тоттырмыйлар. Берсе, Рыжий дип йөрткәне, ияләшә башлаган иде, китәр вакыт житте. Агач башына менеп утырырга өйрәттем мин аларны. Чия башына менәләр дә утыралар. Кыланышлары бик кызык. Черныйны алып кайтырбыз дигән идек, тоттырмады. Үзе мин тышта ятканда аяк очына раскладушкага менеп ята, тота башласаң, ысылдап кача.

Быел сентябрь азагына кадәр кыраулар булмады. Георгиннар шау чәчәктә калдылар. Зур гына букет җыеп кайттык. Астраларны тамыры белән алып кайтып чүлмәккә утыртып куйдык. Быел машинада 2500 км юл йөрелде. Аяксыз кешегә әз түгелдер инде бу. Әгәр җәйнең иң матур көннәрен бакчада үткәрмәсәк, күбрәк тә йөрелер иде.

Хәзер инде басылып кына эшләргә иде, ләкин тазалык та шәп түгел әле. Бүген газета-журналларга җибәрергә дип шигырьләр сайлый башлаган идем дә, күңел болганырга тотынды. Бөерләрнең рәте юк. Сидек бик канлы. Бер дә эшкә ярамый башладым. Тора-бара ни булыр тагы?!

**6 октябрь.** Бүген бакчага барып кайттык. Көн салкын иде—2ләр чамасы. Өйдә дә менә ун көн инде җылы бирмиләр. «Өйдә туңып ятканчы тышта туңарбыз, ичмасам»,—дидек тә киттек тә бардык. Без барып кергәндә дача өендә—1 градус иде, керү белән рефлекторны кабызып куйдык, өч сәгать эчендә + 8 булды.

Бакчада инде бар нәрсәгә салкын тигән, ләшперәйгәннәр. Чия яфраклары ямь-яшел килеш утыралар иде, алар да бөрешкәннәр. Ә шулай да кызык хәл: бер чия куагына тамчы да салкын тимәгән. Бер ягында аның кызыл миләш, икенче ягында биек чия. Бу шулар ышыгында калган, күрәсең. Агачлар да тигез картаймыйлар. Бакчада хәзергесе көндә сирень яфракларына һәм кура җиләге яфракларына гына салкын тимәгән. Алар башка агачлардан чыдам икән.

Бүген кайтканда георгин бәрәңгеләрен, гладиолус суганнарын алып кайттык. Һәм өч бөртек ачы торма. Берсе баш кадәр булып үскән. Комга эләккәне.

**9 октябрь.** Бүген Ирекләр машинасы белән бакчага барып кайттык. Аннан элекке көнне М.Мәһдиев, бакчагызга кергәннәр, дип шалтыраткан иде. Тәрәзәнең бер бүлкәсен алып кергәннәр дә бөтен нәрсәнең астын өскә китергәннәр. Хәтта базны да ачканнар. Урын-җир өстенә сиеп чыгып киткәннәр. Бер елны да керми калмыйлар, хәтта ялгышып та. Һәр язны тәрәзәгә пыяла куюдан башлап җибәрәбез. Күпме хулиганлык!

**10 октябрь.** Бүген Фаилне күмәләр. Нурсөя шунда китте. Фаилнең үлгәненә гел ышанасы килми. Өенә кайтып житәрәк бер ишегалдында кыйнап үтергәннәр. Кемнәр икәнен пока белүче юк. Моннан бер ай чамасы элек кенә Д. Зөбәерованың 28 яшьлек малаен кыйнап үтергәннәр иде, инде Фаилне. Фаилне җәлләүдән Нурсөя дә ике-өч көн инде аңгыраеп йөри. «Бер кеше дә болай җәл булганы юк иде»,—ди. Әйе, шәп егет иде. Көн саен диярлек телефоннан сөйләшеп тора идек. «Чаян»ны Фаилдән башка күз алдына да китереп булмый. Юморист № 1 дип йөртә идем мин аны. Җибәргән әйберләрне икенче көнне үк укып чыгып фикерен әйтә иде. Ул «Чаян»да эшли башлагач кына мин дә ныклап юморга тотындым. Бәлки, монда аның йогынтысы күп булгандыр. Җәл егет, бигрәк җәл! Яңа таланты ачылып житкән һәм ныклап торып эшли башлаган иде.

Рәшит Әхмәтҗановның туган көнендә Фаил белән бергә утырган идек. Шәп-шәп тостлар әйткән иде. Миңа карата әйткән сүзләре әле дә хәтердә. Менә, дигән иде ул, күпләребез һәр ел саен туган көннәрен үткәрә, бәйрәм ашларына йөрешә, ә шунда беребезнең дә башыбызга Фәнисне алып килергә дигән уй килгәне юк иде. Рәшит молодец, Фәнисне чакыруы өчен рәхмәт аңа, дигән иде. Кайтканда алар Зөлфәт белән мине озатып, күтәреп кертешеп куйдылар. Минем Испаниядән бер кыз алып кайткан мартини бар иде, шуны берәр рюмка эчтек. Зөлфәтнең аракыны ташлап йөргән чагы иде, Рәшитләрдә дә эчми утырды. Мартинины күргәч: «Мин бу вино турында Хемингуэй әсәрләреннән укыганым бар иде, кабып карамый ярамас»,—дип, ул да авыз итте. Хәзер менә шушы гади, гадәти вакыйгалар, ничектер, Фаил үлгәч янадан күңелдә калкып чыкты. Еш очрашмасак та рухыбыз белән якыннар идек.

Шуна күрәдер инде, анын үлеме бик авыр булды. Фаҗигале үлем ул үзе генә дә тетрәндерә бит кешене.

**12 октябрь.** Кичә, ягъни 11 октябрьдә, 4 шигырь язылды. Үзем 38,2 белән чирләп ятам. Башта бер шигырь артыннан икенчесе туа. Ф.Шәфигуллин истәлегенә багышлаган шигырьне язганда йөзгә газап билгеләре чыккан, күрәсең. Нурсөя куркынып: «Нәрсә булды, кай жирең авырта, йөрәк даруы кирәкмиме?»—дип йөрде. Ике тапкыр йөрәк даруы эчәргә туры килде. Төне буе чирләп чыктым. Нурсөянемескенне төне буе йоклатмадым. Мин чирләсәм, ул үзе чирләгәннән дә ныграк пошына башлый. Соңгы вакытларда бөтен сүзе шул: «Син миннән алда үлсәң, мин не переживу»,—ди.

Берничә көн инде сидек бик канлы килә. Температура бераз бар. 10 октябрьдән грамурин эчә башладым. Нурсөя врач чакыртыйк дигән иде дә, чакыртмаска куштым. Алар да шул анализлар алалар да үземдә булган даруларны бирәләр инде. Мин үземнең хәлемне врачлардан яхшырак беләм инде хәзер. Врачларның күбесе муен сөяге сыну нинди нәтиҗәләргә китергәнен белеп бетерми. Минем чирне йөри алмау гына дип уйлыйлар. Алай гына булса, бу заманда йөрер өчен транспорт житәрлек лә ул. Нурсөядән башка бер кеше дә минем хәлемне белеп бетерми. Ул күзгә карап та мине аңлый. Аңа врач булырга кирәк булгандыр, бәлки. Хәер, врачларның бәгыре бик тиз тупаслана. Ул болай да минем профессорым бит инде.

**14 октябрь.** Сидек кызыл гына түгел—кара жир төсле. Төнлә бик каты чирләп чыктым. Эчне сүс бау белән тын алмаслык итеп кысып бәйләгән кебек авырту.

**15 октябрь.** Кан һәм сидекне алып киттеләр—анализга. Таня исемле сестра килгән иде. Нурсөя машинкада яза. «Казан утлары»на киләсе ел өчен шигырьләр әзерлибез. Соңгы вакытларда чирли-чирли шактый шигырь язган кебек идем, сайлый башлагач, әле тегесе ошамый, әле монсы.

Октябрьнең бу атнасы жылы торды. Әле бүген 7-12 градус жылы.

**16 октябрь.** Нияз Акмалов, Атлас дигән егет һәм Розалия дигән кыз (конферансье) килделәр. Нияз «Яшь ленинчы»га бер мәкалә сорап йөри. Розалиясе—концертлар өчен юмористик әсәрләр. Моңарчы ул Фаил белән эшләгән булган. Юморны яздым мин. Шунсы кызык: нык авырган чагында юмористик әсәрләр күбрәк туа. Бу—көлү аша чирне җиңәргә тырышу, ахры. Муса Җәлил дә бит үлемгә хөкем ителгәч никадәр юмористик шигырьләр язган.

*Дәвамы киләсе саннарда*

# БӨЕКЛЕК БАСКЫЧЛАРЫ

## 1912 ел

**1 гыйнвар.** Шагыйрьнең «Былтырның хисабы» исемле фельетоны «Шүрәле» имзасы белән басылып чыга. Еллык отчет рәвешендә язылган бу фельетонда: «Былтыр Петербургта «В мире мусульманства» дигән әллә нинди рус исемендә бер чын мөселман пәйда булды. Ул әллә ниләр эшли... Багана-багана хәдисләр дәреж итә. Мусульманин, ди, панисламизм, ди, единоверцы, ди. Әлхасыйль, бигрәк җете кызыл мөэмин булып кылана. Мөселманнар: «Ай-һай, тиз узмаса ярар иде»,—дип, шиктә торалар»,—дип яза шагыйрь.

Үзен «политик» дип атаган Тукайның сизгерлегенә гаҗәпләнми мөмкин түгел: шагыйрь үлеп, ике-өч ел да үтми, М. Хаҗи-Теләшинең провокатор һәм авантюрист булганлыгы фаш ителә.

Яна 1912 елны Тукай Казан артында, Өчиле авылында каршылый.

Өчиледән Казанга «Ялт-йолт» журналы редакторы Әхмәт Урманчиевкә хат яза. Үзенең авылдагы тормышыннан ризалыгын, канәгатьлелеген белдерә. Ләкин ул анда ял итеп, дәваланып кына ятмый, туктаусыз эшли, яза. Үзенең яраткан журналы «Ялт-йолт» турында кайгыртудан туктамый.

**Ел башы.** «Яшен ташлары» исемле китабы басылып чыга.

**12 гыйнвар.** Өчиле авылыннан Ф. Әмирханга хат яза. Хат үзе сакланмаган, бары тик конверты гына исән.

**Гыйнвар.** Бераз тернәкләнүгә, Тукай дәртләнеп эшкә керешә, «...көне буе йоклап, төне буе язып утыра башлады. Язган язуларын Габдулла һәрвакыт миңа биреп куя иде. Арчага барганда, ирем анын язуларын почтага алып барып сала иде» (җингәсе Рабига истәлегеннән).

Өчиледән Казанга Әхмәт Урманчиевкә хат яза.

**20 гыйнвар.** Оренбургта «Вакыт» газетасы укучыларына Тукайның шигырь җыентыклары басылып чыгуын хәбәр итә.

**21 гыйнвар.** «Мич башы кыйссасы» исемле юмористик очеркы «Шүрәле» имзасы белән басылып чыга.

**11 февраль.** «Балалар күнеле» китабы (икенче кыйсем. Казан, «Өмид» матбагасы, 32 б., 5000 данә) басылып чыга.

**Февраль азагы—март башы.** Туганнарының: «Тагын бераз тор әле»,—дип кыстауларына да карамастан, Тукай февраль азагында Өчиледән Казанга кайткан. «Казанга кайтыш» исемле автобиографик очеркыннан (11 мартта басылган) күренгәнчә, ул Казанга кайткач, тыныч, аулак җирдән фатир табып, шау-шулы иптәшләреннән читтәрәк яшәргә карар бирә. Һәм ул квартирада бер атна чамасы торып та чыга.

Истәлекләрдән күренгәнчә, Өчиледән киткәндә ул инде рухи һәм физик яктан да нык төшкән, озак-озак утырып яза-эшли башлаган.

Казанга аны Кәбир абыйсы ат белән илтеп куя. Рабига җингәсе ике мамык мендәр бүләк итә.

**Март.** «Болгар» һәм «Шәрык» кунакханәләрендәге суыктан туеп һәм авылдагы тынлыкка күнеккән шагыйрь тыныч фатирда торырга, азрак аралашырга, күбрәк

ижат эше белән шөгыльләнергә план корып кайта. Овражная урамындагы бер йортка фатирга да урнаша. Ләкин андагы шартлардан канәгать булмыйча, янадан кунакханәләрдән номер эзли. Нәтиҗәдә «Свет» кунакханәсендә бер бик матур, якты, затлы җиһазлы бүлмәгә урнаша. Әмма бу юлы да уңмый, номерында күселәр ана тынгылык бирми. Бу турыда «Казанга кайтыш» исемле әсәрендә кызганыч һәм көлке рәвештә тасвирлап яза.

**13 март.** «Гасыр» китапханәсендә Г. Коләхметов, Ш. Әхмәров һ. б. белән сөйләшеп торганда, күренекле татар революционеры, большевик-ленинчы, Тукайның якын дусты Х. Ямашев баш миенә кан йөгерүдән үлә.

**18 март.** Җәмәгатьчелек Х. Ямашевны зурлап күмә. Озатучылар саны күп була. Газеталар бу югалтуга үзләренең мөнәсәбәтләрен белдерәләр. Биографиясе бирелә, кайгы мәкаләләре басыла, шигырьләр багышлана.

Бу үлем Тукайны, һичшиксез, тетрәткән, ул шактый вакыт исенә килә алмаган. Мәрхүмгә багышланган шигырьләренең бер ай узгач кына язылуы да шул турыда сөйли.

**31 март.** «Ялт-йолт» журналының 36 нчы саны дөнья күрә. Бу санда «Америкадан Вәли муллага телеграмм», «Вәли мулладан Америкага», «Көлеп язмыйбыз, көлеп әйтмибез» исемле фельетоннары «Гөмберт» имзасы белән басылган.

**Апрель башы.** Фатирда яшәү шартларыннан канәгать булмыйча, Тукай «Свет» кунакханәсенең бер матур, якты номерына урнашып яши башлый. «Иптәшләремнең: «Синдә чахотка бар»,—диюләреннән гаҗиз булып, алардан читтәрәк бу номерга күчкән идем»,—ди үзе Габдулла Гыйсмәтигә (1883—1939), монда күчүенең сәбәбен аңлатып.

Петербург мулласы, дин галиме, җәмәгать эшлеклесе Муса Бигиевтән Петербургка килергә чакырып бер-бер артлы ике хат ала.

**7 апрель.** «Хөрмәтле Хөсәен ядкяре» исемле шигырен яза.

**14 апрель.** Җәй буе кыргыз даласында кымыз белән дәвалануны күздә тотып (Троицк мулласы Габдерахман Рахманкулов та чакырып киткән була), Троицкига барырга, бераз сәламәтләнгәч, көз көнендә Петербургка барып докторга күренергә ниятләп, «Фултон» пароходында Казаннан Самарага юнәлә. Аны пристаньга дусты, «Ялт-йолт» журналы редакторы Әхмәт Урманчиев озатып төшкән.

**15 апрель, кич.** Пароход белән Самарага килеп төшә («...икенче көнендә бугай, төнгә табарак Самарага життем»). Анда бик мәһабәт бинага урнашкан «Бристоль» кунакханәсенә туктый. Шул көнне үк Самараның мулласы, «Икътисад» журналы мөхәррире Фатыйх Мортазин белән очрашып, озаклап сөйләшеп утыралар.

**16 апрель.** Сәяхәтен дәвам итеп, Самарадан поездга утырып Уфага китә. Аны вокзалга Фатыйх Мортазин җибәргән шәкерт резиналы фәйтун белән озатып куя.

**18 апрель.** Х. Зәбири алып биргән билет белән поездда Тукай Уфадан Петербургка китә.

**20 апрель.** Иртәнге сәгать сигездә поезд белән Николаевский вокзалга килеп төшә. Үзен чакырып хат язучы Муса Бигиевкә телеграмма җибәргән булса да, аны каршылаучы булмый. Ул, извозчикка утырып, М. Бигиевнең өенә бара (Сергеевская, 81). М. Бигиев аны кабул итә һәм үз өендә үзенең бүлмәсенә урнаштыра. Тукай биредә үзенең элекке танышлары, иптәшләре белән дә күрешә алмаган хәлдә, 5 көн яши.

Муса Бигиев белән Петербург имамы, җәмгыяте хәйрия мәктәбенең мөдире Лотфулла Исхаковларда кунакта була. Шагыйрь белән күрешергә курсистка кызлар киләләр, ләкин, авыруын сылтау итеп, Тукай аларны кабул итмәгән.

Петербург бае, Муса Бигиевләр партиясе тарафдары Галим Максудов үзенең Истамбул дарелфөнүнен тәмамлап кайткан улы Кәрим белән күрешер, танышыр өчен, үзләренә кунакка чакырып Тукай янына киләләр.

**25 апрель.** Тукай «Нур» газетасы идарәсенә бара. Анда ул элекке иптәшләре Кәбир Бәкер, Габделкәрим Сәгыйтовлар белән күрешә. Сафа Баязитов, студент Шакир Мөхәммәдъяровлар белән очраша. Ул Муса Бигиев өендә яшәп ятудан кыенсынуын һәм аерым номер алып торасы килүен әйтә.

**Апрель ахыры—6 майга кадәр.** Ш. Әхмәтҗанов Тукайга Петербургта чыга торган большевистик «Звезда» газетасында басылган Хөсәен Ямашев турындагы мәкаләсен күрсәтә. Шагыйрь укый да: «Менә заман. Безнең хакта пайтәхеттәге рус газеталары да сөйли башладылар бит. Күптән кирәк иде... Мин Хөсәен мәрхүмне тәкъдир вә ихтирам итәм һәм аны бик сагынам... Мин үзем социалист түгелмен, шуның өчен дә ул мәсләктәге кешеләр хакында артык сүз сөйли алмыйм. Фәкать, һәркем үз мәсләген гүзәл аңлап, чыннан халыкка, ватанга хезмәт итсен иде»,—ди.

**5—6 май.** Тукайның Петербургтан китәсе тәгаен билгеле булгач, иртән Сафа әфәнде Баязитовның Мойкадагы квартирында шагыйрь хөрмәтенә иртәнге аш мәҗлесе ясала. Кич белән зур бер сәүдә оешмасында хезмәт итүче Мөхәммәтша Җиһаншин квартирасында Тукай хөрмәтенә озату мәҗлесе үткәрелә. Биредә, приказчик вә сәүдәгәрләрдән башка, яшьләрдән Шакир Мөхәммәдъяров, Кәрим Сәгыйтов, Кәбир Бәкер, берничә Петербург мөгаллиме, Муса Бигиев, Петербург имамнарыннан Сафа ахун Баязитов, Лотфулла Исхаков катнаша. Кунакка чакыручы күп булса да, Тукай ул дәгъватларны кире каккан. Хикмәт авыруында һәм һаваның салкын, юеш булуында гына түгел, әлбәттә. Шуңа күрә сәүдә хезмәткәрләре һәм приказчиклардан торган 30-40лап кеше, шагыйрьне бер генә мәртәбә «мәшәкатьләргә» теләп, уртак мәҗлес оештыралар.

**6 май төне.** Петербургның Николаевский вокзалыннан Тукай поезд белән Уфага китә. Вокзалда аны озатырга дуслары һәм фикердәшләре Кәбир Бәкер, Шәриф Әхмәтҗанов, Шакир Мөхәммәдъяров, Кәрим Сәгыйтов һ. б. белән бергә имамнардан Сафа ахун Баязитов, Лотфи әфәнде Исхаков, зыялы мөгаллимнәр, байлар, төрле сәүдә йортларында хезмәт итүче мөселман приказчиклары, төрле мәктәпләрдә укучы яшьләр, студентлардан торган 30 лап кеше җыйнала.

**7 май, иртәнге сәгать 10 нарда.** Петербургтан Мәскәүгә килеп җитәләр һәм озак тормыйча Тукай Уфага юнәлә.

**8—9 май.** Петербургка сәяхәтендә унбиш көн чамасы йөреп, янадан Уфага кайта. Бу сәфәрдән ул гаять йончып, арып кайта. Бу вакытта инде Уфа яшәргән, агачлар яфрак ярган, җир өсте яшел мамык кебек яшь үләннәр белән капланган, кымызлар хәзерләнгән була. Тукай Уфаның саф һавасын, матур бакчаларын ярата, кымыз эчә. «Сәламәтлек һавасы эчәм» дип сөйли иде Г. Тукай,—ди М. Гафури үзенең истәлегендә.

**9 майдан соң.** Тукай Уфада яши.

«Уфа Тукайның дәрәҗәсенә мөнасип һичбер хәрәкәт күрсәтә алмады. Тукайның Уфага килү хөрмәтенә һичбер мәҗлес-фәлән тәртип кылынмады. Аның Уфага килгәнен күп кеше белми дә калгандыр.

Тукайның Уфада үткәргән ун-унбиш көн гомере «Сабах» көтепханәсенең артындагы бүлмәдә үтте»,—дип яза М. Гафури.

Истәлекләргә караганда, Уфада Тукай Себер якларында мөгаллимлек кылучы Мөбарәк Әмиров белән очраша. Ул аннан Себергә кайчан баруы, анда нинди шартларда эшләве һәм кемнәрне укытуы турында гаять кызыксынып сораша.

Уфада янадан докторга күренә. Бу турыда 12 нче майда Кәбир Бәкергә язган хаттан укыйбыз: «Уфа докторына кан тәхлиле тугърысында бардым... Җүтәлдән бер-ике төрле дару бирде. Кымыз эчәргә кушты».

Тукай Уфада бер атналап тора. Монда шагыйрь күбрәк вакытын М. Гафури белән уздырган. Кымыз сатыла торган бакчага чыгып, яшел чирәм өстендә кымыз эчәләр, Агыйдел буендагы бакчага чыгып, биек ярдан баржа, буксир, салларны күзәтәләр... Бер атнадан соң, әүвәлге карары буенча, кымыз эчәр өчен Троицкига китәргә карар кыла.

**Май азагы.** Берничә көннән Хәкимҗан Бакиров Тукайны кымызга Габдрахман Рахманкуловның дачасына илтеп куя.

Совет власте елларында бу урыннарда кымыз белән дәвалану санаторийлары ачыла.

Шагыйрь исә: «Троицкида берничә көн торгач, сахрага, шәһәрдән егерме биш чакрым җиргә киттем... Анда хәзрәт тарафыннан ялланган казакълар

аның йөзләп баш биясен савып, бүтән малларын күтәп торалар. Ике киез өйдән гыйбарәт шул казакъ авылына өченчегә мина махсус чатыр тегелде. Шәһәр смрадыннан, завод агуыннан, бозык һавадан качып чыгып, арбадан пароходка, пароходтан поездга кучә-кучә эштән чыккан мин бичара, ахры, бер рәхәткә, тынычлыкка барып егылдым... Бу—сахра... коры степь һавасы... Бөтен нәрсә табигый...»—дип яза. Бу казакъ даласына барган беренче көнне үк күнел күтәренкелеге белән табигатьнең матурлыгына, киңлегенә рухланып шигырь дә яза:

*«Валлаһи, и валлаһи, и валлаһи,*
*Бәхте барлар кырда җәйли, валлаһи!*
*Ак кумәч белән ашарлык саф һава;*
*Җир яшел, кошлар да сайрый, валлаһи!*
*Ак болыт, кучмә казаклардай кучеп,*
*Бер куньшлык җирне сайлый, валлаһи!*
*Аз гына бер җил исү белән үлән*
*Җирдә уйный кайный-кайный, валлаһи!*

**Май азагы—июльнең 20ләренә кадәр.** Казакъ даласында ике ай-ике ай ярым вакыт яши. Бирледә ул «Мәкаләи махсуса»ның икенче кисәген язып (5 бүлекчә), почта белән Казанга җибәрә. «Хәзер җиләк-җимеш вакыты» фельетоны да җәйләүдә язылган булуы мөмкин.

Шәһәрдән аның янына килгәләп йөргәннәр. Үзе дә берничә мәртәбә, чакыруларга җавап йөзеннән, Троицкига барып кайткан.

Кайбер истәлекләргә караганда, Тукай ял иткән вакытта тагын бүтән җирләргә дә барган. Үзе кымыз эчеп дәваланган казакъ авылыннан ерак түгел Кушкүл авылына килә. Халыкка яна шигырьләрен укый. Күлдә көймәдә йөри, болындагы чәчкәләр белән хозурлана.

**Июльнең 20ләре.** Ялы ял төсле булды дигән фикергә килгәч, үзендә азмы-күпме хәлләнү дә сизгәч, Тукай кайтыр юлга чыга. Июльнең егермеләрендә, ниһаять, Казанга, «Свет» кунакханәсендәге номерына кайтып керә. Ис алып, хәл җыеп тормастан, «Ялт-йолт»тагы вазифасын башкарырга керешә. «Җан азыклары» җыентыгын матбугатка әзерләргә тотына.

Троицкидан кайтып бер-ике көн үтүгә, Фатыйх Әмирхан белән икәүләп фоторәсемгә төшәләр.

**21 июль.** Календарьчы Шәрәф Шәһидуллин тарафыннан 1913 ел өчен чыгарылган «Заман календаре»нда Тукайның фоторәсеме һәм кыскача тәрҗемәи хәле урнаштырылган.

**26 июль.** Казанда Евангелистлар урамындагы Хәсәновлар йортында татар яшьләренең әдәби түгәрәге җыйнала. Бу утырышта журнал чыгарырга карар бирелә. Русларның әдәби журналлары кебек күләмле булуы күздә тотылып, аның татар яшьләрен оештыручы, берләштерүче үзәк булырга тиешлеге искәртелә.

Җыелышта бу мәсьәлә Гәрәй һәм Барый Хәсәновлар ... , Габдулла Тукай, Фатих Әмирхан, укытучы Гафур Коләхметовларның актив катнашы белән хәл ителә һәм әдәби-мәдәни «Ан» журналы чыгарырга карар бирелә. Басма өчен исемне Тукай тәкъдим иткән.

**5 август.** «Хәзер җиләк-җимеш вакыты» исемле сатирик мәкаләсе «Шүрәле» имзасы белән басылып чыга.

**Көз башы.** Казанга килгән шагыйрь һәм мөгаллим С. Сүнчәләй Тукай белән очрашып тора. Мәгълүм истәлегендә ул болай дип яза: «Бу вакыт Тукайның хәле тәмам беткән, нервлары какшаган. Кечкенә генә нәрсәгә дә кәефе китә, бик тиз ачулана, юк-бар нәрсәдән дә шикләнә, курка, берәүне дә күрәсе килми иде».

Сүнчәләй авылына китәр алдыннан саубуллашырга да кергән. Тукай шунда аңа: «Менә, сиңа бүләгем булсын»,—дип, үзенең көмеш сәгатен бүләк итә. Бу аларның соңгы мәртәбә очрашулары була.

Тукай «Свет» номерларыннан янадан «Болгар»га күчә.

**Күз.** Журналист Шиһап Әхмәров истәлегенә караганда, Тукай үзенең барлык шигырьләрен мәҗмуга итеп бастыру хокукын Г. Шәрәфкә биреп, аның белән договор төзи һәм шул җыентык («Мәҗмугаи асарь»)ны әзерләү өчен бик бирелеп эшкә керешә. Г.Шәрәфнең бу договорга нинди шартлар куюы билгеле булмаса да, Тукайга якын кешеләр Тукай өчен бу договорның «кабальный», ягъни арзан гына хакка авторлык хокукы тулысынча сатылган булуын сөйлиләр.

**Октябрь.** Авыруы каләм тотарга комачаулый башлый. Бу вакыт ул, «Ялт-йолт»ны чыгаруга хезмәт куюдан тыш, «Җан азыклары» җыентыгын матбугатка әзерли.

**5 ноябрь.** «Ялт-йолт» журналының 45 нче саны дөнья күрә. Биредә «Шүрәле» имзасы белән «Мәкаләи махсуса» әсәренең VI—IX бүлекләре, шунда ук «Валлаһи» шигыре, «Гөмберт» имзасы белән «Хаксызлыктан котылдык» исемле мәкаләсе урнаштырылган.

**Күз.** Тукай яраткан һәм мәхәббәт турындагы шигырьләренең күбесен аңа мөнәсәбәттә язган Зәйтүнә туташның Казаннан Чистайга китүен Тукай бик авыр кичерә. Ана кинәт кояш сүнгән, дөньяның яме киткән кебек тоела. Бу мәхәббәтен күпләрдән яшерсә дә, дусларыннан берсенә Зәйтүнәне һаман яратуын, онnetwork алмавы, сагынуы турында сөйли.

**10 декабрь.** Казанда «Кояш» исемле демократик юнәлештәге газета чыга башлый. «1912 нче елда караңгы Казан өстенә «Кояш» чыгып, «Йолдыз»ны сүндерде»,—дип яза Тукай, бу вакыйгага рухланып.

**15 декабрь.** Казанда «Аң» исемле әдәби-иҗтимагый журнал чыга башлый. Редакторы һәм нашире «Гасыр» китап ширкәте башлыкларыннан берсе— Әхмәтгәрәй Хәсәни (1883—1938). Киңәшү-сөйләшүдә, булачак журналның идея-политик һәм әдәби-эстетик юнәлешен билгеләүдә һәм Хәсәнине бу эшкә күндерүдә Тукай якыннан катнашкан. Журналга исемне дә Тукай тәкъдим итә. Беренче санында Тукайның журнал чыгу уңае белән язылган «Аң» шигыре урнаштырылган.

**29 декабрь.** «Вакыт» газетасы Г. Тукайның «Җан азыклары» исемле шигырь җыентыгы басылып чыгу турында «Яңа басылып чыккан иң мөһим әсәрләр...» дип игълан бастыра.

**1912 елның ахыры.** «1912 елның ахырында (числосы исемдә калмаган),—дип яза, авыр көннәрдә шагыйрьгә ярдәм кулы сузган профессор Г. Клячкин,—миңа, авыру Тукайны барып карарга үтенеп, татар яшьләреннән берничә кеше килде. Исемдә калганынча, Тукай ул вакытта Московский (хәзерге Киров) урамында номерларда тора иде.

Мин анда неврастения күренешләре белән бергә җитди авыру таптым. Иптәшләре аның мондый нервлы хәлдә булуын буржуаз язучыларның кайберләренең һәм полиция агентларының аны туктаусыз эзәрлекләүләреннән килеп чыккан даими борчылулар аркасында булган, дип уйлыйлар иде».

*Ахыры киләсе санда*

Лирон
Хәмидуллин

# «КИТАП» ШИРКӘТЕ ҺӘМ ТУКАЙ

Тиздән Габдулла Тукайның тууына 125 ел тулачак. Шагыйрьнең Казанга кайтып яши башлавына да быел 104 ел була. Вафатыннан соң узган йөз елга якын гомердә Тукайның иҗатын һәм биографиясен барлауга багышланган бик күп гыйльми хезмәтләр язылды, берничә истәлек тупламасы басылып чыкты. Әдәбият галиме Ибраһим ага Нуруллинның «Атаклы кешеләр тормышы» сериясеннән бай мәгълүматлы, күләмле «Габдулла Тукай» дип исемләнгән ике китабы да татар һәм рус телләрендә басылып таралды. Рус мәдәниятендә атаклы шәхесләр тормышын барлауга багышланган шундый китаплар чыгаруны XX йөзнең егерменче елларында Максим Горький башлап җибәрсә, татар дөньясында Ибраһим аганың ул хезмәте беренче карлыгач булган иде. *(«Габдулла Тукай» китабының татарчасы 1979 елда нәшер ителде.)* Шагыйрьнең күптомлыклары да һәр ун ел саен диярлек басылып тора. Чордашларының аңа багышланган истәлек язмалары да ара-тирә нәшер ителгәли.

## 1

Шушындый зур эшләр башкарылуга да карамастан, без әле бүген дә сөекле Тукаебыз иҗаты һәм биографиясе белән тулаем таныш дип әйтә алмыйбыз. Кешенең сыйнфый халәтенә чамадан тыш әһәмият бирелгән бер җөмһүрияттә яшәү дәверендә безгә бөек шәхесләребезнең тулы биографиясен, көндәлек аралашу даирәсен ачыклап бетерү мөмкин дә булмагандыр, мөгаен. Хәзер исә башка дәвер башланды. Инде безгә Тукайның замандашлары тарафыннан язылган истәлекләрне кыскартмыйча һәм үзгәртмичә, ничек язылган булса, шулай туплап чыгарырга кирәктер. Шул исәптән Кәбир Бәкернең 1914 елда нәшер ителгән «Тукай—Петербургта» китабы белән Шакир Мөхәммәдъяровның 1918 елда Мәскәүдә дөнья күргән «Тукай кем?» дигән китабын да кабат бастырып чыгару һич тә зыян итмәс иде. К. Бәкер китабыннан аерым өзекләрне «Тукай турында хатирәләр» китапларында күргәләргә туры килсә дә, шагыйрь белән Казанда һәм Петербургта якыннан аралашкан Ш. Мөхәммәдъяровның истәлекләре әлегә чаклы беркайчан да кабат басылмады шикелле. Мондый хәлнең төп сәбәбе, минемчә—бу шәхеснең заманында Гаяз Исхакый белән дустанә мөнәсәбәттә булуында һәм Совет хакимияте дәверендә «милләтче» буларак гаепләнеп, зинданнарда утыруында.

«Тукай кем?» дип исемләнгән китабында ул, әлбәттә инде, Тукай белән Исхакый арасындагы мөнәсәбәтләргә дә күп урын биргәндер.

Казанга килгәч тә Тукайның «Әл-ислах» газетасы тирәсендә оешкан даирәгә якын торуы, беренче көннәрдән үк шул газетада мәкалә һәм шигырьләрен урнаштыруы, «редакциядә эшләп алулары» турында күп язылды. Шул җирлектә шагыйрьнең Фатих Әмирхан һәм аның тирәсендәге шәхесләр белән якыннан аралашып китүе турында да күп мәртәбәләр әйтелде. Хәтта ул елларда «большевик Хөсәен Ямашевны» да фәкать шул даирәгә керүче итеп карау канунлаштырылган иде. Гәрчә ул Казан укытучылар мәктәбендә бер елларда укыган шәриктәше Гаяз Исхакыйдан һич тә читләшмәгән булса да. Әдипнең «Зиндан» әсәренә генә күз төшерик: 1907 елның гыйнвар ахырларында төрмәдән азат ителгән Г. Исхакый иң әүвәл йомышчы малайга бу хакта: «Син хәзер Хөсәенгә барып әйт»,—ди. Хөсәен белән Сәгыйть (Рәмиев) килгәч, Шакирны (Мөхәммәдъяров) эзләргә җибәрәләр.

Әйе, Тукай Казанга килгәч тә Вафа Бәхтияров редакторлыгында чыга башлаган «Әл-ислах» газетасы кешеләре белән якыннанрак таныша. 1907 елның 3 октябрендә «Әл-ислах»ның беренче саны басылып чыга. Берничә көннән соң Тукай Казанга килеп төшә. Газетаның 3нче санында, 17 октябрьдә Тукайның «Тәнкыйть—кирәкле шәйдер» исемле мәкаләсе дөнья күрә. Ф. Әмирхан шагыйрь белән танышуын болай искә төшерә:

«Бер көнне өемә китапчы Шәрәфләрнең кечесе—Борһан—бер яшь егетне ияртеп килгән иде.

—Бу Габдулла Тукаев була,—дип, кунакны миңа танытты.

Бу әүвәлге күрешү миндә Тукаев хакында бер билгеле тойгы калдыра алмады. Шушы вакыйгадан берничә көн үткәч миңа газетада чыгару өчен аның бер мәкаләсен бирделәр. Мин мәкаләдән бер-ике җөмләне төшереп калдыру шартын... сөйләгәч... иптәшләр: «Тукаев бунар риза булмас», диештеләр. Шул тугрыда сөйләшер өчен Тукай үзе «Әл-ислах» идарәсенә килде, шунда без аның белән икенче мәртәбә күрештек. Моннан соң ул ... идарәханәгә еш-еш килеп йөри башлады. Вә бик тиз арада бербергемезгә шәхси ихтирам саклаша башладык. Озак вакытлар еш-еш очрашсак та... сөйләшә торган мәсьәләләремез газеталар, яңа китаплар, шигырьләр тирәсендә генә әйләнә дә... (ул) идарәханәдән китәргә ашыга, мин дә аны туктатмый идем... Ул, минем тәҗрибәмчә, дөрес сүзле, гакыл вә мантыйктан бигрәк, хискә бина итә торган, тормышында садәлекне һәр нәрсәдән алда күрә торган кеше иде...


*«Әл-ислах»чылар В.Бәхтияров (сулдан-уңга), К.Бәкер, Ф. Әмирхан, И. Әмирхан һәм Г. Тукай.*

Бервакыт яз житте. Тукай идарәханәдә тагы да ешрак була, озак-озак та утырып кала торган булды. Бервакыт Тукай, миңа сөйлисе сүзләре барлыгын әйтеп, минем белән... шәһәр тышына чыгып китте.

—Мин үзем килеп эләккән кругымнан разый түгел... Мин соң дәрәҗәдә эшлексезләндем. Бүлмәмдә көне-төне буе вакытларын кая куярга белмәгән кешеләр җыелып яталар...

Миннән һичбер җавап көтмичә, ярты сәгать микъдары сөйләп барды... Үзенең эш эшлисе килгәнен, бу эшсез, «идеалсыз», «чиле-пешле кешеләр» тирәсеннән котылырга теләгәнен, ләкин үзендә анлык куәт юк икәнлекне бәян итте... Тукай хис белән генә тора торган кеше булганга күрә, бер план тәгъкыйб итү аның өчен бөтенләй имкян тышында иде... Шулай да без аның белән бу вакыйгадан соң мәхрәм дуслар булып киттек...»

«Бервакыт яз житте... бу вакыйгадан соң без дуслар булып киттек» җөмләсен укыгач, Фатих Әмирхан белән Тукай арасындагы дустанә мөнәсәбәтнең шагыйрь Казанга килгәч үк түгел, ярты ел чамасы вакыт үткәч кенә башланып киткәнлеге аңлашыла. «Минем белән шәһәр тышына чыгып китте» җөмләсенә карата шуны әйтергә кирәктер: Ф. Әмирхан, В. Бәхтияров һәм тагын кайбер дуслары ул елларда җәйге айларда Түбәнге Кабан күленең аргы башындагы Суконный бистәсенә «дачага чыгып» яши торган булалар.

Фатих Әмирханның 1913 елда «Ан» журналында басылган истәлегеннән шактый ук озын өзек китерелүнең кирәклеген укучы соңга табарак аңлар, мөгаен.

Дөрес, Тукайның чордашлары истәлекләрендә дә төгәлсезлекләр очраштыргалый. Мәсәлән, Галиәсгар Камал истәлегендә «Әл-ислах» газетасының Тукай Казанга кайткач

кына, 1907 елның октябрь ахырларында гына, чыгарга ниятләве турында әйтелә. Аның хатирә язмасы 1933 елда нәшер ителгән. Мөгаен, шул елда, шагыйрь вафатыннан соң егерме ел үткәч язылгандыр да. Тукайның кайбер башка чордашлары да шагыйрьне бик соңлап искә ала, Совет хакимияте дәверендә—утызынчы елларда гына истәлекләрен язалар. Мөгаен, Фатих Сәйфи-Казанлы шагыйрьнең тәүге өч томлыгын әзерләгәндә аларга шундый мөрәҗәгать белән чыккандыр. Бу вакытта инде аларның күбесе яна таләпләргә ярарга тырышыбрак эш иткән. Шагыйрьне кайбер дус-ишеннән аерып, аны большевиклар йогынтысынарак тартырга тырышкан. Шул сәбәпле утызынчы, кырыгынчы елларда тупланган кайбер истәлекләрне кабат бастырганда, аларны күләмле искәрмәләр белән тулыландыру зарурлыгы көн кебек ачык.

Совет хакимияте дәверендә басылган хезмәтләрдә, шул исәптән И. Нуруллинның «Атаклы кешеләр тормышы» сериясендә чыккан китапларында Тукаебыз биографиясендәге шактый зур бер «китек урын» күзгә ташлана. Әйтик, аның Казанга күчеп килгәннән соңгы беренче кышын уздыруга караган чоры ул хезмәтләрдә әйтелер-әйтелмәс рәвештә генә йөгереп үтелгән. Һәм шулай эшләнүнең сере дә бик өстә ята: бу кышта ул, башлыча, миллионнар белән эш йөртүче бай баласы Дәүләтшин Габдерахман Галләм улы белән якыннан аралашкан. Ягъни, «бай-буржуйлар белән якын мөнәсәбәттә» булган. Г. Г. Дәүләтшин—Әхмәт бай Хөсәенев тарафыннан уллыкка алынган шәхес. Шуна күрә әлеге дәвер татар матбугатында ул кешене еш кына Габдерахман Хөсәенев буларак та таныйлар. Мәсәлән, узган гасыр башында Гаяз Исхакый исеме белән чыккан берничә китапның иганәчесе һәм нашире буларак Г. Г. Хөсәенев күрсәтелә. Идрис Багдановның «Помади мәсьәләсе» пьесасы да 1908 елда шушы нәшриятта басыла. 1907 елда нәшер ителгән «Зиндан» җыентыгына кереш сүз язучылар да Сәгыйть Рәмиев белән Габдерахман Хөсәенев—әдипнең Казан укытучылар мәктәбендә укыган елларындагы шәриктәше. Шулай ук алар бер үк елларда Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәсендә дә бергә укыталар бугай.

Янадан кайтып, замандашлары язган истәлекләрнең сызылмыйча нәшер ителгән өлешләренә күз салыйк. *(«Тукай турында хатирәләр». 1976 ел.)* Тупламага кергән күп кенә истәлекне «заманга яраклаштыру» үзен нык сиздерә. Мисалга С. Рәмиевнең күп кенә урында өч нокта белән тәмамланган хатирәсен китерергә була. Казанга кайткач та «Тукай бераз вакыт Шәрәфләргә—«Мәгариф» көтепханәсенә саткан шигырьләреннән алган гонорары белән җан асрап килә,» дип яза Галиәсгар Камал. (Шул көздә авылына, солдатка каралырга кайтканда алып кигән «көзге пальто, яна штиблет, яна кепка» да шул Шәрәфләр биргән акча исәбенә алына, билгеле.) «Шуннан озак та үтми... «Әл-ислах» газетасы чыга башлагач,—дип дәвам итә Г. Камал.—Тукай шунда җиң сызганып эшләргә тотынды. (Ягъни, һәр санга диярлек мәкалә һәм шигырьләрен биреп бара. Әмма хезмәт хакы алып эшләми.) Ләкин ярлы оешманың (нигездә шәкертләр тарафыннан тупланган мая исәбенә нәшер ителгән газета) барлы-юклы акчасына чыгарыла торган «Әл-ислах»тан алган чирек-чорык гонорарлар гына Тукайның тормышын тәэмин итә алмыйлар. Шул вакытларда шул яшьләр тарафыннан «Китап» исемендә бер ширкәт төзелеп, Тукайны шунда урнаштырып, аена 25 сум айлык белән экспедитор итеп куялар...»

Галиәсгар Камалның 1930нчы еллар башында язылган бу истәлегендә ике төгәлсезлек күзгә чалына. Алдарак әйткәнемчә, берсе «Әл-ислах»ның чыгу вакытына кагыла. Икенчесе—«Әл-ислах» тирәсендә оешкан яшьләр төркемен «Китап» нәшриятын оештыруга мөнәсәбәте булган икенче төркем белән берләштерү. Беренче төркемдә Фатих Әмирхан, Вафа Бәхтияров кебек «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укыган шәкертләр өстенлек итә. Аларның төп иганәчесе—уртакул сәүдәгәр Салих Гобәйдуллин улы Газиз, булачак күренекле тарихчы галим. Әдәбият фәнендә ул төркем «Ислахчы»лар дип йөртелә. Икенче төркем—ишлерәк һәм баерак. Алар «Таңчылар» төркеме дип йөртелә, 1906 елның маенда чыга башлаган «Таң йолдызы» газетасы тирәсенә берләшкән яшьләр. Әйдәп баручылары Гаяз Исхакый. Соңрак аларга бу ике төркем арасында да «үз кеше» булырга тырышкан Кәбир Бәкер дә килеп кушылачак. Тиздән «Оренбург якташлыгы» аны үзенә тартачак.

Әйе, икенче төркемгә, башлыча, Казандагы укытучылар мәктәбендә (Учительская школа) тәрбияләнгән һәм күпмедер дәрәҗәдә «Хөсәения» мәдрәсәсе белән дә

якын мөнәсәбәттә торган Гаяз Исхакый, Сәгыйть Рәмиев, Фоат Туктар, Шакир Мөхәммәдьяров, Габдерәүф Ниязбаев, Габдерахман Дәүләтшин-Хөсәенев һ. б. кергән. Сәгыйть, Шакир һәм Кәбир Бәкер «Хөсәения» мәдрәсәсенең элеккеге алдынгы шәкертләре. Гаяз, Фоат, Габдерәүф һәм шул ук Шакир Учительская школада бер чордарак укучылар. Г. Исхакый шуннан соң Оренбургка чакырыла, «Хөсәения» мәдрәсәсендә С. Рәмиев, Г. Дәүләтшин, Г. Ниязбаев белән бер вакыттарак мөгаллимлек итә. (Бу «Таңчы» «эсерлар» исемлеге Г. Ибраһимовның «1905 ел революциясе эчендә...» хезмәтендә дә китерелә.)

Бу ике төркем, бигрәк тә аларның әйдәүчеләре, танылып килүче әдипләр Фатих белән Гаяз арасында күпмедер дәрәҗәдә иҗади көндәшлек сөреме барлыгы да чит күзләргә күренеп торырлык. «Әл-ислах»чылар «Таң йолдызы» газетасы вәкилләрен, «таңчылар» исә «ислахчы»ларны бик үк өнәп бетермиләр. Ә Казанга яңарак кына килгән Тукай «ислах»чыларга якынрак торса да, «таңчылар» белән дә дустанә мөнәсәбәттә була. Бу дәвердә әле ул Сәгыйть Рәмиевне үзенә якын, һәм хәтта үзеннән өстенрәк шагыйрь дип тә таный. Кайбер истәлек язмаларында шул хакта Тукайның үз сүзләре китерелә. Казанга килгәч тә иң беренче эзләп тапкан, танышкан ике-өч кеше арасында да Сәгыйть Рәмиев исемлектә алгы сафта тора..

Ә Сәгыйть Рәмиевнең исә якташы, бер мәдрәсәдә бер чорда укыган һәм укыткан Габдерахман Дәүләтшин белән дустанә мөнәсәбәттә булганлыгында шик юк. Өстәвенә, икесе дә бер үк елларда әдәби иҗат белән дә шөгыльләнә башлыйлар. Г. Дәүләтшин-Хөсәенев иң әүвәл Н. В. Гогольның «Өйләнү» комедиясен тәрҗемә итә һәм аны 1905 елда аерым китап итеп бастырып та чыгара. Казанда һәм башка шәһәрләрдә татар театр труппалары калкып чыккач, «Өйләнү»не кат-кат сәхнәләштермәгән коллектив калмый диярлек. Оренбург янәшәсендәге Каргалыда туып-үскән Габдерәүф Ниязбаев та шул ук елларда иҗат итә башлый. Казан укытучылар мәктәбендә укыганда тәүге тапкыр сәхнәгә чыккан, 1906 елның 22 декабрендә Казанда рәсми рәвештә оештырылган беренче театр уеныңда актив катнашкан бу егет тиздән пьесалар тәрҗемә итү һәм татарча пьесалар язу эшенә дә керешеп китә. Аның берничә пьесасы «Сәйәр» һәм башка труппалар тарафыннан сәхнәләштерелә. Татар театры тарихын өйрәнүгә зур өлеш керткән галим Һәнүз Мәхмүдев аның узган гасыр башында Петербургка, цензура идарәсенә берничә тәрҗемә һәм оригиналь сәхнә әсәрен җибәрүен, аларны татарча бастырырга һәм татар сәхнәсендә куярга дип, рөхсәт алырга тырышуын да билгеләп үтә. Шундый ук үтенечләр белән Казан губернаторына һәм Петербург түрәләренә аның якташы Габдерахман Дәүләтшинның да берничә мәртәбә мөрәҗәгать иткәне була. Шул ук вакытта Г. Дәүләтшин үз әсәрен—«Яшь хатын» драмасын—иҗат итәргә дә өлгерә. «Октябрьгә кадәрге татар театры» китабында (1988 ел, 41 бит) Һ. Мәхмүдев Г. Дәүләтшинны «Таждаров Д. псевдонимы белән яза...», дип белдерә. (Бу әсәрнең авторы Г. Дәүләтшин булганлыгын 1916 елда «Вакыт» газетасы да язып чыга.) «1910 елга кадәр спектакльләрен «Яшьләр труппасы» исеме белән биреп килгән... артистлар 1907—1908 елларда гына да «Ике гашыйк» һәм «Алдым-бирдем» (Г. Исхакый), «Бәхетсез егет» (Г. Камал), «Оят, яки Күз яше» (Я. Вәли), «Яшь хатын» (Д. Таждаров) әсәрләрен сәхнәләштереп, шактый уныш һәм популярлык казаналар», дип хәбәр итә галим. Ә шул ук китапның 81 нче битендә исә : «Д. Таждаровның... 1907 елда басылып чыккан «Яшь хатын» әсәрендә мәгърифәтчелек идеяләре, рационализм өстенлек итү бик табигый. Драма үзенең эчтәлеге, куелган мәсьәләләре, образларның бирелеше ягыннан ул чорда язылган әсәрләрнең күбесеннән өстен тора», дип тә яза ул. Бу әсәр революциягә чаклы «Сәйәр» һ. б. труппалар тарафыннан еш сәхнәләштерелгән. «Сәйәр»дән тыш бу драманы «Нур» (Уфа), «Ширкәт» (Оренбург), «Мохтарият« (Әстерхан) театр труппалары да, Орск, Троицк шәһәрләре һәвәскәр артистлар төркемнәре дә сәхнәләштергән.

1917 елгы вакыйгалардан соң «миллионер Әхмәд бай углы»ның пьесалары ни өчен сәхнәләштерелмәве һәммәбезгә аңлашыладыр.

Бу төркемнән Шакир Мөхәммәдьяров та үз иптәшләреннән калышмаска тырыша. 1907 елда ул Ш. Жәмирев псевдонимы белән А. П. Чеховның «Предложение» водевилен «Кыз сорау» дип тәрҗемә итеп, бастырып чыгара. «Сәйәр» труппасы

бу әсәрне шул ук елда сәхнәләштерә. Соныннан да әлеге комедия шул һәм башка труппалар тарафыннан кат-кат уйнала. 1913 елда Петербург университетын тәмамлаганнан соң, Шакирның байтак кына мәкалә-очерклары, хокук фәненә багышланган хезмәтләре дөнья күргән. 1918 елда ул, беренчеләрдән буларак, күренекле чордашына багышланган «Тукай кем?» дигән китабын да Мәскәүдә нәшер итәчәк. Ә 1912 елда, Тукай Петербургка килгәндә, «аның янына табиб-профессорны алып килүче студент» та ул булган.

Габдулла Тукай Казанга килгәч тә «Әл-ислах» тирәсендә оешкан яшьләрдән тыш, «таңчы»лар төркеме яшьләре белән дә ярыйсы ук якыннан аралашкан. Мәсәлән, Г. Исхакыйның иҗаты белән ул Уральскида яшәгән вакытыннан ук таныш була. Камил Мотыйгый тарафыннан нәшер ителгән, татар телендәге беренче журнал булган «Әлгасрелҗәдит»нең ин тәүге ике санында ( 1906 ел башы) Г.Исхакый тәрҗемәсендә Н.Гогольның «Борынгы алпавытлар» повесте басылып чыга. Ул елларда Г.Тукай, белгәнебезчә, хәлфәсе нәшер иткән газет һәм журналларны чыгарышуда актив катнаша. Әлбәттә инде ул шул елларда ук Г. Исхакыйның үз әсәрләрен дә укыган һәм бу әдипнең кемлеген белгән була. Ә 1907 елның маенда, Уральскида чакта, әдипкә багышлап «Кем ул?» шигырен иҗат итә. Ләкин элегрәк елларда безнең галимнәребез дә, соңлабрак Тукайга багышлап истәлек-хатирәләр язарга керешкән кайбер замандашлары да иганәче һәм нашир буларак татар мәдәнияте үсешенә беркадәр өлеш керткән «буржуй» Габдерахман Дәүләтшинны, «ак эмигрант»лардан Гаяз Исхакый, Фоат Туктаровларны һәм гомеренең бер өлешен Сталин төрмәләрендә уздырган «милләтче» Шакир Мөхәммәдьяровны телгә алырга базмаганнар. Шул сәбәпле Тукайның «танчылар» төркеме белән булган мөнәсәбәтләре күрсәтелмәгән диярлек. Дөрес, Тукай нәкъ Казанга кайткан көннәрдә генә Г. Исхакыйны сөргенгә озатканнар. Алар ул көздә көрешмиләр дә бугай. Тагын беразвакыттан соң, 1908 елның башында, бу төркемнән тагын берничә кешегә, шул исәптән арада иң актив булган Ш. Мөхәмәдьяровка Казанда яшәү тыела. Ул туган-үскән төбәгенә, Орск шәһәренә, сөргенгә озатыла.

1920—1930 елларда фәкать Галимҗан Ибраһимов кына үз хезмәтләрендә ул төркем вәкилләрен еш телгә ала. Әлбәттә инде, күп очракта аларның «тискәре» эш-гамәлләрен барлаганда. Әйтик, «Әсәрләр»енең 1984 елда нәшер ителгән 7нче томының 408 битендә ул: «Гаяз Исхаковлар компаниясе... Казанда 1906 елның май 18ендә «Таң» исемендә газета чыгара башладылар. «Таң» («Тавыш», «Тан мәҗмугасе») редакциясе үзенә кирәк чыгымнарның зур өлешен Әхмәд бай Хөсәеневнең угылы Габдерахман Дәүләтшиннан һәм Бөгелмәдә урта тип сәүдәгәр Шакир Хәкимевтән алдылар», дип яза. Әйе, Г. Дәүләтшин—революциягә кадәр «иң бай татар» исеме белән йөргән Әхмәд байның асрамага алган улы. Әхмәд байның үз баласы булмый. Әхмәд бай Хөсәенев тырышлыгы белән, нигездә аның мең-миллионнары исәбенә ачылган «Хөсәения» мәдрәсәсе мөдәррисе һәм аның карамагындагы таш мәчетнең мулласы Габделгалим Габделгалләм улы Дәүләтшин да Габдерахманның агасы буладыр. Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең әлеге томы ахырындарак (517 биттә) китерелгән искәрмәдә Габдерахман турында «Оренбург бае, миллионер, 1нче Дума депутаты» дигән сүзләр дә теркәлгән.

Рәсмиләштерелгән мәгълүматым булмастан, үз фикерләвемчә, бу ике ага-брат, мөгаен, Әхмәд байның карчыгы Бибибану абыстай (ул заманда бай хатыннарын да «абыстай» дип олылаганнар) белән туганлык мөнәсәбәтендә торганнардыр. Хәер, шул елларда матбугатка чыгарылган бер фельетонында Оренбургта яшәп иҗат иткән әдип Фатих Кәрими минем бу фикерне дәлилли дә сыман. «Корсак» дип исемләнгән сатирик хикәясендә әдип урыннан-урынга күченгәләп, «эшнең җүнен тапмый йөргән» берәүнең: «Минем бәхетем юк, миңа иярмиләр... Казанга кайтам... Габдерахман аркылы, абыстай кулы белән Әхмәд байның кесәсен бушатам», дип хыяллануын яза. Бу хыяллануда «абыстай» белән Габдерахманның туган икәнлегенә ишарә ачык сиземләнә, минемчә. («Корсак» әсәреннән бу кыска өзек шулай ук Г. Ибраһимовның «Вак буржуазия «социализмы» группалары» хезмәтеннән күчерелде».)

## 2

Менә шул Дәүләтшин-Хөсәенев фамилиясен йөрткән кеше 1907 елның ноябрь башларында Казанда үз акчасына китап бастырып сатучы «Китап» ширкәтен ача. Китап сәүдәсе белән шөгыльләнергә тотына. Тукайны үзенең ярдәмчесе итеп ала. Үзе дә 1906 елның башыннан китап сәүдәсе белән шөгыльләнгән Гыйльметдин Шәрәф шул хакта түбәндәге мәгълүматны китерә («Ан» журналында, 1914 елда чыккан истәлек): «1907 елның ноябрь числоларында.... (хәрби хезмәттән котылып кайткач) Тукайны «Әхбар» газетасын чыгарырга чакыра башлыйлар.» Газета чыгаруны Харис Фәйзуллин оештыра. Ул, Төркиядә укып кайтканнан соң, дистә ел чамасы «Хөсәения»дә укыткан һәм янарак кына Казанга күчеп килгән була. Газетаны шул ук Г. Дәүләтшин катнашында чыгарырга ниятләгән булсалар кирәк. Тукай ул газета эшен үз җилкәсенә алырга батырчылык итми. Соңрак биргән аңлатмаларында ул «Әхбар»да эшләргә алынмавының сәбәбен «шул чорда русча белүем чамалы иде» дип аңлата.

Г. Шәрәф дәвам итә: «Газетага (эшкә) керү урынына ул вакыт «Китап» исемендә нәшрият эшен башлаган Габдерахман Дәүләтшинга экспедитор булып керә. Тукай «Китап» нәшрияты өчен контор итеп алынган «Мәскәуский номерлар»ның берсенә күчә. (Ул кунакханә Мәскәү урамының тимер юл вокзалына якынрак өлешендә урнашкан була.) Анда берәр ай чамасы торгач, «Китап» нәшриятының конторы белән бергә «Уральский подворье»га күчә һәм шул контор бүлмәсендә яши. Тукай «Китап» нәшрияты заказ биреп чыгарган китапларның корректурасын карый (бүгенгечәрәк итеп әйтсәк—редакцияли була инде), почтага китаплар әзерләп илтә. Берәр китап матбагадан чыкса, Казан китапчыларына (ягъни, китап белән сату итүчеләргә) кирәк кадәр илтеп тапшыра иде... Тукай, конторада кунып торуы өстенә, айга егерме биш сум вазифа (эш хакы) ала иде... 1908 сәнә (ел) көзгә таба «Китап» нәшрияты эшен туктатты. Тукай да аның белән эшен өзеп, (янадан) «Болгар» номерларына күчеп тора башлады. 1908 сәнә август башында «Яшен» журналының беренче номеры чыга. (Нашире һәм мөхәррире Г. Камал.) Бу беренче номерында башыннан ахырына кадәр Тукайның каләме йөри...» дип яза Г. Шәрәф.

Әлеге истәлекне укыгач шунысы ачыклана—Тукай Казанга килүенең икенче елыннан ук «Болгар» номерларында түгел, ә «Китап» ширкәте конторасында яшәгән икән. Шунда ул кыш чыккан. Киләсе елның җәй урталарында, Г. Камал «Яшен» журналын чыгарырга рөхсәт алгач, элекке эшеннән китеп, янадан «Болгар» кунакханәсенә кайткан һәм әлеге журналны чыгаруда катнаша башлаган. Мөгаен монда ул сәркәтип вазифасын үтәгәндер.

Әйе, бу кыска гомерле журналны Г. Камал белән Г. Тукай бергә чыгаралар. Нашир һәм мөхәррир булу өстенә рәссам вазифасын да үтәүче Г. Камалны Тукай ара-тирә, «рәсемнәрне вакытында бирмисең» дип битәрләп тә алгалый торган була. Димәк, бу журналда инде ул үзен житди мөхәррир дәрәҗәсендә тоя башлый...

Инде «Китап» нәшриятына бәйле башка төр истәлекләргә әйләнеп кайтыйк. И. Нуруллин «Габдулла Тукай» китабында шагыйрьнең бу кыштагы тормыш-яшәешенә бәйле түбәндәге ике-өч җөмләне теркәгән (129 бит): «Тукай ... бераздан яңа оешып килә торган «Китап» исемле кечкенә нәшриятка 25 сумлык айлык белән экспедитор булып урнаша... Корректура карый, борын очын тирләтә-тирләтә посылка тегә, тартынмый-нитми почтага күтәреп китә». Һәм бу хакта башка бер җөмлә дә юк. Ярты ел буе Тукайның бушлай, контора өчен арендаланган кунакханә бүлмәсендә яшәү факты да искә алынмаган. Әйтерсең лә һаман шул «Болгар» кетәгеннән килеп-китеп эшләп йөри. Әйе, бу китапның битләрендә Тукайның фәкать «Болгар»да яшәгәнлеге генә теркәлгән. 1912 елның башында, Өчиледә ике ай чамасы торып кайтканнан соң, җылы, мичле өйдә яшисе килеп фатир эзләүләре дә, апалы-сеңелле ике марҗа өендә «бер атна, буш бутылка төсле, идәндә аунаулары» да, бу шапшак хуҗалардан өч тәңкә зыян күреп котылганы да телгә алынмаган. Шуннан соң да әле ул «тар бүлмәле Болгар»га кайтмый, иркен, якты бүлмәле, яхшы җиһазлы «Свет» кунакханәсенә барып урнаша. «Әмма яхшы, матур... Бүлмә эчендә нур... Жуынгычы—мәрмәр... Язу өстәле әллә ничә тартмалы...» дип искә ала Тукай үзе бу дәверне. Ләкин монда да ул озак яшәми. Бердән, мондагы күселәр шагыйрьнең

иртәгә дип хәстәрләп калдырган «шикәр, булкиларны... төнлә кетер-кетер китереп... ком итәргә» керешәләр. Икенчедән, авыруы аны тизрәк кымызга барырга, бераз дәваланырга куша. Шушы «нурлы, күселе иркен бүлмә»дә бер ай чамасы яшәгәннән соң ул, мартның соңгы көннәрендә (хәзерге исәп белән апрельнең уннары тирәсендә) Уфага дип юлга чыгып китә. Һәм шул сәфәрдән инде ул җәй ахырларында гына әйләнеп кайтачак. Ерак сәфәрдән, кымыздан кайткач та ул «Мәскәуский урамдагы... пәрәмәчле «Амур» кунакханәсенә урнаша. 1912—1913 елларның кышын ул шунда, җылыда уздыра. Исмәгыйль Рәмиев «Шагыйрьнең «апартаменты» дип исемләнгән истәлек язмасында *(«Истәлекләр. Татарча басма сүз». 1965)* шушы «мосафирханәнең икенче каттагы 9 нчы бүлмә»сен тасвир итә дә инде.

«Шагыйрьне күреп белүем 1911—1913 елларга туры килә,—дип башлый И.Рәмиев истәлекләрен.—Шагыйрьне төрле чолганышта очратырга туры килде. Әмма мин аның үтә кабынып китеп иләмсез чыгыш ясаганын, йә булмаса каушап калган чагын очратмадым... Аз сүзле иде ул... «Амур» кунакханәсенә шагыйрь 1912 елның җәй ахырында, Троицк тирәсендә кымызда булып кайтканнан соң урнаша... Тукайның бүлмәсе буйга җиде, ине биш адым булыр. Ятак урыны фанер ширма белән бүлеп куелган. Ул мосафирханә тынгач, төнге тынлыктан файдаланып эшли иде». Башка чордашлары истәлекләренә караганда, шагыйрьнең «Болгар»дагы бүлмәсе буйга 3—3 ярым, ингә ике ярым метр чамасы булган.

Бу кышта янәшәдәге 11нче бүлмәдә Фатих Әмирхан яши. Һәм шунда алар, элегрәк ике арада килеп туган ниндидер аңлашылмаучылыкны онытып, яңадан дуслашып китәләр, диелә истәлекләрдә. Ике бүлмә арасындагы юка дивар аша Фатих Әмирхан шагыйрьнең төннәр буе йөткереп чыкканлыгын ишетеп, борчылып ята торган була. Клячкин хастаханәсенә дә Тукайны шушы бүлмәдән озаталар.

Замандашлары язган истәлекләрдә Тукайның «Китап» нәшриятында егерме биш сумга эшләп йөрүе табигый тоелса да, 1960—1970 елларда исә кайберәүләрнең аны азсыныбрак сөйләүләре хәтердә калган. Ә бит күп кенә башка нәшриятларда һәм китап басмаханәләрендә эшләүчеләр дә ул заманда шул чамада ук эш хакы алганнар, югыйсә. Мәсәлән, кеше фатирында яшәп, өч-дүрт җанлы гаилә асраган Мәҗит Гафури да ул елларда нәкъ шул күләмдә мәгаш алып, Уфада Кәримевләрнең «Шәрекъ» нәшриятында корректор булып эшләп йөри. Оренбургта Кәримев—Хөсәеневләр китап ширкәтендә эшләүче корректор-мөхәррирләр дә шундый ук эш хакы алганнар. Фәкать миллионер Рәмиевләр генә үз басмаханәләренә корректор вазифасын үтәргә чакырып китерелгән Шәриф Камалга баштарак аена кырык, аннары йөз егерме сум түләгәннәр. Ш. Камалдан алдарак шундый ук эш хакы түләү шарты белән алар шагыйрь Габдулла Тукайны да чакырган булганнар. «Ике тәкә башы бер казанга сыймас» дигәнрәк фикердән чыгып булса кирәк, шагыйрь ул тәкъдимне кабул итмәгән.

Кабат Тукайның Казанда уздырган беренче кышына әйләнеп кайтыйк. Бу кышта язган үз хатларын күздән кичерик.

«1907 ел, 30 декабрь. Габдулла Кариевкә. Хөрмәтле аркадаш Габдулла Хәйруллин җәнабләре! ... Бу сәнә (ел) гаҗәп булды... Мин Казанны вә туган җирем буларак Казан арты авылларын күреп, күп гыйбрәтләр вә хиссиятләр алдым... Әлхәмделиллаһ, монда күңелле... Үзем теләп кенә «Әл-ислах»ка хезмәт итәм. Җалуние башка җирдән алам...»

Уральскида шагыйрьнең ике апасы да яшәп калды бит әле. Икесе дә Газизә исемле. Апаларының икесе дә бер исемдә булганлыктан соңгы елларда күренгәләгән кайбер язмаларда аларны бер-берсе белән буташтыргалыйлар да шикелле. Ә берничә ел элегрәк дөнья күргән бер ханымның хатирәләрендә хәтта ки өлкән Газизә, Габдулланы (ә аннан алдарак кече Газизәне дә) Уральскига чакырып китереп, кеше иткәне өчен «усал җиңги» буларак телгә алына. Әйе, өлкән Газизә, уртакул сәүдәгәр Галиәсгар Госманов хатыны, шагыйрь атасының сеңлесе күпләребез күңелендә мәңгегә изге җан буларак истә калырга хаклы. Ә кече Газизә, Тукайның бертуган апасы (аналары гына башка) шулай ук хөрмәтләп искә алуга лаеклы. Уральскида яшәү дәверендә нәкъ шул кече Газизә энесенең өс киемнәрен юып, ямап, кирәк вакытларда башкача булышлык итеп яшәгән ич. («Усал җиңги» әйтеме кулланылган әлеге истәлек язмасында Тукайның киемнәрен ямап-карап торучы итеп тә башка

бер кеше телгә алына.) Нәкъ шушы кече Газизәнең һәрдаим апасы белән жизнәсе алдында «ятимлектә гомер кичерүче» энесен жәлләп искә алулары—Тукайның Җаек тарафына сәфәр кылуына сәбәп булган да ич. Шагыйрьнең бертуган апасы Газизә Забировага язган хатлары сакланмаган булса кирәк. Тукай томнарына кертелмәгәннәр. (Аның истәлекләре язучы Мөхәммәд Гали китабында теркәлгәннәр. Ә улының истәлек язмалары 1960—1970 елларда Казанда вакытлы матбугат битләрендә күренгәләде.)

Тукайның олы апасына язган ике хаты «Әсәрләре»нең бишенче томына (1986 ел) кергәннәр. Хатларның кыскарагы яңа ел алдыннан, 1907 елның 30 декабрендә җибәрелгән. Ике-өч битлесе 1908 елның 27 мартында язылган. Ул хат «Сөекле гаммәм (атам белән бертуган апам) Газизә апай!—дип башлана.—Каз вә кортлы (кызыл эремчекле) майларыгызны алгач бер хат язган идем. Шул вакыттан бирле Сездән хат-хәбәр юк... Мин Казаннан, әүвәл язганча, бик разый. Тагын әйтәм, дус-иш күп.... Китаплар һәркөн яңадан-яңа чыгып тора. Үземез дә язамыз. Әле бу арада тагы зур гына бер шигырь китабы яздым. Чыккач та Сезгә җибәрермен... Без хәзер Әхмәд байның угылы илә бергә «Китап» нәшрияты исемле бер ширкәт ясадык. Һәртөрле яңа китаплар сатып алып вә үземез бастырып сатабыз. Һәркөн һәр тарафларга җибәрәбез. Мин китапларның хаталарын төзәтәм. Хак куям. Сораган кешеләргә җибәрәм. Контора минем номерымдадыр. Бу эштән яхшы гына акча алам. Әлхасыйль, хәлем яхшы, әлхәмделиллаһ... Энегез Г. Тукаев.» Адресым «гор. Казань, издательство «Китаб». Вәссәлам,» дип тә өстәгән.

Бу хатта язылган «Китап» нәшрияты исемле бер ширкәт ясадык» сүзләренә карата әлегә берничек тә җавап биреп булмый. Г. Дәүләтшинның бу ширкәтне ачарга рөхсәт алган документларын архивтан тапмыйча торып аңа җавап бирүе читен. Мәгәр, «бер ширкәт ясадык» җөмләсеннән, бу эшкә аларның килешеп, бергә тотынуларын чамаларга була.

1908 елның 9 июнендә Габдерахман Дәүләтшинга юлланган хатында Г. Тукай мондыйрак сүзләр язган: «Әгәр Сездә миңа тиешле акча, үзегез әйткәнчә, беткән булса, пожалуйста, Сез хәзер 25 сум акча биреп йибәренез әле. Мин сезгә, вәгъдәм буенча, тиздән бер китап бирермен». Шул том ахырындагы искәрмәдә исә (278 бит) «Китап» нәшриятына вәгъдә ителгән ул китапның «Алтын әтәч» исемендә икәнлеге, А. С. Пушкинның «Сказка о золотом петушке» поэмасының тәрҗемәсе икәнлеге белдерелә. Озакламыйча бу китап Г. Дәүләтшин заказы белән Харитонов басмаханәсендә басылып та чыга.

Бу соңгы хат эчтәлегеннән күренә ки, 1908 елның июнь башларыннан Тукай инде «Китап» ширкәтендә эшләми. Димәк, Галиәсгар Камал көлкеле «Яшен» журналын нәшер итү мәшәкатьләренә дә шул вакытта ук керешкән булгандыр. Уральскида көлкеле «Уклар» журналын чыгарышуда актив катнашкан (кайбер галимнәребез фикеренчә аның мөхәррире булган) Тукайны да шул вакытта ук үз журналын чыгарышырга димләгәндер, мөгаен.

«Китап» нәшрияты һәм китап сату ширкәтенең 1908 елның ахырларында ябылу сәбәпләре миңа мәгълүм түгел. Мөгаен Әхмәд бай Хөсәенев вафатыннан соң, аның бердәнбер варисы буларак, Габдерахман Габделгаллә улына күләмлерәк сәүдә эшләрен үз җилкәсенә алырга туры килгәндер. Миңа фәкать шунысы мәгълүм: 1916 елда Оренбургтагы «Ширкәт» труппасы Д. Таждаровның «Яшь хатын» драмасын кабат сәхнәләштерергә ниятләгәч, автор, ягъни Г. Г. Дәүләтшин-Хөсәенев ул әсәрне кабат карап, беркадәр үзгәртеп чыккан. Димәк, ул вакытта инде ул Оренбургта яшәгән (Хөсәенев байларның төп сәүдә базасы шунда урнашкан). 1917 елгы үзгәрешләрдән соң сәүдәгәр Хөсәеневләрнең мал-мөлкәте Совет хакимияте тарафыннан үзләштерелсә дә, исән варисларының күпчелеге репрессияләнми. Бәлки ул байларның, милләттәшләре аң-белемле булсын дип, күпләп мәктәп-мәдрәсәләр ачканлыгы да истә тотылгандыр. Фәкать Оренбургтагы «Вәлия» мәдрәсәсе башлыгы, «Дин вә мәгыйшәт» журналының нашире Мөхәммәдвәли мулла Хөсәенев кенә кулга алына һәм 1933 елда төрмәдә вафат була.

Фәридә
Хәсәнова

# «МӘХӘББӘТ ШАГЫЙРЕН ТАНЫЙ БЕЛЕГЕЗ!»

## РӘДИФ ГАТАШКА 70 ЯШЬ

*Мәхәббәт шагыйрен таный белегез!*
*Әй, кешеләр, аңа тик сүз бирегез!*
Рәдиф Гаташ

Гасырлар чиге әдәбиятында күренекле шәхесләрдән идеал эзләү мотивы көчәеп китте. Хәтта татар шигъриятендә Кол Гали, Акмулла, Кандалый, Тукай, Дәрдемәнд, Такташ, Җәлил, Ф. Кәрим, Туфан, С. Хәкимнәрнең әдәби образлары пәйда булды. Шагыйрьләрнең бу юнәлештәге эзләнүләре бүген дә дәвам итә. Ф. Шәфигуллин, Рәш.Әхмәтҗан, М. Әгъләм, Р. Ягъфәровләргә шигырь, багышлама, пародия, одамәдхия, мәрсия, истәлек-хатирә, эпиграмма жанрындагы тезмә формалы әсәрләр саны арта бара. Исемнәре аталган әлеге шәхесләр безнең арада юк инде. Бөекләрне искә алу рәвешендәге шигырьләрнең арта баруы шагыйрьләрне идеалны үз араларыннан эзләүгә этәрә булса кирәк. Сәбәбе дә ачык: дөньяда үрнәк дәрәҗәсенә куеп табынырлык кыйммәтләр кими бара.

Әлеге күренешнең 70 яшьлек гомер бәйрәмен каршыларга әзерләнүче шагыйрь Рәдиф Гаташ белән дә бәйләнеше бар. Бүгенге көннән исән шагыйрьләре арасында үзенә багышлап язылган шигырьләр саны буенча Р. Гаташка тиңнәр юк кебек (булса, Р. Фәйзуллин һәм Г. Морат кына булыр). Хәзер күп кенә шагыйрьләр, үзләренә багышлап язылган мәкалә, шигырьләрне туплап, аерым җыентыклар чыгара башлады. Кирәкле эш бу. Р. Гаташ турында да шундый китап булды: «Гаташнамә» дип атала. Әмма «Гаташнамә» дә Гаташка дигән шигъри багышламаларның барысын да туплап бетерә алмаган. Шулай да җыентыктагы кайбер шигырьләргә игътибар итмичә булмый. Менә Р. Мингалимнең «Каләмдәшем Р. Гаташны озаграк күрми торганда туган уй» исемле шигыре. Шигырь Гаташның көлгән чагындагы портретын сурәтләүгә багышлана. Гаташ көлүе ул «тере матурлык», «рәхәт түгелү», «тавышны көмеш тәнкә сипкәндәй сибеп көлү»,—дип яза шагыйрь дусты. Р. Вәлиев тә «Шагыйрьләр мәңге картаймый» исемле шигырен Гаташның бер юбилеена багышлый. Шигырь Гаташның Башкортстандагы Марс исемле туган авылы белән билгеле планета төшенчәсе аша сүз уйнатудан башланып китә. Р.Вәлиев, Гаташның «давыллы күңеле», «кайнар җилле шигыре»нә игътибар итеп, бик матур багышламашигырь яза. Якташы Р. Миңнуллин Гаташны «чыклы үлән», «таллы алан»ына кайтара да, яшьлектәге истәлекләр җуелуына игътибар итмәстән, шигыренә тизрәк әйләнеп кайтырга чакыра.

Р. Гаташ иҗатының төп юнәлешләрен ачып, шигырь яратучылар күңелендә югалмас урынлы символик шигырьләрен дә искә алып, шагыйрьнең холык-фигылен күрсәтеп, биографиясенең кайбер мизгелләренә тукталып, боларның барысын да

бер шигырьгә «сыйдырып бетерә алган» шагыйрь ул—пародияләр һәм эпиграммалар остасы Ләбиб Лерон. Әлеге «Сөю шагыйре» дип аталган җиде строфалык шигырь Гаташның туган ягын да, шигърияткә аяк баскан мәшһүр алтмышынчы елларны да, беренче җыентыгы «Гөлләр су сорый»ны да, «Ирләр булыйк!» исемле кыйбла-шигырьне дә, робагый-газәлләрне, «Мин Жирский!» дигән шагыйрьлек фәлсәфәсен, остазлык фактларын, хәтта язмыш сынауларын да күрсәтергә сәләтле булып чыккан. Кыскасы, әлеге шигырь Гаташның теләсә кайсы «Сайланма әсәрләр»енә шигъри кереш сүз ролен үти алырлык дәрәҗәдә тыгыз, мәгънәле, тәэсирле язылган. Шигырь моннан ун ел элек туса да, укыр өчен һаман кызыклы һәм яңача кабул ителә, аңа тик Тукай бүләген генә өстәп куясы калган.

*Күңел һәрчак якты, садә булыр—*
*Шигырь кебек булса гүзәлләр.*
*Гаташ йөрәгеннән сезгә күчәр*
*Робагыйлар белән газәлләр,*

—дип яза Л. Лерон.

Шагыйрь-каләмдәшләре генә түгел, Р. Гаташ иҗаты турында язмаган тәнкыйтьче-галим дә калмады кебек инде. Аның өчтомлык «Сайланма әсәрләр»енә хәтта өч тәнкыйтьче кереш сүз язган. Шагыйрьнең, 90нчы еллар тирәсеннән башлап, актив рәвештә Көнчыгыш шигърияте традицияләрендә иҗат итүен Х. Миңнегулов «Газәл жанры һәм Гаташ иҗаты», «Робагый жанры һәм Гаташ» һ. б. хезмәтләрендә бик тәфсилләп язып чыкты. Х. Миңнегулов язмаларында Гаташның шигырьгә килү юлы, остазлары фатихасы, шагыйрьнең шәхси сыйфатлары, татар шигырен пропагандалау юнәлешендәге эшенә басым ясала. Шагыйрьләрнең, яшьрәк вакытларында лирик шигырьләр язып, олыгая төшкәч, лиро-эпик (хәтта эпик) жанрга өстенлек бирүләре табигый күренеш. Гомер буена лирика өлкәсенә тугры калып иҗат итү бик сирәк шагыйрьләргә генә эләгәдер. Х. Миңнегулов «бөтен күзәнәкләре белән шагыйрь» (Хәсән Сарьян) булган Гаташка нәкъ менә шул яктан якын килә.

Билгеле, шигърият фәненең олуг белгече Т. Галиуллин Р. Гаташ турында язмый кала алмый иде. Галим хезмәтләрендә Гаташ «кырык беренче елгылар обоймасы» кысаларында карала. Сүз дә юк, шагыйрь—оста оратор. Дөрес, Т. Галиуллин башка «кырык берләр»нең дә шигырь уку сәнгатенә соклана, әмма Гаташ дәрәҗәсендәге аһәң, тавыш, яттан уку осталыгы, сәхнә темпераменты сирәкләргә генә бирелә шул. Галимнең игътибарын Гаташ иҗатындагы романтизм җәлеп итә. Юкка гына Т. Галиуллин Гаташны «XX гасыр татар шигъриятенең соңгы дәрвиш романтигы» дип атамый. Галим фикеренчә, Гаташ романтизмының сәбәбе: көчләп чукындыру, милли изүне татымаган бәрәкәтле Башкортстан туфрагы. Галим шулай ук Гаташ турында «зыялы тәнкыйтьче һәм остаз» буларак та язып чыга.

Р. Ганиева, Й. Нигъмәтуллина, Ф. Урманче, И. Вәлиулла һ. б. галимнәр шагыйрь иҗатына саллы гына бәяләрен биреп киләләр. Шулай да Х. Миңнегуловның бер фикерен ассызыклап үтәсе килә: «Шунысын да әйтик: гәрчә Р. Гаташ хакында фәнни-тәнкыйди язмалар шактый булса да, аның шигъри фикерләү үзенчәлеге, поэтик эзләнү-табышлары әле тиешенчә ачылмаган, Г. Ахунов сүзләре белән әйткәндә, аның поэзиясе тикшеренүчеләр өчен әле һаман да «каты чикләвек» булып калуында дәвам итә».

Сайланма әсәрләр җыентыклары чыгару хәзер һәр язучы-шагыйрьнең үзмаксатына әйләнеп бара булса кирәк. Дөрес, Гаяз Исхакыйның унбиштомлыгын тулысынча күрү бәхетенә ирешерме-юкмы татар укучысы, анысын әйтүе кыен. Шулай да Т. Миңнуллинның унтомлыгы, Ф. Яруллинның сигез (биш һәм өчтомлыклар), Р. Харис, Р. Миңнуллиннарның җидетомлык, Р. Фәйзуллинның биш һәм алтытомлык, Р. Вәлиевнең, М. Галиевнең дүрттомлыклары дөнья күрде, башка шагыйрьләрнең дә том-том китаплары чыгып килә. Хәтта шагыйрьләрнең күптомлыкларына күпсенеп караучылар да күренә башлады. Татар халкында «кеше тавыгы күркә булып күренә» дигән әйтем яшәп килә. Рус шагыйрьләренең күптомлыкларын беркем күпсенми, ә татар шагыйренең җиде томлык сайланма

әсәрләрен кабул итмәүне милли тарлык димичә, ни дисен. Билгеле, хөрмәтле Туфан ага Миннуллин, «ә сыйфат» диячәк инде. Татар шигырендә «революция ясаган» Р. Фәйзуллиннын «сайланма китап—шагыйрь йөрәгенен кардиограммасы» фикере белән килешкән хәлдә, алда «татарның тәрсез коймаклары»н киләчәктә күрергә мөмкин булсын дип өметләнергә генә кала.

Тик бу сөйләшү шагыйрь Р. Гаташны барыбер читләтеп узачак. Анын «Сайланма әсәрләре» бары өч томлык кына, гәрчә шагыйрьнен иҗаты аннан күпкә артык булса да. Р. Гаташ, сайланма әсәрләрен өчтомлыкка «сыйдырып» бер тапкыр аптыратса, мондый төр җыентыкнын формасын «кечерәйтеп», икенче тапкыр гаҗәпләндерде. Хәтта монын белән генә дә чикләнеп калмыйча, бер сериядәге һәр китабына өч галимнән өч төрле кереш сүз «яздырып», тагын бер «мөгез чыгарды».

Шагыйрьнен беренче томга кергән шигырьләрен берничә символик сүзтезмә белән тасвирлап булыр иде. Алар: «Дингез кирәк җилкәнгә», «Тик кагылма романтикама!», «Бик охшыйсым килә дингезгә!», «Чыктан куркыр чакмыни!», «Минем дә бит юлда корабым», «Күнелем тулган мен сорау белән», «Мин бер башак кырда үскән», «Мин дөресен сөйлим», «Мин бу җиргә ялга тукталдым», «Зәңгәр кое» һ. б.лар. Мисал өчен китерелгән берничә сүзтезмә генә дә Р. Гаташның романтик шагыйрь булуын күрсәтеп тора. Шагыйрьнең лирик герое «кара җирнең кара икмәген ашап үсә», берьяктан авылдан ераклашуына кайгыра, икенче яктан үз-үзен битәрле кебек тоела: «Җирне сөйгәч, читләшәсен нигә аннан син?»—дип өсти дә «Вәгъдә» шигырендә һәркем сокланып укырлык шигырь юллары калдыра:

*—Гомер атлы зәңгәр бәйге аты!*
*Син егылсаң кабат тормам мин;*
*Ләкин вәгъдә: яшәгәндә Җирдә,*
*Кайгы игене чәчеп урмам мин.*

Беренче томга тупланган шигырьләрнең берсеннән-берсе матур икәнлеген әйтми булмый. Һәрберсе укучы күнелендә уңай хисләр генә уятырга сәләтле. Шулай да аларда «беркатлылык, донжуанлык» һ. б. «кимчелекләре» булган боек күнелле «боек» лирик геройнын беренче җавапсыз мәхәббәте, унышсызлыклары да күренә. Кыскасы, лирик герой үзен яратмаганнарны да яратырга сәләтле булып чыккан, хисләренең чын күнелдән булуы белән дә ышандыра, шагыйрь биредә катлаулы метафоралар белән мавыкмый, гади сүзләр белән гади генә фикер әйткән кебек була. Гадәттә юмор шулай белдерелә. Тик Гаташны юморист шагыйрь дип атау дөрес булмас иде. Әмма шигырьләрендә шаянлык, җорлык сыйфатларын тоярга була. Менә бер мисал:

*Әгәр мәхәббәт эшендә*
*Шундый кенәгә туса,*
*... Мактау, жалоба, тәкъдимнәр*
*Язылып торган булса,*
*Жалоба язган кенәгә*
*Җирдән зур булыр иде...*
*Мактау сүзләре җыелса,*
*Океаннар тулыр иде.*
*Яңа туфан калкыр иде,*
*Тәкъдимен язса кеше...*
*Әллә ниләр булыр иде.*
*Аллага шөкер, мәхәббәт—*
*Һәркемнең яшерен эше.*

Шагыйрь иҗатыннан «үтергеч көлү» эзләмәскә кирәк. Юк ул. Гаташ үзенең көлү объектларын «Шат күнелләләр җыры»нда әйтеп тә бирә.

*Безнең көлү—башка төрле көлү:*
*Гариплектән, бәхетсездән көлмибез без,*
*Мыскыл итә белмибез без—*
*Кабахәт көлүе түгел безнең көлү.*

Шигырьдә ул үз серен дә ача: Гаташ яшь бер кызның тигез тешен күрсә көлә, саф һавада йөрсә, утын ярып, тау шикелле өйсә көлә ала. Ә күп вакытта елыйсы килгәндә дә көлә.

*Танымассың:*
*Вакыт-чорга җайлап,*
*Модный костюм кия шайтан да,—*

дип тә шаярта белә безнең шагыйрь. Шагыйрьнең «Лирик шаярулар—усал елмаюлар» исемле туплам шигырьләре бар. Нигездә алар шагыйрьлек вазифасы, әдәби тәнкыйть турында, чын шигырьне яклау төсендә язылган. Күп очракта шагыйрьнең тәнкыйте үз-үзенә дә юнәлдерелә. Башкаларның үзенә карата язылган шигырьләренә ул бик игътибарлы. Зыялы кеше («талантлы укучы») позициясеннән чыгып, аларга үткен шигъри җавабын да бирә белә...

Шагыйрь иҗатында чын татар ире образы көчле бирелә. «Малайлар» шигырендә ул үсмерләрнең тыелган әйбергә тартыла торган күнелен тасвирлый: аларга романнар түгел, анекдот кирәк, яшереп кенә трубка йөртү, хәтта сүгенү, ерак юллар, адаштырган утлар кирәк. Ә менә «Кырык яшьлек дуска» шигырендә Гаташ кырык яшьлек ирнең сыйфатларын саный: ул кырык һөнәр белә, кырык яшьтә инде чәчмиләр—ә урып-җыялар, кырык яшьтә үз улыңны, кызыңны сөяләр, кыскасы, гомернең бу чорында «кырык җирдә чөй калдырыр юләр генә», дигән нәтиҗә ясый шагыйрь. Гаташ «кырык яшьлек кешегә ни җитми» соравын да куя. Үзе үк җавап та бирә: аңа бераз гына яшьлек, бераз гына картлык җитми икән. Сүз уңаеннан шуны да әйтеп үтик, башка шагыйрьләрнең дә кырык яшькә багышланган шигырьләре еш күренә. Мәсәлән, Р. Харисның «Кырыкны узгач», Р. Рахманиның «Кырыктан соң», Р. Корбанның «Кырыкта» шигырьләре. Р. Миннуллин да гомер бәйрәмнәренә берничә шигырь багышлый. Күрәсең, безнең татарга вәхиләр кырык яшьтә чынлап та иңә булса кирәк.

«Ирләр булыйк» дәрәҗәсендәге шигырьләр язу өчен илһам шагыйрьләргә сирәк киләдер. Мәктәпләрнең югары сыйныфларында әтәч, көчек, каз бәбкәләре һ. б. (11 сыйныфта!) геройлар түгел, нәкъ менә без исемен атап үткән шигырьләр бирергә вакыт җитмәдеме икән? Сүз уңаеннан, Р. Гаташ әсәрләренең мәктәп программасында юклыгын әйтү белән генә чикләнәбез.

Чын шигырь көнкүреш ваклыкларыннан өстен булырга, укучыны матурлыкка сокланырга өйрәтергә тиешлеген һәркем белә. Шагыйрьләрнең «күктән йолдыз чүпләве» беркемгә дә сер түгел. Р. Гаташ та «чүпли ул йолдызларны», әмма Җиргә нык басып, шуна һәр шигыренә диярлек, Җир төшенчәсе килеп керә. Крестьянча уйлап, философча яза булып чыга түгелме соң? Гаташның «крестьяны» да бик нәзәкатьле басып тора белә. Безнеңчә, «улыма да мин җавап түгел, сорау калдырырмын» дигән Гаташның нәзәкатьле шигыре шулай туа. Бу очракта «затлы шигырь иясе» дип атаган Х. Миңнегуловның сүзләрен расларга гына кала.

«Сайланма әсәрләр»нең икенче томына кереш сүзне Р. Зәйдулла язган. Текстган шагыйрьнең эмоциональлеген, остазына чиксез ихтирамын тоймый калу мөмкин түгел. «Рәдиф Гаташ күзләре тирә-юньнән гел матурлык эзли»,—дип яза Зәйдулла. Беренче томда төрле елларда иҗат ителгән шигырьләр, лирик цикллар, шигъри хатлар урын алса, икенче том шагыйрьнең узган гасырның җитмеш-сиксән, туксанынчы еллар башы иҗатын иңләгән. «Шәрекъ чоры» шигырьләре дә биредә тупланган.

Гаташның Зөлфәт, Н. Гамбәр, Р. Сибат һ. б. шагыйрьләргә «шигырь юлы»н күрсәтүе билгеле. Шәкертләрнең остазга багышлап шигырьләр язуы да була торган хәл. Ә остазның талантлы шәкертенә багышлап шигырь язуы еш күзәтеләме? Юк,

дисәк, дөрес булыр кебек. Әмма, жылы сүзен әйтеп, «уңдырышлы туфрак»ны күрсәтеп, чәчмә формалы кинәш сүзен җәлләмәс чын остаз Гаташка бу гына аз. Икенче томга Зөлфәткә багышланган шигыре дә кергән. «Ике урман арасы» исемле шигырь ул. Белгәнебезчә, шагыйрь Зөлфәтнең 1995 елда шул исемдәге китабы чыккан иде. Зөлфәткә биредә «моннар баласы», «мәхәббәт баласы», «болан баласы» кебек метафоралар ява. Гаташ үз укучысына ышана, шәкерте шигырьләрен яратып укуы сизелә, яшьлектән шактый ераклашса да, шагыйрьнең алда гомере «барасы да барасы» икәнлегенә ышана. Ә менә Зөлфәтнең Гаташка багышланган шигыре бармы соң?

Зөлфәт 1991 елда остазына «Юл өзеге» исемле күләмле багышламасын яза. Гаташ биредә «егет-аксакал» образында бирелә. Әлеге жанр шигырьләренә хас булганча, анда соклану, горурлану хисләре ташып тора. Гаташ шәкертләре өчен «хәлфә», хәтта хәлфә генә дә түгел, «хәтфә хәлфә» булып кала. Шигырьдән күренгәнчә, шәкертләре алдагы тормышларында килеп туган ситуацияләрдән чыгу юлын Гаташ өйрәтүләреннән чыгып билгели. Зөлфәтнең «Син әйткәнчә, бөек идеаллар одеялга калды бит, хәлфә!»—дип ачынып әйтүен башкача аңлатып булмас кебек. Шунысы кызыклы: әлеге «яшьлек идеалын одеялга оттыру» детале С. Сөләйманованың Гаташка булган бер багышламасына да килеп керә. Шулай да Р. Миннуллинның хат стилендә язылган «Дуска җавап» шигыре әлеге бәхәсләргә нокта куя кебек:

*Ташыйсың син, түгеләсең—*
*Бер дә тынып тормас идең.*
*Ә бит күпме ташыса да,*
*Ярларына кайта Идел.*
*Кайта...*

(1973)

Гаташ үзенең «Әмәкәйдә «Гамлет» исемле шигырен тагын бер шәкерте Н. Гамбәргә багышлый. Шигырь авылдагы яшь укытучы егетнең, укучыларын ияртеп, кышын, алты чакрымдагы күрше авылга барып, кино карау фактын искә төшерә. Шигырьдә Гамбәргә турыдан-туры мөрәҗәгать итү юк, ул киногa баручы биш кешелек төркем эчендә генә бара. Ә менә Зөлфәтне Гаташ кисәтә: иҗат ул шәраб кебек: үзе ачы, үзе татлы, ахыргача эчә торган, дип. Ф. Гыйльминең дә иҗат перспективасы билгеләнә. Кыскасы, остаз шәкертләрен онытмаган. Икенче томга тупланган шигырьләрнең идеясен шагыйрьнең

*Чәчмәсәм дә, туган җирдә мин дә*
*Сөрдем, тырмаладым.*
*Беркөн киттем, буразналар калды*
*Һәм җир сызмаларым,—*

юлларына сыйдырып булыр иде кебек. Ә лирик геройның төп халәтен «Нәрсә булды безгә? Нәрсә булды күзгә? Килде жиргә быел ике яз!», җөмләләре чагылдыра.

Икенче томда шагыйрьнең «Яшьтәшләремә—шагыйрьләргә» исемле Р. Харис, Г. Рәхим, Рәш. Әхмәтҗанга багышламасы урын алган. Шигырь кырык беренче елда туганнарның кырык яшьлек мизгелен чагылдыруга юнәлдерелә. Гаташ кырык яшьтә елга башланган җирнең ераклашуына, җырларның гадиләшүенә игътибар итеп, кырык беренче елгы дигән сүзне ишетүгә, кешеләрнең сискәнеп куюлары турында яза. Кырык беренче елгыларны кешелек хәтере һаман да тере яра дип кабул итүен искәрә. Шагыйрь «без әтисез үссәк тә, улларыбыз әтиле» дип юана. Шагыйрьнең әлеге томында башкорт һәм Башкортстаннан чыккан шагыйрьләргә багышламалар да тупланган.

Р. Гаташ, әдәбиятта беренчеләрдән булып, Тукай-Зәйтүнә мөнәсәбәтләренә игътибар иткән шагыйрь. Аның берничә шигыре менә шул четерекле мөнәсәбәтләрне чагылдыра. Гомумән, Тукай темасы шагыйрь иҗатында шактый зур урын алып тора, аны берничә планда тикшерү юнәлеше булганлыктан, без Тукай кабере очында

Зәйтүнәнең Коръән укуы кебек нәфис детальнең бары тик Гаташка гына хас булуын әйтү белән чикләнәбез. Бары тик Гаташ иҗатында гына очратырга мөмкин булган сәнгатьле детальләр авторның тәнкыйди позициясен чагылдырырга сәләтле булып чыга. Шагыйрь кулланган детальләр төзәп атылган ук шикелле үткен дә, төгәл дә, сатирик төстә бирелеп, татарның үз сүзләре белән дә төзелә, чит телдән кергән сүз кулланып та ясалган була. Менә шуларның берничәсе: «анонимга поскан йөз», «мәкер магистры», «Иуда «таланты», «көнгә иезуитча ярашу», «плебей-әрсездәге узурпатор фәлсәфәсе» , «хаклык корбаны», «карьера дип хәйлә кору», «кеше башын таптап йөреп, кешелеккә хезмәт итү сәнгате», «үзеңнән дә ваграк интригаларның сине күмеп китүе», «өметсез эшнең оптимисты», «максат оппортунисты», «Иблис шайкасындагы кешелексез кеше тарафдары», «флюгер күк әйләнергә әзер тору», «ак перчаткалы кул пычраткан кәгазьләр». Күренеп тора, болар инде әзер образ, боларга комментарий соралмый.

«Сайланма әсәрләр»нең өченче томына кереш сүзне галимә Р. Ганиева язган. «Заманның шигъри пәйгамбәре» хезмәте Гаташ иҗатын дөнья әдәбияты традицияләре белән бәйләп аңлатуга нигезләнә. Р. Ганиева бик җентекләп шагыйрь иҗатын үткән, хәзерге һәм киләчәк белән бәйли. Лирик шигырьләрнең үзәк мотивларын ачыклый, мәхәббәт лирикасы үзенчәлекләренә игътибар итә. Бу том үз эченә газәл, робагый, мәдхия, касыйдә, лирик циклларны туплый. Кыскасы, бу том—Гаташның мәхәббәт лирикасы.

Мәхәббәт лирикасы шигырьләрендә лирик геройның авторга якынаюы, хәтта тәңгәлләшеп тә китүе күзәтелә. Гомумән, күңел лирикасында шәхси башлангыч, хисләр үзгәрү сизелеп тора. Шул сәбәпле лириканың бу төре иң эмоциональ жанрлардан санала. «Һәрнәрсәдән матурлык эзли» торган шагыйрьнең Шәрекъ әдәбиятына мөрәҗәгать итүе аңлашыла. Шәркый мәдәниятнең, рухи нигезләргә таянып, чиксез яшәешнең матурлыгын, гармониясен ачарга омтылуы мәгълүм. Мисал өчен Гаташның бер газәленә мөрәҗәгать итик, берьюлы ритмик буыннарны кисеп үтә торган цезуралар тәртибенә дә күз салыйк:

*Ал йөзең ни? / яшь җанныңмы / тәрәзе? //*
*Бал яккан битең! / татлыдыр / кәрәзе! //*

*Сипкелләрең / бал сакчысы— / корт күче... //*
*(Айга килгәнме / йолдызлар— / һәммәсе?!) //*

*Көн йөзле яр, / ал битле яр, / бал йөзлем! //*
*Гөл иреннәр, / ишетеп, көн / ләмәсме!—//*

*Пакь җаныңның / тәрәзе—бул / са йөзең, //*
*Иреннәрме— / хис, теләкләр / чәчкәсе? //*

*Унсигезгәчә, / кәрәзнең / ящрен саф /*
*Мөһрен саклаган, / рәхмәт, / корт әнкәсе!//*

*Ник бар дөнья / әрсез бүген: / бал сорый, //*
*Гашыйк Гаташ / турында ни / әйтәсең?!*

Газәлнең рифмасына игътибар итсәк, рифмалашкан сүзләрнең барысы да ачык иҗекле икәне күренә, тик соңгысы гына ябык иҗек. Ләкин, биредәге «ң» авазы укыганда барыбер йотылып, ачык иҗек формасын ала. Димәк, «ни әйтәсең» түгел, дөресе: «ни әйтәсе» булырга тиеш. Шулай ук икенче строфаның беренче юлы да ачык иҗеккә тәмамланып калган, ә башка строфаларда дөрес ябык иҗек күзәтелә. Бу газәлдә иң беренче күзгә ташланган үзенчәлек шул: рифмалашкан алты юлның өчесе өндәү билгесеннән булса, калган икесендә сорау, тагын икесендә сораулы өндәү күзәтелә. Сорау билгеләре дә, өндәү билгеләре дә риторик планда алынган. Ирексездән Р. Фәйзуллинның әле 1987 елда ук язылган фикере искә төшә: «Белдереп

үтәргә кирәк нәрсәләрнең тагын берсе шул: китапта өндәүләр, бигрәк тә сораулар бихисап күп. Ир уртасындагы кеше күп сорауларга үзе җавап та бирә алырга тиештер бит!». Күренекле шагыйрьнең кисәтүен эчтән генә «йотып», газәлләр укуны дәвам итик.

Хәзерге шигъриятьтә газәл жанры аеруча узган гасырның 90 елларыннан соң күпләп языла башлады. Татар шагыйрьләреннән бу өлкәдә иң уңышлы эшләүче ул—Р. Гаташ, тагын М. Мирза актив рәвештә газәлләр иҗат итүгә кереште. Дөрес, икеюллык бәет строфасы белән шигырь язу күп шагыйрьдә күзәтелә. Мәсәлән, Ә. Синугыл-Куганаклы иҗатынын күп өлешен икеюллык шигырьләр алып тора. Ул аларны хәтта аерым җыентык итеп тә чыгарды. Билгеле, газәл жанрының остасы—ни әйтсән дә, Рәдиф Гаташ. Аның хәтта газәл китаплары да берничә: «Бу—сина кылган догам: шигырьләр, газәлләр, робагыйлар», 1997; «Гөлләр су сорый: Сайланма лирика (1961—1998)», 1998; «Газәлләр», 2001; «Гамь шәрабе: шигырьләр, җырлар, газәлләр, робагыйлар», 2001; «Мәңгелек сусау (Хиссият аятьләре): шигырьләр, газәлләр, робагыйлар», 2005; «Сайланма әсәрләр»: 3 томда; кереш сүз авт. Р. Ганиева, 3 т.: Хиссият аятьләре, шигырьләр, 2009.

Исемлектән күренгәнчә, Гаташның мәшһүр Хафиз белән ярышырлыгы бар. Ә хәзер газәл тарихына күз салыйк. Газәл жанры «Газәлләр шаһы» дип исемләнгән фарсы шагыйре Хафиз Шәмсетдин исеме белән бәйле. Хафиз Ширази (чын исеме Шәмсетдин Мөхәммәт) 1320—1390 еллар тирәсендә яшәгән фарсы шагыйре булган. Ул күпсанлы газәл, касыйдә, кыйтга, робагый, мәснәвиләр язган.

Газәл герое үз теләге белән кавышырга, аларны аерып торган каршылыкны җиңәргә омтыла, әмма бу теләген беркайчан да тормышка ашыра алмый. Эмоциональлек, психологизм, фәлсәфи киеренкелек газәл жанрының серлелеген тәэмин итә торган сыйфатларның берсе булып кала. Гаташның мәхәббәт лирикасы шигырьләре нәкъ менә газәл жанрында иң биек ноктасына ирешә дигән нәтиҗә килеп чыга.

Шулай да шагыйрьнең мәхәббәт лирикасы Шәрекъ жанрлы шигырьләрдә генә көчле бирелә дип санау дөрес булмас иде. Тигез мәхәббәтнең югары ләззәт мизгелен ул «Яшәү җыры» силлабик шигырендә сала. Гаташның башка шигырьләре рухи эчтәлек белән сугарылган булса, нәкъ менә «Яшәү җыры» гашыйкларның физик халәтен сурәтләп бирүгә юнәлтелә. Бирелә шагыйрь интим хисләрне матур сурәт дәрәҗәсенә кадәр күтәреп тасвирлауга ирешкән. Эстетика принциплары да сакланган, бер генә тупас сүз дә кулланылмаган, шигырьне укыган кеше музейдагы «Йокыга талган гүзәл»не караган кебек хис кичерер дип ышанырга була.

Менә без татарның бик тә билгеле шагыйре, Тукай премиясе лауреаты Рәдиф Гаташның өч томлык «Сайланма әсәрләр»ен күзәтеп чыктык. Билгеле, Гаташның шигъриятен Көнбатыш һәм Көнчыгыш традицияләре буенча да күзәтергә, тема, жанр һәм форма яңалыгы буенча да өйрәнергә мөмкин. Шагыйрьнең верлибр һәм катнаш үлчәмдәге (полиметрик) шигырьләрен төзелеш, ритм һәм рифма системасы, поэтика һ. б.лар буенча тикшерергә дә була. Әмма нинди юнәлештән барсан да, бер фикергә юлыгасың: Гаташ шигырендә усаллык юк, ул кешеләргә рәнҗеми, заман белән ярышмый, базарга авышмый, өстәгеләргә елышмый гына шигырь дөньясында яши бирә. Такташ премиясе иясе Гаташ башка шагыйрьләр кебек публицистикага да, прозага да күчми, шигырьгә тугры шагыйрь булып кала бирә. Хәтта шагыйрьнең каләмдәшләре иҗатына бәя биреп язылган китабы да «Шигърият, синең хакка!» дип атала. Аның иҗаты—шигърияте, халыкчан. Үзе дә халык тарафыннан якын ителә торган шагыйрь.

# ТОРМЫШ СӘХНӘСЕНДӘ

## КАМИЛ КӘРИМОВНЫҢ «КОМ СӘГАТЕ» РОМАНЫН УКЫГАННАН СОҢ

Әсәр әдәби камиллеккә ирешкән очракта үзенең авторына охшаш була. Чыннан да, әсәрдә наданның наданлыгы, хөсетнең хөсетлеге, ялагайның ялагайлыгы, ниһаять, яхшының яхшылык эзе барыбер сурәтләнеп кала. Китап язучы һәр очракта үзенең кимчелекләрен көче житкән кадәр яшерергә, уңай якларын гына күрсәтергә тырышып эшли. Нәкъ шул яшерергә тырышуы фаш итә дә инде язучыны.

Бу фикер миндә Камил Кәримовның «Ком сәгате» исемле китабын укыганнан соң башыма килде. Моңа кадәр Камилнең романын журнал вариантында укыганым юк иде. Укыйсы килүемнең сәбәбе дә шактый сәер иде—«Казан утлары» редакциясендә эшләүчеләрне өйрәнү язучыга шактый кирәк нәрсә.

Башкаларга да шулаймы икән, ярты сәгать сөйләшү миңа журналның еллык тупланмасын карап чыгуга тиң мәгълүмат бирә. Бер керүемдә журналда күптән түгел генә эшли башлаган Камил Кәримовка юлыктым. Өстәл артында тыныч кына эшләп утыра. Әңгәмә барлыкка килгәч, эшеннән туктап, тыңлап тора башлады. Егетнең тыңлавы җәлеп итте мине. Безнең чорда сирәк очрый торган әдипләрчә анализлап, фикерләрне мыегына урап тыңлау йөзенә чыккан иде аның. Минем тарафтан бу инде чып-чыннан дуамал беркатлылык: «Бу кешенең әсәрләре житди булырга тиеш»,—дигән фикергә килдем мин һәм аның китабын сорап үзенә хат яздым. Укучы ачыклар—ялгышмадым шикелле...

***

Иң беренче күзгә ташланган нәрсә—китапның бизәлеше.

Соңгы елларда татар рәссамнәре, Мәскәү «даһиләре»нең кимсетүләренә үч итеп, Аурупа ысулында иҗат итә башладылар. Рәссам И. Нәфиев плагиатлыкка барып житмәсә дә, тулысынча Марк Шагалны кабатлаган. Әгәр китапның авторы Камил Кәримов булмаса, бәлки шушы бизәлеш килешкән дә булыр иде. Бу очракта әсәрләрнең эчтәлеге белән иллюстрация арасында капма-каршылык барлыкка килгән.

***

Каләм зәхмәте белән хасталанып алган кеше белә, әсәргә исем табу иҗатның иң җаваплы, катлаулы мәсьәләсе. Дөрес, мөгез чыгарырга көйләнгән исемне әмәлләве әллә ни катлаулы түгел. Бер-ике сүзгә әсәрнең эчтәлеген сыйдыра алган исемне табу гаять катлаулы!

«Ком сәгате»... Бу прибор борынгы Бабилда уйлап чыгарылган булса да, безгә ул борынгы греклар аша килеп кергән. Уникегә бүленгән цифрблаттагы вакытны күзәтү жиңелрәк булса да ком сәгате (клипсидра) кеше гомеренең кире кайтмаска туктаусыз узып торуын төгәлрәк күрсәтеп тора. Әле күптән түгел генә гомер—ком шарны тутырып тора иде. Карасаң, аның урынында бушлык кына калды...

Романны укып чыкканнан соң ирексездән шуны тоеп аласың: күптән түгел генә әсәрнең персонажлары, аларның куанычлары белән шатланып, кайгы-хәсрәтләрен уртаклашып хыял дөньясында яши идең. Алар кая китте? Алар сәгать комы шикелле юкка чыкты—үзеңнең шәхси ыгы-зыгыларың тынгысызлыгында калдың...

Камил Кәримов романын кисәкләргә бүлеп, һәр бүлегенә аерым исем биргән. Ул исемнәр татар фольклорындагы табышмакларны хәтерләтә. Алар укучыны эчтәлеккә яшерелгән яшәеш серен ачарга чакырып, сине кызыксындырып тора. Табышмак феномены белән генә чикләнеп калмыйча, халкыбызның зур горурлыгы саналган мәкальләрне, тапкыр әйтемнәрне хәтерләтә. Белмим, автор аны Нәкый Исәнбәт

жыйган томнардан сайлап алганмы, әллә халык авызыннан ишеткәнме? Соңгы чиктә исемнәрне автор үзе иҗат иткәнгә охшый. Бу үзенчәлекне әдәбият галимнәре игътибарсыз калдырмаслар дип ышанасы килә...

«Инештән су эчмиләр...» Ә бит мин үсмер чакта гына да инеш суын тәмләп эчәләр иде. Өч миллиард тонна җир канын суыру, минерал ашламалар инешләребезнең суын эчмәслек дәрәҗәгә җиткереп пычратып ташлады.

Әсәр Татарстан җирендә бораулап су чыгаруга багышланган.

Ислам дине суны изгеләштерә. Дин мөселманнарны су хәзинәсенә ихтирам белән карарга өйрәткән. Роман авторының шушы үзенчәлекне сурәтләргә көче җиткән. Пушкинның шигырендә сурәтләнгән Бакчасарай фонтанын күрү белән урыслар: «Кая соң моның фонтаны?»—дип аптырап калалар. Су тамчысының күз яшен хәтерләткән, тамчы тавышының бөек моңын аңларга аларга бөеклек баскынлыгы комачаулый...

«Мактап арыгач, яманласаң да була.» Бу исемдә чорның төгәл метафорасы. Картларның «теленне тый», дип кисәтүләре минем яшьлек чорымда «кешене мактама да, хурлама да—кулыңнан килгән кадәр реаль ярдәм генә ит» мәгънәсендә яңгырый иде. «Җаны төшеп калды», «Кичә яраган... бүген ярамый», «Ата казына мыек чыккан», «Әти хатыны янына».

Кисәк исемнәренең берсен тикшереп карыйк. «Әти хатыны»—әни булырга тиеш бит. Элек чыннан да шулай булган. Әтиеннең хатыны бер генә булмаган очракта да аның беренчесен «дәү әни» дип атап йөрткәннәр. Кәримов «әти хатыны»н бүгенге көндә гаиләләрнең нигезе какшавын, хатын алыштыруларның, никахсыз яшәүләрнең ишәюен аңлатыр өчен кулланган. Бу Камил Кәримов иҗатының үзәк бер ысулы, аның язу үзенчәлеге. Шушы алымны романны укый башлау белән тоеп аласың. Үзенчәлек моның белән генә чикләнми. «Ком сәгате» авторының күзәтүеннән чынбарлыкның әһәмияткә лаеклы берәмлекләре читтә кала алмый. Кәримовның әдәбиятыбызга керткән яңалыгы җитди игътибарга лаек. Урыс телендә киная ярдәмендә сурәтләү притча дип атала. Татар әдәбиятында моңа кадәр бу жанр юк иде шикелле... Роман тиклем күләмле әсәрне әлеге жанр кысаларына сыйдыру һәм шартына туры китереп сурәтләү өчен әдәби осталыкка ия булу кирәк. Авторыбыз моңа чынлап торып ирешә алган.

***

Әдәбиятта әсәрнең эчтәлегенә карап аның өстәмә жанрын билгеләү гадәткә кергән. Гариф Ахуновның әсәрләре нефть чыгаручыларга, Әхсән Баянның «Ут һәм су» исемле романы гидроэлектростанция төзүчеләргә багышланган иде. Бу авторлар партия таләпләренә буйсынып, социалистик ярышның даһилеген, хезмәт героикасының данын сурәтләргә тырышканнар. «Ком сәгате»ндә хезмәт адәм баласының көнкүрешендәге гаилә кору, тамак туйдыру, тораклы булу, нәсел калдыру һәм яшәешнең чиктән тыш мөһим мәсьәләсе—җәмгыятьтә көн күрү өчен кулай урын эзләп табуның бер өлеше, шул мәшәкатьләрнең берсе итеп сурәтләнгән.

Бу язмам белән мин әдәбият галимнәренең өлешенә керергә теләмим. Әсәрнең эчтәлеген сөйләүне дә өстемә алмыйм, чөнки бу эшне авторның үзеннән остарак башкару мөмкин түгел.

«Ком сәгате»нең персонажлары Татарстан җиреннән бораулап су чыгара. Гарәп сәяхәтчеләренең Идел Болгарстанын, соңрак Казан ханлыгын сурәтләгәндә аның җирендәге мул сулы зур елгалары, чиста инешләре, көмеш чишмәләренә һәр язмада диярлек сокланмыйча калмаганнар. Кайда соң ул сулар? Ни сәбәп шул мул сулы илдә җирне бораулап артезиан коелары ясау мохтаҗлыгы туган? Шушы сорау әсәрне укыганда тынгы бирмичә колагымда туктаусыз ишетелеп торды...

Гомеремнең зур бер өлеше су сахрасында үткәнгәме, мин Камил Кәримовның су стихиясен эзлекле, тирән мәгънәле итеп сурәтли алуына сокланып укыдым. Әсәрнең башыннан ахырына кадәр сүз эш процессы, хезмәт турында бара. Шуңа карамастан, автор совет чорында әсәрдән әсәргә кабатланып торганлыктан саруларны кайнатып бетергән «производственная тема» шаблонында бирмәгән. Әсәрнең геройлары да социалистик ярышның роботлары түгел. Алар тормыш-көнкүреш аренасында язмыш билгеләгән катлаулы рольне уйнаучы реаль шәхесләр.

Роман утыз ел эчендә авыл халкына өч йөздән артык артезиан коесы казыган су

бораулау остасы Фазыл Шәмсетдиновны пенсиягә озату мәшәкатьләреннән башланып китә. Әгәр бу хәл Көнбатыш илләре, яисә Австралия, Яна Зеландия шартларында булса Фазыл Шәмсетдинов: «Ниһаять, шушы куанычлы көнгә килеп житә алдым. Хәзер инде эш белән чиләнмичә, үз иркемә рәхәтләнеп яшәп калыйм. Минем кайсы илләрне, Жир шарының кайсы урыннарын күргәнем юк? Сәяхәткә йөрүне Яна Каледониядән, яисә Фиджи атауларыннан башлап жибәрсәм ничек булыр?»,—дип турфирма белән элемтәгә керүдән башлар иде. Япониядә пенсиягә чыккан кеше ял итү турында һич тә кайгыртмый. Анда хезмәт коллективы ял вакытында үзләренең пенсионерларын да ияртеп баралар. Фазыл белә, Жир шарындагы иң бай, нефть сатудан триллионнарга житкән «яшел акча» туплаган илдә пенсия акчасына кешечә яшәү мөмкин түгел.

Ул моны яхшы аңлый. Кадрлар бүлеген житәкләүче Зөмәйрәгә ул үзенең киләчәген менә ничек сурәтли:

—Пенсионер дигәч тә—аягым-кулым исән, сау-таза, шөкер. Менә күрерсең, мин әле икенче профессия үзләштереп, яңадан яшь башлыйм.

Автор менә шушындый катлаулы мәсьәләләрне диалоглар ярдәмендә, яисә персонажларның гамәлләре аша укучыга житкереп бара. Бу ысул һичшиксез Камилнең уңышларының берсе.

Китап уку культурасына, матур әдәбиятның үзенчәлек серен аңлаучыга Кәримовның иҗат ысулы татар әдәбиятын басып киткән ясалма, ихахайлы юмор түгел икәнлеге аңлашыла торгандыр? «Ком сәгате»ндәге тыштан көлке генә тоелган проблемаларның нигезендә Рәсәй империясе шартларында тормыш-көнкүреш шыксызлыгы, хезмәтнең чиктән тыш арзан бәяләнүе, адәм баласының кадерсезлеге җәйрәп ята. Совет чорында язылган әсәрләрдә шушы проблемаларның яктыртылмый калуы аларның бәяләрен, тормыш чынбарлыгыннан читтә торуларын исбатлый иде.

Су скважиналары бораулау бригадасы авылдан авылга, районнан районга күчеп эшләп йөри. Шушы мөмкинлектән файдаланып роман авторы Татарстанның табигатен, туган якның гүзәл ландшафтын истә калырлык итеп сурәтли алган.

Авторның төп максаты урбанизация фаҗигасенә бирешмичә исән кала алган татар авылларындагы тормыш-көнкүрешкә багышланган булса да яшәеш аренасы киң диапазонда, милләтнең туктаусыз югала торган өмет-багланышлары фонында сурәтләнгән. Мина «Ком сәгате»ндә анализланган егет белән кыз, ир белән хатын арасындагы мөнәсәбәтләр, гаилә кору, гыйффәтлелек, чын мәхәббәтнең билен сындырган гламур секс базары, шушы чиктән тыш интим, акыл белән аңлап булмаслык тойгылар чытырманы каплаган мөнәсәбәтләрнең әсәрдәге садә сурәте ошады. Матурлыкка өндәү бүгенге көн әсәрләрендә һәрдаим күләгәдә кала килде.

***

Коммунистлар партиясе игълан иткән әхлак кодексын хәтерләүче бармы икән? Гасырлар буе женесара мөнәсәбәтләрнең, гаилә тормышының нигезен саклап торган шәригать кануннары да базар мөнәсәбәте шартларында күзгә күренеп зәгыйфьләнде.

Язмамның сюжетыннан читкә тайпылмыйча гына гаилә җылысында яңа буын тәрбияләү кануннарын җимерә башлаган сексуаль хөррият фаҗигаләрен искә аласым килә. Бу мәсьәлә «Ком сәгате»ндә шактый уңышлы, төрле яктан сурәтләнгән. Монда үсмерлектән яңа гына житкән кыз дәрәҗәсенә атлап килгән Әлфинәнең саф мәхәббәте, Фазылның шул җир йөзендәге иң зур, иң татлы бүләктән колак кагу фаҗигасе. Әмирнең хатыны Суфияның кияүгә чыкканчы кулдан кулга тапшырылып, азгынлыкта яшәвен ачыклагач олыгайган көнендә ташлап китүе—боларның барысы да укучыны ышандыра алырлык дәрәҗәдә сурәтләнгән.

Бүген матур әдәбиятыбыз дөньякүләм кризис чолганышында калды. Туган телебездә язылган әсәрләрне ишәйтү, китап укучыны, журнал әбунәчеләрен саклап калу өчен аяусыз көрәшергә туры килә. Менә шундый шартларда «Ком сәгате» дәрәҗәсендәге әсәрнең барлыкка килүе тел сәнгатенә карата өмет уята.

**Миргазиян ЮНЫС.**
*Мәскәү.*

# ГОМЕР БАЛКЫШЛАРЫ

ФОАТ ГАЛИМУЛЛИНГА 70 ЯШЬ

Зыялылык һәм затлылык кебек күркәм сыйфатларны кеше каян ала? Алу бер хәл... «Тормыш» дигән озын юлның катлаулы һәм текә баскычларын үткәндә бу сыйфатларны югалтмыйча, каралтмыйча ничек саклап калып була?

Сабый бала Фоат күңелендә сугыш каһәрле ике ягы белән истә калган. Берсе—ятимлек, икенчесе—ачлык. Өч бала белән тол калган Нурхәят апа гаиләсенә дә әнә шул ике золым бергә килеп керә. Ләкин авырлыклар никадәр зур булмасын, шушы золымнарны көч-хәл белән җиңә-җиңә, өч ир-бала үсеп аякка баса.

Фоат 1952 елда Арпаяз башлангыч мәктәбен, аннан 1955 елда Пычак җидееллык мәктәбен тәмамлый. Озын буйлы, арык гәүдәле бу малайның мәктәптә уку елларында ук төрле яктан сәләте барлыгы күренә. Татар теле һәм әдәбияты укытучысы Гөлсем апа үзе ач булса да тавышы көр булган малайның матур итеп шигырьләр укуына игътибар итсә, 1957 елда Кукмара районында Татарстан яшьләренең Беренче фестивалендә җыр белән катнашкан яшь егетне район мәдәният бүлеге мөдире, сугыш каһарманы Сәет Сәгыйтев күреп алып, «синең урының мәдәният юлында» дип хәер-догасын бирә һәм аны Арпаяз авылы клубы мөдире итеп билгели.

1967 ел Фоат Галимуллин өчен борылыш елы була. Инде төрле фестивальләрдә катнашып урыннар яулаган, әзме-күпме үз исемен мәдәният әһелләренә ишеттерү бәхетенә ирешкән, Алабуга мәдәният-агарту училищесын тәмамлап, «халык театры режиссеры» белгечлеге алган, солдат хезмәтен татыган, өйләнеп гаилә корып җибәргән Фоат Галимуллин Татарстан радиосындагы дикторлар конкурсында катнаша һәм җиңеп чыга. Монда ул Камал Саттарова кебек тәҗрибәле диктор белән бергә эшләү, Габдулла Шамуков, Госман Әхмәтҗанов, Мәрьям Арсланова, Айрат Арсланов, Ибраһим Гафуров кебек сәхнә һәм сүз осталарының матур, файдалы киңәшләрен ишетү бәхетенә ирешә. Бигрәк тә адаш абыйсы Фуат Халитовның ярдәмен нык тоя.

1969 елда Мәскәү радиосында өч айлык стажировка үткәндә, беренче категорияле диктор Фоат Галимуллинга исеме бөтен илгә мәгълүм Юрий Левитан белән якыннан аралашырга, аннан дәресләр алырга һәм бу сирәк тавышлы талант иясенең үзенә карата уңай мөнәсәбәтен тоярга туры килә. Бервакыт Юрий Борисович шәкертләре арасында рәсми хәбәрләрне үзе сыман итеп уку буенча ярыш оештыра, ә анда татар егете Фоат Галимуллин җиңеп чыга! Остазы шуның өчен ана Останкино башнясында урнашкан «Күкнең җиденче каты» ресторанына чакыру билеты бирә.

Радиода эшләгән елларында Фоат Галимуллин Казан педагогика институтының тарих-филология факультетын тәмамлый, ә 1974 елда әдәбият кафедрасына укытучы итеп эшкә алына. Аннан—декан урынбасары вазифасы, аспирантура, филология фәннәре кандидаты булу, факультет деканы, докторлык диссертациясе, профессор исеме, кафедра мөдире...

1990 елдан СССР һәм Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, ике срок рәттән Татарстан Язучылар берлеге рәисе, Татарстан Дәүләт Советы депутаты... Күп инде алар санап китә калсаң...

1999 ел. Җәмгыять инде дистә еллап күчеш чорында яши. Шушы елның май аенда башланган Татарстан язучылары корылтае өзелеп калды. Буталчык һәм авыр чорда берлекне әйдәп барырлык җитәкче сайланылмады. Язучылар үзләре дә шактый

кыен хәлдә. Чөнки озакка сузылган тартышу беркем файдасына да сөйләми иде. Тиз арада татар әдәби хәрәкәтенең башында тора алырдай зат кирәклеге кискен рәвештә килеп басты. «Ризалашу—синнән, сайлау—бездән!» диләр Фоат Галимуллинны бу житди эшкә кодаларга дип «Аккош күле»нә килгән язучылар. Үзенә йөкләтелергә тиешле эшнең бөтен житдилеген күз алдында тоткан Фоат Галимуллин тагын бер зур сынау алдында кала. Бик күп могтәбәр кешеләрнең күзе өмет һәм теләктәшлек белән аңа төбәлгән. Ничек шуны аңламыйсың да акламыйсың инде?!

Бер срокка сайланган Фоат Галимуллин 6 ел дәвамында Татарстан Язучылар берлеге рәисе вазифасын башкара. Шуның өстенә якташлары—Кукмаралылар—Татарстан Дәүләт Советына депутатлыкка сайлап куялар. Дәүләт Советы сессиясендә исә Фән, мәгариф, мәдәният һәм милли мәсьәләләр буенча даими комиссиянең әгъзасы буларак, аңа тагын бер эш йөкләтелә. Тарта торган йөк никадәр генә авыр булмасын, Фоат Галимуллинның кешеләр белән эшли белү тәжрибәсе, халык күңеленә якынлыгы, әдәбият һәм аның фәнен тирәнтен өйрәнгән һәм бу өлкәдә үзенең фикере, кыйбласы булуы, аңа могтәбәр язучыларыбызның һәм якташларының ышанычын акларга, үзенә тапшырылган вазифаны намус белән үтәп чыгарга ярдәм итә.

Алып бара торган хезмәтенең киң колачлы булуы, әлегә кадәр дә әдәбият дөньясында танылган галимнең фәнни һәм ижади эшчәнлеген тагын да кинәйтә, тагын да камилләштерә. Татар әдәбияты тарихының төрле чорларын чагылдырып язган күп санлы фәнни хезмәтләре (аларның саны алты йөздән артык), шулар арасында күренекле язучы Гариф Ахунов ижатын яңа күзлектән чыгып бәяләгән «Инешләр Иделгә кушыла» китабы, 20-30нчы еллар татар әдәбиятында эстетика кануннарының һәм социологизм таләпләренең үзара мөнәсәбәтен тикшереп язган «Эстетика һәм социологизм» дигән монографиясе, төрле чорларда яшәп ижат иткән аерым язучыларның ижатын өйрәнеп-тикшереп язган «Офыклар алдан күренә» мәкаләләр жыентыгы, «Мәгъсүм Насыйбуллин: язучы турында биобиблиографик китап» кебек хезмәтләре булган галим тагын бер житди китабы «Эзләнү китабы» белән жәмәгатьчелекне куандырды. Әлеге китапта автор татар әдәбиятындагы күп кенә катлаулы мәсьәләләргә үз фикерен белдерә, яңа гасыр чигендә әдәби хәрәкәтнең үзенчәлекләрен билгели. Әлеге китап, яңа гасыр башланган чорда язылып, татар ижтимагый аңы каршында торган шактый катлаулы, буталчык мәсьәләләргә күпмедер дәрәжәдә жавап та иде. Галимнең «Эстетика һәм социологизм» китабында вульгар социологизм мәсьәләсе 20-30нчы еллар әдәбиятына бәйле тикшерелсә, «Эзләнү китабы»нда исә бу күренешнең ике гасыр чигендәге әдәбияттагы роле ачыклана. Автор игътибар үзәгенә татар әдәбиятының башка әдәбиятлар белән бәйләнеше, халкыбызның бөек шәхесләре һәм татар милләтен күтәрүдә аларның роле, тел, сөйләм культурасының бүгенге халәте, яшь буынга әдәбиятны өйрәтү мәсьәләләрен дә куйган. Гомумән алганда, галимнең ныклы принципка корылган фәнни хезмәтләре татар әдәбияты белеме фәнендә житди урынны алып тора.

Алда язганыбызча, торгынлык чорыннан соң туган демократик үзгәрешләр бөтен тармакларга да үтеп керде. Янарыш чорында алгы сафта булып, вәзгыятькә муафыйк яңа фикер үткәрергә тырышу һәрбер кешедән дә килә торган эш түгел ул. Галимебезнең мәктәпләрдә татар әдәбиятын укыту буенча иң кыен вакытларда яңа дәреслекләр, уку әсбаплары, методик кулланмалар төзүен батырлык дип кабул итәргә кирәктер.Чөнки бу елларда кискен булып килеп баскан «әдәбиятны ничек укытырга, нинди методлар белән укытырга һәм ни өчен укытырга?» дигән сорауга Ф. Галимуллин педагог һәм методист, сүз остасы һәм галим буларак, беренчеләрдән булып жавап бирде. Аның авторлыгында 1987 елны IX сыйныф өчен төзелгән туган тел һәм әдәбият дәреслеге,1991 елда X сыйныф өчен туган тел һәм әдәбият дәреслеге,1995 елда рус мәктәпләренең VI сыйныфында укучы татар балалары өчен дәреслек—хрестоматия,1995 елда татар урта гомуми белем мәктәбенең XI сыйныфы өчен дәреслек, 2000 елда X сыйныф өчен дәреслек, 2001 елда шундый ук мәктәпләрнең VII сыйныфы өчен дәреслек төзелде.

Фоат Галимуллинның мәктәпләр белән бәйләнеше дәреслекләр төзү белән генә чикләнми. Озак еллардан бирле ул үз кафедрасы укытучы-галимнәренең мәктәптә

педагогик практика белән житәкчелек итүен күзәтүдә тота, даими рәвештә үзе мәктәпләргә чыга, төрле мәктәпләр базасында фәнни конференцияләр, очрашулар үткәрүдә катнаша.

Мәгълүм булганча, соңгы елларда сүз сәнгате шактый аксый. Бу бер татар мәдәниятенә генә кагылмый. Еш кына радио, телевидениедән тапшырулар караган-тыңлаган вакытта элеккеге дикторларны искә төшерәсең. Урысларның Левитаннары булмаган кебек, татарларның да, нишләптер, Галимуллиннары, йә булмаса, алар дәрәҗәсендәге бүтәннәре (Ф. Галимуллинның укучысы Тәлгать Хамматшинны санамаганда) юк. Бу нәрсә? Кешеләрнең, шул исәптән рухи байлык ияләре—мәдәният юлындагыларның да—сүз сәнгатенә, аның нечкәлекләренә, нәфисләкләренә битарафлыгымы? Әллә бөтен нәрсәне дә, шул исәптән телне дә, коммерция кебек җансыз, рухсыз, нурсыз күренешләрнең җинүеме?

—Дикторлык элек бик житди һәм кирәкле һөнәрләрнең берсе иде. Диктор турыдан-туры халык белән аралаша, хакимият карашларын дөрес һәм ышандырырлык итеп халыкка житкерә. Ә монда инде тавышның көче, аһәңе әһәмиятле рольне уйный. Башка һөнәр ияләренә үз эшләрен башкарганда махсус бурычлар куелган кебек, безнең һөнәргә дә таләпләр куела иде. Бигрәк тә турыдан-туры эфирга чыгып сөйләгәндә җаваплылык нык арта. Хәзергеләр кебек теләсә нәрсә сөйләп утырып булмый. Мин хәзерге алып баручыларның күбесен кабул итеп бетерә алмыйм,—ди Фоат Галимуллин.

Килешәм, килешми мөмкин түгел, дикторлык эшенең бөтен нечкәлекләрен белгән Фоат Галимуллинга түгел, әле безгә дә, авызы әйткәнне колагы ишетми торган, теленә салынып сөйләп утыручыларны тыңлап утыруы җиңел түгел.

Фоат Галимуллинның бу юнәлештәге эшчәнлеге дә хуплауга лаек. Аның сәнгатьле уку буенча басылган «Укучыларны сәнгатьле укуга өйрәтү», «Мәктәптә сәнгатьле уку» дигән кызыклы һәм житди хезмәтләре бүгенге яшьләрне сүзнең серләренә, нечкәлекләренә өйрәтүдә әһәмияткә ия.

Чорыбыз шагыйре Ркаил Зәйдулла үзеннән алда яшәп иҗат иткән талантлы шагыйрьләрнең күп кенә сыйфатларын туплаган каләмдәше Мөдәррис Әгъләмов истәлегенә кызыклы буыннар чылбыры төзи: Мөхәммәдъяр—Акмулла—Тукай—Туфан—Мөдәррис.

Фоат Галимуллин—укытучы, методист, әдәбият галиме, диктор, җәмәгать эшлеклесе... Әгәр дә санап киткән өлкәләр буенча аерым-аерым шундый буыннар чылбыры төзүче булса, һичшиксез, ул чылбырның һәрбер очын Фоат Галимуллинга китереп тоташтырыр иде. Бу өлкәләрнең кайсысын гына алсак та, ул үзен чын остаз, талант иясе итеп күрсәтте. Ә андый затлар тормышыбызда күп түгел бит. Ләкин алар булганнар, бар һәм тагын да булырлар...

Милләтебезнең фидакарь инсаннары... Гадәти тормышта ниндиләр алар? Кулымда күренекле әдип Рафаэль Сибатның «Көлдән күтәрелгән гөлләр» дип аталган китабы. Дәһшәтле 1941 елда туып, сугыш уты көйдергән сөремле-көлле туфрактан гөлләрдәй балкып күтәрелә торган көчле рухлы шәхесләр турында сөйләнелә әлеге китапта. Канлы елларда дөньяга килеп, дагалы итекләр сытарга-изәргә маташканда догалы мизгелләр коткарып калган өч кеше язмышында халкыбызның могҗизалы да, аянычлы да тарихы чагыла. Шул өч кеше арасында—Фоат Галимуллин. Фоат Галимуллин күренекле әдибебез Мөхәммәт Мәһдиев кебек көлле туфрактан күтәрелгән. Ә көлле туфрак—ул бәрәкәтле туфрак. Көлле туфрак начар уңыш бирә алмаган кебек, китапта язмышлары сурәтләнгән төрлесе төрле тармакта эшләгән өч зат та бу тормышта үз урыннарын гына табып калмаганнар,ә кылган изге гамәлләре аша башкаларга төшкән авырлыкларны да күтәргәннәр, авыр минутларда төрле кешеләргә төрлечә ярдәмгә килгәннәр.

Галимулла бабасының намаз-ниязлы нигезендә догалы мизгелгә туры килеп тугангамы, Фоат ага—чын-чынлап бәхетле язмышлы кеше. Чөнки ул житмеш яшен тутырган көннәрдә дә әдәбият фәненең алга китеше, татар халкының киләчәк язмышы өчен уйланып, борчылып, яшь вакытындагы тырышлыгы белән армый-талмый эшләп йөри. Шул көннәрдә генә, аның житди күзәтүләренең тагын бер нәтиҗәсе булып, XX гасыр идеологиясе басымы астында татар язучыларының проза

өлкәсендә сәнгатьлелек өчен көрәшләрен яктыртып язган «Татар әдәбиятында эстетик эзләнүләр» дигән китабы табадан төште.

Ул бүген дә Татар дәүләт-гуманитар университетының биш профессор һәм алты доцентны берләштергән татар әдәбияты һәм методикасы кафедрасын җитәкли. Укыткан шәкертләре аның кул астында докторлык, кандидатлык диссертацияләре язалар һәм аларны уңышлы яклыйлар.

Ф. Галимуллин заман үзгәрешләренә, көн таләпләренә туры китереп, татар һәм рус мәктәпләре өчен дәреслекләр, уку әсбаплары, методик кулланмалар төзи. Төзегән китапларын Татарстан мәктәпләрендә генә түгел, башка төбәкләрдә дә укытучылар көтеп ала. Укытып чыгарган меңләгән шәкертләре исә үзләре төрле дәрәҗәдәге мөгаллимнәр рәвешендә милләтебез балаларына аң-белем, тәрбия бирүдә аның юлын дәвам иттерәләр.

Ул бүген дә сүзе һәм эше белән халык арасында. Галилеге белән гадилеген, гаделлеге белән таләпчәнлеген бергә кушып, халыкка, фәнгә хезмәт итү юлында. Ул—татарлар яшәгән һәрбер төбәктә билгеле, үз, якын.

Ә без исә, үз чиратыбызда, милләтебезнең йөз агы булган затлы шәхесне күркәм юбилее белән котлап, аңа исәнлек-саулык, озын, куанычлы гомерләр телик.

**Әлфинур НӘҖИПОВА-ЗИННӘТУЛЛИНА,**
*ТДГПУ доценты.*

## Хөрмәтле укучыларыбыз һәм авторларыбыз!

**Журналыбыз белән даими танышып баручылар белә булыр: бездә «Казан утлары» архивыннан» дигән рубрика бар. Бу сәхифә байтак еллар гамәлдә булса да, элегрәк елларда материаллар сирәгрәк чыга иде. Соңгы вакытта «архив» активлашты, журналның һәр санында диярлек татар тарихыннан иҗтимагый әһәмияткә ия булган фотосурәтләр басылып килә. Теләгебез—алга таба да рубриканы кызыклырак һәм мәгънәлерәк итү. Бу эшне уңышлы дәвам итү өчен сезнең дә булышлык кирәк. Сезгә мөрәҗәгать-гозеребез шул: үзегезнең шәхси, гаилә альбомнарында яки оешма-учреждение архивларында сакланган кызыклы, тарихи-иҗтимагый кыйммәте булган (әдәбият һәм сәнгатебезнең мәшһүр шәхесләре, истәлекле мәдәни вакыйгаларга караган күренешләр, Казан һәм Татарстан тарихын яктырткан сурәтләр һ.б.) фоторәсемнәрне безгә юлласагыз икән! Шул рәсем турында аңлатма-комментарийларның булуы да шарт, әлбәттә. Без аларны журналда файдаланганнан соң, кире ияләренә кайтара алыр идек.**

**Әйдәгез, кадерле укучылар, мөхтәрәм милләттәшләр, кайдадыр киштә-шкафларда, альбом-папкаларда ябылып яткан истәлекле ядкарьләрне яктыга чыгарыйк, халкыбызның рухи елъязмасы сәхифәләре булып киләчәк буыннарга хезмәт итсен алар! Сездән кызыклы фотоматериаллар көтәбез.**

## Исмәгыйль Гаспринскийның тууына 160 ел

Исмәгыйль Мостафа улы Гаспринский (Гаспралы, Гасфарый, 1851—1914)— күренекле кырымтатар мәгърифәтчесе, әдип, журналист һәм җәмәгать эшлеклесе. Ул XIX гасыр ахыры һәм XX гасыр башында бөтен дөнья төрки-татарлары һәм мөселманнарының иҗтимагый фикере үсеше тарихында янарыш-җәдитчелек идеяләрен таратучы һәм шул максатка армый-талмый хезмәт иткән фидакяр зат. Гаспринскийның төп максаты, гомумиләштереп әйткәндә, барлык төркиләрне бер милләт итеп оештыру һәм гомуми уртак тел булдыру, замана таләпләренә һәм дөньяның фәнни-техник казанышлары шартларына яраклы тирән белемле яшьләр әзерләрлек мәктәп-мәгариф системасын гамәлгә ашыру.

Исмәгыйль Гаспринский Кырымдагы Бакчасарай шәһәрендә 1883 елда «Тәрҗеман» исемендәге гомумтөрки газета нәшер итә башлый һәм барлык фикерләрен халыкка матбугат аша тарата. Бу газета озак еллар ике телдә—төрки-татар һәм русча нәшер ителгән. Гаспринский шулай ук дәреслекләр һәм башка төр китаплар да язып бастыра, бүтән газета-журналлар нәшер итә. Арадан иң абруйлысы—«Тәрҗеман» газетасы Россия империясендә яшәгән төрки халыклар өчен дистә еллар дәвамында төрки телдә нәшер ителгән бердәнбер вакытлы матбугат органы вазыйфасын үтәгән. Бу газета 1918 елга кадәр өзлексез чыга. Гаспринский вафатына кадәр аның мөхәррире була. Татар журналистикасына нигез салган әдипләр, мөхәррирләр һәм наширләр «Тәрҗеман» газетасы белән тыгыз хезмәттәшлек итеп, шунда чыныгу алганнар һәм сыналганнар.

1905 елда Идел буендагы татар матбугаты беренче адымнарын Гаспринскийның «Тәрҗеман»ы үрнәгендә башлап җибәрә. Идел-Урал буе татарларының беренче дулкын матбугатында, нигездә, «Тәрҗеман»ның йогынтысы көчле булган. Тел ягыннан һәм газетаның бизәлеше, материалларның бирелеше, рубрикалар кебек җәһәтләрдә татар газеталары башлангыч чорда «Тәрҗеман»ны хәтерләткәннәр һәм, берникадәр, аның дәвамчысы булганнар. Ә «Тәрҗеман», үз нәүбәтендә, Европа һәм Төркия вакытлы матбугатының бай традицияләрен файдаланган.

XIX гасыр ахырында И.Гаспринскийның мәгърифәтчелек идеяләре тәэсирендә һәм аның яңача укыту ысуллары үрнәгендә Идел-Урал татарларында, Себердә һәм Урта Азиядә җәдиди мәктәпләр һәм мәдрәсәләр ачылып, унай нәтиҗәләр биргән.

Егерменче гасыр башы татар мәгърифәтчеләре, әдипләре һәм матбугат әһелләре И.Гаспринскийның кайбер карашлары белән ризалашып бетмәсәләр дә, аның Россия татар-мөселманнары өчен алгарыш һәм фикри этәргеч биргән олуг остаз булганлыгын тәкъдир иткәннәр.

**Раиф МӘРДАНОВ**

Фирдәвес
Гарипова

# АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

## Кече Чынлы

Кече Чынлы авылы Чүпрәле районының көньягында, Чынлы елгасы буена урнашкан. Җирле үзидарә советы авылда, Кече Чынлы исемен йөртә. Район үзәгеннән авыл 28 чакрымда, Борындык тимер юл станциясеннән—25, Тәтеш пристаненнан 85 чакрым ераклыкта утырган. Авыл һәм елга атамасы тарихи чыганакларда очрый.

Кече Чынлы авылы Казан ханлыгы чорында ук булган. Тарихи чыганаклар күрсәтүе буенча, бу җиргә XVII гасырда йомышлы татарлар килеп урнаша башлый. Бу турыда Г. И. Перетяткович түбәндәгеләрне яза «...Беркадәр соңрак (1663 елда) 25 йомышлы татар Чынлы елгасының югары агымына китереп утыртыла һәм аларга чәчүлек, печәнлек җирләре бирелә». 1859 елда халыкны исәпкә алу мәгълүматларына караганда, Кече Чынлы авылында 293 хуҗалык булган, 2485 кеше яшәгән (1230 ир-ат һәм 1255 хатын-кыз). Авылда 4 мәчет булган. Шушы ук чыганакта Кече Чынлының Сембер губернасындагы иң зур 320 авылның берсе һәм Буа өязенең (авыл бу заманда Буа өязенә караган) 15 зур авылы арасында иң зурысы булуы искәртелә. Анда тагын шундый юлларга тап булабыз: «...татарларның кечерәк кенә авыллары белән беррәттән, сәнәгать йортлары (промышленные заведения) булган зур һәм күп хуҗалыклары да бар. Мондыйларга Иске Шәйморза, Кече Чынлы, Шихардан һ.б. авылларны кертергә мөмкин». Бу чыганакта Кече Чынлы авылы халкы дәүләт крестьяннары («владельческие») дип атап үтелә.

Кыскасы, Кече Чынлы авылы Казан ханлыгы чорында иң зур авылларның берсе булган.

Авыл халкы дәүләт крестьяннары булгач, идарәләре дә дәүләтнеке саналган. Кече Чынлы авылы халкы нигездә игенчелек белән шөгыльләнгән.

Авыл картлары әле 1920 елларда да авылда 9 мәчет булганлыгын сөйлиләр. Әмма 1920 еллардан соң аларның манаралары киселә һәм мәчетләрне мәктәп итәләр. Мәчетләрнең манаралары төрлесе төрле вакытта киселгән. Мәсәлән, урталыктагы мәчетнең манарасын илленче елларда гына кискәннәр. Манараны кискән «Чатан» кушаматлы кешегә 2 пот арыш биргәннәр дип сөйлиләр.

Авылның ни өчен Кече Чынлы дип аталуы, ягъни әлеге исемнең кайдан килеп чыгуы турында халык телендә берничә легенда йөри.

Чынлы—чин (сан, дәрәҗә) дигән сүздән килеп чыккан дигән фикер бар. Янәсе, бу җирләр чинлы кешегә бирелгән булган, шуннан Чинлы—Чынлы атамасы килеп чыккан.

Кече Чынлы авылы атамасы Чынлы (Цыльна, Цильна) инеше исеменнән алынган дигән фикер дә яши. Инеш исеме (ягъни, Цильна) Казан ханлыгы чоры чыганакларында очрый.

Чынлы сүзе русча целина—«үзләштерелмәгән чирәм җир» сүзеннән килеп чыккан дип тә әйтәләр. Элекке заманнарда бу тирәләр чирәм җир булган. Тора-бара монда халык килеп урнаша башлый, авыллар оеша. Ә авылларны күренекле кешеләр исеме белән атап йөрткәннәр. Мәсәлән, Кәрим Чынлысы—Кече Чынлы, Ярәмәй Чынлысы—Зур Чынлы. Кәрим Чынлысы урнашкан чирәмлек җирләр Ярәмәй Чынлысыныкыннан

*Дәвамы. Башы 2006 елның 6нчы санында.*

кечкенәрәк булган. Шуңа күрә Кәрим Чынлысын—Кече Чынлы (Малая Цильна), Ярәмәй Чынлысын—Зур Чынлы (Большая Цильна) дип йөртә башлыйлар.

Кече Чынлы жирле үзидарә советы жирендә яши торган халыкның күпчелеген татар-мишәрләр тәшкил итә (аз гына санда казан татарлары да яши). Авылга беренче нигезне салучылар да—татар-мишәрләр. Әмма аларның монда кайчан һәм кайдан килеп урнашулары турында төгәл мәгълүматлар юк.

Мишәрләрнең килеп чыгышын һәм таралышын өйрәнгән галимә Р. Г. Мөхәммәтова фикеренә караганда, Буа, Чүпрәле, Чистай районнары һәм Чуаш республикасы жирләрендә яши торган мишәрләрне формалаштыруда Тамбов һәм Түбән Новгород губернасыннан XVII гасырның икенче яртыларында күчеп килгән татар-мишәрләрнең роле зур булган.

Безнең фикеребезчә, татар-мишәрләр проблемасын күзәткәндә өч чорны исәпкә алырга кирәк.

Беренче чорда акацирларны искә алу зарури. Алар безнең эрага кадәр VII—X гасырларда Көнчыгыш Европада яшәгәннәр. Урман белән бәйле бу тугандаш кабиләләрне төрле диалектларда төрлечә атап йөрткәннәр: бер диалектта—акацир дип, икенчесендә мишәр дип. Акацир да, мишәр дә—«урман кешеләре» мәгънәсендә кулланылган. Ука суы буйларында мишәрләр яшәгәнгә күрә, руслар әлеге жирләрне «мещерские земли» дип йөрткәннәр. 1152 елда Юрий Долгорукий монда бер шәһәргә нигез сала. Бу шәһәр 1471 елга кадәр «Городец Мещерский» дип, аннары Касимов (Касыйм) шәһәре дип аталган.

Икенче чор XVI гасырдан башлана. 1540-50 елларда ук, ягъни Казан ханлыгы басып алынганчы, мишәрләр Казан ханлыгы жирләренә үтеп керәләр. Мәсәлән, Н. К. Карамзинның «История государства Российского» (СПб, 1819—Т. VIII) дигән хезмәтенең 232—236 битләрендә мондый юллар бар: «Безнең елъязмалар 1551 ел датасы белән Иделнең унъяк ярында мордва, чирмеш, чуаш h.б. халыклар белән бергә, беренче тапкыр можар-мишәрләрне атыйлар». М.Худяков үзенең «Очерки по истории Казанского ханства» (Казан, 1923) дигән китабында мишәрләрнең бер өлешен Казан ханлыгына Шаһ Гали алып килүен яза.

Өченче чор XVII гасырдан алып XIX йөзнең беренче яртысына кадәр булган вакытны үз эченә ала.

Күрәсең, Кече Чынлы авылын нигезләүче мишәрләр бу тирәләргә икенче чорда килеп урнашканнар булыр.

Кече Чынлы халкы жир белән бәйләнгән газапларны хәйран күрә. 1760 елда Буа өязе Кече Чынлы авылында алпавыт Мотовилов крестьяннарның 849 дисәтинә жирен тартып ала. 1905 ел революциясе вакытында крестьяннар 300 дисәтинә жирне аяусыз көрәш нәтижәсендә кире кайтаралар. 1906 елның 5 апрелендә Кече Чынлыга 50 стражник белән пристав Соболев килә. Бәрелештә 400гә якын кешедән дүртесе үлә, 100 кеше каты яралана.

Бүгенге көндә Кече Чынлы авылында 602 хужалык бар, анда ике меңнән артык кеше яши.

Авыл матур урынга урнашкан. Аны урталай бүлеп Чынлы елгасы ага. Моннан тыш тагын Торна елгасы, Дингелди һәм Садыйк елгалары бар.

Авылның бер басуын Пугачев кыры дип йөртәләр. Монда Емельян Пугачев гаскәре белән ял итәргә туктаган булган дип сөйлиләр. Мамай исемле бер кеше шунда яшәгәнгә, бер басу Мамай кыры дип аталган. Авыл эчендә бер калкулык Әтәч тавы (Куцат тавы) дип йөртелә.

Кече Чынлы талантларга бай. Анда артистлар Ринат Тажетдинов һәм Харис Төхфәтуллов, язучы һәм тәржемәче Кыям Миңлебаев, галим Рәдиф Жамалетдинов туып-үскән.

## Аксу

Аксу авылы Буа районында, район үзәге Буа шәһәреннән 30 чакрым, жирле үзидарә советы үзәге Бик-Үти авылыннан—5, Килдураз тимер юл станциясеннән—15, Тәтештән 72 чакрым ераклыкта урнашкан.

Аксу атамасы урысча исемнәр белән тарихи белешмәләрдә ныгып калган.

1898 елда дөнья күргән тарихи белешмәдә авыл Белая Волошка дип аталган һәм анда татарлар яши дип әйтелгән. К.П.Берстельнең тарихи белешмәсеннән күренгәнчә, Белая Волошка авылында 1596 татар кешесе яшәгән.

Олы буын вәкилләре Аксу авылы оешу тарихын болай сөйлиләр.

Аксу авылы утырган урында куе урман була. Урман уртасында инкүлектән чишмә агып чыккан. Ерак та түгел Бола суы аккан. Бола суына бер чакрым кала Каты җир дигән урын булган. Шул тирәдә матур болын да җәелеп яткан. Шундагы Кара кизләү дигән чишмә янында Аксу исемле кеше яшәгән. Тора-бара бу җирдә 6—7 хуҗалыктан гына торган Аксу авылы барлыкка килә.

Бола суының икенче ягында Кокуй дигән урыс авылы утырган була. Анда бай алпавыт яшәгән. Бу авыл халкы Аксу авылын бер дә яратмаган, халыкны һәрдаим кыерсытып, кыйнап, җирләрен тартып алып торганнар. Бу кыерсытуларга чыдый алмыйча, Аксу бабай, башка кешеләрне дә ияртеп, тау башындагы чишмә янына килеп урнаша. Халык урман кисә, басу ясый һәм йортлар сала башлый. Чишмәнең суы бик мул һәм тәмле була. Хәзер аны кое итеп эшләгәннәр, исеме—Бикәмәт коесы.

Яна урында авыл 50—60 хуҗалыкка кадәр үсә һәм тирә-ягы биек койма белән әйләндереп алынган була. Бу койманы чит кешеләрнең һөҗүменнән саклану өчен төзегәннәр. Күчеп урнашкан авылның исеме Аксу бабайга нисбәттән Аксу атамасы алган.

50—60 йорттан торган Аксу халкына авылдан чыгу өчен бары бер капка булган. Кешеләр кая гына барсалар да шушы капкадан чыгып йөргәннәр. Авылда кешеләр күч-күч булып, укмашып, бер ишегалдында 10—15 хуҗалык яшәгән. Болай яшәү тора-бара авыл халкында ризасызлык тудырган. Халык һаман арта барган, ә койма белән әйләндереп алынган кечкенә авылда халык бернинди һөнәр белән дә шөгыльләнә алмаган.

Авыл халкы уйлаша да, җир бүлүчене (землемер) чакыра. Җир бүлүче килә, халыкка җир бүлеп бирә һәм хуҗалыкларны урамнарга урнаштыра. Шуннан соң авыл зурая башлый, халык ишәя. Игенчелек белән көн күрәләр.

Вакыт үтә, халыкның белемгә булган ихтыяҗы арта. Бу вакытта авылда мәчет тә, мәдрәсә дә булмый. Халык авылдан 5 чакрым ераклыктагы Бик-Үти авылына мәчеткә йөреп гыйбадәт кыла. Тора-бара ике авыл өчен бу мәчет кысрыклана һәм Бик-Үтиләр Аксу халкын китерми башлыйлар. Шуннан соң Аксу халкы авылда мәчет төзергә карар кыла. Авылның нәкъ үзәк өлешенә мәчет салып куялар. Тора-бара мәчетләр саны 5 кә житә. Әйе, заманында Аксу 5 мәчете белән дан тоткан.

Тирә-яктагы авыллар Аксу авылын Кишер Аксуы дип йөртәләр, чөнки бу авылда һәр гаилә кишер утырта һәм сатуга чыгара.

Кишер чәчү моннан 100—150 еллар элек башланган. Авыл олылары сөйләвенә караганда, бер кеше Әстерхан шәһәренә яшәргә күчеп китә. Әстерханда бераз торганнан соң, бу кеше бераз орлыклар табыштырып Аксуга кайта һәм кишер чәчү белән шөгыльләнә башлый. Бу эштән ул шактый гына керем ала һәм, аңардан күреп, башка хуҗалыклар да кишер үстерү кәсебенә керешәләр. Колхозлашканчы һәр хуҗалык 2—3әр гектар кишер чәчкән һәм аны якын-тирәдәге авылларга сатып күп кенә керем алганнар. Хәзерге вакытта да Аксу халкы бу һөнәрне ташламый.

1923 елда авылда беренче әртил төзелә. Аңа «Кызылармеец» дигән исем бирәләр. 1925 елда авылда мәктәп ачып җибәрәләр. Янында интернаты да була. Күрше авыл балалары анда кунып та кала.

1986 елда авылда унъеллык урта мәктәп ачыла. Ул мәктәп хәзер дә эшли. Анда тарих музее бар. Музейга экспонатларны халыктан җыйганнар.

Авыл озын-озын өч урамнан тора: Кырый урам, Урта урам һәм Чуаш урамы.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

# М

**МАЙЛИН** Баимбәт Жармагамбәт улы (1896, хәзерге Казакъстан Респ. Кустанай өлкәсе Таран а.—25.2.1937), казах язучысы. Казах совет әдәбияты башында торучыларнын берсе. 1913-15 «Галия» мәдрәсәсендә белем ала. Анда булачак татар язучылары Ш.Бабич, Ф.Бурнаш, Х.Туфан, С.Кудашлар б-н таныша; Г.Ибраһимовтан дәресләр ала. Анын житәкчелеге астында әдәби ижат б-н шөгыльләнә башлый. 1915 елда Уфада казах авыл кызынын фажигале мәхәббәте турында «Шүганын белгісі» исемле повестен бастыра (нигезендә Г.Ибраһимов кушуы буенча язылган ирекле темага сочинение ята).

Октябрь рев-циясеннән сон М. әсәрләренен төп герое—социализм төзүчесе. «Раушан-коммунист» (Кызыл Урда, 1929) исемле повестендә гади казах хатынынын актив жәмгыять тормышына күтәрелүе тасвирлана. Казахстандагы социаль үзгәрешләр «Азамат Азаматыч» (Кзыл Урда, 1934) романында чагылдырган. Аерым пьесалары милли азатлык өчен баш күтәрү (1916) һәм Гражданнар сугышы вакыйгаларына багышланган. М.нын аерым сюжет линияләре, сәнгати фикерләү рәвешләре, проза стиле Г.Ибраһимов һ.б. татар язучыларын хәтерләтәләр. Мәкаләләрендә үзенен ижат тамырлары татар мәдәниятенә барып тоташканын әйтеп үтә. Гаепсезгә репрессияләнә; үлгәннән соң аклана.

Әсәр.: Толык жинак. 4 томда. Алматы, 1933-36; Повести и рассказы. М., 1958.

Әд.: Жармагамбетов К. Б.Майлин: Жизнь и творчество. А.-А., 1962; Түркістан: Халакаралык энцикл. Алматы, 2000.

*Р.К.Ганиева.*

**МАКСУД** (Максудов) Мәхмүд Гыйсаметдин улы (15.1.1900, Казан губ. Лаеш өязе Югары Кибәхужа ав.—10.11.1962, Мәскәү), язучы, тәржемәче. Мәскәү унтын тәмамлый (1934). 1918 елдан Мәскәүдә яши, «Чулпан» газетасы редакциясендә тәржемәче, «Яшь эшче» газетасында редактор (1921-26), «Нәшрият»тә баш мөхәррир (1926-28), «Центриздат»нын татар әдәбияты секциясен (1928-31) һәм «Профиздат»нын милли әдәбиятлар секторын житәкли (1932-33). 1933-34 тә «Коммунист» газетасында әдәби хезмәткәр. 1918 елда Окт. революциясе көне унаеннан «Бәйрәм житә» дигән беренче очеркын бастыра. Башка очерклары социализм казанышлары, халыклар бердәмлеге темаларына багышланган («Яна шәһәр һәм анын кешеләре», 1949; «Тынычлык вахтасында», 1955). Бөек Ватан сугышы елларында политрук, батальон комиссары, политбүлек агитаторы, «Советский воин» газетасы мөхәррире урынбасары вазифаларын башкара. «Яз жыры» (1929; 2 басма 1990), «Канлы божралар» (1929), «Изге көрәшкә» (1941), «Яна тормыш юлында» (1980) кебек хикәя жыентыклары; «Үч һәм нәләт жыры» (1944), «Гөлжамал апа Мәскәүдә» (1948) исемле лирик-публицистик характердагы шигырь жыентыклары; М.Жәлил турында «Сагынган минутларда» (1963) дигән истәлекләр китабы, Г.Тукай, Г.Ибраһимов, М.Гафури, К.Нәжми, Һ.Такташ, М.Әмир, Ф.Кәрим ижатларына багышланган мәкаләләр авторы. Татар теленә А.С.Пушкиннын «Дубровский» (1934) һәм «Скупой рыцарь» («Саран рыцарь», 1948), М.Горькийнын «Мать» («Ана», 1951), Л.Н.Толстойнын «Война и мир» («Сугыш һәм тынычлык», т. 1-4, 1954-57) һәм «Анна Каренина» (1960), И.С.Тургеневнын «Рудин» (1959) әсәрләрен, Көнч. әдәбияты классикларыннан Низами, Абай поэмаларын, «Поэты Прибалтики» («Балтик буе шагыйрьләре»; Литва ССР ЮСнын Мактау грамотасы, 1948) жыентыгын татар теленә тәржемә иткән. 2 нче дәрәжә Ватан сугышы , Кызыл Йолдыз орденнары белән бүләкләнгән.

Әсәр.: Әсәрләр.К., 1934; Сайланма әсәрләр. К., 1952; Әсәрләр (1919-1959). К., 1960.

Әд.: Хәйри Х. Мәхмүд Максуд ижаты // Татар совет әдәбиятында реализм мәсьәләләре. К., 1960; Шамов А. Зур тормыш // Казан утлары. 1980. №1.

*Г.М.Габделхакова.*

**МАКСУД** Сөндекле (псевд., чын фам. һәм исеме Максудов Садыйк Мубинович)

*Дәвамы. 2005 елның 4нче саныннан басылып килә.*

(15.9.1904, Сембер губ. Буа өязе Сөндек (Сөендек) ав. —декабрь 1981), шагыйрь. Башкорт һәм татар телләрендә иҗат итә. 1924 елдан Донбасс шахталарына китә; совет-партия мәктәбен тәмамлагач (Артёмовск шәһ., 1927), Щербиново рудникларында татар һәм башкорт шахтёрлары арасында уку-яза белмәүне бетерү өлкәсендә эшли. 1931-35 тә «Донбасс эшчесе» дигән татар газетасы редакциясендә әдәби хезмәткәр. 1935 елдан Башкортстанда яши: Башглавлит, Язучылар оешмасында, радиоком-тта, «Әдәби Башкортстан» ж-лында эшли. Әдәбиятка прозаик буларак килеп керә («Күмер тавышы», 1930), ләкин алга таба күбрәк поэзия жанрында иҗат итә. Аның беренче язмалары 1930 елларда «Эшче», «Игенчеләр» газеталары һәм «Яшь эшче» кебек үзәк матбугатта дөнья күрә. Татар һәм башкорт поэзиясендә беренчеләрдән булып эшчеләр һәм шахтёрлар темасын күтәреп чыга («Донбасс ударниклары», 1931; «Стаханов турыһында йыр», Уфа, 1938; «Мәхәббәт», 1938 җыентыклары). «Урал шигырьләре» (1948), «Хезмәткә дан» (1950), «Тормыш шатлыгы» (1960) җыентыкларына кергән шигырьләрендә дә производство темасы үзәктә тора; аларда Куйбышев ГЭСын төзүчеләр, геолог һәм нефтяникларның хезмәтенә дан җырлана. М.С.нең иҗади уңышларыннан —Мариуполь шәһ. оккупацияләнгәндә немец фашистлары тарафыннан җәберләнгән танылган стахановчының батырлыгы турындагы «Макар Мазай» (1950) һәм революционер «Иван Якутов» турында поэмалар тора. Соңгы елларында лирик миниатюралар һәм сигезьюллыклар жанрында яратып иҗат итте («Без кабызган уттар», Уфа, 1974; «Кемнен кулы матур?», 1977). Балаларга адресланган «Һунгы хат», Уфа, 1934; «Буяусы малайзар», Уфа, 1957 китаплар авторы; А.С.Пушкин, М.Ю.Лермонтов, М.В.Исаковскийның кайбер әсәрләрен башкорт теленә тәрҗемә итә. Бөек Ватан сугышында катнаша, медальләр белән бүләкләнә.

Әсәр.: Шигырьләр, поэмалар. К., 1941; Сайланма әсәрләр. К., 1955; Бессмертие. Уфа, 1972.

Әд.: Әдипләребез: Биобиблиографик белешмәлек. К., 2009. Т.2.

*Г.М.Габделхакова.*

**МАКСУДИ** (псевд., чын исеме билгесез) (15 йөзнең 2 нче яртысы—16 йөзнең 1 нче яртысы), төрки-татар шагыйре. Дини-дидактик шигъри хикәятләрдән торган «Һәза китабу фи бәйани могъҗизаи бин-нәби» («Пәйгамбәр кылган могъҗизаларны аңлата торган китаб», 1515, басыла 1848) исемле китап авторы. Күләме—6150 бәйт. М. укучыларны диннең сафлыгын сакларга, ислам идеаллары өчен көрәшкә әзер булырга, янаган куркынычлык алдында бердәмлеккә чакыра. Сүзләренең ихласлыгын, ислам диненең бөеклеген исбатлау өчен, ул пәйгамбәр кылган могҗизалар, җиннәр, кяферләр б-н көрәше турында яза. Хикәяләр бай, образлы тел б-н аерылып торалар, аларда татар халык лексикасы элементлары бар. Җыентык татарлар арасында кулъязма рәвешендә таралган була.

Әсәр.: Могҗизнамә. К., 2002.

**МАКСУДОВА** Зәйнәб Абдулҗәмил кызы (28.3.1897, Вятка губерниясе Алабуга өязе Уразай а.—3.2.1980, Казан), археограф. 1904-11 елларда «Буби» мәдрәсәсенең кызлар сыйныфында укый. 1912 дә икееллык пед. курслар тәмамлый, рус телен өйрәнә, экстерн рәвешендә имтиханнар тапшырып, Атбасар пед. көллиятен тәмамлый (Казахстан), урта мәктәпләрдә укыта. 1920 дән Ташкентта: Үзбәк хатын-кызлар ин-тында укыта, Урта Азия ун-тында укый. 1922 дән Казанда. Ликбез курсларында, Совет сәүдә техникумында, урта мәктәптә, 1957-67 елларда Казан пед. ин-тында гарәп телен укыта. Шәрекъ телләрен яхшы белә, татар мәктәбендә рус телен өйрәтү методикасы б-н шөгыльләнә. Борынгы татар әдәбияты ядкәрләрен өйрәнә. Әсәрләре татар халкының рухи мәдәниятенә зур йогынты ясаган күренекле фән һәм мәдәният эшлеклеләре турында биобиблиографик каталог төзи (ТРның Милли музеенда саклана) ( 7 меңнән артык шәрекъ авторлары, 30 меңгә якын әсәрләр исемен үз эченә алган). Методик әсбап һәм фәнни мәкаләләр авторы.

*Р.Р.Мусабәкова.*

**МАКСУДОВА** Шәһидә Габдрахман кызы (29.11.1926, Алабуга кантоны Уразай а.—7.2.2009, Казан), тәрҗемәче, язучы. Казан. ун-тын тәмамлый (1952). 1954-57 елларда ТАССР Китап палатасында, 1959-68 елларда Әлмәт ш. Техника йортында, 1969-83 ТАССР Язучылар берлегендә китапханәче булып эшли. Русчадан татарчага Л.Н.Толстойның «Булька» (1953) исемле хикәяләр җыентыгын, В.А.Чивилихинның «Ёлки-моталки» («Урман-чытырман», 1977) повестен, Д.Н.Валеевның «День икс» («Шартлы көн», 1982) пьесасын; казах һәм каракалпак язучылары әсәрләрен тәрҗемә итә. Яшүсмерләр өчен язылган «Минем кала алуым» (1972, рус телендә 1976), «Асылбикәне җирләгәндә» (1996) повестьләр авторы.

Әсәр.: Минем кала алуым. К., 2006.

Әд.: Шәһидә Максудовага 80 яшь // Казан утлары. 2006. № 11.

**МАЛИКОВ** Әдип Малик улы (16.8.1921, хәзерге Башкортостан Респ-

касы Янаул р-ны Иске чат ав.—23.4.2009, Әлмәт ш.), язучы, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1979). М.Горький исем. Әдәбият ин-тын тәмамлый (Мәскәү, 1957). Бөек Ватан сугышында катнаша. 1940-46 елларда Төньяк Сахалинда: разведчиклар бүлеге командиры, «Тревога», «За Советскую власть» исемле фронт г-талары хәбәрчесе. Көньяк Сахалинны азат итү сугышларында катнаша (1945). 1946-49 да Татарстан радиок-тында башта балалар тапшырулары, соңрак әдәби-драматик тапшырулар мөхәррире. 1951-60 та «Яшь сталинчы» г-тасы үзхәбәрчесе. 1955 тән Әлмәт шәһ. яши. 1965-67, 1972-82 елларда ТАССР Язучылар берлегенең Әлмәт бүлеге җаваплы сәркатибе. М. «Совет әдәбияты» ж-лында басылып чыккан «Атаудагы хисләр» (1945) поэмасы аша әдәбиятка кереп китә. Сугыш хатирәләре аның бөтен иҗатын биләгән. Әсәрләрендәге икенче төп тема—Татарстан җир асты байлыклары, шул өлкәдә эшләүче респ-ка нефтьчеләренең көнкүрешен сурәтләү.

Әд.: Әдипләребез: Биобиблиографик белешмәлек. К., 2009. Т.2.

**МАЛИКОВА** Мәдинә Габделхак кызы (5.8.1935, Сарман р-ны Мортыш Тамак ав. туа), журналист, язучы, ТАССРның, РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1976, 1985). Казан педагогия ин-тын тәмамлый (1959). 1959-64 елларда «Чаян», 1964-87 дә «Азат хатын» (1978 дән җаваплы сәркатип) ж-ллары редакциясендә. 1989-90 да ТР Язучылар берлеге идарәсе рәисе урынбасары. 1993 тән Бөтентатар Кызыл Хаҗ җәмгыяте президенты. М.ның әдәп-әхлак мәсьәләләренә караган язмалары республика һәм үзәк матбугатта еш басылып килә. Аның «Юлдашлар» (1967) дигән беренче хикәяләр җыентыгы да әхлак проблемаларының кискен куелышы белән җәлеп итә. «Казан каласы—таш кала» (1971; русчага тәрҗемәдә «Свет улыбки Моны Лизы», 1985), «Егетләккә бер адым» (1978), «Янар таулар яктысында» (1980) повестьлары, «Шәфкать» (1984; русчага тәрҗемәдә «Милосердие», М., 1988), «Басып сайрар талы бар» (1987), «Фидая» (1991), «Алтын ятьмә» (2001), «Кызыл гөл» (2005) романнары иҗат интеллигенциясе вәкилләре тормышыннан алып язылган. Үзенең геройлары: актёрлар, режиссёрлар, рәссамнар, музыкантлар, врачлар, галимнәр образлары аша М. кешелек кыйммәтләренең асылын ассызыклый, ялагайлык, икейөзлелек, миһербансызлык кебек сыйфатларны фаш итә. М. иҗатына нечкә лиризм, характерларны сурәтләүдә тирән һәм төгәл психологик алымнар белән эш итү хас. Бигрәк тә хатын-кыз образларын уңышлы сурәтли. Аның «Хөкем» (1969), «Адашканга юл кайда» (1971; русчага тәрҗемәдә «Мелодия огней», М., 1986), «Югалган якутлар» (2004) повестьлары, «Өермә» (2003) романы детектив жанрда язылган. М. шулай ук драматургия өлкәсендә дә эшли. Аның «Йөрәк ничек түзсен» (1989 да сәхнәләштерелә), «Оҗмах балалары» (1990 да сәхнәләштерелә), «Моңнар төште башыма» (1992 дә сәхнәләштерелә), «Синең өчен үзем үләрмен» (1994 тә сәхнәләштерелә) пьесалары Минзәлә, Әлмәт татар драма т-рларында куела. Х.Ямашев исем. Респ. пр. лауреаты (1980).

Әд.: Хантемирова Г. Төсләр балкышы // Казан утлары. 1981. №8; Галимуллин Ф. Халатың ак, күңелең пакь булса // Казан утлары. 1983. №9; Әдипләребез: Биобиблиографик белешмәлек. К., 2009. Т.2.

*Г.М.Габделхакова.*

**МАЛЫШЕВ** Сергей Владимирович (27.9.1950, Казан—7.6.2007, шунда ук), шагыйрь, тәрҗемәче, ТР ның атказ. мәдәният хезмәткәре (2000). Казан ун-тының механика-математика ф-тын тәмамлый (1972). 1991 дән «Идель» журналы мөхәррире. «Хәтер яфраклары» («Листья памяти», 1984), «Төнге сөйләшү» («Ночной разговор», 1993), «Кирегә санау» («Обратный отсчет», 2000) лирик җыентыклар, балалар өчен язылган «Дөньяда бар нәрсә дә кызыклы» («Всё на свете интересно», 1986), «Сырлы бер нәрсә» («Что-то полосатое», 2003) китаплар авторы. М.ның поэзиясе—ясалма пафостан принципиаль ерак торган «тын лирика»; балалар өчен язган шигырьләренә йомшак юмор хас. Рус теленә Г.Кандалый, Дәрдемәнд, Ф.Кәрим, Х.Туфан, З.Нури, Ш.Галиев, И.Юзеев, Х.Халиков, Ә.Гадел, Р.Мингалим, Ф.Яруллин, Р.Миңнуллин, Г.Зәйнашева, Р.Вәлиева, М.Фәйзуллина әсәрләрен, мөнәҗәтләр тәрҗемә итә.

Әд.: Страшнов С. Возраст ответов (о молодой волжской поэзии) // Молодые о молодых. М., 1988.

*Р.Р.Мусабәкова.*

*Дәвамы киләсе саннарда.*

Рөстәм
Акъегет

# СУ ЙОТКАН АВЫЛ ӨСТЕНДӘ ЯЛГЫЗ КӨЙМӘ

Еракта—жир белән күк тоташкан офыкта рәшәләнеп күренгән каен урманы—балачактан бүгенгәчә хәтердә сакланган иң якты сурәт. Без яшәгән дөньяның чиге шундадыр, урман аръягында инде нindидер бер яна, серле хәят башланадыр дип уйлый идем. Баш очымнан узган уйчан болытлар да үзләре белән шул урманга ымсындырып дәшә кебек иде. Шул чакларда миңа гаҗәеп бер төш керде. Гомергә онытылмаслык төш. Имеш, биниһая киң-якты бер хәят кочагында икәнмен, тирә-юньдә—күз камаштыргыч гүзәл гөлләр, салават күпередәй аллы-гөлле ефәк канатлы күбәләкләр, иннәремә әкияти кошлар килеп куна һәм бу күренешләр каяндыр ишетелер-ишетелмәс кенә килгән талгын-тылсымлы көйгә ярашып, бер-бер артлы алышынып тора. Елмаеп уяндым да, каенлык аръягын күрдем дип уйладым. Мин, сабый, шуна ышанып, чын күңелемнән сөендем.

Тик ул якты каенлыкны өнемдә күрүләр насыйп булмады. Бәләкәй идем шул әле мин, ул каенлыкка житү—татлы бер хыял гына иде...

...Хәзер инде мин дөньяны күккә ашкан таш йортның биек тәрәзәсе аша күзәтәм. Аста—тирән чоңгыл төбендә тузан һәм төтен катламы, урам гөрелтесе, узышка чыккандай чабышкан машиналар, бәрелә-сугыла каядыр ашыккан пәлтәләр, пәлтә эченә поскан бәндәләр... Монда һәркемнең үз кайгысы, үз борчуы, күршесенең хәлен белергә беркемнең дә вакыты юк. Агачлар да әллә нинди бит монда: матурлыйк дип башларын кырыкканнар да, дәү йортлар арасында гарип кәрләләр кебек утыралар, киек кошлар оя корыр ябалдашларына тәмәке төпчекләре ябышып калган. Шәһәр шул бу, монда йортлар агачлардан биегрәк...

Ул авыл да, балачагымда барып күрергә жирсенгән каенлык та еракта, бик еракта калды. Хәзер инде ул урманнан чакрымнар гына түгел, еллар да аерып тора. Авылдан без язмышка ияреп киттек. Тәкъдир юллары Әтине бер эштән икенчесенә, аның белән бергә безне дә каладан-калага, саладан-салага йөртте дә йөртте. Шулай бертуктаусыз күченеп йөри торгач, ахырда Казанга—Әмәт тау итәгенә озаккарак килеп төпләндек. Без урнашкан урам нәкъ шулай дип—Әмәт итәге урамы дип атала иде. Соңрак аны Тихогорский итеп үзгәрттеләр. Менә анда инде агачлар өй түбәләреннән биек иде! Ул агачлар жәйләрен үзләренең бишек-ябалдашларында зәңгәр күкне тирбәттеләр, ә көзләрдә—ук булып өскә үрләгән яшь тармаклары белән һава ярып, безнең өскә килгән соры болытларны куаладылар. Күрче, үзендәге гармонияне саклау көче ничек зур бу Табигатьнең, кем белә, бәлки, ул әнә шул агачларга гына күккә күтәрелү хокукы биргәндер...

Язмыш юллары бормалы дип тиктомалдан әйтмәгәннәр икән. Жәйнең

якты иртәсе иде. Әни мине «Суконка»—Сәкләр бистәсенә ияртеп китте. Мәчет тирәсенә житкәч, юан бүрәнәләрдән буралган, әле дә тазалыгын җуймаган ике катлы йорт янында тукталдык. Күп серләр ачылды миңа ул көнне. Бу бит Әниемнең туган йорты икән, үзенең яшьлеген ул менә шушында каршылаган. Шомлы 30нче еллар килгәч, йорт хуҗасын—Әнинең кардәшен Беломорканалга куалаганнар, бу аның мәңгелеккә китеп баруы булган. Шуннан Әни авылга сыенган. Афәт килүен сизенеп, бабам белән әбием алданрак кайтып урнашкан булганнар...

Әни, капка баганасына маңгаен куеп, озак кына дәшми торды. Аннары мине җитәкләп урам буйлап алып китте. Июнь иде. Тупыллар мамык очыра. Тып-тын. Кеше күренми диярлек. Яртылаш мәрткә киткән бу урамны вакыт зилзиләсе читләтеп узгандыр да, шуңа аның әллә кайчангы—патша заманындагы йөзе үзгәрешсез калгандыр кебек тоела. Ул чагында Әни ниләр уйлады, ниләр кичерде икән? Бөдрә таллар толым чылаткан Кабан ярына алып чыгып, ул миңа ни әйтергә, нәрсә аңлатырга теләде икән?

Шаляпин һәм Тихогорский урамнары чаты. Безнең йорт Әмәт тауның нәкъ күтәрелә башлаган җирендә—итәк очында. Дәү чуен плитәләр түшәлгән керү юлы челтәрләп бизәкләнгән борынгы тимер баскычка тоташа. Йортны урам яктан каеннар үз кочагына алган, алма бакчасында сарай бар, аның янындагы мунчаның морҗасыннан ялкау гына төтен күтәрелә... Чын Казан инде бу!

Казанга күченеп килгәч, ярты ел буе бистәнең икенче очындагы 14нче мәктәптә укып йөрдем. Ерак иде, ләкин аның нәкъ менә шул ягы ошый иде миңа. Шулай Әмәт тавын бер менеп, бер төшеп йөри торгач, яз да житте. Мәктәп букчасын җилкәдән-җилкәгә ыргыткалап өйгә ашыгам, кояш нуры күзне чеметтерә. Сукмактагы соры ташларның битен юып уйнак ерганаклар йөгерешә. Урам буйлап ике яклап тезелгән каеннар, ботакларына сарылган салкын тамчыларны шыбырдатып, муенга салып шаярталар. Язгы су шавы, сыерчыклар җыры, бала-чага чыр-чуы—бу авазлар барысы бергә кушылып, күңелгә әле моңа кадәр таныш булмаган әллә нинди бер ашкындыргыч рәхәтлек бирә.

Мәктәптә ярыйсы гына укыдым. Тырышсам, тагын да яхшырак укый алган булыр идем, әлбәттә. Математика белән әдәбиятны үз иттем. Өлкән сыйныфларга житкәндә тәмам китап колына әверелгән идем инде.

Яңа уку елын мин Газ урамындагы мәктәптә башладым, монысы инде өебезгә якын гына. Белмим, әллә мәктәптән мәктәпкә еш күченеп, укытучылар һәм сабакташлар гел үзгәреп торгангамы, шуңа күрә аларда «тамыр җәяргә» өлгерә алмый калгангамы, мәктәп тормышын беркайчан да сагынганым булмады бугай. Шулай да, уку еллары, яшүсмер чаклар сагышка салып искә төшә...

Йортыбызның урнашкан җире дә, әчке бүленеше дә минем өчен—яшьлек хисе кerә башлаган җилкенчәк өчен бик тә кулай иде. Өйалдыннан керүгә, озын коридор башланып китә. Ул бинаның переметры буйлап сузылган, шунлыктан йокы бүлмәләренә дә, кухняга да, ул заманның бер зиннәте—ваннага да аерым ишекләрдән керешле. Коридорның иң башындагы беренче бүлмәдә университетта укып йөрүче абыем Равил Фәйзуллин ел-ел ярым чамасы яшәде. Аның янына атнага бер тапкыр төрле вузлардагы дуслары—әдәбият сөюче студентлар җыелыша. Аларның кайберләре еллар узгач татар әдәбиятында күренекле каләм ияләре булып танылдылар. Илдә әле «Хрущев җепшеклеге». Алар бер-берсенә үз шигырьләрен укыйлар, тыелган татар язучыларының әсәрләре, татар теленең кысылуы, шәһәрләрдә милли мәктәпләрнең ябылуы турында кызып-кызып сөйләшәләр. Мин исә, кулыма китап алам да, укыганга сабышып, бер читтә тын гына утырам,

ишеткәннәрне күңелгә сала барам. Тел очында торган сораулар күп күбен, тик әйтмим, түзәм, чыгарып җибәрерләр дә, бүтән кертмәсләр дип куркам. Алардагы ихласлык, хисләр җителеге, фикер батырлыгы, көрәш дәрте, дөньяны пакьләү өчен чын йөрәктән янып-көюләре сокландыра иде мине. Ничек яшь, никадәр саф булганнар алар, омтылышлары да нинди чиста булган! Исерткечләр белән шаярганнарын да, хатын-кыз турында гайбәт сөйләшкәннәрен дә хәтерләмим.

Мин ул елларда бик күп укыдым, кулыма ни килеп керсә, шуны укыдым, яшереп кенә шигырь яздым һәм КДУ ның филология факультетына керергә хыялландым. Тик бу хыял бер елга соңарып тормышка ашты. Мәктәптән соң җәһәннәм тишегендәге Нефть базасы ягында—агач эшкәртү комбинатында эшләргә туры килде. Иртәнге биштә сикереп торып, ашык-пошык чәй чөмерәсең дә, 10нчы автобус тукталышына чабасың. Халык өерен ерып керә алсаң, утырасың, елгырлыгың җитмәсә —басып каласың. Күктә әле Ай хуҗа, йолдызлар җемелдәшә, ләкин ашыгырга кирәк—эш сәгате төп-төгәл 7дә башлана. Цехта салкын, дегет һәм буяу исе борынны яра, төшке ашка туңган пәрәмәч һәм ачыган каймак китерәләр. Шулай да миңа монда ошый иде. Агач белән эш итәсең бит! Агач ул—тере җан иясе. Юкәнең дә, каенның да, чыршы-нарат яисә имәннең дә—үз холкы, үз кирелеге. Ләкин чын оста кулына килеп кергәч, алар үзләренең башбирмәс холкын онытып, аның ихтыярына буйсына, ахырда сәнгать әсәре ярала. Цехта агач уючы бер телсез абый бар иде. Эшләгәндә иреннәрен кыймылдата, үзалдына нидер мыгырдангандай итә—ул шулай агач белән сөйләшә диләр иде. Бәлки шаяртып кына әйткәннәрдер, тик мин моңа чын күңелемнән ышана идем, хәзер дә ышанам.

Балигъ булмаганнар өчен эш көне бер сәгатькә кыскарак. Кич житкәнче мин инде өйгә кайтып керә идем.

Ә бер көнне... бер көнне әллә нәрсә булды. Көзге эңгердәге очрашу күңелне иләсләндерде—бездән бер йорт аша гына яшәүче күрше кызы миңа яндырып карап үтте. Шул мизгелдә дөнья үзгәрде. Өлкән сыйныфта укып йөри иде ул. Бераз киткәч, кисәк борылып елмайды да, үзенең кызыл пәлтәсе белән мәктәп тыкрыгына кереп югалды. Шул төндә кыз минем төшкә керде. Гел кызылдан гына киенгән дә, сары яфрак бураны эченнән килә, имеш. Яшь, чибәр, чем-кара күзләреннән ымсындыргыч ялкын сирпелә... Кар төште. Эштән кайтышлый күреп гаҗәпкә калдым: капка төбендәге яңа яуган карга кемдер минем исемне язып киткән. Оялчан идем мин ул чакта. Шулай да, аңлашу мизгеле озак көттермәде. Казанда могҗиза белән генә сакланып калган татар мәктәпләренең берсенә—Татарстан урамына йөреп укый иде ул кыз. Их, аның дәресе бетүен көтеп, Тукай тукталышындагы агачлар ышыгында зар-интизар булып торган чаклар!..

Еллар узгач, Васильево станциясендә кыска гына тукталыш вакытында каршы якка баручы поезд тәрәзәсенә күз салдым һәм... тагын шул якын-таныш караш сискәндереп, җанны өтәләде. Ул түгелме соң бу?! Мин аңышып өлгергәнче, поезд кузгалып та китте. Тәрәзәгә ташландым, ләкин тышта каршы поездның соңгы вагоннары йөгерешә иде инде. Яшьлектә табынган караш идеме ул, әллә башкамы?—монысы инде мәңгелек сер булып калачак.

Менә мин дә студент булдым. Казан университеты филология факультетының рус-татар бүлегенә укырга кердем.

Мәктәптә чакта Джек Лондон белән мавыккан булсам, студент елларында Бунинны, Чеховны, Горькийны, Купринны тулысынча укып чыктым; зур әсәрләреннән алып, шәхси хатларына кадәр берсе дә калмады. Бу әдипләрнең каләм кодрәте таңга калдыра иде. Бигрәк тә Чехов. Аннары

яшь чакка яшәү мәгънәсен эзләү хас бит. Кешеләрне тану, аларның холкын аңлау, тормыштагы вакыйгаларның асылына төшенү җәһәтеннән, Горький әсәрләре җайлы гына итеп күп нәрсәгә өйрәтте. Горький тагын бер ягы белән якын: көн саен диярлек аның эзләре калган урыннар буйлап атлый идем бит. Ул чакта әле Казанның борынгы өлеше үзгәрешсез диярлек саклана иде. Автовокзал янында бөтен шәһәргә нибары ике тугыз катлы йорт булып, алары да минем күз алдында төзелде.

«Минем университетларым»да язганча, төшенкелек баскан чакларында Горький Татар бистәсенә юл тоткан, шунда күңеленә юаныч тапкан. Анда бөтенләй башка, саф-чиста тормыш алып баручы ягымлы йөзле, игелекле кешеләр яши, рус сүзләрен ватып-җимереп, кызык итеп сөйләшәләр, кичләрен мөәзиннәр биек манаралардан әкияти бер мәкам белән намазга чакыра... Булачак әдипкә татарларның тормышы үзенең өметсезлек тулы яшәешеннән җайлырак, уңайлырак булып тоелгандыр инде.

Шәһәрнең татар ягы мине дә үзенә бик нык тарта иде. Татарстан урамындагы Кызыл (Казаков) мәчетнең нигез ташларын да калдырмаганнар бит ичмасам. Чын архитектура шедевры булган югыйса! Нариманов һәм Татарстан урамнары почмагындагы Исмәгыйль хажи йортын да хәтерләүчеләр сирәк инде. Мин белгәндә аның аскы катында ипи кибете иде. Бу бина да ниндидер тарихи кыйммәткә ия булгандыр дип уйлыйм. Сабакташ дуслар белән бергәләп тә, ялгызым гына да татар халкы тарихына, мәдәниятенә бәйләнышлы әнә шундый урыннарның барысын барлап чыктым бугай.

Горький вакытындагы кебек үк булмаса да, ул елларда әле Татар бистәсендә татар теле өстенлек итә иде. Бала-чага ана телендә сөйләшүдән гарьләнми, картлар мәчеткә чалма-чапан киеп бара иде, татар мәктәбе эшләп килде. Кыскасы, милли тормыш рәвешен сакларлык мохит яши иде. Әмма бу миллилек чаткыларына мөнәсәбәт елдан-ел кырыслана барды. Татар мәктәпләре бетерелде диярлек, татар теле почмакка кысрыклап кертелде, ул «кухня теле» булып калды. Милли хисләрен югалтып өлгермәгән кеше ата-бабалары җирендә килмешәк хәленә төште. Чалма-чапанлы бабайлар да зират капкасыннан кереп гаип булды...

Яңа бистә зиратының капкасы элек Мех комбинаты ягында, алтынчы трамвай тукталышы янында иде. Бу зиратка беренче тапкыр атлап кергәнем хәтердә. Җәйнең яфрак та селкенми торган җилсез бер көне иде. Зират эче тып-тын. Капканы керүгә, ап-ак озын яулык бөркәнгән намаз карчыклары, шушы тынлыкны бозмаска теләгәндәй, пышылдашып кына нидер сөйләшә. Йөзләре ягымлы, күзләрендә—шәфкать яктысы. Бу ак әбиләр миңа адәм балаларының мәңгелек йортындагы тынычлыкны саклау өчен махсус куелган затлар булып тоелды. Узып баручылар сирәк кенә биреп киткән хәер акчасын да алар үзенә бер битараф тыйнаклык белән кабул итәләр, җиңелчә баш селкеп кенә рәхмәт белдерәләр дә, ашыкмый гына догага керешәләр.

Ул көнне мин беренче тапкыр Фатих Әмирхан, Габдулла Тукай, Мәрҗани, Сәйдәш каберләрен күрдем. Аллеялар пөхтәләп җыештырылган, чисталык-тәртип, тынлык-тынычлык. Шул тынлык эчендә ап-ак күбәләкләр бөтерелә, әйтерсең, әрвахларның җаны кояш күрергә чыккан...

Минем тормышта шундый бер чор булып алды, юк, авыр чор дип әйтмим, әмма, үзем дә аңламастан, гел зиратка юл тота идем. Анда мин игътибар итмәгән, һич югы яныннан узмаган берәр кабер калдымы икән?! Тоташ яңгыр пыскып торган көзге көннәрнең берсендә мин янтайган, яшел мүк белән капланган бер кабер ташына юлыктым. Мүктән арындырып карасам, анда мондый юллар уелган:

Бу дөньяның ваклыгына
Вакланасым килмәде.
Тар ләхетне кабул иттем,
Тарсынасым килмәде.

Аннары мин кабер ташындагы датага игътибар иттем: үлгән елы—1937. Нәрсә бу, очраклы хәлме? Ничек кенә булмасын, әлеге эпитафик язу күңелне тетрәтте.

Хәзер инде мин зиратка сирәк барам, бармый калып булмаганда гына барам. Дуслар-танышларымның бик күбесе кайтмаска дип шунда күченде. Каберләренә бармасаң, алар әле дә исәндер кебек...

Әмәткә кайтыйк әле. Бистәнең исеме рәсмияттә Ометьево дип йөртелсә дә, Дәрвишләр, Каувәл һәм башка бик күпләренеке кебек ук, бу атаманың тамыры да татарга тоташкан. Монда борынгыдан ук татар авыллары булган, руслар килгәч, атаманы үз телләренә яраклаштырганнар.

Мәктәп елларында, студент чагымда мин бу бистәнең бөтен яр-чокырын, кеше аягы басмаган чытырманлыкларын капшый-капшый диярлек өйрәнеп чыктым. Чөнки мәктәптәге сабакташ дусларым шул ярларга кереп поскан өйләрдә яши иде бит. Студент булгач, университетның Кызыл Позиция урамындагы тулай торагына—курсташлар янына да шул ук ярлар аша турыдан гына элдертә идем.

Абый өйләнеп, фатир алды, аның бүлмәсе миңа калды. Хәзер инде анда минем дуслар җыела. Бәйрәмнәр, туган көннәр еш кына бездә уза. Никадәр мәрхәмәтле, сизгер күңелле, зирәк булгансың икән бит син, и, минем кадерле Әнием! Тыйнак кына тормыш итсәк тә, минем дусларны һәрчак якты йөз, тәмле сүз, пәрәмәчле кайнар чәй белән каршы алдың, мохтаҗлыкта калган иптәшләрем өчен безнең өй сыеныр урын булды.

Дуслар тагын шунысын да белә: бәйрәм җитсә, бездә аларны бәлеш көтә. Ә инде бәлешне минем Әниемнән дә тәмлерәк итеп пешерә алган кеше юктыр ул!

Октябрь һәм май бәйрәмнәрен көтеп ала идек. Демонстрациягә мәҗбүриләп чыгарсалар да, анда дуслар, күптәнге танышлар белән күрешү, төркемгә берләшкән яшь канның кайнарлануы, алда көтелгән бәйрәм киченең күңелне җилкетеп торулары—болар канатландыра, ашкындыра... Шулай да, барыннан да бигрәк, Яңа елны ярата идек без. Аның сәясәткә катышы юк, транспорант-флаглар да күтәреп изаланасы түгел. Күңел бәйрәме, мәхәббәт һәм могҗизага ышану бәйрәме. Их, ул студент чакларның Яңа еллары! Почмакта—чыршы утыра, ике-өч шәм яна, магнитофон әйләнә, табында—дуслар, янәшәдә—сөйгән яр. Аякларның гел Татар бистәсенә тартылуы юкка гына булмаган икән, ул кыз шуннан иде, ул да университетта укып йөри. Сәгать уникене сукты. Һәм без, без инде хәзер өлкән курслар, чыр-чу килеп, тау шуарга юнәләбез. Ә тау дигәнең безнең Тихогорский урамы үзе инде! Чана җен тизлеге белән аска оча, җил сызгыра, кызның колагына үрелеп, күңелдә йөрткәннәрне—күзенә туры карап әйтергә базмаган сүзләрне пышылдыйсың. Ул моны ишетми, әлбәттә. Ишетми, әмма тоя. Чөнки, әнә, чанадан төшеп калмаска тырышкан булып, сине кысыбрак кочып ала. Мин аны авыр сүз әйтеп, хәтта ялгыш кына кырын караш ташлап рәнҗетүдән курка идем. Ә күзләре... Аның күзләре нәрсәгәдер гаҗәпләнүдән бервакыт шулай зур булып ачылган да, шушы гаҗәпләнү йә нәүмиз үпкәләү, кайчак балалык наянлыгы чаткылары белән кушылып, гел шул хәлендә калгандыр кебек тоела.

Чана оча, исәрләндерә, баш әйләнә. Юк, бер йотым шампаннан яисә кысыр шәрабтан түгел, мәхәббәттән әйләнә ул башлар!

Арабызда рәсемгә һәвәс бер егет бар иде, без биибез, җырлыйбыз, күңел ачабыз, ә ул, бахыр, мыштым гына нидер төшерә. Кышкы пейзаж ясаган икән, аның матурлыгына шаккаттык. Хәер, бу рәсемнең шаккатырасылары алда булган икән әле. Рәссам пейзажны миңа бүләк итеп китте. Аны кәгазьләр арасына салып куйдым да, шуның белән онытылды. Күп еллар узгач, иске кәгазьләремне тәртипкә салып баш әйләндергәндә, тагын килеп чыкты ул. Инде чүпкә ташлыйм дигәндә, рәсемне ераккарак куеп карыйсы иттем һәм ... сискәнеп киттем: миңа аннан Яна ел кичендәге әлеге кыз карап тора иде.

Без аның белән ике ел йөрдек. Ике ел буе үзем өчен дип сакладым, тик ул башкага насыйп булды.

Практикада чагында ул атна саен Казанга кайтып йөрде, ике көннең берендә хаты килеп торды. Күптән түгел мин әнә шул инде саргая башлаган хатларны яңадан укып чыктым. Онытылып-йотлыгып, күз яшьләре аша укыдым. Һәм бөтен шигырьләремне ерткалап ташлыйсы килде. Юк, күпме генә изалансам да, бу хатлардагы кебек кайнар хисләр белән яза алмамдыр инде мин, мөгаен...

Әй, ул Әмәтнең якты кышлары! Тәрәз каршындагы агач ботакларына, алсу алмаларны хәтерләтеп, кызылтүшләр кунган. Зәмһәрир суыкларда дөнья ап-ак бәскә төренә дә, Әмәт гүзәл бер кышкы бакча килбәтенә керә. Кыш көннәрендә иң яраткан эшем—мунча ягу иде. Шөкер, өйдә бу җаваплы вазифа минем өскә йөкләнгән. Эшне кичтән үк башлап куям. Чөнки көндезләрен су колонкасына якын барам димә, ә төнлә—беркем юк. Су басымы көчле, күз ачып йомган арада чиләк мөлдерәп тула. Ерак ташыйсы да түгел, ике сәгать дигәндә—су әзер. Ә инде мунчаның үзен иртән—бөтенесе эшкә китеп беткәч, берьялгызым калып, иркенләп-тәмләп ягам. Башта мичнең көл-күмерен түгәм, идән себерәм, утын кертәм. Аннары мич төбенә коры йомычка салам. Ашыкмый гына, эчке бер рәхәт тантана белән, ут элгезәм, ялкын үрли барган саен, өскә утын тезәм. Ут тәмам дөрли башлагач, мич авызы каршына тәбәнәк урындык куеп утырам да, ялкын биюен—тереклек һәм үлем туен күзәтәм. Имәннәр, каеннар, өрәңгеләр—барысы да шау кызыл күмергә әверелә. Аларга бура ниргәсе дә, ишек борысы да, түшәм матчасы да булу язмаган. Бу агачлар дистә еллар, бәлки, гасырлар дәвамында менә шушында—мунча мичендә янып көлгә калу өчен үскәннәр... Әкренләп мунчага җылы керә, тәрәзәне каплаган боз эри, кышкы иртәнең яктысына юл ачыла.

Хәер, кыш артыннан язларга да юл ачыла. Язгы яңгырларда саф тамчылар тәрәз каршындагы каен чукларын сәйләндәй сырып алалар да, төнге фонарь яктысында әллә нинди тылсымлы чигешләр булып җемелдәшәләр. Зирәк акыл белән яратылган бу табигать! Исәрләндергеч яз һавасы күкрәккә, күзәнәкләргә генә түгел, яшь күңелгә дә тула. Менә хәзер, менә шушында нидер булыр, нindидер тәкъдири кискен үзгәреш килер кебек тоела. Тагын берничә атнадан төнге Әмәт күгендә торна тавышлары ишетелә. Һәм шуннан соң сөйләп-тасвирлап булмастай хәлләр башланып китә. Алмагачлар, чияләр, шомыртлар чәчәккә күмелеп, бакчалар ап-ак төскә керә. Сирень ботаклары, үз чәчәкләре исеннән исереп, киерелеп ачылган тәрәзә кочагына егылалар. Йортлар агач ябалдашлары куенына кереп югала. Дөнья ашкындыргыч-исәрләндергеч исләр әсирлегенә төшә. Яз—азатлык фасылы. Тик ул гашыйк җаннар өчен газап чоры. Шашкын язда гашыйкларга Ходай Үзе ярдәм бирсен. Әнә бит, күкрәк читлегендә Йөрәк, менә чыгам, менә чыгам дип ярсына...

Көннәр җылытуга мин йә алмагач төбендәге сәкегә, яисә төз лапас астына «башка чыгам». Зачет-имтиханнарга шунда әзерләнәм, яңасе.

Әзерләнерсең, бар! Әнә, алмагач ябалдашын аралап, күктән йолдызлар күз кыса, күләгәләр кочышлы уйный, күңелдә вәсвәсә. Ул арада капкага әкрен генә чуерташ бәрелгәне ишетелә. Бу теге кышын кызыл пәлтәдән йөргән кыз инде. Сессиягә әзерлегемне тикшермәкче, имеш. Ун минутка гына дип керә дә, берзаман баксаң, төн үтеп тә киткән, Ходайның соңгы йолдызы инде таң нурында эреп бара...

Ул чакларда анын җәйләре дә ашыкмыйча гына үтә иде бит. Әкрен генә алмалар, грушалар сусыллана. Тупыл бураннары әллә никадәргә сузыла, күктә талу белмәс чатлыкойрыклар чөкердәшә. Әмәттә тынлык хөкем сөрә. Сирәк-мирәк кенә йә боз төшеп, йә күк күкрәп, бу тынлыкны бозып ала да, аннары тагын, гүя, вакыт акрыная, Әмәт татлы йокыга тала.

Шулай йокымсырый торгач, ул, җирән мәчедәй посып кына көз якынайганын сизми дә кала.

Нишлим, яшьлегем эзләре калган Әмәтне мин гел якты төсләр белән генә сурәтләдем менә. Әлбәттә, анын кара-караңгы буяуларга манчылган яклары да булды, ул һич кенә дә әкияттәге илаһлар атавы түгел, ә фани дөнья тәртипләре белән яши торган гадәти бер бистә иде. Исерекләрнең канга батып сугышканнарын да, башка явызлыкларны да күрергә туры килде. Әмма безнең яшь йөрәкләр вәсвәсәгә бирелмәде—андый кырын эшләргә кушылып китмәдек. Моның өчен без Ходайга мең рәхмәтле.

Шәһәр һөҗүме дәвам итә. Арыш серкә уйнаткан кырларга, көтүләр сөт җыйган болыннарга, балык уйнаган күлләргә, үрдәкләр бәбкә чыгарган камышлыкларга каршы аяусыз сугыш бара. Шәһәр Әмәткә дә басып керде. Безнең йортны да, хәрабәләр генә калдырып, изеп үтте ул. Монда да өй түбәсе агачлардан биек булмаска тиеш дигән гармония канунын санга сукмый торган ят тормыш башланды.

Җил-исәре дә кызганыч хәтта. Ул да инде хәзер алай ук исәр-иреклe түгел. Юлында киртәләр очрап кына тора: йә таш йортлардан әлхасил «Кытай дивары»на чәпелә, йә бетон корылмаларның тимер түбәләренә канатын сыдыра, йә инде машиналарга, поездларга бәрелеп гарипләнә. Башакларны сыйпап, ябалдашлар белән шаярып йөри торгач, кызып китеп, болытларны чиксезлеккә таба куып исүләр юк инде ул хәзер... Җилләр дә кызганыч шул инде.

Мин дөньяны башы күккә тигән йортның иң югары катындагы балконнан күзәтәм. Аста машиналар чабыша, адәм балалары тыз-быз килә—фани тормыш кайный. Ә өстә... Күктә болытлар тын гына, уйчан гына балачакка таба, сурәте күз алдыннан китмәгән каенлыкка таба агалар да, агалар. Юк ла инде ул каенлык хәзер, сабый чакның тылсымлы төшләре дә инде бүтән кабатланмас.

...Кичке шәфәкъ иде. Яр башына басып, Чулман өстендә ишкәк ишкән картны күзәттем. Су төбендә калган авылы өстендә көймәсе белән әрле-бирле йөзә иде ул...

***Редакциядән:***

*Бу айда каләмдәшебез, журналыбызның даими авторы, шагыйрь Рөстәм Акъегеткә (Фәйзуллинга) 60 яшь тула. Аны юбилее белән котлап, яңа иҗат уңышлары, сәламәтлек телибез.*

# БӨДРӘ ТАЛЛАР СИМФОНИЯСЕ

Танылган рәссам, күләмле нәкыш әсәрләре, пейзаж, портретлар остасы рәссам Зөфәр Гыймаев татар сынлы сәнгатенә 1970нче еллар ахырында, авыл тормышына багышланган зур картиналары белән килеп керде. Тормышны белү, хезмәт кешесенә мәхәббәт, авыл стихиясен–чәчәкле-гөлле илаһи тирәлеккә төреп, күпне күргән аксакалларны, ак яулыклы гүзәл әбиләрне идеаллаштырып мон, табигать матурлыгы аша–әхлагыбызның тере итеп сурәтләү–аның какшамас иҗат принципларына әверелде («Дәүәнигә хат килде», «Батыр», «Бәйрәм бүген»әсәрләре һ. б.). Сәнгать көллияте (1966-76), Ленинградта И. Е. Репин исемендәге нәкыш, сынчылык һәм корымчылык институтында, 1978–80 елларда Казанда, Х. Якупов җитәкчелегендәге СССР Сәнгать академиясе остаханәсендә алган белем профессиональ осталыкның нигезен тәшкил итте. 90нчы еллар ачкан мөмкинлектән файдаланып миллилек, традицияләрне кайтару, меңьеллык тәрәккыят нәтиҗәсендә тупланган «асылташларны» бүгенге чор вазгыяте белән тоташтыру принциплары игълан ителгән заманда З. Гыймаев–милли идеалларны алга сөргән зур иҗат, мәдәният темасына, сәнгать кешеләренең күләмле образларына таба йөз тотты. Оста С. Сәйдәшев, Б. Урманче, Г. Рахманкулова, Нәкый һәм Празат Исәнбәт, Р. Бикчәнтәев, М. Сәлимҗанов, Р. Мостафин портретлары аша заманыбыз мәдәниятен, анын омтылышларын, төп миссиясен сурәтләде.

Без яшәгән XXI гасыр сукмакларына ташып чыккан бу иҗади дулкынның аерым чагылышы–яратып, сөеп башкарган балалар портреты жанры (« Алиса», рәссамның улы, кызы портретлары, «Витя», «Мәрьям» һ. б.)–чәчәк, гөл кебек ачылган балачак һәм тотрыклы, дәрәҗәле иҗат балкышы–Зөфәр Гыймаевның бөтен нечкәлеге белән тоеп, күңеле аша үткәреп, көчле, нәфис итеп ачкан ике зур иҗат өлкәсенә әверелде («Наил Дунаев», «Туфан Миннуллин», «Татар моны. Халык шагыйре Илдар Юзиев»–әдипнең Казан панорамасына индерелгән зур портреты). Портрет өлкәсендәге мул һәм кодрәтле эшчәнлеге өчен рәссам 2003 елда Б. Урманче исемендәге сәнгать премиясенә, ә 2005 елда Татарстанның Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булды.

Замандашларыбызның рухи дөньясын баетуда шулай ук З. Гыймаевның татар авылы, урман-күл, тау-болын күренешләрен сурәтләгән пейзажлары да зур роль уйнады.

«Бәрәзәбаш авылы» пейзажында (1978) рәссам бөдрә яшел таллар, кызыл түбәле шакмаклы йортлар, ташып торган алтынсу–яшел авыл басулары эчендә чайкалып утырган биек манаралы агач татар мәчетен сурәтли; курай кебек, моңлы манарасы белән ул, әйтерсең, күкләргә тоташкан... Яшел түгәрәк таплар өермәсеннән гыйбарәт, җилкән кебек җилфердәгән «каурый» агачлар мәчеткә дә, бөтен могҗизалы тирәлеккә, күктә чайкалган зәңгәрсу-ал болытларга да яшәү ритмын, хәрәкәтчәнлек, тормыш аһәңен өстиләр сыман... Җирне-күкне тоташ бер ягымлы стихия итеп сурәтләгән аллы-гөлле бу пейзажның сере–аның, бөтен горизонталь яссылыкны ярып, түргә, югарыга ашкынган перспективасы... Бу–конкрет табигать күренешен, җирне-туфракны, агачларны, мәчет-йортларны матур итеп, бизәкләп-түгәрәкләп, күңел күзе аша үткәреп сурәтләгән пейзаж гына түгел. Әсәрнең төп идеясе–арткы планда күтелмәгәндә кабат калкып чыккан алтын болын, кыр-басуга охшашлы татар тормышының дәвамлылыгына, мәңгелегенә–мәдхия ирештерү. Ышану-өмет... Хыял... Ялвару һәм сөю.

Татарстан Рәссамнар берлеге рәисе Зөфәр Гыймаев 60 яшен зур иҗади байлык белән каршылый. Татар мәдәни мохитеннән аерылгысыз иҗаты инде бүгенге көн кысасында кыйммәтле мирас, гүзәл табигать, кешелеклелек һәм туган илгә мәхәббәт симфониясе ул.

**Розалина ШАҺИЕВА**

## Фоат Садриевка 70 яшь



Татар әдәбиятының кайсы гына тармагын алсак та дөнья мәйданына күтәреп күрсәтә алырдай талантлы иҗатчылар барлыгын аңларбыз. Үткән ел республикабызның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булган Фоат Садриев—һичшиксез, әнә шундый әдип.

Фоат Миңлеәхмәт улы Садриев 1941 елның 10 мартында Татарстан АССРның Мөслим районы Олы Чакмак авылында туган. Үз авылларында җидееллык, аннан күрше Шуган авылында урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, 1958 елдан хезмәт биографиясен башлап җибәрә: колхозда эшли, авыл китапханәсендә мөдир вазифаларын башкара. 1963—1970 елларда башта Сарман, соңыннан Мөслим районы газеталарында әдәби хезмәткәр, бүлек мөдире, Мөслим метеостанциясендә метеоролог булып эшли. 1972 елның октябреннән 1981 елның көзенә кадәр ул—Мөслимдә чыга торган «Авыл утлары» исемле район газетасының редакторы хезмәтендә. Эшеннән аерылмыйча укып, 1965 елда В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының филология факультетын тәмамлый. 1981—1982 елларда Мәскәүдә РСФСР Культура министрлыгы каршындагы бер еллык Югары театр курсларында укып кайта.

Фоат Садриевның «Оҗмах ишеге төбендә» исемле кечкенә күләмле беренче комедиясе 1970 елда «Идел» әдәби альманахында басылып чыга. Шуннан соң ул «Их сез, егетләр!..», «Ач тәрәзәң...», «Кондырлы кодачасы» исемле пьесаларын яза. 1976—1980 елларда аларның өчесе дә Әлмәт татар драма театры сәхнәсендә куелып, тамашачылар һәм театр тәнкыйте тарафыннан җылы каршы алына.

Үткән гасырның сиксәненче елларында Ф. Садриев проза жанрында җиң сызганып иҗат итә башлады. Хәзер аның укучылар яратып каршылаган күп санлы повестьлары һәм хикәяләре бар. Ә 1993 елда әдипнең «Таң җиле» романына багышланган әдәби дискуссия журналыбыз битләрендә ел буена дәвам итте.

Соңгы елларда Ф. Садриев «Бәхетсезләр бәхете» һәм «Авылдан хатлар» исемле китаплары белән үз укучыларын сөендерде.

Әдипнең әсәрләрендә замандашларыбызның катлаулы рухи-әхлакый дөньясы тасвирлана, халкыбызның озак еллар дәвамында раслана килгән матур сыйфатлары мактала, аларның яшәүчән көче һәм безнең чор өчен мөһимлеге күрсәтелә. Әсәрләргә укучы күңелен тартырдай сәнгатьчә матур тел һәм югары образлылык хас.

## Сәйдә Зыялыга 70 яшь



Шагыйрә һәм проза әсәрләре авторы Сәйдә Зыялы (Сәйдә Закир кызы Зыятдинова) 1941 елның 27 мартында Татарстанның Теләче районы Шәтке авылында урманчы гаиләсендә дөньяга килә. Ул туып күп тә үтми, сугыш башлана, әтисе Закир абзый фронтка китә һәм шул китүеннән инде кире кайтмый—сугыш кырында ятып кала. Шуңа күрә Сәйдәнең балачагы һәм үсмер еллары ятимлектә, күп яшьтәшләренеке кебек ачлы-туклы, күз яшьле авыр тормыш кысаларында уза. Шулай да белемгә омтылыш аны тормыш авырлыкларын җиңәргә өйрәтә: туган авылында—җидееллык, күрше Олы Нырсы авылы мәктәбендә урта белем алып, ике ел колхозда эшләгәч, 1963 елда ул Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга килә. 1968 елда университетны тәмамлап, берникадәр вакыт Татарстан Министрлар Советы каршындагы архив идарәсендә кече фәнни хезмәткәр булып эшли, аннары күңеле тарткан, хыялында күптән йөрткән эшкә—«Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй») газетасы редакциясенә әдәби хезмәткәр булып күчә, соңга таба редакциянең бүлек мөдире вазифаларын башкара. Язучының беренче әдәби әсәрләре дә нәкъ менә шушы газетада эшләгәндә дөнья күрә башлый. Ул 1977 елда Татарстан Журналистлар берлегенә кабул ителә.

1983-1992 елларда С. Зыялы «Сөембикә» журналында әүвәл әдәбият бүлеге мөдире, аннары журналның җаваплы сәркәтибе булып эшли. Бу елларда көндәлек матбугатта бер-бер артлы «Тугрылык», «Саба җиле» дигән поэмалары һәм шәлкем-шәлкем шигырьләре басыла. 1988 елда Татарстан китап нәшриятында чыккан һәм яшь авторларның әсәрләре тупланган «Беренче карлыгачлар» җыентыгында «Җыелмаган җиләк» дигән гомуми баш астында шагыйрәнең бер бәйләм шигырьләре урнаштырыла, 1991 елда исә «Айның тулган чагы» исемле беренче мөстәкыйль шигъри китабы дөнья күрә.

С.Зыялы проза әсәрләре—бәяннәр («Кайнар сукмаклар», «Кар карасы», «Кара таплы бизәк», «Югалту»), хикәяләр («Юл читендә», «Буранлы төн», «Ике дөнья арасы», «Ачылмаган бөре», «Сыну», «Яз салкыннары» һ.б.), публицистик мәкаләләр авторы буларак та укучыларга таныш. Күренекле әдип Мәгъсум Хуҗин С.Зыялы иҗаты турында болай дип язды: «Аның «Кайнар сукмаклар», «Кар карасы» исемле повестьларында, шулай ук хикәяләрендә шигырьләренә хас лейтмотив—тормыш яме мәсьәләсе үзәктә тора. Язучының балалар өчен язылган һәм юмористик хикәяләре дә шактый, алары да шул очтан». С.Зыялының үзенчәлекле әдәби образлар һәм вакыйгалар аша үзенең тормыш гаме, яшәү мәгънәсе турындагы уй-фикерләрен, фәлсәфи карашларын гәүдәләндергән бу проза әсәрләренең бер өлеше 2001 елда нәшер ителгән «Кайнар сукмаклар» исемле китабында тупланып дөнья күрде.

1991 елда аңа «Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелә.

С.Зыялы—1992 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

***Редакциядән:***

*Каләмдәшләребезне юбилейлары белән кайнар котлыйбыз, аларга сәламәтлек һәм яңа иҗат уңышлары телибез!*




*Шагыйрь Хәсән Туфан яшәгән йортка истәлек тактасы кую көнендә. Фоторәсемне*



*Дөньякүләм мәшһүр галим, академик Роальд Сәгъдиев (1932). Хәзерге вакытта Америкада яши. 1969 елда төшерелгән фото.*



*Якташлар. Сулдан уңга: язучы Рафаэль Сибат, авыл хуҗалыгы хезмәткәре Рәфикъ Рәуфов, галим Фоат Галимуллин. 2002 ел.*



*җентекләп карaганда бик күп мәшһүр шәхесләрне танырга мөмкин. 1982 ел.*



*Татарстанның халык шагыйре Фәнис Яруллин. 2008 ел.*



*Режиссер Дамир Сиражиев (сулда) һәм драматург Юныс Сафиуллин. 90нчы еллар.*

## Хәйретдин Мөҗәйнең тууына 110 ел

Шагыйрь һәм прозаик Хәйретдин Мөҗәй (Мөҗәһит Хәйретдин улы Хәйретдинов) 1901 елның 26 мартында хәзерге Башкортстанның Туймазы районы Төрекмән авылында туа.

Унсигез яшендә ул Кызыл Армиягә алына, һәм шул вакыттан соң аның бөтен гомере хәрби хезмәткә бәйле: озак еллар чик буе гаскәрләрендә хезмәт итә, Урта Азиядә басмачыларга каршы көрәшә, 1938 елда Хәсән күле янында япон самурайларына каршы барган сугыш хәрәкәтләрендә катнаша. Бер үк вакытта Хәйретдин Мөҗәй әдәби иҗат белән шөгыльләнергә дә вакыт таба: егерменче еллар ахырыннан башлап, газета-журнал битләрендә аның хәрби тормышка, чик сакчыларының көндәлек хезмәтенә багышланган һәм аларның уй-фикерләрен чагылдырган шигырьләре, очерклары һәм хикәяләре еш басыла. 1932 елда Казанда «Мылтыклылар» исеме белән шигырь, хикәя һәм очерклары тупланган аерым җыентыгы дөнья күрә.

Хәйретдин Мөҗәй Ватан сугышының беренче көннәрендә үк алгы сызыкка баса, гвардияче полк командиры буларак, үзенә йөкләнгән сугышчан бурычларны үти, оборона һәм һөҗүм операцияләрен башкаруда күп тапкырлар кыюлык һәм шәхси батырлык үрнәкләре күрсәтә. Ләкин 1942 елның җәендә, Харьков юнәлешендә һөҗүм хәрәкәтләре барышында ул командалык иткән полк дошман чолганышында кала һәм айдан артык сузылган авыр бәрелешләрдән соң, полктан исән калган авыр яралылар, шул җөмләдән полковник Хәйретдин Мөҗәй дә, фашистлар кулына әсир төшә. Аларны Германиягә озаталар. Шагыйрь әсирлектә дә фашизмга каршы көрәшен туктатмый: Мюнхен шәһәрендәге совет хәрби әсирләре лагеренда төзелгән интернациональ антифашистик яшерен оешма җитәкчеләреннән берсе була. Бу яшерен оешма баш күтәрү өчен әсирләрне коралландыру чарасына керешә. Ләкин 1943 елның ахырында гестапо яшерен оешманың эзенә төшә, җитәкчеләрен Дахау концлагерена яба һәм, озак газаплаулардан соң, үлем җәзасына хөкем итеп, 1944 елның 4 сентябрендә үлем карарын гамәлгә ашыра. Ул көнне җәзалап үтерелгән туксан ике Дахау тоткыны арасында шагыйрь, совет офицеры—полковник Хәйретдин Мөҗәй дә була.

Аның Ватан сугышы чоры әдәби мирасыннан «Сугыш көндәлеге» язмалары сакланып кала. Язмалар, татарча һәм рус теленә тәрҗемә ителеп, 1968, 1978 елларда аерым китаплар булып та басылып чыга. Шигъри иҗатыннан үрнәкләр исә татар телендә—«Алар сафта» (1961) һәм русча тәрҗемәдә—«Три поэта-воина» (1979) исемле күмәк җыентыкларда урнаштырыла.

Ак җилкән

Балачак белән яшьлек арасындагы гүзәл дөньяда яшәүчеләр, бу—безнең сәхифә!

# ХИКӘЯ ЯЗА АЛАСЫЗМЫ?

*1нче санда укучыларыбыздан шулай дип сораган идек. 3 вариантта бирелгән башламнарның теләгәнен сайлап алып, аларны нәни хикәя итеп үстерергә кирәк иде. Мондый хикәячекләр килә башлады. Аларның кайберләрен инде укый да аласыз.*

*Бу иҗат бәйгесе дәвам итә. Иң җилле өч хикәячек авторларының кулына керәчәк бүләкләр дә («Сүнмәс утлар балкышы» китабы) әлегә редакциядә кала бирә.*

## Табыштылар!

***Идел үзенә кирәкмәгән бөтен нәрсәне ярга чыгарып аткан. Камилә «Fanta»дан бушаган шешә эчендә түгәрәкләп бөгәрләнгән конвертлы хат күреп өнсез калды...*** Ә бу хатта болай диеп язылган иде: «Мин ялгыз гына авыл читендә яшәүче Ак әби булам. Бәлки, бу хатымны берәрсе табар һәм укыр дип өметләнәм. Мин ялгыз торам, серләремне сөйләр кешем юк, кайбер чакта гына песиемә сөйлим, тик аңа сөйләнгән сүзләрем һәрвакыт җавапсыз кала. Менә шуның өчен бер кәгазь битенә үземнең серемне ачарга булдым. Мин яшьли бер хата ясадым, үземнең газиз баламны балалар йортында калдырып чыгарга мәҗбүр булдым. Еллар агым сулар кебек үтә торды, хатамны аңлап, төзәтергә уйлаганда инде соң иде, минем нарасыемны тәрбиягә алганнар иде. Мин аның кайда яшәгәненә хәтле белдем, әмма анда барырга җөрьәт итмәдем... Минем кызым да гаиләледер инде, ничек яши икән, их, беләсе иде дә бер күрәсе иде...»

Кәгазьдә адрес язылган. Камиләне яшен суккандай булды, бу бит аларның өй адресы! Ул бит әнисенең елый-елый сөйләгәнен, әниле бала дөньяда иң бәхетле кеше икәнен белеп үсте. Ә аның әнисе ана назыннан мәхрүм калган... Нишләргә? Әнисенә бу хат турында ничек итеп әйтергә? Әллә әйтмәскәме? Аның күнелендә берсен-берсе узып төрле уйлар чабышты. Һәм ул берничә көн бер нияткә килә алмый азапланды. Бу хат берничә ел элек язылган иде. Ак әби, бәлкем, исән дә түгелдер дип уйлады ул һәм әнисенең йөрәген тикмәгә тетрәндерүдән курыкты. Ә бәлки Ак әби исәндер, мин әниемне әнисен күрү бәхетеннән мәхрүм итәмдер дигән уй да гел борчып торды аны. Менә ул телевизордан Әниләр бәйрәме турында ишетеп калды һәм кич белән әнисенә серне ачарга булды. Әнисе ашарга пешереп йөргәндә ул кинәт кенә сорау бирде: әнием, әгәр син үз әниеннен исән икәнен белсән, нишләр идең? Гафу итә алыр иденме? Әнисе каушап калды, нәрсә әйтергә дә белмәде. Аның күз алдыннан үзенең авыр, ачы,

күз яшьле тормышы үтте. Тик үзен кулга алып, кызым, син нишләп миңа мондый сорау бирергә уйладың әле, диде... Камилә әнисенә түкми-чәчми барын да сөйләп бирде. Әнисе ни әйтергә дә белмәде, ул телсез калды. Аның йөрәге чәнчеп-чәнчеп алды... Төн уйлады, көн уйлады, һәм, ниһаять, күрсәтелгән адрес буенча китте.

Авыл читендә ялгыз каендай ялгыз бер йорт тора. Гөлчәчәк ханым бу йортны бик тиз тапты һәм акрын гына капканы ачып, ишек алдына узды. Менә аның ишекне кагарга дип күтәрелгән кулы катып калды... Ул, үзендә көч табып, ишекне какты. Өй эчендә ак күлмәктән, ак яулыктан дога укып бер әби утыра иде. Гөлчәчәк ханым аңа шешә эчендәге хатны күрсәтте. Йортта тынлык урнашты. Бу тынлыкны беркем дә бозарга теләмәде. Ана белән бала арасында күпме әйтелмәгән сүзләр, үпкәләр, мәхәббәт ята иде. Алар, бер-берсенә карашып, боларны сүзсез дә аңладылар...

**Булат САДРИЕВ.**
*37нче гимназиянең 7б классы укучысы.*
*Казан.*

## Номерсыз машина эзе

***Төн уртасы булгач, шәһәр автобуслары йөрми иде инде. Юл читендә берүзе басып торган Алия янына номерсыз машина килеп туктады...***

Бу—мажаралы һәм хәтәр вакыйганың башы түгел, дәвамы иде.

Эчке эшләр бүлегендә кичләрен соңга калып урамда ялгызы булган хатын-кызларны талап-көчләп, кайсын юк итеп йөрүче җинаятьчел төркемнең эзенә төшү эшен майор Мирзинга йөкләделәр. Ул үзенең өч кешелек экипажы белән атна буе төнге шәһәр урамнарын күзәтеп йөрде. Шул вакыт эчендә тагын шундый берничә җинаять кылынуы теркәлде. Әмма ни кизү торучылар, ни Мирзин үзе әлеге җинаятьчеләрнең эзләренә төшә алмады.

Ахыр чиктә ул, тәвәккәлләп, кыю, кискен, хәтәр эшкә ниятләде: махсус капкын корырга, аңа җим итеп... спортфакның өченче курсында укучы сеңлесе Алияне куярга. Алия—таза гәүдәле, төскә-биткә чибәр, самбо, каратэ алымнарын яхшы үзләштергән кыз. Өстәвенә абыйсы аңа полиция академиясенең байтак серләрен дә өйрәткән иде.

Абыйсы белән алдан сөйләшеп куйганча. Алия иптәш кызлары белән төнге кафедан уника туларга унбиш минутта автобус тукталышына килеп басты. Иптәш кызлары, урамның икенче ягына чыгып, җиңел машина туктаттылар да, утырышып китеп тә бардылар.

Шул арада Алия янына номерсыз, кара тәрәзәле иномарка килеп туктады. Шофер егетнең алгы ишекне ачуы булды, арткы ишектән килеп чыккан икенчесе Алияне кисәк кенә этеп, алгы утыргычка сөрлектереп екты. Шул егылу Алияне хәвеф-хәтәрдән саклап та калды: аның башына сугарга кизәнгән шоферның тимерле кулы, ялгышып, кызны арттан буарга үрелгән өченче егетнең чигәсенә тондырды һәм ул шундук идәнгә мәтәлеп төште. Шофер кизәнгән кулын тартып алырга өлгергәнче, Алия, мәче тизлеге белән аның кулын эләктереп алып, кычкыртып-сүгендереп, артка борып кинәт каерды да, абыйсы биргән кул богавын тиз генә кесәсеннән алып, киертеп тә куйды, богауның икенче боҗрасын арткы ишектән керергә әчкә сузган икенчесенең кулына каптырып куйды.

Абыйсы майор Мирзин экипажы килеп җиткәндә, акырышып йолкынган

җинаятьчел төркем үз машиналары эчендә капкынга эләккән иде инде.

Номерсыз машина эзе шушы җинаятьчел төркемнең штаб-үзәге булган әлеге төнге «Пар күбәләк» кафесына алып килде.

Төн уртасында чибәр татар кызының берүзе юл читендә басып торуының серенә җинаятьчеләр тәмам авызлары пешкәч кенә төшенделәр.

**Хәнәфи**

## Кара савыты

***Йокыдан уянып та житмәстән Наилнең башына шундый уй килде:***

—«Казан утлары»ндагы кыска хикәяләр турындагы игъланга җавап итеп, «Кара савыты» исемле әсәрен җибәрергә. Чехов әйтмешли: яшьләр сюжет-тема табалмыйча аптырый, менә мин шушы кара савыты турында да хикәя язып ташлый алам.

—Ләкин бу хикәя Чеховныкы түгел, минеке булачак!—диде Наил үзалдына.—Укыгыз, әфәнделәр, без дә Антошадан ким түгел.

«Кеше җанына сусаган һәм малга комсыз бәндә Сөләй фатирындагы язу өстәлендә пычранып беткән, китек кырлы кара савыты бар.

Кара савытындагы карага кемнәр генә каләмнәрен манчымый!

Сөләйнең Гуңгыйк исемле улы, калку гәүдәле, шара күзле, әйтерсең лә анның билен кысып, күзләрен маңгаена менгергәннәр. Бүген кич Гуңгыйк кара савытындагы карага бозык каләмен манып, укытучысы турында инша язды. Гуңгыйк укытучысын үлеп яратмый. Шулай да: яшәсен минем кадерле укытучым, дип, өйгә эшен темамлады.

Гуңгыйктан соң әтисе, кара савытын борын төбенә үк шудырып (Сөләй тавык күзле иде), күршесенә ачу итеп: ул халык дошманы, дип югарыга бәла язды.

Барысы да йоклап беткәч, Сөләйнең хатыны Фәхисә кара савытын чоланга алып чыгып, сөяркәсенә түбәндәге хатны язды: и сөеклем! Сагындым үзеңне. Сөләйне җенем сөйми. Төннәрен ул кочса, сине күз алдыма китерәм. Кочаклауларың, үбүләрең мең ләззәт бит синең. Иртәгә Сөләй дуңгыз командировкага китә, сәгать төнге бердә лапас артына кил!

Кара савыты түзә, мескен. Нишләсен инде? Ул җансыз, ихтыярсыз, ул кешеләрнең икейөзлелегенә битараф, каләмнәре нинди булуга карамастан, теләсә кемгә манчыттыра.»

**Рабит**

## Игелек

***Идел үзенә кирәкмәгән бар нәрсәне ярга чыгарып аткан. Камил «Fanta»дан бушаган шешә эчендә түгәрәклэп бөгәрләнгән конвертлы хат күреп өнсез калды.*** Кемнең нинди серләрен саклый икән ул? Хатыны белән ут ягып талашкач, тынычланыйм, бераз йөреп керим дип елга ярына чыккан ир чит-ят берәүнең язмышына килеп кушылырга торамы? Юктыр ла, берәр төрле тузга язмаган чүптер әле, бала-чага шаяртуы. Камилнең тар авызлы савыттан калын конвертны алам дип ничекләр интеккәнен сурәтләүне сикереп кенә узарга рөхсәт ит, укучым. Шешәдән, ни гаҗәп, кәтелгән бер урынына ике калын конверт чыкты. Аларның икесенә дә шәмәхә төстәге

шыгырдап торган чит ил акчалары салынган иде. Гомерендә кулына доллар, евро тотып карамаган Камил миңгерәүләнеп калды. Әллә ничә кат санады, чутлады, безнең акчага күчереп, исен җыя алмыйча утырды... Их, шулай гына булса иде дә... Конвертларның берсеннән, каһәре, җанны бик үк иркәләми торган кәгазь кисәге дә чыкты шул. Кулдан тигезле-тигезсез басма хәрефләр белән анда түбәндәгеләр язылган иде: «Мин бер түрә кисәге. Тир түгеп тапмадым, ришвәт буларак кесәмә керде бу акчалар. Алар минем кулымны пешерә... Үзем кире кайтарыр идем дә, ул кеше алдына ни йөзем белән барыйм. Шешәне табып алучы теләсә ни эшләсен... Телисең икән, үзеңдә калдыр син аларны, моңа хакың бар. Тапшырам дисәң, менә сиңа адрес...».

Адрестан соң тагын бер җөмлә өстәлгән: «Мин бүген ләх исерек, аек баштан, бәлки, бу гамәлне кылмас та идем...».

Шешә табу мажарасыннан соң Камил ашаудан калды, ябыкты, гел үз эченә бикләнеп йөри торган караңгы адәмгә әйләнде. Ахыр килеп түзмәде, көннәрдән бер көнне, мунчадан чыккач, чип-чиста тәненә кетер-ак күлмәген, аның өстеннән пинжәген киеп, кәгазьдәге адреста күрсәтелгән кешене эзләп китте.

Яше 40-45ләр чамасындагы уртачарак кына буйлы, ачык чырайлы ир иде бу. Камилне ул ишек янында басып тыңлады, шешә эченнән алынган теге хатны кат-кат укып чыкты, евроларны әйләндереп-әйләндереп карады, иснәп тә алды бугай әле. Аннары бөтен барлыгы белән балкып, Камилне түргә дәште. Ике бүлмәле бик тар хрущевкада яши икән Фәнүс гаиләсе белән. Хатыны авылга, авырган әнисенең хәлен белергә кайтып киткән. Кече малае мәктәптә икән. Аннары Фәнүс икенче бүлмәгә керә торган ишекне ачты. «Фаяз, чык әле, улым, бире, кунак абыең белән күреш»,— диде ул. Коляскасының көпчәкләрен куллары белән әйләндерә-әйләндерә килеп, 14-15 яшьлек үсмер Камилгә күрешергә кулын сузды. «Безгә бит фатир бирделәр. Дүрт бүлмәле. Теге синең елга табылдыгың үз вакытында шул юлларда йөргән иде,—дип киная белән Камилгә күз кысып сөйләп китте Фәнүс.—Анда безнең Фаязга бөтен шартлар каралган. Күчкәләгәнче аз-маз ремонт ясап аласы бар иде дә, кесә такырлыгы хут бирми. Мөмкин булганның барысын саттык инде, менә шыр ялангач диярлек утырабыз.» «Минем компьютерны сатмадылар,—дип сүзгә кушылды Фаяз.—Дуслар белән дә шуның аша аралашам, дөнья белән дә танышам.»

Ике ир кухняда сөйләшә-сөйләшә чәй эчтеләр, мәй дә кабып куйдылар.

Күпме генә кыстаса да, Камил акча алмады Фәнүстән. «Ремонтыңны очла да, тизрәк күченегез, фатирыгызның рәхәтен күрегез»,—диде ул йөзендә шатлык балкыган иргә.

Әлеге мажаралардан соң Камил гаиләсенең эшләре гел үргә китте. Ни хикмәт, шуннан бирле киселепләр акчага тилмергәннәре булмады. Вакыт үтә торды, Камилләрнең балалары үсеп житте. Ходай рәхмәте, малай да, кыз да бик җүнле булдылар, укыдылар, тырыштылар, зур абруйларга ирештеләр, хәләл көч белән мал табып, гөрләтеп муллыкта яшиләр. Камилнең теге ут ягып талаша торган хатыны «җанкисәгем» дип кенә тора хәзер!

**Руфия ХӘМИДУЛЛИНА,**
*Казан*

# БӘЛӘКӘЙ ЗӘКИ

## Арба өстендә

Мин гомерем буена чит-ят җирләрдә йөрдем...

Бер ялга кайтканда әтиемнән сорыйм:

—Әти! Син пар ат җигеп ничәнче елны тракторларга гәрүчи ташыдың әле?

Әти аз гына утыра да исенә төшерә:

—Утыз алтынчы елны, улым. Апрель уртасыннан май беткәнче. Нигә сорыйсың син ул хакта?

Әтинең әйткәненнән мин хәтер яңартам. Шул утыз алтынчы елның язында без әти белән икәү пар ат җигелгән озын гына арба алдында, аска җәйгән чүпрәк паласта утырабыз. Безнең артта арбага салган гәрүчиле ике зур, озын мичкә. Барган уңайга әти чыбыркы сабы белән күрсәтеп миңа сөйли:

—Әнә, улым, уңдарак, ярты чакрым чамасында биек, текә тау. Ул тауның исеме Бакыр Чагыл. Урысларның Петр Первый дигән патшалары шул тау астында мич салдырып, Бакыр Чагыл тау ташыннан бакыр эреткән. Мич урыны әле дә бар. Күрәсеңме ул тауны?

—Ы-ы, күрәм. Өстендә бөркет очып йөри.

Әти җентекләбрәк карый.

—Күзең очлы икән синең. Чыннан да бөркет оча тау өстендә. Бакыр Чагылның теге ягындагысы—Җомай тавы. Бик күп еллар Җомай исемле бер казакъ бабай шул тау эченнән  кайлә белән чокып таш чыгарды. Ә менә без менеп барган тауның исеме Сәхәп дип атала. Менеп түбән төшкәч, Байгара исемле тау булачак...

Шулчак сибәләп вак кына яңгыр ява башлады. Әти атларны туктатып арбадан төште дә, мине күтәреп җиргә бастырды. Үзебезнең аска җәйгән чүпрәк паласны алып, мине баштанаяк шул паласка төрде.

Үзе елмая:

—Лотфулла Писерның яраткан, төпчек улын яңгыр чылатмасын әле...

Мине күтәреп утыртты да, арбаны урап чыгып аның теге ягыннан үзе дә менде. Егылып китмәсен дип уң кулы белән мине кочаклады. Сул кулы белән дилбегәне тарткалап атларны кузгатты.

—На-а, малкайлар! На-аа!

Ара-тирә палас аркылы мине сөйгәләп куя.

—Мин сөйләгәннәрне ныклап исеңдә калдыр, улым. Үскәч кирәк булуы бар.

Атлар ике мичкә гәрүчи төягән арбаны тауга өстериләр. Сәхәп тавына менеп барабыз... Ул вакыттагы яуган яңгыр, чүпрәк паласка төренгән кыяфәтем, 1936 елның язы онытылмаслык булып истә калган. Миңа ул чакта ике яшь тә тугыз  ай чамасы булган икән...

## Качкынлык

Күпмелек булганмындыр, төгәл генә әйтә алмыйм. Өч яшь тирәседер, мөгаен. Әни колхоз эшенә йөри: иртән яследә калдыра, кич алып кайта. Миңа, дус малайлар белән көнозын урамда «трай тибеп», уйнап кына йөргән ташбашка, ул ясленең бер тиенгә дә кирәге юк. Күрше дуслар Җомай Габдрахманы белән Хирахау Халите яслегә йөрмиләр, теләгән җиргә баралар, теләгәнчә уйныйлар. Ә ясләрендә тезеп кенә, кулларына тотыныштырып йөртәләр, өйлә ашын ашагач аерым агач караватка йокларга яткыралар: «Йом күзләреңне! Икесен дә йом! Йокла!»

Әйбәт кенә уйнап йөргән чакта йоклыйсы килми бит ул.

Ничә көн барганмындыр ясленәренә?.. Чөнки мин әле саный да белмим.

Ә ясле йорты биек каланчалы Пожарный каршында. Урам аша гына. Башы калай белән ябылган, кызылга буялган. Эченә керә торган ишегенә әллә ничә басмалы баскыч белән менәргә кирәк. Баскычы тактадан ясалган.

Көннәрдән бер көнне өйлә ашыннан соң тагын мине көчләп йокларга яткырдылар: «Йокла!» Күзләремне берәмләп тә йомып карыйм, икесен бергә дә... Йомган көйгә ике күз дә шунда ук ачылалар да, аннан соң аларны һич йомып булмый. Йоклап булмый инде! Миңа «Йокла!» дигән олы гәүдәле апа тегеләй-болай йөрде дә, минем каршыдагы сандык өстенә мендәр генә салып ятты, шунда йоклап та китте. Үзенә «Йокла!» дип әйтеп тә тормады. Мин аңа карап бераз яттым да, торып утырдым. Караваттан егылмас өчен тарттырып бәйләгән челтәргә аякларының баш бармакларын тыгып баса-баса өскә күтәрелеп, челтәрнең икенче ягына чыктым. Менгән кебек аяк бармаклары ярдәмендә идәнгә төштем. Теге апа йоклый, хәтта азрак кына хырлап та куя. Ул уянмасын дип аяк очына гына баса-баса баскычка чыктым. Ә аннан үзем генә төшә белмим икән. Әнинең кулына тотынып төшә идем бит мин бу баскычтан. Арт белән төштем. Кайту ягына йөгерәм. Өйгә керү юк, еппәреләм генә Хирахау Халите белән Җомай Гаптерие өйләре ягына. Алар безнең урамнан түбәнрәк торалар. Караңгылана башлаганчы өчәүләшеп Хирахауларда «мытыеслы» уйнадык...



Әни эштән кайтышлый мине алырга яслегә кергән. Ә мин анда юк. Кайда бу? Яследә белмиләр. Әни Хирахауларга килеп (кемдер әйткән!) минем ямаулы чалбарлы артыма зур учы белән ике мәртәбә чәпәде дә, үзе алдыннан йөгертә-йөгертә, әрли-әрли алып кайтып китте...

Икенче көнне иртән тагын яслегә... Әни мине җитәкләгән. Атлый торгач, кәкре тыкрыкка килеп җиттек. Кулны әнидән тартып алдым да, йөгереп шул тыкрыкка еппәрелеп кереп тә киттем. Әни мине тыкрык уртасында күлмәктән эләктереп алды. Биргәли башлады. Мин сөрән салып акырып елыйм. Үзем такмаклыйм: «Бармыйм яслегезгә-ә! Бармыйм! Барыбер качам мин аннан! Кача-ам!»

Гадәткә әйләндердем мин ясләдән качуны. Саклыйлар качмасын дип, ә мин һәркөнне качам. Бер көнне качып, Тал Борынына посып ятып йоклаганмын. Төнлә белән ай яктысында тапканнар. Елый-елый эзләгәннәр.

«Яследән качулар» ничек булып беткәндер, хәтердә юк. Тик тал арасында йоклаганнан соң минем яслегә барганым булмады кебек.

## Ата каз маҗарасы


1937 ел. Июльдә миңа дүрт яшь тулачак. Әни иртән колхоз эшенә китәргә әзерләнә. Көндезлеккә миңа эш куша:

—Зәки улым! Кояш абзар кыегының уртасына җиткәч, көмәч калае белән казларга ашарга бир. Вак итеп ипи турап эченә тутырып куйдым. Солылары янында. Кара аны, ишетсен колагың, уенга алданып онытa күрмә.

—Ярар, онытмам.

«Кояш абзар кыегының яртысына җиткәнче» уйнарга урамга чыкмыйча кояшны сагалыйм, күздән ычкындырмыйм. Азрак йөрим дә ишек алдында кояшка карыйм, азрак йөрим дә тагын карыйм. Ә кояш үч иткәндәй һич кабаланмый, һавада бер урында тик торган кебек. Бик озак көттереп көчкә-көчкә барып җитте ул теге «абзар кыегының яртысына». Ипи туп-тулы түгәрәк көмәч калаен корсакка терәп күтәреп, киттем чыгып казлар ашатырга. Ишек алдына чыгу белән ике ана каз бәбкәләре белән, зур гәүдәле, озын муенлы ала ата каз, мине уратып алып, иярделәр миңа. Ишек алдының кырыенарак, арбалар йөрми торган урынга, читәннән ерак түгел җиргә куйдым теге ипи калаен. Җиргә куйдым да турая башладым. Шулчак теге ала ата каз озын муенын

тагын да ныграк озынайтып сузып минем ялангач корсактан томшыгы белән эләктереп алды. Корсакның тиресен үзенә тарта, муенын боргалап, минем корсактагы эләктергән жирне борыпмы бора. Авыртудан мин жир жыртып акырам. Өстәвенә ике канаты белән миңа бирепме бирә. Минем кот очты! Качарга чамалыйм. Житмәсә, мине уратып алган ике ана каз, бәбкәләре белән ата казга көч-гайрәт биреп, миннән көлгән кебек «пипиләп» тавыш биреп боталаналар... Ничек житте алай, көчкә ычкынып йөгерә-кача ишек алдыннан чыгып киттем. Ата каз тешләп борган жир күбеп чыкты. Авырта.



Әти иртән ат белән урманга киткән иде. Каршысына йөгердем. Бераздан арбага утын төягән әти күренде. Кулын сузып, мине арба өстенә тартып алды...

Корсактагы күпкән жирне әтигә күрсәтеп, үземне ата каз ничек итеп талаганны сөйләп бирдем. Әти шунда әйтеп куйды:

—Син, улым, үсеп житкәч егет буласың. Татар егете. Бу ата казны син болай гына калдырма. Үч ал син анардан.

—Ничек итеп, әти?

—Синең кебек чакта Эстәрле елгасы янында безнең күрше Кара Абдулла бабайның ата казы мине дә нәкъ синең кебек итеп талаган иде. Икенче көнне киндер күлмәк кидем дә, ул ата казны муеныннан тотып, суда өстерәп йөрдем. Шуннан соң ник миңа бер тисен...

Кич буена уйланып йөрдем дә,икенче көнне теге ата каздан үч алдым... Әти әйткәнчә...

Шуннан соң ата казыбыз, очраганда азрак ысылдап алгаласа да, башка миңа һөжүм итмәде...

## Балыкчы булдым

Шул ук 1937 ел. Әле яз үтеп бетмәгән.

Миннән дүрт яшькә зуррак Мансур исемле абыем балык тотарга йөри башлады. Кармагы бар. Бәләкәй-бәләкәй генә ташбаш исемле балыклар алып кайта. Аның капкачлы кечкенә тимер савыты бар. Кесәсенә салып йөртә. Шунын эчендә эреле-ваклы кармаклары бар. Минем дә балык тотарга барасы килә. Сорыйм абыйдан: «...Бер генә кармак бир әле миңа», дим.

Кесәсеннән теге калай савытны чыгарып капкачын ача да, эчендәге кармакларны саный:

—Берәү, икәү ..., жидәү.

Жиде кармагы бар! Әлләлә-ә-ә!

Санап бетергәч, савытның капкачын яба да, чалбар кесәсенә сала.

—Кит бар! Үземә дә нибары жидәү генә.

—Берсен генә бир инде-е?

—Суктым, ектым! Кит моннан!

—Берне генә-ә?

Мина сыек зәңгәр күзләрен теки дә, кармак урынына киңәш бирә:

—Балнис белән ышкул артында дөнья хәтлек кыягазлар аунап ята. Шуларны бер капчыкка жый да, Үтил Хәйрулла бабайга алып бар. Жыйган кыягазга кармак бирә ул...

—Бер генә кармак бир инде-е?

—Бирмим дидем бит инде. Соранма да.

Икенче көнне көтү белән торам да, Пожарныйдагы солы салып ат башына кидерә торган баулы капчыкны эзләп табам да, китәм балнис йортына кыягаз жыярга. Балниска күрше генә «ышкул» ишек алды. Кыягаз анда да күп. Кыягаз жыеп Үтил Хәйрулла бабай йортына табан китәм.

Таш келәт яныннан минем якка Үтил бабай килә. Сорый:

—Нәстә алып килдең, улым?
—Кыягаз.
—Кем улы син?
—Лотфулла Писернең иң бәләкәй улы.
—Ала-ай икән. Кая, карыйк.
Капчыкны ала да, селки—авырлыгын чамалый.
—Бик күп түгел икән. Нәстә сорарга итәсең инде?
—Кармак кирәк. Балык тотарга.
—Карма-ак?! Монда бер кармаклык юк бит. Нәстә эшләрбез икән соң? Азрак бит.
Мин мышкылдап танауны тартам да, аны күлмәк җиңе белән тиз генә сөртеп алып, соранырга тотынам:
—Үтил баба-ай! Җитмәсә дә, бер генә кармак бир инде, ә?
—Ярар, бирермен. Лотфулла малае булгач, бирергә кирәктер. Әйдә, келәткә керик. Күтәр капчыгыңны. Шунда бушатырсың кыягазыңны. Тик кыягазың азрак. Иртәгә тагын шушының хәтлек китер, ярармы?
—Ярар.
—Иң бәләкәе сиңа кармакның. «Чебен кармагы». Илләмә ташбаш, чабак, алабуга дигән балыклар шәп эләгәләр инде. Өлгер генә тартып чыгарып.
Кечкенә бер кыягазга төреп, миңа кармак тоттыра.
—Югалта күрмә кайтканда!
Ниткән югалту ди ул! Рөхсәтсез-нисез әнинең токмач кисә торган пычагын алам да, Тал Борынына төшеп китәм. Бер төп-төз озын талны кисәм. Менә шәп кармак сабына!
Өйгә кайткач, чыгып китмичә шунда уралам. Миңа әнинең өйдә юклыгы кирәк. Мине чуаш җебе кызыксындыра. Энә-җеп, ямаулыклар тутырган фанер тартманы шкаф астыннан эзләп табам. «Чуаш җебе»—киндердән эрләгән нечкә генә, үзе бик нык җеп. Аны чуаш хатыннары базарда бәйләме белән саталар. Берсе бер тәңкә. Әни аны: «Ямауга шәп җеп!»—ди. Җепне табам да, чамалап, үземә кирәк хәтле кисеп алам. Тартманы урынына куям.
Җепнең бер очын теге очлы кармакка бәйлим, икенче очын теге озын талның нечкә очына бик ныклап бәйләп куям. Кармак—әзер!
Кармакны җилкәгә салып «балык тотарга» китәм. Кем дә булса минем балык тотарга барганны күрсен иде дә бит, Пожарный эчендә берәү дә юк шул. Дежур бабай Пожарныйның каланчасы башына менеп утырган. Мине күрми дә...
Берәү дә күрмәсә дә, урам уртасыннан атлыйм, Эстәрле елгасына «балыкка барам!..»
Урам бетеп, Эстәрле елгасына терәлеп туктаган җир безнең ише ыбыр-чыбыр малайларның су керә, балык тота торган урыны иде.
Эләкмәдеме микән диеп вакыт-вакыт кармакны судан алып карыйм. Юк балык! Тагын салам кармакны суга. Тагын алам тартып. Юк балык!..
Бервакыт арттан миңа кемдер дәшә:
—Нәрсә, Писер баласы, балык тотасыңмыни?
Әйләнеп карыйм. Шушы урамның очында яшәүче Мөхми Гәрәй тора басып. Урамча—Гуркый! Миннән 3-4 яшькә олы. Әйбәт малай ул—бәләкәй малайларны кыйнамый. Мин дәшмим. Тагын сорый:
—Эләгәме балык?
—Юк. Эләкми шул нигәдер.
—Балык күп ул монда. Чиртәме?
«Чиртәме» дигәннең мин нәрсә аңлатканын белмим.
Шуңа күрә дәшмим.
—Нигә дәшмисең? Теленне йоттыңмы әллә? Кая, карыйм әле кармагыңны. Челәүчене бармы икән, әллә балык ашап киттеме икән?
Кулдан кармак сабын ала да, судан кармакны тартып чыгара.
—Челәүчене юк бит кармагыңда.
—Нәстәмә ул челәүчен?
—Ә син балыкны кармакка ничек эләгә дип уйлыйсың? Ә?

—Су астыннан йөзеп барганда, кармакның очлы башына ышкылып эләгә дип уйлыйм.

Көлә Гуркый:

—Дурак син, Писер баласы! Дурак! Балык тотканда кармакка челәүчен кидерәләр. Аякка оек кигән кебек итеп. Бел, белмәсән! Балык кармактагы челәүченне ашый башлый да, очлы кармакка эләгә. Кармакны йота да, йөзеп китә башлый. Тартып аласын кармакны. Эләккән балык тыпырчынып кармак белән бергә судан килеп чыга...

Сөйләвеннән туктап, кармак җебенә карый:

—Синен кармакның тәләкәсе юк бит. Ник куймадың?

Мин тәләкәнең нәрсә икәнен белмим. Дәшмим.

Гәрәй җирдә яткан бер коры чыбыкны алып, бармак озынлыгы хәтлек кенә итеп сындырып ала, кармак җебен кармактан үзенең кендегенә хәтлек итеп үлчи дә, шул урынга теге чыбык кисәген бәйли. Кармакны миңа тоттыра да, теге чыбыкның калганын тотып, яр туфрагын казый башлый. Казыган туфрак эченнән берничә челәүчен килеп чыга да, боргаланып-боргаланып шуышып кача башлыйлар.

—Качмый торыгыз әле!

Миңа борылып, «Сал түбәтәеңне!»—ди.

Мин аңа түбәтәйне бирәм. Ул челәүченнәрне түбәтәй эченә сала.

—Тот! Качып чыгып китмәсеннәр.

Бер челәүченне алып, учына салып шап-шоп китереп, икенче учы белән берничә тапкыр суга да, кармакка кидерә. Кармак сабын минем кулдан ала. Кидерелгән челәүченгә төкерә дә такмаклый:

*Балык кап-кап,*
*Яр башында ялтырап ят!*

Челәүченле кармакны суга сала. Кармак бата, ә тәләкә су өстендә йөзеп йөри—батмый. Мине өйрәтә Гуркый-Гәрәй:

—Балык челәүченле кармакны йоткач, йөзеп читкә китә башлый. Шулчак су өстендәге тәләкә бата башлый. Тартып аласын кар...

Мин акырам:

—Тарт, Гуркый! Тарт! Бата бит тәләкән!

Гәрәй кармакны тартып ала. Тик анда ... балык та юк, челәүчен дә юк.

—Пис-сер! Киш-шер! Акыра дөнья ертып. Балыкны куркыттың бит акырып. Ишәк!

—Балык су астыннан ярда кычкырганны ишетәмени инде?

—Ишетә шул! Шуна күрә балык бит ул—ишетә дә кача. Шаулама, акырма бүтән. Тик кенә утыр к... кысып...

Түбәтәй эченнән өзек ярты челәүне ала да, кармакка кидереп, аны суга ташлый:

*Балык кап-кап,*
*Яр башында ялтырап ят!*

Гәрәйнең кармакны суга салуы була, тәләкә шунда ук суга чума. Гуркый кармакны тартып чыгара... Кармакта көмеш төсле, ап-ак бер балык чәбәләнә-чәбәләнә ярга килеп төшә дә, җирдә сикерә башлый. Гуркый аны кармактан ала да миңа тоттыра.

—Тот, Әхмәт Зәки! Ташбаш исемле балык була бу!

Күп тә үтмәде, Гәрәй әллә ничә ташбаш тотты. Кармакны миңа бирә:

—Әйдә, балык тотарга үзең өйрән инде хәзер. Мин карап торыйм, ничек тотарсың икән.

Ул өйрәтеп кырда басып тора. Мин ташбашлар тотам. Тагын дүрт-биш эләкте.

Балыкларны түбәтәйгә тутырып, әллә кем булып, киттем өйгә кайтып... Пожарный кырыеннан үтәм. Әти белән бергә Пожарный эчендә бабайлар утыра. Минем балыкларга карап барысының да исләре китте. Берсе әйтә:

—Мондый балыкчы малаең булгач, син, Лотфулла, хәзерге көннән балык кына ашап яшәрсең инде.

Икенчесе:
—Сатарга да калыр әле.
Өченчесе, түбәтәй эченә карап:
—Сатарлык юк әле монда. Ашарга гына җитәрлек.
Мин:
—Күп тоттым!—дим.—Әле ярда, тал арасында куыш ясап, күбесен шунда калдырдым. Түбәтәйгә сыймадылар алары. Иртәгә алып кайтырмын.
Бабайлар шаулашып көлешәләр. Берсе әйтә:
—Бу малаең синең, Лотфулла, чын балыкчы булган да киткән бит. Ай-һай оста сөйли. Куышта, имеш. Балык та тоткан, арттырып сөйли дә белә.
Түбәтәй белән балык күтәреп өйгә керәм дә, аларны кин тәрәзә төбенә матур итеп тезеп куям. Йоклап иртән торсам, анда бер балык та юк. Тәрәзә төбендә ялманып ала песи генә утыра.

## Үгезле хатирә

Алтынчы сыйныфта укыганда, кар яугач, мин үзебезнең бер яшьлек печкән үгез-бозауны кул чанасына җигеп, шуны тартып йөрергә өйрәттем. Үгезнең җигеләсе килми, ә минем җигәсе килә—үгез белән айдан артык тартыштык, көрәштек, сугыштык. Тәки мин җиңдем, үгезне җиктем. Шулай булса да үгез вакыт-вакыт буйсынмаска тырышып, фетнә куптарып, киребеткән холкын күрсәткәләп ала иде. Үгезне җигәм, урманнан рөхсәтсез утын ташыйм, өй диварларын сыларга кешеләргә кызыл балчык, ком, ат тизәге сатам. Печән җитсә, яланнан йөк-йөк печән ташыйм. Әти гражданнар сугышыннан бик нык имгәнеп чыккан, миннән дүрт яшькә олы абый эшкә йомшак. Гаиләдә утын, печән әзерләүдә мин, унөч яшьлек малай, төп көч.

Ике яшьлек үгез йөкне арбага күпме төясәң дә тарта торган яхшы эш малына әйләнде. Элекке елдагы кебек үҗәт булмаса да, кайсы чакны, бигрәк тә эссе көннәрдә, чыгымлап, «кигәвенләп» ала торган гадәте бар.

Беркөнне мин Локман Атрубы дигән яланга печән алып кайтырга киттем моның белән. Үгез пошкыргалап ярты юлдагы Гөмбәз үреннән түбәнгә табан төшеп бара. Көн эссе, кигәвеннең иң кызган, күбәйгән чагы. Үгезнең сыртына кызгылтырак зур кигәвен кунса, ул «мңгырт» дигәнгә ошаган тавыш бирә. Мин өскәрәк, фурман урәчәсенә утырганмын. Үгез «сигнал биргән» көенә каеш чыбыркы белән бер сугуда теге зур кигәвенне бәреп төшерәм...

Гөмбәз елгасы аша салынган ялан күперенә якынлашабыз. Үгез нилектәндер адымнарын тизләтте. Соры кигәвеннәр аның арткы ике боты арасында җыелганнар, бәләкәйрәк түбәтәй хәтлек өелеп торалар, канын эчәләр. Үгезкәем күпергә килеп тә керде, кырт унга борылды, урәчәсез күпердән... суга сикерде!

Бу турда су әле тирән түгел, тезгә дә җитми. Тик су астында калын булып кара, йомшак ләм катламы җыйналган булган. Ике тәртә арасындагы үгез тоташы белән су эчендә. Арбаның алгы ике тәгәрмәче, алгы кучәр күпер читендә асылынып торалар. Арба үзе ике арткы тәгәрмәч белән күпер өстендә. Үгез исә кырын төшеп яткан да, шул хәлендә суга, ләмгә батканнан-бата бара. Мин, нәрсә эшләргә дә белмичә, каушап калдым. Агач камыт кигән үгез буылып хырылдый ук башлады. Чишенмичә суга сикердем дә, камыттагы заноза бауларын чишеп, үгезне камыттан азат иттем. Ә үгез ята рәхәтләнеп су эчендә, кымшанмый да. Кигәвеннәр дә юк ана, печәнгә дә барасы юк. Ләмгә батканнан бата баруын белми дә. Батып үлсә?! Арбадан тиз генә сүс арканны чишеп алам да, тагын суга кереп китәм. Үгезнең ике мөгезенә арканның бер очын ныклап бәйлим, икенче очын тотып елга ярына чыгам. Ярда үсеп утырган тал куакларыннан юанрак талны сайлап алдым да, арканны тарттырып шуңа бәйләп куйдым. Үгез башы аркан белән мөгезеннән тарттырылган, суда ятса да хәзер батмый инде... Тояклары су астындагы каты төпкә җитте, ахрысы, үгезнең гәүдәсе батудан туктады. Су өстендә исә мөгезле башы гына күренә...

Бу суга кереп яткан җык үгезне чыгарырга кирәк бит инде?! Нишләргә? Чыбыркы белән ярыр идең, гәүдәсе тоташ су эчендә. Арканнан тартып карыйм, үгез селкенми дә. Арбаның артын алгы кучәрдән күтәреп алып, күпернең икенче ягына алып чыгып, юл читенә куйдым. Алгы кучәрне, ике алгы тәгәрмәчне, ике тәртә белән агач

камытны да арба янына алып чыктым. Арбаны җыеп куйдым. Ә үгезнең гаме юк, ята рәхәтләнеп су эчендә. Хәтта күзен дә йомган. Әллә йоклый инде?

Арба янына чыгып утырдым. Юеш киемне салып үләнгә җәйдем—кипсен. Өстә бер чалбар гына калды. Уйлыйм: «Көн сүрелә төшкәч, ачыккач, чыгар әле бер!» Яттым арба янына яшел үләнгә.

Бераз яткач, колакка трактор тавышы килеп керде бит; «Ток! Ток! Ток!» Тал арасыннан тавыш килгән яккарак чыгып карыйм. Бик ерак түгел, ярты чакрым чамасы булыр, Бакыр Чагыл тау астындагы иген кырында ХТЗ тракторы эшләп йөри. Нииндидер культиватор таккан. Киттем шунда. Тракторда күрше урамда яшәгән Каран Биктимере утыра. Тоташ кара тузан каплаган. Агарып күзләре белән тешләре генә күренә. Миннән өч яшь кенә олы бу. Сугыш башланганнан бирле колхозда эшли. Олылап исәнләшәм моның белән:

—Биктимер абзый, исәнлекме? Айгырыңны туктат әле,—дим.

Тракторын туктатты, газын акрынайтты. Тракторыннан төшеп кул бирә. Аңлаттым менә хәлне.

—Әйдә, чыгарыш инде.

—Кәничне!

Тиз генә трактордан культиваторын аерып алды.

—Утыр! Киттек! Күптән кызык күргән юк иде. Барыйк әле. Ату чуаш аты кебек эш тә эш.—Юктан да кызык таба белә торган малай ул Биктимер.

Тоташы белән су эчендә яткан үгезне күргәч, тракторчы Биктимернең шатлыгының иге-чиге булмады. Бот чаба-чаба көлде. Үзе сөйләнә:

—И-и! Күпер хәтлек күпердән сикер инде, ә?! Арба белән!

Үзе генә сикермәгән, арба хәтлек арба белән бит!

Куанып, көлеп туйгач, елмайган күзләрен текәп:

—Тагын арканың бармы?—дип сорады.

—Бар, сүс аркан бар.

—Син, давай, чалбарыңны да сал. Ыштаның булса, аны да сал. Ике аркан белән үгезнең бот төпләреннән яхшылап бәйлик. Ике урыннан—алдыннан да, артыннан да. Менә кадәр трактор белән берәү дә суга баткан үгезне тарттырып чыгармаган. Әле без синең белән беренчеләр булабыз!

Мин тоташ чишенеп суга төштем дә, ләмгә бата-чума үгезне корсагының алдыннан, артыннан, бот төпләреннән ике сүс аркан белән уратып бәйләдем. Ярда ике аркан очларын бергә бәйләп, элмәк ясап, трактор артына тактык. Моның өчен Биктимер тракторны арты белән ярның кырына ук китереп туктатты. Арканны таккач, Биктимер тракторга менеп утырды.

Үгез алай-болай була күрмәсен дип мин бераз «шыртлыйм».

—Син, Биктимер, кисәк тарттырма. Акрын гына, салмак кына өстерәт. Ялгыш үгезне үтереп куймыйк.

Газны аз-маз гына ачып, үгездән күзен алмыйча, Биктимер тракторны алга бирә башлады. Аркан нык тартылды һәм ... үгез ләм эчендә кузгала башлады.

—Китте бу, китте!—дип, мин ярда сикергәлим. Тракторда Биктимер «ур»ра!» кычкыра. Үгезне өстерәп сөзәк ярдан яшел чирәмгә алып менгәч, тракторын туктатты. Ул трактор туктау белән, үгез торып басты. Өстеннән шабырдап су ага. Мин исем китеп үгезгә карыйм:

—И-и!—дим.—Карале, Биктимер, үгезгә. Бик шәп итеп юылып чыккан бит бу. Кызылы—кызыл, агы—ак!

—Бә-әәк кызык булды бит әле бу, әй!—диде Биктимер.—Синең белән миңа бу гомер буена сөйләргә истәлек булып кала бит инде.

Шул вакыйгадан соң күп еллар узар, күп юллар үтелер. Авылга ялга кайткан чакларда мин Биктимер абзыйның хәлен белергә керәм. Ул бүген дә исән-сау. Инде сиксәнне узган тимер кебек таза бабай, күз тимәсен. Очрашкач, безнең авызлар ерыла, исәнлек-иминлек сорашкач, «теге үгезне судан трактор белән өстерәткәнне» искә алабыз, көлешәбез. Шул вакыйга чыннан да икебез өчен дә малай чакның иң кызыклы хатирәсе булып калды...

**Зәки ЗӘЙНУЛЛИН**

## Профессор мәсьәләне чишә алмаган

Ни хикмәт, профессор белән беренче очрашуым М. Горький исемендәге Культура һәм ял паркында булды. Чаңгы секциясенең көз айларындагы тренировкасы алдыннан "мускулларны кыздыру" өчен бер сукмак буйлап ашыкмый гына чабып бара идем. Кинәт каршыма кап-кара зур сакаллы бер бабай чатыр чабып килеп чыкмасынмы! Яшерен-батырын түгел, бераз каушап калдым, шулай да, аңа юл бирим дип, сукмактан читкә тайпылырга башым житте. Ә ул мине, унжиде яшьлек университет шәкертен, мөгаен, спорт сөюче мәсләктәше дип күзаллагандыр, уң кулын күтәреп, үзенчә сәламләп узып китте.

Соңыннан, аны университет коридорында күргәч, сабакташларымның берсеннән белештем: паркта очраган сакаллы "бабай" алгебра кафедрасының мөдире профессор Морозов Владимир Владимирович булып чыкты. Хәзерге яшем каланчасыннан карасаң, ул бик яшь булган әле ул чакта.

Ике ел узгач, аның лекцияләрен тыңлау да һәм аның каршысына утырып имтихан бирү дә насыйп булды. Имтихан бирүче житмеш биш студент арасында ул паркта очраган малайны танымагандыр дип уйлыйм. Билет сорауларына җавап биргәндә дә бераз каушаган идем. Шуңа күрәдер, исбатларга тиешле бер теорема авторының исемен бозып, Фредгольм диясе урынга Гредфольм дип ычкындыруым аның ачуын чыгарыр дип бөтенләй югалып калмавым үзенә күрә бер казаныш булды ул чакта. Әмма профессор, хәзер аңлавымча, Зигмунд Фрейд әсәрләре белән таныш булгандыр, ят исемне ялгыш әйтүемнең сәбәбен яхшы белгәндер. Аның куе сакал белән чикләнгән битендә елмаю билгеләре күренеп үтте. Имтиханны исән-имин ерып чыктым.

"Бабай"ның кемлеген әйткән сабакташым белән дуслашып та киттек. Вуз тәмамлавыбызга ярты гасырдан артса да, очрашкалап торабыз, һич югында телефон аша гына булса да хәл белешәбез. Бер очрашу вакытында мин ана профессорны беренче тапкыр кайда күрүемне сөйләгән идем. Ә ул миңа профессор белән булган бер мәзәк вакыйганы бәян итте. Шуны сез журнал укучыларыбызга да житкерергә булдым.

Владимир Владимировичның кафедрадагы хезмәттәшләре, бигрәк тә гүзәл затлар, аның ни өчен гомерен ялгыз, заяга уздыруы белән кызыксыналар иде. Кайчандыр, яшь чагында аның, университетта эшләгән бер чибәр кызга гашыйк булып, җавапсыз мәхәббәткә юлыкканы, чибәрнең аның дустын тормыш иптәше итеп сайлаганы, шуннан соң яшь математикның шул чибәргә тугрылыгын гомер буена саклавы турында үзем дә ишеткән идем.

Хәер, сүземне мәзәк вакыйга дип башлаган идем бит әле. Шулай, көннәрдән бер көнне, кафедрадагы гүзәл затлардан иң шаянлыдыр инде, болай дип сорый:

—Владимир Владимирович, зинһар, әйтегез әле, йоклаган чакта сакалыгыз ничек урнашкан була, юрган астындамы, әллә өстәме?

Профессор, бераз уйланып торгач, болай ди:

—Бу турыда моңарчы уйлаганым юк иде әле. Әмма чыннан да бик кызык, житди һәм мөһим проблема. Ярый, сез миңа хет бер генә атна вакыт бирегез, мин шул арада тикшеренүләр уздырырмын, мәсьәләгә ачыклык кертермен.

Әмма атнадан да күбрәк вакыт уза, ә профессор сакалы турында берни дә әйтә алмый. Ниһаять, ул проблеманың чишелеше юклыгын танырга мәжбүр була. Чөнки йокларга яткач "проблема" йокыга китәргә комачаулый, ә тәмам арып йокымсырый башлаганда "аң" дигәне сакалның юрганга карата торышын ачыклап хәтер сандыгына салып куярга өлгерә алмый икән. Ассистентка-фәләне булса, мәсьәлә чишелер иде кана. Ләкин профессор буйдак килеш гомер кичергән шул.

**Ким ШАКИРОВ**

## Ictimagi-mədəni tormışıbızdan
## Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

### ТУКАЙ СӘЯХӘТКӘ КИТТЕ

Татарстан Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев Санкт-Петербургка эш визиты белән барды. Ул Төньяк башкала җәмәгатьчелегенә «Янарыш» фондын тәкъдим итте. Санкт-Петербургның Пушкин музеенда Габдулла Тукайга багышланган «Мин мәңгелеккә омтылам» күргәзмәсенең ябылу тантанасында катнашты.

Тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне торгызу республика фондын тәкъдим итү чарасы Борис Ельцин исемендәге Президент китапханәсендә узды. Китапханәдә проектка багышланган стендлар, Изге Болгар һәм Свияжск шәһәр-утравындагы тарихи һәйкәлләр, яңа төзеләчәк корылмаларның макетлары урнаштырылган иде. «Тарихи һәм мәдәни мирасыбызны киләчәк буыннарга саклап калдыру теләге мәдәният өлкәсе вәкилләрендә генә түгел, ә матди хәленә карамастан, илдә яшәүче күп халыкта кайгыртучанлык уятуы сөендерә. «Янарыш»ка ярдәм итәргә теләүчеләр бик күп. Һәркем хәленнән килгәнчә булыша, без аларның һәркайсына чиксез рәхмәтле»,—диде М. Шәймиев.

Чарада Россия Конституция суды рәисе Валерий Зорькинның сәламләвен дә укыдылар. «Янарыш» фондын тәкъдим итүдә катнашучыларны һәм кунакларны Санкт-Петербург вице-губернаторы Роман Филимонов, Ленинград өлкәсе вице-губернаторы Александр Кузнецов та сәламләде. Әлеге чарада Татарстан Премьер-министры урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева да катнашты.

Шул ук көнне М. Шәймиев Президент китапханәсе директоры Александр Вершинин белән очрашты. Татарстан Дәүләт Киңәшчесе фондны тәкъдим итү чарасын югары дәрәҗәдә оештырулары өчен рәхмәт белдерде. Очрашу барышында Президент китапханәсе һәм Татарстан Республикасы арасында алга таба хезмәттәшлек итү хакында фикер алыштылар. Мәгълүм ки, моңа кадәр З. Вәлиева һәм А. Вершинин Казанда Президент китапханәсенең филиалын булдыру турындагы килешүне имзалады. Ул шәһәр үзәгендә урнашыр дип көтелә.

Төньяк башкалага эш визиты барышында М. Шәймиев Пушкин исемендәге илкүләм музейда да булды. Биредә Татарстан Милли музее оештырган, татарның бөек шагыйре Габдулла Тукайга багышланган «Мин мәңгелеккә омтылам» күргәзмәсенең ябылу тантанасы узды. Әлеге күргәзмә юктан гына Пушкин музеенда оештырылмаган. Тукай гомереңен башыннан ахырына кадәр күңелендә рус әдәбияты даһиена зур ихтирам саклаган. Ул Пушкин, Лермонтов һәм күп кенә башка рус шагыйрьләренең шигырьләрен татар теленә тәрҗемә иткән. Күргәзмәдә Татарстанның танылган рәссамнары әсәрләре дә урын алган. Күргәзмә исә алга таба Россия һәм БДБ илләре буенча сәяхәткә китәчәк. Тиздән күргәзмә Мәскәүдә күрсәтеләчәк.

### ҖӘЛИЛ ПРЕМИЯСЕ ЛАУРЕАТЛАРЫ

Муса Җәлил исемендәге республика премиясе комитеты утырышы узды. Ябык тавыш бирү юлы белән быелгы бүләк ияләренең исемнәре ачыкланды.

Җырчы Филүс Каһиров, Казан милли тикшеренү технология университеты аспиранты Ярослав Ключников, Әлмәт татар дәүләт драма театры коллективы шагыйрь бүләгенә лаеклы дип табылды. Ә бер премияне «Ялкын» журналы һәм Татарстан Республикасы Яшьләр үзәге бүлеште. Комитет, Төркиядә узган XXV Бөтендөнья кышкы универсиадасы җиңүчесе—чаңгычы Алия Иксанованы бүләкләү өчен, ТР хөкүмәтенә өстәмә—бишенче премия сорап та мөрәҗәгать итте.

Һәр премия, махсус таныклык һәм күкрәк билгесеннән тыш, 100 мең сумга тиң. Аны лауреатларга Бөтенроссия яшьләр көнендә—27 июньдә тапшыру күздә тотыла.

### БӨЕК ШАГЫЙРЬНЕ ЯД ИТЕП

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында бөек шагыйребез Һади Такташның тууына 110 ел тулуга багышлап, «Киләчәккә хатлар» дип исемләнгән тантаналы кичә булды.

Гыйсъянчылык рухындагы иҗаты белән

халкыбызның сөеклесенә әверелгән шәхескә багышланган кичәне шагыйрьләр ачып җибәрде. Татарстан Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов, Ренат Харис, Рәдиф Гаташ, Газинур Морат, Эльвира Һадиева, Рүзәл Мөхәммәтшин татар шигъриятенен классигына карата уй-фикерләрен ялкынлы шигырь юллары белән әйтеп бирде. Кичәгә шагыйрьнең якташлары—Мордовиянең «Якташлар» татар милли-мәдәни мохтәрияте рәисе, Мордовиянең атказанган эшкуары, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Шамил Бикмаев, Саранскидагы «Мәгариф» татар китапханәсе мөдире Рәшидә Ипкаева, Саранскидагы «Татарстан» сәүдә йорты генераль директоры Ринат Альмяшов та килгән иде. Алар шагыйрьнең юбилеен үзләрендә дә зурлап билгеләп үтүләре турында сөйләде, Саранскида татар китапханәсе ачуда зур ярдәм күрсәткәне, китаплар җибәргәне өчен Татарстан хөкүмәтенә рәхмәт белдерде. Аннары Г. Камал театры артистлары тарафыннан Һ. Такташның тормыш юлын, каршылыклы иҗатын, трагик язмышын чагылдырган театрлаштырылган тамаша күрсәтелде.

Соныннан Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева чыгыш ясады. Ул Һади Такташның идеологик басымга бирешмичә, каршылыкларны җиңеп, үзенең асылын саклап кала алган бөек шагыйрь булуын әйтте.

## ЭРМИТАЖДА—СӘНГАТЬ КОРАЛЫ

Татарстан Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев Казан Кремлендә Дәүләт Эрмитажы директоры Михаил Пиотровский белән очрашты. Башкалабызга ул «Эрмитаж-Казан» үзәгендә «Дәүләт Эрмитажы җыентыгыннан сәнгать коралы» күргәзмәсен ачуда катнашу өчен килгән.

Минтимер Шәймиев Татарстанга игътибары һәм «Татарстанның мәдәни мирасы: борынгы Болгар шәһәре һәм Свияжск шәһәр-утравы» проектына ярдәме өчен Михаил Пиотровскийга рәхмәт сүзләре җиткерде. Ул шулай ук кунакка Тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне торгызу республика фондының беренче елдагы эшчәнлеге йомгаклары турында сөйләп үтте. М. Пиотровский (ә ул «Янарыш» фондының Попечительләр советы әгъзасы булып тора) алга таба да фонд эшчәнлегенә ярдәм итәсенә ышандырды.

Әңгәмә барышында «Эрмитаж-Казан» үзәгендәге мәдәни проектлар, аерым алганда, сәнгать коралы күргәзмәсе буенча фикер алышу булды.

## ТУГАНДАШ ИЛНЕҢ ЯҢА КОНСУЛЫ

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Төркиянең Казандагы Генераль консулы Әхмәт Акынты белән очрашты.

Ф. Мөхәммәтшин Акынты әфәндене сәламләп, аны Төркия Республикасының Казандагы Генераль консулы вазифасына билгеләнүе уңаеннан котлады. Ул Татарстан һәм Төркияне бер-берсе белән җылы мөнәсәбәтләр генә түгел, бәлки традицияләрнең, тел, тарих һәм мәдәниятләрнең охшашлыгы да бәйләвен ассызыклады. «Без кайбер мәсьәләләрдә Төркиядән үрнәк алдык»,—дип искәртте Татарстан парламенты башлыгы һәм, Төркия белән Татарстан тормыш эшчәнлегенең төрле өлкәләрендә актив хезмәттәшлек алып бара, дип өстәде.

Әхмәт Акынты очрашу барышында Дәүләт Советы Рәисенә Казанда Төркия вәкилләре катнашында булачак кайбер вакыйгалар турында сөйләде. Аерым алганда, башкалабызда март башларында сәүдә-икътисади хезмәттәшлек буенча Россия-Төркия хөкүмәтара комиссиясе утырышын уздыру турында сүз барды.

## ТУФАН ПЛАНЕТАСЫ

Кояш системасындагы кече планеталарның берсе татар шагыйре Хәсән Туфан исеме белән аталган. Бу турыда диплом-таныклыкны Татарстан Милли музеена даими саклануга Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева тапшырды.

Планетаны Хәсән Туфан исеме белән атау нияте хакында 2010 елның декабрендә, атаклы шагыйрьнең тууына 110 ел тулуны Казанда бәйрәм иткәндә белдерелгән иде. Кече планеталарны астрономик исемләү комиссиясе ТР Мәдәният министрлыгы, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Язучылар берлегенең уртак тәкъдимен хуплаган. Әлеге күк җисеме Җирдән 250 миллион километр ераклыкта урнашкан, диаметры—3 километр. 48631 нче «Хасан Туфан» планетасын 1995 елның сентябрендә һәвәскәр астроном Тимур Крячко Казан дәүләт университетының В. Энгельгардт исемендәге обсерваториясенең Төньяк Кавказдагы Зеленчук станциясендә ачкан булган.

## БЕРЛӘШҮ

2011 елның 2 февралендә РФ Мәгариф һәм фән министрлыгының 156нчы «Югары һөнәри белем бирүче федераль дәүләт автономияле белем бирү учреждениесе «Казан (Идел буе) федераль университеты»н үзгәртеп кору турындагы боерыгы чыкты.

Хәзер, Мәскәү фәрманы буенча, Казан (Идел буе) федераль университетына Татар дәүләт гуманитар-педагогика университеты, Казан дәүләт финанс-икътисад институты, Алабуга дәүләт педагогия университеты кушыла. Димәк, хәзер монарчы мөстәкыйль эшчәнлек алып барган дүрт югары

уку йорты бер түбә астында яши башлый.

Бу унайдан кушылучы югары уку йортлары ректорлары тарафыннан да боерыклар игълан ителде. Хезмәткәрләргә, алда кушылу көтәчәкне искәртеп, язмача хәбәрләр җибәрелде.

Инде хәзер әлеге үзгәртеп коруның бик уйлап, язмышларны катлауландырмыйча гына гамәлгә ашырылуын көтәсе кала.

### ТАГЫН БЕР АКАДЕМИЯ

Агымдагы елның сентябрендә Казанда Идел буе физик культура, спорт һәм туристлык академиясе ачыла. Россиянең спорт, туристлык һәм яшьләр сәясәте министры Виталий Мутко белдерүенә караганда, бу уку йорты кадрлар әзерләү белән беррәттән, ил җыелма командалары өчен спортчылар үзәге дә булырга тиеш. Академия ачу өчен матди-техник база да, кирәкле кадрлар да бар инде.

### ЯҢА РӘИС

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының баш режиссеры Фәрит Бикчәнтәев Татарстан Театр эшлеклеләре берлеген җитәкләде. Ул әлеге вазифада берлек белән 1989 елдан бирле җитәкчелек иткән халык артисты Ринат Тажетдиновны алыштырды. Яна рәис 7 февральдә республика Театр эшлеклеләренең VI съездында сайланды. Әлеге чарада РФ Театр эшлеклеләре берлеге рәисе Александр Калягин һәм ТР вице-премьеры—мәдәният министры Зилә Вәлиева катнашты.

### КАМАЛЛЫЛАР ГЕЛ ЮЛДА

Быел гына да Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының берничә зур гастроле оештырылды. Ел башында коллектив Латвиянең башкаласы Рига шәһәрендә булды. Анда «Телсез күке», «Яшь йөрәкләр», «Кара чикмән» спектакльләре күрсәтелде. Ә 13-20 гыйнварда театр Мәскәүдә гастрольдә булды. Гастрольләр Кече (Малый) театр сәхнәсендә зур уныш белән үтте. Гастроль ачылу тантанасында Татарстан Премьер-министры урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева да катнашты.

### ХАЛЫК ШАГЫЙРЕН ЗУРЛАДЫЛАР

22 гыйнвар көнне Мәскәүдә Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллинның иҗат кичәсе зур уныш белән үтте. Асадуллаев йорты дип аталган мәдәният үзәгендә үткән бу очрашуга Мәскәүдә яшәүче мәшһүр шәхесләр—галим-академиклар, дипломатлар, язучылар, сәнгать әһелләре, гомумән, зыялылар күпләп килгән иде. Кичәне Мәскәүнең татар милли мөхтәри автономия рәисе, генераль-полковник Рәсим Акчурин ачты. Шагыйрьнең татар иҗтимагый тормыштагы һәм әдәбияттагы урыны, «Казан утлары» журналындагы хезмәтләре турында Татарстан Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов сүз әйтте.

Кичә шигырь, җыр, музыка белән аралаштырып алып барылды. Шигырьләрне автор үзе һәм артистлар башкарды. Шулай ук кичәдә шагыйрьнең улы Газиз һәм оныгы Чулпан да шигырьләр укыдылар. Р. Фәйзуллин иҗаты турында Мәскәүдә яшәүче язучылар Ринат Мөхәммәдиев, Җәмил Мостафин, Азат Абдуллин, Нәзифә Кәримова, Рауль Мирхәйдәров, Венера Вәлиева һ. б. сөйләде.

Иҗат кичәсендә Татарстанның танылган артистлары Зилә Сөнгатуллина, Илдус Әхмәтҗанов, Мөнир Якупов катнашты, Мәскәү артистлары Наилә Фатехова, Роза Хәбибуллиналарның катнашуы да бәйрәмгә ямь өстәде.

Шул ук кичәдә Татарстанның Россиядәге Тулы вәкаләтле вәкиле урынбасары Алмаз Фәйзуллин Мәскәүдә яшәүче шагыйрь Әхмәт Саттарга «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» танылыгын тапшырды.

Тукайның 125 еллык юбилее алдыннан үткәрелгән шигърият бәйрәме югары күтәренкелек шартларында узды һәм анда катнашучылар мондый очрашулар ешрак булсын иде дигән теләк белдерделәр.

### ЛЕГЕНДАР БАЛЕРИНА

Казан хореография училищесында Татарстан, Башкортстан һәм Россиянең халык артисты Нинель Юлтыеваның 85 яшьлек юбилее уңаеннан тантана булды.

Нинель Даут кызы, балачактан күп михнәтләр күреп үсүенә карамастан, белемгә омтыла. Аның әтисе, язучы Даут Юлтый—репрессия корбаны. Уфада яшәгән кызның талантын хореографлар яшьтән күреп ала. Санкт-Петербургтагы хореография училищесында укыган балерина, сугыштан соң Казанга кайтып, М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрында эшли башлый. «Бакчасарай фонтаны», «Аккош күле», «Зөһрә» һ. б. бик күп балетларда бии. Үзе дә педагог буларак, шактый гына спектакльләр куя. Нинель Юлтыеваны балет сәхнәсенең легендасы дип юкка гына атамыйлар. Ул сәнгатебезгә инде 65 ел буе хезмәт итә. Аның укучылары арасында үзебездә генә түгел, чит илләрдә дә балетмейстер булып эшләүчеләр бар. Нинель ханым бүген дә училище студентларын бию серләренә өйрәтә. Ул хореография училищесында сәнгать җитәкчесе булып эшли.

23 мартта М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрында балет остасының юбилее уңаеннан «Баядерка» спектакле күрсәтеләчәк.

## «ХӘЗИНӘ»ДӘ КҮРГӘЗМӘ

«Хәзинә» милли сәнгать галереясендә рәссам Зөфәр Гыймаевның шәхси күргәзмәсе ачылды. Ул останың 60 яшьлеге уңаеннан оештырылды.

Экспозициядә рәссамның 76 эше тәкъдим ителә. Зөфәр Гыймаев төрле жанрларда бердәй уңышлы иҗат итә. Ул аеруча портрет ясау остасы буларак танылды. Рәссам татарның атаклы шәхесләре—Салих Сәйдәшев, Бакый Урманче, Гайшә Рахманкулованың монументаль образларын иҗат итте.

Рәссам иҗатында пейзаж да зур урын алып тора. Зөфәр Гыймаевның эшләре нигездә татар авылы тормышына багышлана.

Зөфәр Гыймаев Үзбәкстанның Наманган шәһәрендә туа. Казан сәнгать училищесында, И. Репин исемендәге Ленинград сәнгать институтында белем ала. 1978-80 елларда СССР Сәнгать академиясендә Харис Якупов остаханәсендә укый.

Бүгенге көндә ул Татарстан Рәссамнар берлеген житәкли. Зөфәр Гыймаев—Татарстан Мәдәният министрлыгының Б.Урманче исемендәге премиясе, республикабызның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе.

## АЛИЯ МЕДАЛЬЛӘРЕ

Казан кызы—чаңгычы Алия Иксанова 15 чакрымга сузылган дистанциядә Россия җыелма командасы өчен көмеш медаль яулады. Бу инде аның Бөтендөнья кышкы Универсиадасындагы дүртенче медале.

Казан дәүләт педуниверситетының өченче курс студенты Алия беренче алтын медален классик стильдә (5 км) беренче килеп яулады. Ә дуатлон төрендә (ярты дистанцияне классик стильдә, икенче яртысын тимераяк стилендә үтү) «көмеш»не яулады. Беренче урыннан Алияне 0,6 секунд аерып тора.

3-5 чакрымлы триумфаль эстафетада да Татарстан чаңгычысы Россия командасының иң яхшы спортчысы иде. Үз алдына куелган максатын ул яхшы үтәде. Алия Иксанова ике тапкыр Универсиада чемпионы булды.

Зур уңышы белән Алияне Россия Президенты Дмитрий Медведев котлады.

## ОСТАЗНЫ ИСКӘ АЛУ

Февраль аенда күренекле педагог, галим, Казан дәүләт университеты журналистика һәм социология факультетының беренче деканы Флорид Әгъзамовның тууына 75 ел тулды. Шушы уңайдан ТР Сәүдә-сәнәгать палатасының конференцияләр залында «Татарстан журналистикасы XXI гасырда: үсеш юллары» дигән темага фәнни-гамәли конференция булып үтте. Анда Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Журналистлар берлеге рәисе Римма Ратникова, республика матбугат һәм гаммәви коммуникацияләр агентлыгы житәкчесе урынбасары Нурия Беломоина, Казан федераль университеты проректоры Ариф Межведилов, журналистика һем социология факультеты деканы, профессор Васил Гарифуллин, күпсанлы галимнәр, Флорид Әгъзамовның хезмәттәшләре, укучылары, якташлары, туганнары, республика газеталары редакторлары катнашты.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМ

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, Татарстан Республикасында әдәбиятны һәм сәнгатьне үстерүгә зур шәхси өлеше өчен «ТАТМЕДИА» ачык акционерлык җәмгыятенең «Казан утлары» журналы редакциясе» филиалы проза бүлеге мөхәррире **Кәримов Камил Әдһәм улына** «Татарстан Республикасының атказанган сәнгатькәре» дигән мактаулы исем бирелде.

***


2011 елның 17 февралендә Арчада яшәп иҗат итүче язучы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре **Радик Хәбибрахман улы Фәизов** 80нче яшендә вафат булды.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Беренче биттә:* «Бәрәзәбаш авылы». **Зөфәр Гыймаев** рәсеме.

*Дүртенче биттә:* язучы **Равил Сабыр**.

# Яңа китаплар




Татар халкы тарихы (иң борынгы заманнардан алып XVII гасыр ахырына кадәр): Татар урта гомуми белем бирү мәкт. 10 с-фы өчен уку әсбабы. Авторлар: Д. М. Исхаков, И. Л. Измайлов, И. А. Гыйләҗев, М. М. Гибатдинов. Казан: Мәгариф, 2009. – 423 бит. 3000 данә.

Уку әсбабында татар халкы тарихын заманча якын килү нигезендә комплекслы өйрәнүгә беренче омтылыш ясала. Татар тарихының күп кенә аспектлары уку-укыту әдәбиятында тәүге тапкыр карала. Укучылар игътибарына авторлар тарафыннан хәзерге тарих фәнендә киң тикшерелүче яңа тарихи концепцияләр һәм теорияләр, фәнни әйләнешкә яңа кертелгән күп кенә тарихи чыганаклар тәкъдим ителә.




Балачак энциклопедиясе: икенче китап. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. – 200 бит. Тиражы – 3000 данә.

Бу китапка, нигездә, татар балалар әдәбияты тарихында эз калдырган язучылар турында (биредә аларның кырыктан артыгы теркәлгән) мәгълүмат бирелгән. Шулай ук, ул язучыларның портретлары, иҗатларының кайбер үрнәкләре урнаштырылган. Китапның төзүчеләре – Т. Шакирова, Л. Шәех. Бизәлеш мөхәррире – Р. Хәсәншин.



Равил Сабыр

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)